www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Мөхәммәт МИРЗА. Җир – үз күчәрендә... *Цикл*. ....3

Марат КӘБИРОВ. Дога. *Повесть*. ....7

Рүзәл МӨХӘММӘТША. Минем Такташ. *Кечкенә опера өчен либретто*. ....52

Ринат МӨХӘММӘДИЕВ. Ак кәгазь нидән саргая... *Роман*. ....65

Рухия АХУНҖАНОВА. Бишек җыры көйләп тирбәтә җил... *Шигырьләр*. ....119

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Кол Шәриф. *Романнан өзек*. ....122

ЯҢА ИСЕМНӘР

Гөлсинә ХАНӘФИ. Яши белеп яшәү – акыл күрке... *Шигырьләр*. ....131

Айсинә СӘЛАХОВА. Кулдашым. *Хикәя*. ....134

*Җәһәт тәнкыйть:* сәхифәне Дания ЗАҺИДУЛЛИНА алып бара. ....146

*Балалар китапханәсе:* Айшә МАСКИ. Бүренең «туганлыгы». *Шигъри әкият*. ....148

ДӨНЬЯ ХАЛЫКЛАРЫ ӘДӘБИЯТЫ

Нодар ДУМБАДЗЕ. Кан авазы. *Хикәя*. *(Рәшит БӘШӘР тәрҗемәсе)*. ....151

«ШИФАЛЫ КУЛЛАР» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Зинаида ЗАХАРОВА. Елама, әни! *Хикәя*. ....157

*Фотоархив*: Кыям Миңлебаевның тууына 90 ел. ....167

«ТАТАРСТАН. ТАРИХ. ШӘХЕСЛӘР» ӘДӘБИ ОЧЕРКЛАР КОНКУРСЫ

Айсылу ИМАМИЕВА. Туган җирнең бәрәкәте – күкрәп үскән иген кырында. ....168

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА. Ошбу җиһанда якты юл... ....171

КАЙТАВАЗ

Фоат ГАЛИМУЛЛИН. Ватан дигән татлы сүз. ....177

Фәрит БАТТАЛОВ. Нәфрәт уятмады, ләкин күңелне кайтарды. ....179

ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Рәйсә МУСАБӘКОВА. Тукай: Пушкиннан «игътибас иткән бу баш». ....182

ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

«Иман һәм гаилә – тормыш нигезе». *Исмәгыйль ШӘҢГӘРӘЕВ белән Ландыш ӘБУДӘРОВА әңгәмәсе*. ....184

*Фән:* Айрат СИТДЫЙКОВ, Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Кубрат хан токымнары язмышын ачыклау. ....187

*Музейларыбыз:* Алсу ӘХМӘДУЛЛИНА. Шиһабетдин Мәрҗанинең Ташкичүдәге музее. ....188

*Шаян сәхифә:* Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ алып бара*. ....189

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

КАЗАН УТЛАРЫ
(«Огни Казани»)
№ 6 (1160) 2019

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Ринат Закиров**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Данил Салихов**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Ленар Шәех**

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Фәнил Гыйләҗев, Фирүзә Җамалетдинова, Айсылу Имамиева, Камил Кәримов.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Вагыйзова, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева.**
*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Люция Сөләйманова** (өлкән бухгалтер).
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1617).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
💻: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

TM Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.05.2019, график буенча 29.05.2019, басылып чыгу вакыты 10.06.2019.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-1455. Тираж 5773.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2019 ел



Мөхәммәт
Мирза

# ҖИР – ҮЗ КҮЧӘРЕНДӘ...

## Адәм баласы

ЦИКЛ

Туганлык хисләрен
Басып китсә нәфсе,
Адәм баласының
Бер-берсен күрәлми
Мәңге тилмерәсе...

***

Сәбәбе – бердәнбер,
Юк читтән эзлисе...
Адәм баласының
Ямьсезлегендә тик
Гаепле көзгесе...

***

Мыскалга салына,
Сатканы, алганы.
Адәм баласының
Бармагы очында
Үлчәнми калганы...

***

Буе житкәненчә
Җимеше өзелгән...
Адәм баласының
Барасы юлына
Киртәләр тезелгән.

---

Мөхәммәт МИРЗА (1953) – *шагыйрь; биш томлык «Сайланма әсәрләр», «Киек каз юлында», «Тере су», «Адәм баласы» һ.б. күпсанлы китаплар авторы. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

***

Җир – үз күчәрендә.
Күк – үз кабыгында...
...Адәм баласына
Табылып торыр гел
Нидер табынырга.

***

Көн арты көн үтә,
Ел сүтелеп бетә.
Адәм баласының
Гомере сәгате –
Тукталганын көтә.

***

Җиңе сызганылган,
Иңгә йөк салынган.
Адәм баласының
Маңгаена сырлап:
«Эш» – диеп язылган.

***

Ярын җуйган елга
Җәелеп саегыр...
Адәм баласының
Кайсылары гына
Шуңарга кайгырыр.

***

Өермә котырып,
Кубарылыр тузан.
Адәм баласының
Догалы куышын
Афәт урап узар.

***

Чакрымлы катлам боз
Япкан ут-вулканын.
Адәм баласының
Исенә төшерер
Бөтен онытканын...

***

Борылып караса,
Күрмәгәнен күрер...
Адәм баласының
Үткәненнән качып,
Киләчәге килер...

***

Җисеме асылы –
Төсендә, исендә...
Адәм баласының
Җенси азынуы
Хайвани хисеннән.

***

Халыклар төрмәсе
Булганда хак иле,
Адәм баласының
Коты табанына
Төшәре билгеле...

***

Туган туфрагында
Куышын коралган.
Адәм баласының
Нәселе-касәбе
Дәвамы юралган.

***

Галәмнәр бер-берсен
Кысрыклап киңәя...
Адәм баласының
Туганнан бизүе-
нә ачык киная.

***

Мәхәббәт колы бар,
Бар нәфесе колы.
Адәм баласының
Шулар коллыгыннан
Юктыр котылыры.

***

Шар куып, туп тибеп,
Капкага ыргылган.
Адәм баласының
Бар уе, гамәле
Алдауга корылган...

***

Бар гомере торадыр
Югалту, табыштан...
Адәм баласының
«Батмамын» дигәне
Саламга ябышкан...

***

Якты көн йотылды
Төннең упкынына...
Адәм баласының
Әверелүеме
Вакыт тоткынына?!

***

Узганга – салават,
Тузганга – ямаулык...
Адәм баласының
Яраклашуында
Гөнаһлы зарар юк.

***

Тукранның тәүбәсе,
Тартайның – телендә;
Адәм баласының
Тәкрарлар һәммәсе
Картайган көнендә...

***

Кош-корты, терлеге,
Бәрәңге, суганы...
Адәм баласының
Шулар хәстәрендә
Гомере узганы...

***

Тәгәрәп төште дә
Тозлары чәчелде...
Адәм баласының
Бер тамчы күз яше
Яшенгә әверелде...

***

Күзе – тәрәзәдә,
Терсәге – тезендә...
Адәм баласының
Кайсын, кайда көтә
Тәкъдире көзендә...

***

Көтеп юрамаган
Юктыр беркеме дә...
Адәм баласының
Хакын сорамаган
Юктыр бер көне дә...

***

Яшереп куйганы –
Кара көн көткәнгә...
Адәм баласының
Үтмәс мохтаҗлыгы
Һаман өркеткәнгә...

***

Бәхәссез хакыйкать:
Берчак шәме сүнәр...
Адәм баласының
Тәмугка дучары
Кыйммәтрәк түләр...

***

Диңгез кибеп корыр,
Эреп кибәр котып...
Адәм баласына
Ташкүмер буласы –
Эренле ут йотып...

***

Куркуы чигенгән;
Качкан оялуы...
Адәм баласының
Калган: кансызлыгы –
Җаннар кыялуы...

***

Ялганы ялына
Сагыздай береккән.
Адәм баласының
Атказанганыннан
Алаша өреккән.

***

Эзләрне кар күмә,
Юлларны ком баса...
Адәм баласының
Югалмас эзләре
Хәтерен җуймаса...

***

Ниятенә кергән
Тапмый, алмый калмас...
Адәм баласының
Асылташ тотканы
Бакырга алданмас.

***

Елгаларны бора,
Күчерә тауларны.
Адәм баласының
Ни кушсаң – майтарыр
Күче-көче бары...

***

Тылмачка мохтаҗлык
Күрмәгән тел иде...
Адәм баласына
Телен җеназасыз
Җирлисе көн килде?..

***

Җанисәп ала ил:
Ни нәрсә нияте?..
Адәм баласының
Баш саны булыр ким –
Кемнең җинаяте?

***

Күктән сөрелгәннәр –
Җирдә пәйгамбәрләр...
Адәм баласының
Ниләр күрәсеннән
Шулар хәбәрдарлар.

***

Сүзем – дөрес, дияр,
Юлым – туры, дияр...
Адәм баласының
Гел: «Мин» дигәненә
Күк күзе тиз тияр.

***

Тулып килгәнендә
Асмандагы айның,
Адәм баласының
Өметләнеп көткән
Хәле абайланыр...

***

Кубып авар хәтта
Корычтан койганы...
Адәм баласының
Төптәй басып торыр,
Табанын тойганы.

***

Туа-тумышыннан
Тоташ билгесезлек...
Адәм баласына
Язмыш мәхрүмлеге –
Хатынсыз, ирсезлек...

***

Мәсхәрәләп көлү –
Баеп масаюдан...
Адәм баласының
Күңеле күгендә
Кояшы баюдан.

***

Дулар, җәнҗал корыр,
Тибәр дә аударыр:
Адәм баласының
Кәеф-сафасында
Дорфа дуамаллык.

***

Төсләргә моң сарган,
Моң тулган төсләргә...
Адәм баласының
Күңеле бакчасына
Теләп ямь өстәргә...

***

Кызарып тулды да
Күктә Ай тотылды...
Адәм баласының
Манылган каләме
Яза алмый торды.

***

Таныш-белеше бар,
Барып-килеше бар.
Адәм баласының
Очын-очка ялгар
Алыш-биреше бар.

***

Күзен ябып, язын
Кар базы ачылыр.
Адәм баласының
Бәрәңгесе ачлык
Афәтен качырыр.

***

Кырлары кысылган,
Тарайган болыны...
Адәм баласының
Моңарга битараф
Маңкортлы буыны.

***

Җитмәсә – җаен тап,
Әҗәткә алып тор...
Адәм баласына
Бушка килеп, кыйммәт
Түләре – вакыттыр...



Марат
Кәбиров

# ДОГА

ПОВЕСТЬ

**1**

Сорыкортның соры тормышын бик мул буяулар белән, төсләрен, исләрен, хисләрен тәфсилләп, җәелеп китеп сурәтләргә дә мөмкиндер, тик моның белән генә бернәрсә дә үзгәрми – соры тормыш үз төсендә, ә сорыкорт үз көчендә кала. Шуңа барысы да кыскача гына. Кинодагы кебек...

Чираттагы оешманың кадрлар бүлеге. Зур гына бүлмәнең түрендәге өстәл янында уртача яшьләрдәге ханым утыра, ул минем документларны актара, шул ук вакытта нәрсәдер яза һәм ара-тирә миңа сораулар бирә. Утырырга да, узарга да кушучы булмагач, мин ишек төбендә генә басып торам. Бераздан ул башын күтәреп, карашы белән мине бораулый башлый:

– Өйләнгәнме?

– Юк.

– Яшәр урының бармы?

Мин дәшмим. Баш кына кагам.

– Хезмәт стажың ничә ел?

Ул үзе бик ямьсез дә ханым түгел, башка урында очратсаң, мөлаем гына булып та күренә алыр иде. Ләкин өстәл артында үзен бөтенләй әллә ничек тота. Сораулары белешмә алу теләге белән түгел, ә гаепләү исәбе белән бирелгән кебек яңгырый. Алар миңа бөтенләй башка төрле булып ишетелә:

– Нигә һаман өйләнмәдең? Ориентацияң дөресме?

– Хан сараенда яшәмәгәнең күренеп тора инде, вокзалда кунып йөрмисеңме соң хет?

– Нигә һаман да булса эшкә урнашмадың?

Мин канәгатьсезлегемне күрсәтмәскә тырышам.

– Стаж юк.

Миллион да беренче тапкыр ишетелгән таныш җавап яңгырый:

– Без стажсыз алмыйбыз.

– Бер елдан соң була. Сез алсагыз.

---

Марат КӘБИРОВ (1970) – *шагыйрь, прозаик; «Онытма таңнарны», «Мәхәббәт яңгыры», «Китап» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Бу сүзләремне шаяруга санап, елмайган булам. Ләкин теге ханым җитди. Җитди бүлмә эчендә елмаю ятим кала. Билләһи-валлаһи менә, ата-анасын җирләп, зираттан кайтып барган елмаюга әйләнә... Үзем дә үгигә әвереләм. Кәгазьгә ышкылган ручка тавышы да, тәрәзәдән кергән кояш нурлары да, кысып куелган форточкадан кергән һава да – барысы да мине бу бүлмәдән этеп чыгарырга тырышкан кебек тоела. Ишек тоткасына үреләм. Тик шундук гаепләү карары яңгырый:

– Ә документларыңны?!

Бу чынлап та гаепләү карары. Искә төшерми ул, хәстәрләми дә, ә җинаять урынында тоткан шикелле гаепли:

– Башсыз, документларыңны да алмый китәргә җыенасың бит! Шундый аңгыраларны җыеп ятарга юләрләр йорты бар, дип белдеңме әллә?!

– Ә-ә, гафу итегез...

Кире борылып документларымны алам.

– Рәхмәт!

* * *

Эш эзлим... Интернеттагы бөтен сайтларны карап чыктым, өметлерәк кебек күренгән белдерүләр буенча шалтыраттым, кайберләренә барып килдем. Анысы булса, монысы юк, монысы булса, анысы юк, диләрме әле? Мин дә шундыйрак хәлгә юлыктым. Кайдадыр хезмәт хакы аз, кайдадыр штрафы зур – ике-өч минутка соңласаң да, фәлән сумыңны сыдырып калырга торалар, кайда эш графигы һушың китәрлек, кайсылары бөтенләй шикле булып тоелды. Кыскасы, беркая да урнаша алмадым. Бөтенләй үк файдасызга булды, димим инде. Шулай йөри торгач, бер нәрсәне яхшы аңладым – мин эш эзләмим икән, эш кирәкми миңа, ә акча табу урыны кирәк.

Көн саен диярлек нәрсәдер эзләп, нидер табарга маташуым да кайдадыр барып эшләргә атлыгып торганнан түгел. Бары тик әти белән әни алдында яхшатлану өчен генә. Эзлим, табалмыйм, янәсе. Көнозын телефонга карап, диванда аунап та булмый бит инде. Көн буена компьютер чокып та утыралмыйсың. Егерме биштән узган егет ич инде...

Минем яшьтә кешеләрнең гаиләсе, ике баласы, йорты, машинасы була. Минем бернәрсәм дә юк. Һәм булмавына артык исем дә китми. Әнә, әни белән әти таң атса, әләгешеп кенә торалар. Тавыш, гадәттә, акча җитмәүдән чыга. Урамнан берәр квитанция тотып керә дә, башта, тагын акча сораганнар, дип үзалдына чәйнәнеп ала, бераздан әтинең ачуын кабартырга тотына. Менә шуның хәтле түләргә кирәк, акча буламы, кайчан була, күпме була, әле тагын теге нәрсә өчен дә, монысы өчен дә түлисе бар, аннан соң, фәлән нәрсәне алырга да кирәк, үткән айда да алмыйча калдык, безгә мәңге акча җитми инде, әнә кешенең ирләре... Менә шул рәвешле баш катырып, аерылышалмый да, татулашалмый да яшәрлек булгач, гаилә ни пычагыма кирәк инде ир кешегә?

Баласы да кирәк түгел. Вәт менә мине тапканнар инде төнлә тик ята белмәгәч. Карап үстергәннәр инде. Шуннан? Егерме биш яшемә җитеп мин берәр рәхәт күрдемме дә берәр вакыт үземне чын кеше итеп тойдыммы? Белмим, артка борылып карасаң, ах, дип әйтерлек вакытлар бик булмагандыр кебек. Үзләренә дә рәхәт күрсәтмәдем. Кечкенә вакытта «укы», «дәрес хәзерлә», дип нервыларын бетерделәр, үсә төшкәч, хулиганга әйләнмәсен, дип дер калтырап тордылар, аннан соң армия, армиядән кайткач, өйләнер инде хәзер, туйга акча кайдан табарбыз, дип борчылыштылар. Ниһаять, бер кайгылары калды – мине эшкә урнаштыру. Шул да булдымы тормыш?!

Кешенең ниндидер яраткан эше булырга тиеш. Шул очракта гына ул шул һөнәре буенча хезмәт итәргә хаклы. Ә яраткан шөгыле юк икән, эшләмәсен. Яратмый эшләгән эштән дә каһәрлерәк нәрсә юк.

* * *

Шулай бер оешмадан икенчесенә сугылып йөри торгач, кич җитә. Мин бүген иртән булган күренешне искә төшереп елмаеп куям. Әнине искә төшереп: «Ата-бабамнар рухына дога кылам...» – дип кабатлыйм.

Гади генә нәрсә инде ул. Иртән торып, юынып ваннадан чыгуга, әни залдагы бүлмәдә мыштым гына намаз укып тора иде. Намазын укып бетергән бугай инде. Мин аның ише нәрсәне бик аңламыйм, әни үзе дә яңарак кына мавыга башлады әле. Дингә мәхәббәте ташып торганнан микән, әллә шулай итсәң, тормыш көйләнеп китмәсме, дип аптыраганнан гынамы – төгәл әйтә алмыйм. Мин күргәндә, әни намазлыгына тезләнеп утырып, кулларын алга сузып теләкләр тели иде. Тавышы ишетелер-ишетелмәс кенә... Әти уянмасын дипме, башкалар ишетмәсен дипме, пышылдап кына укый ул догаларын. Без, гадәттә, аңа игътибар итмибез, борчып бүлдереп йөрмибез. Бу юлы да игътибарсыз калдырасы идем, үз исемемне ишетеп кенә туктап калдым, аннан соң тыңлап торырга мәҗбүр булдым. Әни минем эшләремнең җайланып китүен, күп акчалар килүен теләп дога укый иде.

– Ата-бабамнар рухына дога кылам... – дигән сүзләрен ишеткәч, пырхылдап көлеп җибәрмәс өчен читкәрәк киттем.

Башта кызык тоелды.

Соңыннан күзгә яшь тыгылды...

Ата-бабалар рухына бәйле көнгә калдыммыни?!.

Бер карасаң, әллә нәрсәсе юк инде аның, тик мин күпмедер дәрәҗәдә өметләнгән идем, шулкадәр ихлас теләкләр кабул булыр да минем эшләрем җайланып китәр кебек тоелган иде.

* * *

Күз бәйләнсә дә, өйгә кайтасы килми. Күңелдә бераз үпкә дә бар кебек. Кемгә икәнен генә төгәл белмим. Әти белән әнигә. Әйе. Битәрлиләр, гаеплиләр... Күңеленә яткан эш таба алмаган өчен генә үз balaңны шулай читләтергә, гел боргычлап торырга ярыймыни инде?!. Үз-үземә үпкәм зур: тот та тәвәккәллә бит инде. Йөр шунда ит чабып. Алланың кашка тәкәсемени син? Кулыңнан башка нәрсә килми икән, булдыра алганыңны кыланырга кирәк. Ә син, имеш, һәркем үз вазифасы белән... Дөньяга. Ник икәнен төгәл генә белмәсәм дә, дөньяга да беркадәр үпкә бар. Үземне бар җирдә дә үги итеп тоям. Нәкъ менә кадрлар бүлегендәге теге ханымның бүлмәсендәге кебек. Бөтен нәрсә мине чит итә, кайдадыр этеп чыгарырга тели кебек.

Караңгылык буйлап атлап киләм. Төнге ишегалдында күзгә төртсәң, күренерлек түгел. Монда агачлар биек булып үскән, аннан-моннан таралган яктылыкны ерак җибәрмиләр.

Кинәт якында гына хатын-кызның үзәк өзгеч тавышы ишетелде:

– Нишлисез сез?! Ah!..

Аңа ир-ат тавышы мыгырдап җавап бирде. Хатын-кыз тавышы елауга әйләнде. Аны дөп-дөп ашыккан аяк тавышлары күмеп китте. Ни булганын ачык күрмәсәм дә, ханымның нәрсәсендер талап алганнарын чамаладым инде. Аяк тавышларыннан үсеп чыккан ике шәүлә тиздән йөгерә-атлый минем якка табан килүче ике ир-атка әверелде. Арырак ханымның ярсып елаганы ишетелә. Мин нишләргә икәнен уйлап өлгергәнче, үз тавышымны ишеттем:

– Тукта! Нишлисез сез?

Килүчеләрнең туктап, миңа үзләренең нәрсә эшләүләрен тәфсилләп сөйләп торырга исәпләре юк иде. Атлаган уңайга берсе кинәт өстемә сикерде, мин читкә тайпылдым, шулай да аның йодрыгы колак төбен сыдырып үтте. Мин икенчесенең кулындагы хатын-кыз сумкасын эләктердем дә кинәт кенә тартып җибәрдем. Сумка каешы нык булып чыкты, ул минем кулны да авырттырды, ирне дә тигезлеген югалтырга мәҗбүр итте, һәм мин аны саллы гына апперкот белән каршыладым. Карак  чайкалып китте, ләкин егылмады. Ул арада ирләрнең икенчесе аяк төбемә тондырды. Кинәт кояш чыккан кебек булды. Мин үземнең кайдадыр очуымны тойдым. Әмма шундук һушыма килдем. Исерек кеше кебек чайкала-чайкала кайдадыр атларга маташам. Ирләр инде юкка чыккан. Сул яктан аяк асты туңдыргыч укол кадагандагы кебек оеп тора.

Кинәт милиция машинасы килеп туктады, аннан чыккан өч кешенең берсе хатын янына юнәлде, калган икесе выжт итеп минем яннан йөгереп узып китте. Чайкалып атлагач, исереккә исәпләделәр бугай, миңа артык игътибар итеп тормадылар. Подъездлар алдына, яктырак урынга чыккач кына мин чайкалудан туктадым һәм шундук теге сумканың кулымда икәнен тойдым. Бу үзенә күрә бер куаныч кебек иде. Юкка гына өлеш эләктермәгәнмен ич, теге ханымның сумкасын саклап алып калганмын. Мин елмая биреп алар ягына атладым.

Ханым инде бераз тынычланган, кулларын болгый-болгый тәртип сакчысына ниләр булганын аңлата иде. Мине күрүгә бер мәлгә сөйләвеннән туктап катып калды һәм икенче мизгелдә кычкырып җибәрде:

– Минем сумкам! – Һәм ул миңа ташланды. – Карак! Менә ул карак!

Аз гына соңласам, тоткынга әйләнәсе идем. Наручник келтерәп ябылганчы, кулны алып өлгердем, ә моны көтмәгән полиция хезмәткәре һушына килгәнче, мин инде ун-унбиш метрны йөгереп узган идем. Ул минем якка ташланды һәм иптәшләренә сөрән салды. Үзем моннан ерак яшәмәгәч, бу тирәнең бормаларын яхшы беләм. Начар да йөгермим...

* * *

Юлны беләм, дисәң дә, тәртип сакчыларының кууыннан күз тонган бугай, әллә нинди урман сыман җиргә килеп чыкканмын. Мин башта каршыда торган текә генә тауга игътибар иттем һәм дертләп киттем – безнең шәһәрдә мондый тау булырга тиеш түгел иде бит, дип уйладым. Ә ул бар иде, әле мин тау түбәсенә үрмәләп баручы ике кешене дә абайлагандай булдым. Озын киндер күлмәк өстеннән камзул кигәннәр, аякларында – читек...

Юк, мондый хәлнең чынбарлык булуы мөмкин түгел дип түбәнгә бактым һәм... Мин үзем дә тауның бер өлешендә идем, ә түбәндә, мин торган урыннан әлләни ерак түгел җирдә елга ага, аның ярлары буйлап кешеләр сибелгән... Алар күннән эшләнгән чиләкләр белән яр читендәге күлләвекләрдә ялтырап яткан сыекчаны җыеп йөриләр...

Шайтан алгыры!..

Мин күзләремне йомып, башымны селкеп алдым.

Файдасы тиде, тау да, елга да, кешеләр дә юкка чыкты. Үзебездән артык ерак булмаган бер исемсез паркка килеп җиткәнмен икән. Кышларын чаңгы шуарга гына йөрештерәбез, шуннан ары бу тирәгә аяк та баскан булмаган икән. Мин кайда икәнемне аңлагач та тирә-ягыма күз салып тордым. Теге тау да, елга да, кешеләр дә – гомумән, шундый күз адаштыруга сәбәпче булырдай бер күренеш тә сизелмәде.

Шуннан чалбарымны күтәреп, өс-башымны тәртипкә китереп куйдым. Монысы тынычлану өчен генә булды бугай, һәм ул чынлап та тынычландырды. Бары тик шунда гына игътибар иттем – теге сумка һаман миндә икән бит. Хәзер инде теләсәм-теләмәсәм дә, ул сумканы ташлап калдырырга кирәк иде. Ә ташлар алдыннан эчендә нәрсәләр барлыгын тикшереп карау һәрвакыт мәҗбүри.

Ләкин сумкада озаклап казынырга насыйп булмады. Аны-моны карамыйча гына, кулны тыгу белән тотарга уңайлы бер нәрсә сөйрәп чыгардым. Кәшилүк иде бу. Кулга тотуга ук саллы булып тоелган иде, ә ачып җибәргәч, бөтенләй катып калдым. Гаҗәпләнү! Шок! Бүтән бер сүз белән дә аңлатып булмый торган халәт инде. Бераздан аны курку тойгысы алыштырды. Үзем дә сизмәстән тирә-ягыма каранып алдым – хәвеф-хәтәр күренми. Күренергә дә тиеш түгел, чөнки хәвеф тирә-юньдә түгел, ул минем күңелдә.

Кулымдагы акчага карап күпме торганмындыр, белмим. Тик шуны әйтә алам, биш меңлекләрдән торган калын гына шушындый пачкага бик озак вакытлар буена карап торырга мөмкин икән.

Акчасын алгач, документларын ни җитте җиргә ташлап калдыру гаделсезлек кебек тоелды. Алар артыннан йөрү җиңел эш түгел, вакыт та акча да кирәк. Әле бер паспорт кына да түгел бугай бит монда, әллә никадәр документ... Якындагы киосктан пакет сатып алдым да сумканы шуның эченә тыктым. Бераз баргач, автобус тукталышындагы эскәмиягә утырып тирә-якны күзәттем. Хәер, күзәтерлек әлләни нәрсә юк иде. Кеше-кара күренмиме дип кенә күз салгаладым бугай. Һәм пакетны шунда «онытып» калдырдым. Бер-ике адым атлауга артымда музыка тавышы ишетелде. Мин борылып карамый булдыра алмадым. Тавыш мин калдырып киткән пакеттан килә иде. Димәк, анда телефон да булган.

Мин кире борылмадым. Юл аша чыгып каршыдагы тукталышка йөгердем. Бер автобус якынлашып килә иде, йөгергән уңайга шунда кереп бастым да тәрәзәдән үзем калдырып киткән пакетка карадым. Анда бер машина килеп туктаган, машинадан төшкән таза гәүдәле ир-егет теге пакетны эләктергән дә тирә-ягына каранып, кемнедер эзли иде. Бу инде полиция затыннан түгел... Димәк, нәкъ вакытында китеп котылганмын.

* * *

Өйгә кайтканда, әти йоклап киткән иде инде. Әни тагын намазлык өстендә утыра. Аның бер сәер гадәте бар, нindидер эшкә тотындымы, төбенә төшмичә туктамый. Бер мәлне фатир тәрәзәләрен алыштыру өчен алдан акча түләп куйдык та тегеләр мошенниклар булып чыкты – әллә күпме кешенең акчасын шулай җыйганнар да югалганнар. Әти кул гына селтәп куйды, кайдан табасың инде хәзер аларны, юкка вакыт үткәргәнче, башка җирдән акча эшләү җайлырак. Ә әни башкача уйлый иде. Ул ничек итсә итеп, көн-төн чабып теге акчаны кире кайтаруга ирешде. Менә шундыйрак гадәте бар аның. Бу кайчагында бик әйбәт, кайчак җанга тия. Чөнки ул бер нәрсәне теләнә алса, өзми дә, куймый да. Ходай Тәгалә белән дә шулай үзенчә сөйләшергә булган, ахры. Әнә бит, көн дими, төн дими, намазлык өстендә утыра. Мин, әлбәттә, аңа бик ышанып җитмим. Дога гына ярдәм итсә, бөтен мулла да миллионер булып бетәр иде. Ә әни...

Кинәт минем уйларым тотлыгып калды. Бүген көн буе чабып йөреп тә бернинди уңай үзгәреш күрмәгәч, дога-фәләненә кул гына селтәгән идем. Әле башкасын хәтерләдем... Минем кесәмдә бер пачка... Банк төргән пачка түгел инде бу, алар бит һәр купюраны йөзәр данә итеп, нәрсәгәдер әзерләп куя. Бу

андый түгел. Кулдан төрелгән... Шуңа күрә күпме икәнен санап карамыйча әйтеп булмый, әллә йөз данә анда, әллә ике йөз... Акча тотып өйрәнмәгәч, каян беләсең... Ләкин шунысы хак: ул акчалар миндә. Күпмедер вакыт эчендә биш йөз мең тирәсе акча кулыма килеп керде. Хәтта минем теләгемне, ризалыгымны да сорап тормыйча. Һәм шул килеш тә мин әле әнинең догасына шик белдереп торган булам. Ә кем әйтә ала бу әнинең теләкләре тормышка ашудан түгел дип?

Мин әлеге вакыйгаларны тагын бер тапкыр күз алдыннан үткәрдем. Әйтеп, адәм ышанмаслык хәл иде бу. Бер уйламаган җирдән кулыма шулкадәр акча килеп керде һәм мин бар хәвефтән дә исән-аман котылдым. Ә тукталыштагы вакыйга. Берничә минутка гына соңласам да, яныма джип килеп туктаячак иде. Ә андыйлар күзенә чалынсаң, мондый очракта язмышың нәрсә белән бетәрен төгәл әйтеп булмый. Каян, ничек эзләп тапканнар? Мин шундук телефон тавышын искә төшердем. Шуның аша, әлбәттә. Тик аларның шулкадәр төгәллек белән эшләве һәм минем нәкъ үз вакытында китеп котылуым... Кинәт күңелне шик айкады. Котылуыммы? Алар эзлиләрдер бит инде һаман. Бәлки, минем кем булуымны да ачыклау мөмкинлекләре бардыр?

Мин шундук киемнәремне алыштырдым да өстемнән салганнарын бер пакетка тутырып урамга чыгып киттем. Подъезд алдында кемдер көтеп торадыр, күзәтәдер кебек тоелган иде. Беркем дә булмады. Пакетны күрше йорт алдындагы чүп контейнерына ташлап, өйгә кергәндә, әни кухняга чыккан иде инде.

– Ничек хәлләрең, балам?

– Синең хәер-фатихаңда, – дип елмайдым мин, аның намазлык өстендә утыруын күз алдына китереп. – Ата-бабалар рухы ярдәм итә...

Ул сынап карап торды да елмайды:

– Алай димә, балам, ярдәм итәр. Ата-баба рухы – зур нәрсә ул.

Әни бу темага озак сөйләргә мөмкин иде. Нәрсәдер турында сөйләү өчен аңа белем кирәк түгел, бер үк фикерне әллә күпмегә төрләндереп әйтә белә, ишеткән-күргәннәрен темага яраклаштырып мисал китерергә дә мөмкин. Шуңа мин сүзне икенчегә бордым:

– Әни, мин иртәгә китәм.

– Ничек китәсең? Кая китәсең?

Кая икәнен мин үзем дә белми идем. Ләкин әлеге хәлләрдән соң монда калу да бик отышлы түгел, каядыр китәргә, беркадәр вакытка булса да, югалып торырга кирәк.

– Авылга, – дидем мин үземнең шулай оста алдаша белүемә үзем дә сокланып. – Дәү әтиләрдә бер-ике көн торам да андагы иптәш малай белән Себергә китәбез. Эшкә урнашырга. Азаматны хәтерлисеңдер бит?

Бер карасаң, бу артык шыттыру да түгел, Азамат чынлап та миңа эш урыны табарга вәгъдә иткән иде. Ул сүзендә тора белүчән егет. Иртәме-соңмы нәрсәдер китереп чыгарачагына өметем бар иде. Азаматны әни дә яхшы белә. Һәм хөрмәт итә. Шалтыратырга кирәк әле аңа...

Әни моны ишетү белән рәхмәтле күзләрен күккә төбәп алды. Бер генә мизгелгә. Тик мин моны сиздем дә елмаеп куйдым. Ялваруларымны Ходай ишетте, Аллага шөкер, дип уйлады инде ул... Ләкин шундук өтәләнергә кереште:

– Бернәрсәм дә әзер түгел бит әле, ник аны алданрак әйтмәдең?

– Берни дә кирәкми, – дидем мин тыныч булырга тырышып. – Киемсалымнарны бүген тутырам.

– Ә акча? Акчаң да юктыр бит?

– Бар, әни. Бераз җыйдым мин.

– Күпме генә җыя аласың инде син... Туктале, менә монда бераз мая бар иде...

Ул ай-ваема карамыйча залга чыгып китте... Мин теге акчаларны чыгарып салудан, «менә, әни, бурычларыгызны түләгез, бераз иркен сулап алыгыз», – диюдән чак тыелып калдым. Акчаны күңелгә сыйдыру да кыен икән.

Һәм ялгыш сүз әйтеп ташламыйм, дип, балконга чыктым...

Күк йөзе чалт аяз иде. Кояш елмая, баш очында гына ак болытлар йөзә. Аларга күз салу белән мин үземнең дә талгын гына йөзеп баруымны тойдым. Шундый рәхәт халәт, канатларыңны җәеп, бөтен дөньяны куеныңа алырдай булып кинәнеп, талгын гына йөзәсең... Беркем комачау итми, бер хәсрәтең юк – күңелеңдә чиксез бер ләззәт, әйтеп бетергесез хозурлык...

Шул ук вакытта аңның кайсыдыр өлешендә әлеге халәтнең бик үк дөрес түгеллеген тоемлау да юк түгел иде. Һәм мин шигемә дәлил эзләгәндәй җиргә бактым.

Ләкин җир дә тоташ гүзәллектән тора. Түбәндә бормаланып елга ага, аның ярларын әле текә тау, әле куе урман алыштыра, шул рәвешле беркадәр баргач, агачлар бәләкәйләнә, куаклыкка әверелә һәм бераздан бөтенләй юкка чыгып, ялан җир башлана. Хәер, моны өстән караганда гына ялан дип әйтеп буладыр, чөнки түбәнгә төшсәң, бу урыннарның сазламык икәне күренә. Әле анда, әле монда хасил булган кечкенә күлләвекләр кояш нурында төрле төсләргә кереп ялтырый. Бу күлләвекләрдә гади генә су түгел, йә алтын, йә гәүһәр, йә әллә күпме төсләргә кереп балкый ала торган тагын нindидер тылсымлы җисемдер сыман тоела...

Уйсулык буйлап кешеләр сибелгән. Алар күннән эшләнгән чиләкләр белән күлләвекләрдәге сыекчаны җыеп йөриләр...

– Улым!

Көтмәгәндә ишетелгән бу тавыштан мин сискәнеп киттем. Һәм ашыгып күккә күз аттым – төн. Җиргә карадым – шәһәрнең гадәти урамы буйлап машиналар агыла... Һәм бер мизгелгә аптырап калдым... Нәрсә булды соң бу? Акылдан шаша башлавым түгелдер бит? Куркуым чынлап булса да, мин баягы күренештән аерылырга теләми идем. Тик әнинең тавышы тагын ишетелде һәм мин өйгә керергә мәҗбүр булдым.

Ләкин эшләрне бетереп урынга яту белән ул дөньяга кабат әйләнеп кайттым. Төш идеме бу, чынбарлыкмы – мин шул дәвердә һәм барысын да күреп-белеп тора идем.

**2**

Күктә бөркет талгын гына йөзә. Ул бер дә читкә күз салмый, фәкать җирне генә күзәтәдер кебек, кайчак үз хуҗалыкларын барлап кайтырга чыккан патша сыманрак та тоелып китә. Ә хуҗалыгы ярыйсы...

Бормаланып елга ага, аның ярларын әле текә тау, әле куе урман алыштыра, шул рәвешле беркадәр баргач, агачлар бәләкәйләнә, куаклыкка әверелә һәм бераздан бөтенләй юкка чыгып, ялан җир башлана. Хәер, моны өстән караганда гына ялан дип әйтеп буладыр, чөнки түбәнгә төшсәң, бу урыннарның сазламык икәне күренә. Әле анда, әле монда хасил булган кечкенә күлләвекләр кояш нурында төрле төсләргә кереп ялтырый. Бу күлләвекләрдә гади генә су түгел, йә алтын, йә гәүһәр йә әллә күпме төсләргә кереп балкый ала торган тагын нindидер тылсымлы җисемдер сыман тоела.

Боларны күрү өчен кош булырга кирәкми. Якындагы текә таулар очына менеп карау да җитә. Санаулы чакрымнарга сыйган тар гына мәйданга елга да, таулар да, урман да, сазлык та кереп өлгергән.

Өлкән яшьтәге карт белән аның утыз биш-кырык яшьләр тирәсендәге улы

тауга үрмәли. Читтән караганда, аларның ата белән ул икәне сизелми дә, авылның ике абруйлы узаманы төбәкнең алда торган эшләрен уртага салып сөйләшер өчен җайлырак урын карыйлардыр сыман тоела. Тирә-як уч төбендәгедәй күренеп торсын, «Менә монда моны эшлибез, тегендә – тегене», – дип билгеләрлек булсын. Алар артык ашыкмыйлар. Тауда үзләрен иркен тоялар. Һавадагы бөркет очышы белән боларның тауга үрмәләвендә ниндидер уртаклык чагыла.

Икесе дә озын киндер күлмәк өстеннән затлы камзул кигәннәр, ни теләсәң, шуны кылырга ирек бирерлек киң чалбар балагын читекләренә тыгып куйганнар. Надирның башында түбәтәй, ул хуҗасы белән бергә туган шикелле бик җайлы утыра һәм кием түгел, ә табигый бер әгъза кебек күренә. Йосыф яланбаш, һәм аның кара чәчләре дә этисенеке кебек кыска итеп алдырылмаган, ә артка каратып тарап куелган, атлаганда ат ялы сыман дулкынланып ала.

Йосыф этисенең тауга үрмәләвенә сокланып туя алмый, яше ару гына булса да, ник бер сулышы капсын да ник берәр хәрәкәтендә уңайсызлык сизелсен. Тау бит инде бу, текә бит. Казан тарафларындагы кебек сөзәк такыр тау да түгел, каен, нарат, имән, чыршы кебек агачлар, куаклар белән капланган, эре ташлы текә тау. Бөркетләр оялый торган. Хәтта Йосыф кебек яшь кешегә дә бик уңайлы түгел. Ә этисе бар дип тә белми, аңа тау ни, тигез җир ни – барыбер.

Тау очына менеп җитү белән Надир улына борыла. Аның йөзе елмаюлы, күзендә дәртле очкыннар уйный.

– Әнә, карале, нинди хозурлык!

Уйсулык буйлап кешеләр сибелгән. Алар күннән эшләнгән чиләкләр белән күлләвекләрдәге сыекчаны җыеп йөриләр. Бер кечкенә чиләк белән күлләвектән алып, аны зуррак чиләккә тутыралар. Шул рәвешле зур чиләк тулгач, аның авызын бәйләп куялар да ары китәләр. Озак та үтми, йөкчеләр килеп әлеге зур чиләкләрне күтәреп алып юл буена илтә. Авылга табан сузылган ат юлы такыраеп беткән, аның читенә буйдан-буйга диярлек әнә шундый чиләкләр тезелгән. Аларны җигүле атларга салып, авыл ягына алып китәләр.

Бу якларның хозурлыгына Йосыфның күзе өйрәнгән инде. Ул аны күрми дә диярлек. Ә менә кешеләр... Алары беркадәр яңалык. Моңа кадәр бөтен авыл халкы диярлек җыелып чыкканы юк иде әле.

– Җир мае ул кадәр күп кирәкми бит, эти, – дип елмая Йосыф. – Чит илгә генә чыгармасаң, аны үзебездә юньләп сатып та булмый.

Надир елмая. Улының иңеннән кагып куя:

– Беркатлы син, – кулы белән тирә-якка ишарә ясап ала. – Күрәсеңме, күпме җирдә ул? Җир өстендә... Үзе чыккан, безгә бары тик җыеп алырга да кулланырга гына кирәк.

– Ләкин аңа ихтыяҗ юк бит, сатып алучы юк.

– Дөнья бүгенге көн белән генә бетми, улым. Җир маеннан ягулык та, төзү кирәк-яраклары да, хәтта дару да ясарга була. Киләчәктә тагын әллә нинди мөмкинлекләре ачылыр. Без генә ул... әле генә... арба майлау өчен кулланабыз. Чөнки ул безнең аяк астында. Ә табан астындагы байлыкның кадере булмый.

Йосыф аста җәйрәп яткан җирләрне тагын бер кат күздән кичерде. Этисе хаклы иде, әлбәттә, байлык аяк астында иде. Ләкин Россия эчендәге ихтыяҗны канәгатьләндерү өчен берничә пот та хәттин ашкан бүген. Һәм аны тәхеткә якынрак булганнар эшли.

– Син нәрсәдер эшләргә уйлыйсың бугай?

– Завод төзергә телим.

Йосыф бу кадәресен үк көтмәгән иде.

– Завод?!.

– Нефть аеру заводы.

Надир сабый бала кебек канәгать һәм дәртле иде. Аны тотып тыярлык түгел. Шуңа Йосыф әтисен бераз кызганып куйды.

– Әти, син бит Себердәге хәлне хәтерлисең, әйеме?

– Себер?

– Әйе, Ухтада завод ясаган кем әле... Фёдор купец... Прядунов... Ул да бит завод ясап, бурычка батып, төрмәдә җан биргән.

Әтисенең йөзендәге сабыйлыкны шундук кырыслык алыштырды.

– Мин – башка камырдан.

– Ул да...

– Минем Россия алдында хезмәтләрем чиксез. Хөкүмәт миңа ышанып карый. Һәм мин бик күп салымнардан азатмын. Хәерчелек, бурычка бату беркайчан да булмаячак.

Йосыф дәшмәде. Надир да ун адым чамасы читтәнрәк урап килде. Тынычланып килде бугай. Улына беркадәр көлемсерәп карап торды да иңеннән кагып куйды:

– Мин сине бәхәсләшү өчен түгел, ә заводны кайдарак урнаштырабыз, дип киңәш итү өчен монда алып мендем.

– Белмим, – диде Йосыф. – Бу шөгыльне мин хупламыйм. Ә инде бик тә телисең икән, аны әнә теге урында эшләү отышлы булыр.

– Елгадан да, авылдан да еракта мы?

– Әйе, эти. Беренчедән, куркынычсыз. Янгын-фәлән чыкса, авылга янамый. Икенчедән, калдыклар елгага агып төшми... Тагын бер мөһим нәрсә: анда чишмәләр күп, ә заводка су кирәк булачак. Урман да якын...

Надир бер мәлгә катып калды. Аннан соң кычкырып көлеп җибәрде:

– Ә син төпле егет, – дип аркасыннан какты аннан. – Мин салым турында гына уйлаган идем. Ә син барысын да исәпләп өлгердең.

Йосыф бертын уйланып торды да тәвәккәлләде:

– Синең игътибар иткәнең бармы икән, эти... Белмим, бәлки, миңа тоела гынадыр... Тик нинди дә булса өлкәдә табыш китерерлек мөмкинлекләр ачыла икән, шундук патша тирәсендәгеләрнең вәкилләре борын төртә башлый, аны ничек тә кулга төшерергә тырышалар. Алтын приискаларын да шулай иттеләр. Тимер, бакыр рудникларын да. Әгәр син төзегән җир маен аеру заводы да табыш китерә башласа, бу тирәдә ыгы-зыгы кубар, дип борчылам.

Надир аны игътибар белән тыңлады да көлемсерәп кенә куйды:

– Борчылма. Мин заманында патша хөкүмәтенә зур хезмәтләр башкардым. Алар миңа ышана, танышлыгым да җитәрлек.

– Үз ихтыярыңда, эти.

– Мин Елизавета Петровнага хат язам. Нефть үрнәкләрен дә җибәрергә уйлыйм. Рөхсәт бирерләр, дип өметләнәм.

– Рөхсәтен бирерләр...

Надир тагын, бәләкәй чагындагы шикелле итеп, улының иңеннән кагып куйды:

– Шулай булгач! Нәрсә, борыныңны салындырып торасың. Заводны төзибез. Ә нефть монда беркайчан да бетмәячәк. Мин кое казып җир астыннан чыгару ысулын да үзләштерәм. Өстәге күлләвекләрдә беткәч, җир астыннан ала башлаячакбыз. Заманалар үзгәреп китсә дә, безнең нәселнең бер шөгыле калачак. Телисеңме, коены күрсәтәм...

Әлеге сазлык урыннан хәтсез генә ара үткәч, елга үрендәге бер аланлыкта

балчык өеме күренә, аның тирәсендә пыр тузып нәрсәдер эшләгән кешеләр күзгә чалына. Тиздән тау битләвендәге сукмак буйлап, ул кешеләр тәңгәленә ике җайдак килеп туктый. Кешеләр янына килмиләр, югарыдан гына күзәтәләр.

Утыз аршынга утыз аршын чамасы мәйданда баскыч ясап, аска казып төшкәннәр.

– Болай иткәндә, ким дигәндә дә 20-30 аршын тирәнлегенә ирешеп була, – ди Надир улына карап. – Ләкин әлеге коеда җир мае күпкә иртәрәк чыкты, шуңа ун аршыннан да тирән төшәргә туры килмәде.

Төптәге коега җыелган нефтьне чиләкләп өскә ташыйлар. Күмер, руда эзләүдә тәҗрибәсе булганнар өчен бу эсул әллә ни катлаулы түгел, әмма...

– Бу авыр, әмма әлегә иң ышанычлы ысул, – ди Надир. – Борынгы гарәп китапларыннан эзләп таптым. Аларда ком булгач, казу җайлы булгандыр, ә безнең җирдә... Менә моның өчен генә айдан артык вакыт китте. Әле таш-фәләнгә очрамаган килеш. Ләкин бер казып куйсаң, елгадан су ташыган кебек җайлы.

Йосыф каршы төшә:

– Болай итеп бетерсәк, безнең биләмәдә казылмаган бер урын да калмаячак.

Надир елмая:

– Анысы да дөрес. Шуңа коены кечкенә итеп казу яхшырак булыр дип уйлыйм. Агач бура белән төшәбез.

Надир үкчәсе белән атының корсагына төртеп ала, улы аңа иярә. Бераздан якында гына урнашкан кое янына килеп туктыйлар.

Мондый кое аларның авылында юк. Ләкин Йосыфның моны судан ераграк урнашкан башка авылларда күргәне бар. Гади генә нәрсә. Ике аршын тирәсе киңлектәге бураны җиргә утырталар да эчен казып баралар. Шул рәвешле, казый торгач, бура җир белән тигезләнә. Аңа тагын берничә ниргә өстиләр. Тагын казыйлар да җир белән тигезләнгәч, тагын ниргә өстиләр... Шул рәвешле, су чыкканчы казыйлар. Кое хасил була.

Ә бу очракта аны җир маен чыгару өчен кулланганнар. Агач чиләкне бау белән коега төшерәләр дә тутырып кабат өскә күтәргәч, зур бурдюкка бушаталар. Барысы да гади генә.

– Әлегә билгеле ысулларның барысын да кулланып карадым, – ди Надир. – Бездә нефть күп. Завод үз-үзен аклаячак.

Йосыф елмая:

– Син, эти, боларны ни өчен миңа күрсәтәсең соң?

Надир дә елмая:

– Менә син үзеңә кара да, миңа кара... – Һәм көтмәгәндә җитдиләнә. – Мин патшага хат язарга булдым. Әгәр үземнең исемнән генә язсам, бу картлачның башы киткән, дияргә мөмкиннәр. Шуңа синең дә ризалыгың кирәк. Тагын берничә кеше булса, бигрәк тә әйбәт.

**3**

Мин төне буена әллә нинди чокыр-чакырлар, нефть тутырылган мичкәләр белән саташып, ниндидер патшаларга хат язып чыктым да таң алдыннан гына йокыга киттем. Ачы тавыш белән будильник чырылдауга бөтен нәрсәне онытып сикереп тордым һәм тиз генә җыенып өйдән чыгып сыпырттым. Әти нәрсәдер әйтеп, сабыр гына аркамнан какты, әни күз яшьләрен сөртеп алды. Бер мизгелгә күңелем тулып, нәрсә өчендер үземне кызганып куйдым. Шулай сәер генә хушлаштык та, мин тимер юл вокзалына элдерттем. Анда баргач, теге акчаны картага салдым – җиде йөз илле мең сум булып чыкты – юлга әни биргән җиде мең дә җитәргә тиеш иде.

Поездга кереп урнашу белән урын җәеп йокларга ятармын, дигән идем. Бәхетсезлеккә каршы, читтәге ике кешелек урын эләкте. Ә күршем – егерме өч яшьләр тирәсендәге чибәр бер кыз булып чыкты. Кергәндә үк белгән шикелле сумкаларын күтәрешеп алып кергән идем, аннан соң урнаштырырга да ярдәм итештем. Аның елмаюы матур иде. Ниндидер әйбәтлек эшләгән саен елмая, шул елмаю өчен генә гел яхшылык кылып торырга мәҗбүр булырсың.

Тик мин сүз бәйләп җибәрә алмадым. Белмим, теге эш табалмыйча каңгырап йөргән дәвердә беркемгә дә, бер җиргә дә кирәксезлегемнән үзбәям төшеп беткәнме, егетләрчә лаеклы итеп сөйләшә алмадым. Ара-тирә сүз алышкаладык инде. Ул үзенең вахта белән эшләвен, нефтянкада аш пешерүен әйтте. Мин – авылга кайтуымны. Тагын нәрсәдер әйтештек.

Нинди станция икәнен хәбәр иттеләр.

– О, миңа тиздән төшәргә... – дип куйды кыз.

– Кызганыч, – дидем мин.

– Ник? – Моны ул шулхәтле ихлас итеп, назлы итеп, гаҗәпләнеп әйтте. Мин елмайдым. Шундый ук назлы итеп, ихлас, рәхәт итеп. Тик бер сүз дә әйтә алмадым.

Бәхеткә каршы, бер станциядә бер көтү егетләр кереп тулды. Болар ниндидер училище балалары иде бугай, барысы да бер тирә, барысы шук – шаярышалар, көлешәләр, тирә-яктагыларга да кызык-кызык сүзләр әйтеп алалар. Теге кыз да аларга карап, берничә тапкыр елмаеп куйды, аннан соң миңа күз атып алды, мин дә елмайдым. Шул рәвешле сөйләшкән кебек булдык. Аннан соң мин кәефем күтәрелеп китмәсме, дип, тамбурга чыгып бастым. Монда тәмәке исе катыш салкынча һава иде.

Ләкин тәрәзәгә күз салу белән... Ниндидер таныш күренешкә юлыккан сыман булдым... Һәм кичә балконда булган хәл келт итеп исемә төште. Юк, андый ук күренеш түгел иде тышта. Тик кайсы ягы беләндер... Һәм мин поезд тәгәрмәчләренең тигез тыкылдавын ишеттем. Дык-дык, дык-дык... Кинәт поезд тәрәзәсендә ниндидер яктылык хасил булды. Һәм мин бөтенләй башка дөньяга килеп эләктем...

Белмим, кем сыйфатында монда күчкәнмендер, әмма үземнең кул-аякларымны да, гәүдәмне дә күрә дә, тотып карый да алмый идем. Болыт идемме мин, әллә томанмы, һава, нур идемме – әйтә алмыйм. Әмма мин монда бар идем һәм барысын да күреп, белеп, ишетеп тора идем.

* * *

Надир мулла дога укып бетергәч, амбар янына җыелган утыз-кырыклап кеше «Аллаһу әкбәр!» дип битен сыпырып куйды. Аннан соң, унлабы җир мае, тагын берничәсе кызыл балчыктан ясалган боламык тутырылган чиләкләрен алып, Надирга иярделәр. Хуҗа казан алдына килеп баскач, эчтән генә тагын ниндидер дога укыды да:

– «Әгузе билләһи минәйш шайтан ирраҗим...» – дип, кулындагы чиләген казанга бушатты. Ул баскычтан төшүгә, нефть күтәреп керүчеләр бер-бер артлы килеп, аны казанга аударды. Һәркайсы эченнән генә дога укып, бисмилласын әйтте. Шул рәвешле тимер казанны тутыргач, аны тирән табакка охшаш капкач белән каплап куйдылар. Кызыл балчык тотып керүчеләр казан белән капкач тоташкан урыннарны яхшылап сыларга кереште. Тагын берничә кеше капкасыннан чыгып торган торебкәгә торба кидереп куйды. Аның төбен дә бик җентекләп сыладылар.

Бу торба түбәнгә табан салмак кына сузылып күрше бүлмәгә чыга һәм салкын су тутырылган шан аша узып, махсус чүлмәк өстендә туктап кала.

Әлегә ул коры. Мичкә ныклабрак яккач, шушы торба эченнән аерылган нефть килеп чыгачак. Сыйфатына карап аны кызылга һәм акка бүләләр.

Читтән караганда, катлаулы кебек тоелмаса да, үз нечкәлекләре бар. Монда мичнең кызулыгын да, суның температурасын да дөрес билгеләргә кирәк. Шулай ук казанның һәм торбаның нинди матдәдән ясалуы да зур әһәмияткә ия. Беренче тәҗрибәдән Надир әлләни зур могҗиза көтмәде. Кул астында нәрсә бар – шуннан эшләнде барысы да. Бу әле сатуга чыгару өчен түгел, ә кимчелекләрен исәпкә алып, киләчәктә нәрсәләр кирәк булачагын билгеләү өчен иде.

– Балчык әзер! – дип сөрәнләде осталарның берсе, тагын бер тапкыр тикшереп чыккач. – Мичкә ягып җибәрергә мөмкин.

Мичкә ягылган иде инде, бары тик аңа утынны күбрәк өстәргә генә кирәк. Мич өчен җаваплы төркем шунда ук эшкә керәште. Аз-азлап кына утын өсти башладылар.

Надир беркадәр карап торды да улына борылды:

– Менә монда ташкүмер отышлырак булыр кебек. Син ничек уйлыйсың?

Йосыф иңнәрен генә сикертеп куйды:

– Шәраб эшкәртүчеләр шулай итә бугай...

Надир кинәт аңа борылды:

– Нәрсә? Шәраб эшкәртүчеләр?!.

– Әйе, мин бер мәлне Твердышевның заводында булган идем.

– Дөрес! Нәкъ менә шулай итәргә кирәк. Юкка булаштык бу корылма белән. Туктатырга да була.

Йосыф аның кыланышын аптырап күзәтте:

– Әти, ярамаган сүз әйтмәгәнмендер бит?

– Һе... Иң кирәкле сүзне әйттең син.

– Аңламадым.

– Нәрсәсен аңламыйсың?!. Сенат сәүдәгәрләрнең шәраб заводларын ябуны таләп иткән указ чыгарды. Хәзер алар корылмаларын кая куярга да белми. Шул исәптән синең Твердышевың да. Тиз генә барып сөйләшергә кирәк. Шуларның корылмаларын сатып алып, үзебезгә яраклаштырырга. Алар бит җиз корылмалар белән эшли. Беләсеңме, нинди сыйфатлы нефть чыгачак?!

Йосыф нәрсәдер әйтеп өлгергәнче, Надир атын чакырып китерде дә атланып авыл ягына очты. Аңа тагын берничә яраны иярде. Калганнар яңа нефть заводының эшен күзәтте. Беркадәр вакыт үтүгә, торба очында торучы шатлыклы аваз салды:

– Нефть килә! Килә! Кызыл төстә!

Якындарак торучылар аның кулындагы чүмечкә иелде. Кемдер бармагын тыгып, иренәнә тидереп карады, кемдер исен иснәп хушланды. Яңа заводтан чыккан нефтьнең беренче чүмече шул рәвешле кулдан кулга күчте. Аны күрү белән кешеләрнең кәефе күтәрелде, шатлыклы авазлар яңгырады. Бөтен халык күңелен гомум күтәренкелек биләде.

– Әй, туктагыз!

Шушы күтәренкелек тәэсирендәдер, мичкә ягучылар да дәртләнеп утын ыргыта иде. Башта Йосыф моны аңлап бетермичә торды, соңыннан үзе дә сизмәстән шунда ташланды:

– Әй, туктагыз! Нәрсә кыланасыз...

Мичкә ягучылар үзләренең артыгын эшләүләрен үзләре дә аңлаган иде инде. Тик ташлаган утынга ут сарылган, аны хәзер кире алып булмый, сүндерәм дип су сипсәң дә, начар булуы бар. Алар ни кылырга да белмичә, гаепле кыяфәт

белән катып торуны белделәр. Йосыфның да мондый эшләрдә тәҗрибәсе юк иде, ул да нәрсә эшләргә кирәген күз алдына китерә алмады. Бары тик көтәргә һәм Ходайга ялварырга гына кала иде. Ләкин озак көтәргә туры килмәде, торба очында торучы кинәт кычкырып җибәрде:

– Болгана! Болгана! Утны сүрәнәйтегез!

Ягучыларның берсе мич ишеген ачып җибәрде дә бер чиләк су тондырды. Ләкин бу су булып чыкмады... Чиләктәге сыекча утка эләгү белән тирә-як ялкынга уралды. Ялкын бер мизгел эчендә мичченең чәчләрен өтеп алды да чиләккә оялады. Мичче куркуыннан чиләген төшереп җибәрде, ул сыекчаны түгә-түгә тәгәрәп китте. Сыекча түгелгән урыннарда ялкын хасил булды. Шулай да куркырлык нәрсә юк иде әлегә. Янгын бары тик мич алдында гына һәм аны сүндерергә мөмкин иде.

– Су сибә күрмәгез! – дип кычкырды Йосыф кемнәрнеңдер чиләк күтәреп килүен күреп, тик соң иде инде. Берничә чиләк су мич алдына сибелде һәм шундук су өстенә калкып ут таралды, күбрәк мәйданны яулады. Инде мич янында әзерләп куйган агачларга да, амбар коймаларына да ут капты. Бу утны су сибеп сүндерү мөмкинлеге дә юк иде.

Йосыф тиз арада яраннарын чакырды да халыкны читкә алып китәргә боерды. Бераздан кешеләр читкә китеп бетте. Һәм шуны гына көткәндәй, казан шартлаган тавыш ишетелде. Казан капкачы күккә күтәрелде, аның белән бергә кайнаган нефть тә тирә-якка чәчрәде һәм бөтен дөнья ялкынга уралды. Моны инде берничек тә тиз генә сүндерерлек түгел иде.

Йосыфның нефть аркасында чыккан янгыннарны күргәне бар иде. Аларны гадәттә тиз генә сүндереп булмый, кайберләре айлар буена пыскып ята. Андый очракларда, төтен артык борчый башласа, янгын урыннарына ком сибәләр иде. Бу җиңел эш түгел, ләкин шуннан да нәтиҗәлерәк башка ысул юк.

Баш күтәрүче крестьяннар да, завод хуҗаларының башбаштаклыгына рәнҗегән урындагы халык вәкилләре дә еш кына ут белән шаярырга ярата, заводларны, рудникларны утка үртәргә генә торалар. Мондый нәрсәләрдән, нигездә, руслар каза күрә, ләкин Йосыфларның рудникларын да берничә тапкыр яндырдылар. Бер мәлне нефтькә бай урында утырган авыл минут эчендә көлгә калды. Әгәр янгын чыгу мөмкинлеге бар икән, ул мотлак чыгачак. Теге сәбәп белән булмаса, бу сәбәп белән.

Шуңа да Йосыф заводны авылдан ераграк төзү ягында булды. Хәзер исә тагын беркадәр нәрсәгә ачыклык керде: нефть запасын заводтан ераграк сакларга кирәк, якын-тирәдә тиз генә алып сибәрлек күләмдә ком торырга тиеш, заводның тирә-ягын янгын узып чыкмаслык дәрәҗәдә итеп сөреп чыкканда да зыян итми. Һәм мичкә ягучылардан аерым бер төркем җыеп, аларны аерым рәвештә укытырга, өйрәтергә кирәк. Бу үзе бер һөнәр кебек ич, күпме ягарга, ничек ягарга, янгын чыга калса, иң башта нәрсә эшләргә – барсын да белеп торырга тиеш алар. Заводны төзеп кую бер нәрсә әле, ә аны нәтиҗәле итеп эшләтә алу, тирә-як өчен куркыныч тудырмау – бөтенләй бүтән.

Уйларына бирелеп, ул Надирның кай арада янына килеп басканын да сизмәде. Әле күптән түгел генә догалар укып, бик зур бер бәйрәм төсендә ачып җибәрелгән заводның соңгы такталары янып бетеп килә иде инде. Әмма әтисенең кәефе күтәренке иде:

– Нәрсә, сабак алып торасыңмы?

Йосыф баш какты.

– Уттан да яхшырак укытучы юк.

Йосыф әтисенең ни өчен шулай бер дә кайгырмавын аңлый алмады. Хәтсез чыгымнар тотып төзелгән завод берничә минут эчендә көлгә калды ич, ә ул

һаман елмаеп йөри. Аның бу соравы йөзенә үк чыккан иде бугай, Надир аңа карап кычкырып көлеп җибәрде:

– Безнең хаталар яна, – диде ул завод ягына ымлап. – Хәзер барысын да өр-яңадан башлыйбыз.

– Бәлки, кирәк түгелдер...

Надир кинәт катып калды, улына беренче тапкыр күргән кебек бик игътибар белән текәлеп торды, аннан тыныч кына итеп:

– Нәрсә сөйлисең син?– диде.

Йосыф уңайсызланып куйды. Ләкин уйлаганын әйтерлек форсаттан файдаланырга кирәк иде, әтисе аны ишетергә әзер бугай.

– Вазгыятьне үзең дә күреп торасың бит, әти...

– Мин мөмкинлекләрне генә күрәм.

– Кайсы өлкәне генә алып карама, тимер, бакыр, алтын булсын, барысын да без башлап җибәрәбез дә аның табыш китерү мөмкинлеге ачыкланса, патша тирәсендә бөтерелүчеләр килеп җитә. Төрле юллар белән кысрыклап чыгарырга тырышалар. Һәм барысын да үз кулларына төшерәләр... Соң, үзеңнең дә әллә ничә руднигыңны тартып алдылар бит...

– Сатып алдылар.

– Ни бәягә?!. Син бит аларны сатарга теләми идең.

Надир дәшмәде, ачуын басарга теләпме, читтәнрәк әйләнеп килде дә:

– Мин иртәгә юлга кузгалам, – диде бөтенләй бүтән тавыш белән. – Шәраб заводларының корылмаларын алып кайтам. Алар сыйфатлы булачак.

* * *

Күз алдымда ут шарлары биешеп алды. Алар таралуга тирә-ягымда тамбур, каршы тәрәзә буенда үбешеп торган үсмер егет белән кыз пәйда булды. Болар унбиш-уналты яшьләр тирәсендәге ыбыр-чыбыр гына иде әле, шуңа мин кыенсынмадым. Елмайдым гына. Мине күрүгә кыз ни өчендер чинап җибәрде һәм алар каударланып күрше вагонга кереп йөгерде.

Аларга әһәмият бирмәдем. Һәм әле генә күземә күренгән... яки төшемә кергән... белмим инде ничек аңлатырга да... әле генә булган нәрсәләрнең бик тә сәерлеген, гайре табигыйлеген тойсам да, ни өчендер аларга да артык игътибар итмәдем. Әйтерсең, кемдер минем аңымны чикләп куйган иде. Бәлки, алай да түгелдер инде, кешенең күзе бит башта аерым детальләрне генә күрә, соңыннан гына нииндидер этәргеч булса, аларны бер җепкә тезә, мантыйгын табарга тырыша. Ә бәлки, көтмәгәндә килеп туган ыгы-зыгы, поезд туктап кешеләрнең чыга башлавы да дикъкатемне алгандыр. Ә алар инде әйберләрен күтәреп, төшәргә, дип киләләр иде. Мин теге кызның сүзләрен искә төшердем: «Тиздән миңа да төшәргә». Һәм кыска гына вакыт эчендә черем итеп төш күреп алган сыман, уянып, үз вагоныма ашыктым.

Теге вакытта кергән шау-шулы үсмер егетләр юк иде инде. Кыз да урынында түгел. Әйберләре... Аның әйберләре турында уйлауга үземнең чемодан искә төште. Мин аны утыргыч артына терәп кенә куйган идем. Әни мәҗбүриләп төяп җибәргән тәмлүшкәләрен алып, теге гүзәлне сыйладым да кабат урынына күтәреп тормадым инде. Әле ул юк иде. Мин тирә-якка караштырып, чынлап та үз урыным янында торганымны чамаладым да ныклабрак эзләргә тотындым. Һәм тирә-юньдәге шүрлекләргә күз салып, утыргычларны күтәреп карагач туктап калдым. Чемодан юк иде. Юкның нәрсәсен эзлисең инде. Шуннан кечкенә сумкамны актарып документларны барладым. Алары да, акча да урынында. Һәм авыр йөктән котылгандай тынычланып калдым.

Кызның да әйберләре юк иде. Каршыга очрамады бит, күрәсең, вагонның теге ягыннан төшеп киткән. Ул эләктермәгәндер ич? Үзенекеләрне алып бетерәлсә дә ярый әле! Һәм мин үземне дөньяның иң ачык авыз кешесе итеп тойдым. Барасы җиргә барып та җитмәдем, ә әйберләрне урлаттым, үземә ошаган кыз белән таныша алмадым. Хәер, аягүрә төш күреп йөргән кешедән нәрсә өмет итәсең инде?!.

Көтмәгәндә, ниндидер уй ялтлап китте һәм мин ишеккә ташландым.

## 4

Әтинең бер сүзе бар. «Барырга телисең икән, артык уйлап торма – атла», – ди ул. Бу юлы да шул дөрескә чыкты. Мин тимер юл вокзалын әйләнеп килеп, автобуслар тукталышы янына җитүгә теге кыз үзе аваз бирде. «Әй!» – дидеме, тагын берәр нәрсә әйттеме, ул тавышка мин борылып карадым һәм икебез дә бер-беребезгә каршы атладык.

– Мин менә килеп җиттем инде, – дип елмайды ул. – Төшәр алдыннан сине эзләгән идем, табалмадым.

Мин иңемне генә сикерттем:

– Тамбурга чыккан идем шул...

Кыз күзләрен шаян елтыратып, миңа текәлде:

– Ә мин тамбурны да карадым. Ике якны да... – Һәм минем ни әйтергә белмичә торуымны күргәч, дәвам итте. – Ярый, менә күрештек бит... Мин Зөһрә булам...

– Таһир, – дидем мин һәм үзем дә аптырап калдым, ә Зөһрә күзләрен елтыратты:

– Шаяртасыңдыр?

– Юк. Чынлап та шулай.

Монда тагын нәрсәдер гаҗәп иде. Сәерме соң шунда? Белмим инде. Таһир-Зөһрә булуыбызмы, көтмәгәндә, кабат очрашуыбызмы, аның мине тамбурда күрмәдем, диюеме... Һәм бу сәерлек турында озак уйланып торырга чара да юк иде.

– Безнекеләр килеп җитмәгән әле, – диде Зөһрә поезддагы өнсезлек башлануыннан курыккандай. – Тиздән җыелырлар. Ә син?.. Син бит башка урынга юлланган кебек идең?

– Әйе... – Һәм мин шунда сәерлекнең сәбәбен аңлаган кебек булдым. – Шайтан алгыры!..

Мин юллар ягына омтылып куйдым, тик безнең поезд киткән иде инде. Һәм кычкырып көлеп җибәрдем.

– Бүген көне буена аңгыраеп йөрим, – дип аңлаттым көлә-көлә. – Беренчедән... Беренчедән, синең белән ни турында сөйләшергә дә белми аптырап килдем.

Бу сүземне ул үзенең җанга ягыла торган елмаюы белән бүләкләде.

– Икенчедән, сумкамны урлаттым. Чемоданны.

– Чемоданны? – Аның йөзенә борчылу кунды, – Их, белгән булса-ам!

– Юк, – дип елмайдым мин тагын. – Белгән булсаң да, ул барыбер поездда китәр иде.

Зөһрә белән аралашу миңа шушы бөтен югалтулардан да кыйммәтрәк иде. Менә монысын әйтергә кыюлык җитеп бетмәде. Кызык инде дөнья, кайчагында иң якының кебек кабул иткән кешегә якын килергә дә куркасың, ә кайчагында... Хәзер мин курыкмый идем. Кәеф тә күтәренке иде. Бер дә юктан. Бер дә юктан гына микән...

– Хәзер нишлисең инде?

– Кичкерәк бирәр нәрсә бардыр әле.

– Юк, – Зөһрәнең тавышында кайгыртучанлык сыман нәрсә чагылып калды. – Иртәгә генә ул якка. Бүген берни дә юк.

Вокзалда куну бәхете күңелне артык назламады. Бу өтек станциядә кунакханә-фәлән дә юктыр әле. Шулай да мин битараф кыяфәт чыгарырга тырышып, иңнәрне генә сикертеп куйдым. Зөһрә бераз уйланып торды да:

– Болай итәргә мөмкин, – дип елмайды. – Безнең белән китеп, буровойда кунасың да, иртән монда вахта автобусы кабат килә. Шуның белән килерсең. Поездга җитешәсең.

Бу начар тәкъдим түгел иде. Шулай да эшкә килүче кешеләрнең кемлеген белмәгәч, бераз сагаеп калдым – алар ни сөйләр бит әле. Тик Зөһрәгә җавап кирәк иде:

– Ничек итәсең?

– Белмим шул, анда урын буламы?

– Табылыр, – дип елмайды ул. – Егетләр дә әйбәт безнең.

Без шулай чөкердәшеп торган арада Дядя Вова килеп җитте. Ул ике метр чамасы, таза гәүдәле кеше иде, авыр сумкасын эскәмиягә куйды да:

– О, Зоечка! Неужели замуж вышла? – дип аны кочаклап алды, аннан миңа кулын бирде. – Дядя Вова.

– Таһир, – дидем мин, аның учында югалып калган кулымның киләчәге өчен борчылып. – Очень приятно.

– Ничава егет! – дип, минем арканы шапылдатты Дядя Вова. – Молодец! Исемнәрегез дә килешеп тора...

Мин: «Бәтәч, син дә татармыни?!» – дип бетә торган анекдотны искә төшереп көлеп җибәрдем. Дядя Вова татар булып чыкты. Үз исеме Вафа икән, ниндидер мультфильмдагыча дядя Степа дип әйтмәкче булганнар да «Степа» берекмәгән, «дядя» белән «Вафа» дигәне генә калган, ахырдан ул «Вова»га әйләнгән. Монысын соңрак белдем. Әлегә сүз минем кияүлеккә кандидатурам турында иде.

– Юк, танышлар гына без... – дип кызарды Зөһрә. – Син бигрәк тагын...

Дядя Вова миңа күз кысты:

– Танышкансың икән, ычкындырма, бырат. Шулхәтле акыллы кыз бу, улым булса, үзем килен итәр идем.

– Ярый инде... – Һәм Зөһрәгә сүзне читкә юнәлтер сәбәп табылды. – Әнә, Клей дә килә...

Клей дигәннәре кыска гына буйлы уртача гәүдәле кеше иде. Ул килеп күрешеп чыгуга тагын кемдер күренде. Шул рәвешле эшчеләр санаулы вакыт эчендә җыелып бетте, һәм без егерме бишләп кеше автобуска кереп утырдык. Монда мин үземне бераз кыенсынулы тойдым, ят кешеләр арасында белмәгән-күрмәгән урынга китеп барганда, артык иркенәеп тә булмыйдыр, ләкин Зөһрә белән сөйләшәсе, ихлас итеп аралашасы килә иде. Ярый, вакыт булыр әле.

Ярты сәгать чамасы баргач, биш-алты кеше төшеп калды. Беркадәр баргач, тагын шулай һәм безгә дә чират җитте. Дядя Вова, Клей, Зөһрә белән мин һәм тагын өч ир әйберләрне күтәреп автобустан чыктык.

Нефть исен бик яман, дип сөйлиләр иде. Мин автобустан төшү белән шул искә юлыгырмын дип борынны җыердым, тик юкка гына икән. Май исе бар иде. Тагын ниндидер... кызган асфальт исе шикеллерәк тә... Машина-трактор төзәтә торган урындагыга охшашрак әчкелтем ис. Бары тик шул гына. Ул миңа хәтта ошый да икән әле.

Автобус тәрәзәсеннән бу як табигате бик матур күренсә дә, без керә торган җир оҗмахка артык охшамаган иде. Бульдозерлар белән тигезләнгән зур гына мәйданны тимер сетка белән уратып алганнар, кызгылт балчыктан булгач, ул тирә-яктагы матурлык фонында бик котсыз булып күренә. Уртадарак биек вышка, аның янында ниндидер корылмалар, бераз читтә дүрт-биш вагончык. Арырак бульдозер, экскаватор, КамАЗ машинасы һәм тагын мин танымаган нәрсәләрдер тезелгән. Вышканың бер ягында бассейнга тартым ниндидер чокыр казып куйганнар, икенче ягында торбалар өеме. Бу торбаларның күплеген күргәч, минем йөрәк жу итеп куйды. Бабайларның авылында багана урынына торба куялар, менә шушыларның беркадәрен кайтарып биргәндә, әби белән бабайның авызлары колакларына җитәр иде. Шул уйдан башка якты нәрсә күренмәде. Янәшәмдә атлап барган Зөһрәнең елмаюын исәпкә алмаганда, әлбәттә.

Ләкин ул елмаю да озын гомерле булмады. Безне күрү белән каршыга уртача буйлы, илле яшьләр тирәсендәге мыеклы кеше килеп чыкты:

– О, яңа көч, яңа тормыш килде монда! Ничек хәлләрегез, ару гына килеп җиттегезме?!

Ул бик кәефләнеп сәламли башлаган иде дә кинәт туктап калды:

– Ә Тарас кайда?

Тарасның кайдалыгын белүчеләр юк иде. Бер-беребезгә карашып алдык та иңнәрне генә сикертеп куйдык. Хәтта мин дә. Шунда мыеклы абзый миңа текәлде:

– Ә син кем?

– Таһир, – тагын иңнәрне җыерырга мәҗбүр булдым. – Ә сез?

Бу сорауны ул көтмәгән иде бугай, мине бик җентекләп өйрәнергә тотынды. Баштанаяк карап чыккач, сорап куйды:

– Монда нишләп йөрисең?

Мин үзем дә сизмәстән Зөһрәгә күз атып алдым. Бер генә мизгелгә. Тик ул моны күреп өлгерде.

– Ә-ә, кунаккамы? – ул елмайгандай итеп кулын бирде. – Хәсән абыең. Мастер.

– Мастер? – Бу сүз миңа бик җылы булып ишетелде, чөнки үземнең дә гомерем шушы сүз белән озак кына бәйле булды – мастерлыкка кандидат, мастер... – Нәрсә буенча?

Хәсән абзый беркадәр аптырап карап торды, аннан көлеп җибәрде:

– Нәрсә буенча?!. – дип кабатлады ул. – Менә шушы куст буенча. Монда минем рөхсәттән башка пес итәргә дә чыкмыйлар. Барысына да мин җавап бирәм. Шул исәптән, Тарасның юклыгы өчен дә...

Ул инде минем хакта онытып, калганнарга борылды:

– Берәү дә шалтыратмадымы?

– Алмый, – диде Клей, – ике, юк, өч көн инде.

– Шайтан алгыры! – Хәсән абзый Клейгә таба атлады. – Ник хәбәр итмәдең? Теге вахтадан берәрсен калдырган була идем. Хәзер нишлибез?

Шунда Дядя Вова алга чыкты:

– Хәзер урнашырга кирәк, Хәсән, – диде ул мастерның аркасыннан кагып. – Кухняда гәпләшербез.

– Анда үзегез гәпләшерсез, – диде мастер. – Ә мине чакырталар. Шайтан алгыры! Таң атса, бер проблема. Инде бу вахта белән адәмчә башларбыз дигән идем. Ярый, барыгыз. Калганнарыгыз әйбәтме?

– Әйбәт!

– Аллага шөкер.

– Яхшы...

Шундыйрак тавышлар ишетелде. Бу юлы мин дәшмәдем. Хәсән абзый каядыр атлады. Бераздан ул кире борылып, Зөһрәгә эндәште. Ләкин кызның сумкаларын миңа өйгәнен күтәп тормыйча, үзе безнең янга килеп җитте:

– Бишенче вагонга урнаштыр кунагыңны. – Хәсән абзыйның тавышында хәстәрлек чалымнары яңгырап китте. – Озаккамы?

– Иртәнгә кадәр.

– Һи, шулай азга гынамыни... – дип елмайды ул һәм Зөһрәгә борылды. – Сиңа, балам, утын ягарга туры килә инде. Теге вахта барысын җимереп китте.

– Ярый, Хәсән абый.

– Яхшы, ял итегез...

Хәсән абзый үз юлы белән атлады. Мин Зөһрәнең сумкаларын вагончик төбенә кадәр илтешеп куйдым да ачкычын алып, бишенче вагонга киттем. Тыштан җыйнак кына күренсә дә, вагон эче кечкенә бер йорт кебек иде. Түрдә зур өстәл, стенасында яссы экранлы телевизор. Бу яктарак ике як читтә – ике диван. Ике тумбочка өстендә ике ноутбук ята. Кыскасы, булыр-булмас кунакханә номерларына караганда, күпкә яхшырак та, уңайлырак та.

Урнаштырыр әйберем, алыштырыр киемем булмагач, миңа монда эш беткән иде. Шуңа ихатага чыктым. Берәр җирдән урап килерменме, дигән идем, тик тирә-якка күз салу белән бу теләк таралды. Тимер-томыр арасында селкенеп йөрүдән әллә ни ләззәт алалмамдыр кебек тоелды. Һәм мин вышка яныннан әйләндем дә кабат вагончыклар янына килдем. Ул арада Зөһрә чыкты:

– Урнашып беттеңме? – диде ул. – Әйдә, безнең ашханәне күрсәтәм.

Ашханәдә әллә нинди яңалык табылмады. Керү белән – юыну бүлмәсе, аннан – өстәл-утыргычлар, түрдә ашарга әзерләү өчен бүленгән бүлмә. Минем мондыйларны юл буйларындагы вагон-ашханәләрдә күргәнем бар иде.

– Кызык түгелме?

Мин каранып торган арада Зөһрә ике чынаяк күтәреп, яныма килеп тә басты:

– Кофе.

– Рәхмәт! – дип елмайдым мин дә. – Кай арада өлгерттең?

– Ә монда кайнаган судан өзелмибез.

Кофе тәмле иде. Өйдән чыкканнан бирле бер чынаяк та кофе эләкмәгән икән миңа. Ләззәтләнеп чөмердем дә:

– Эх! – дип куйдым.

Зөһрә елмайды.

– Син берүзең пешерәсеңме шушында?

– Төрлечә була. Әле моннан ун километрдагы участокта пешерәбез. Тирә-яктагы ашнакчылар барыбыз бергә җыелып пешеренәбез дә үзебезгә тиешлесен монда алып кайтып таратабыз. Вак-төяк нәрсәләрне монда әзерлим инде. Авыр түгел. Пешеренергә яратам мин.

Эшен яратуы Зөһрәнең сөйләү рәвешеннән үк күренеп тора иде. Мин андыйларга сокланып карыйм. Үз эшен яратып эшләгән кеше бәхетле ул. Дөресрәге, яратып эшләрлек эше булган кеше бәхетле. Ә мин...

– Ә утын ягу нәрсә? – дидем мин үземне үз сазлыгымнан сөйрәп чыгару өчен. – Нефть оясында утын ягасызмыни?

Кыз елмайды:

– Белмим, мин кайбер нәрсәләрне утын белән пешерергә яратам. Безнең бит тегендә мич тә бар. Он алып кайтып бирсәләр, икмәкне дә үзем салам. Егетләр дә шулай ярата.

– Ә утынны кем яра?

– Кемнең вакыты бар – шул инде.

– Балта кайда?

– Юк, Таһир, – дип елмайды кыз. – Син кунак. Ә егетләр... Яралар алар.

– Үзеңә кара.

Ул беркадәр уйлап торды да:

– Яхшы, әйдә, – дип ишеккә атлады. – Миңа чынлап та бер-ике кочак ярып куярга кирәк икән.

Без вагон артындагы сарайчык кебек нәрсәгә кердек. Бу утын сарае булып чыкты. Балталарның берничә төре стенага сөяп куелган иде.

– Алайса, син бер-ике кочак утын вакла. Мин тегендә үз эшләремне карый торам. Керерсең. Чәйләп алырбыз.

– Кофелап, – дип төзәттем мин.

Зөһрә тиз генә әйләнеп чыкса, күзе маңгаена менсен әле, дип ярсып эшләдем. Әллә ни кыенлыгы да юк иде инде. Ләкин кыз бик тиз генә чыкмады. Мин сарайдагы утынны ярып бетерүгә караңгы төште. Һәм Зөһрә янына үзем керергә булдым. Тик вагон бикле, ә тәрәзәсе караңгы иде.

Шулай аптырабрак торганда Дядя Вова килеп чыкты:

– Ә мин синең ишекне дөбердәтәм, – диде ул тәмәке суырып. – Йоклап китте микән, качып китте микән, дим. Ә син...

– Сарайда идем...

– Зөһрә әйтергә кушкан иде. – Ул тагын түтен өрде. – Кыскасы, күршедәге кустның ашнакчысы авырып киткән, Зөһрәне мастер килеп алды.

– Бүген кайтмыймы?

– Юктыр, мөгаен.

– Шайтан алгыры... – дип куйдым мин уйчан гына.

– Күңелеңә шик-фәлән кермәсен, – диде Дядя Вова. – Зөһрә бик акыллы кыз. Ә сиңа әйтергә теләгән иде ул, Хәсән әнә Вафа әйтер, борчылма, диде. Так што, кереп йокларга кала инде сиңа.

Мин бер чынаяк салкын су чүмердем дә үз вагоныма юнәлдем. Моңсу иде. Бүген төнлә йокы күрмәм, көтмәгәндә авыруга сабышкан ашнакчыны, аңа алмаш эзләгән мастер Хәсәнне, бер сүз дә әйтмичә китеп барган Зөһрәне сүгеп, рәнҗеп һәм шуңа да күңеле кырылган өчен үземне йолкып чыгармын сыман иде. Алай булмады. Башны мендәргә терәү белән мин ниндидер ләззәткә чумдым һәм бераздан бөтенләй башка дөньяга күчтем. Колагыма таныш тавыш ишетелде:

– Әйдәгез әле, кунаклар, булганына җитешеп утырыгыз әле.

Табында авылның берничә ир-аты утыра иде. Алар рәхмәт әйтә-әйтә, кулларын сөртеп хуҗага карадылар:

– Амин тотарга да ярыйдыр инде...

* * *

– Тотарбыз, – дип сизелер-сизелмәс кенә елмайды Надир карт. – Сезгә бер үтенечем дә бар иде әле. Дога кылыр алдыннан...

Берничә яраны белән кисәк кенә җыенып юлга кузгалса да, Надирнең сәфәре уңышлы булды. Инде кирәге калмаган корылмаларын нәрсә эшләтергә белми аптыраган Твердышев сатып алучы табылуга бик сөенде, хәтта аларны алып кайту өчен үз олауларын да кызганмады. Шул рәвешле, Надир үзенә кирәкле корылмаларга бик җайлы ия булды. Дәртләнеп йөрүенә караганда, аны икенче көнгә үк җыя башлар шикелле иде.

Ләкин Надир завод төзү эшен бөтенләй башка нәрсәдән башлады. Белемгә сәләте булган һәм беркадәр вакыт руслар арасында яшәргә ризалашкан берничә кешегә чапкын җибәрде. Нигә икәнен алдан белдермәде, бары тик үз йортының табын артында сыйланып, дога кылырга җыелгач кына ачып салды:

– Белүегезчә, завод ачарга җыенабыз. Корылмалары да шәраб эшкәртү заводыннан калган кораллар. Аның белән эшләү өчен белемле кешеләр, осталар кирәк булачак. Мин завод хуҗалары белән сөйләшеп кайттым, алар сезне өйрәтергә әзер. Күпмедер вакыт шулар арасында яшәп, барысын күреп, белеп, бөтен нечкәлекләрен өйрәнеп кайтырга кирәк булачак.

Табында тынлык урнашты. Еракка, урыс арасына китәргә атлыгып торучылар бик юк иде бугай.

– Мин сезне бик ашыктырмыйм. Уйлагыз, өегезгә кайтып хәл итегез. Җавапны иртәгә бирерсез.

Кунакларның берсе тамак кырып куйды да кыюсыз гына:

– Мин бара алмыйм...

– Яхшы, – диде Надир шуны гына көткән кебек. – Кем бара алмый, хәзер үк әйтсен. Сәбәбен белдерү мәҗбүри түгел. Бернинди гаепләү булмаячак.

Сүзен әйткәч, табынга күз йөгертеп чыкты. Араларында иң яше шундук күзен читкә алды. Һәм Надир сорамый булдыра алмады:

– Ә син?

– Мин ни... Барасы килми...

Кинәт табындагыларга җан керде. Егеткә карап көлешеп алдылар.

– Яңа гына өйләнде бит, – диде кемдер. – Яшь кәләшен калдырып китәргә теләмидер.

Бу сүздән соң, Надир да көлеп җибәрде.

– Ярый, монда калганнарга да эш җитәрлек, – диде ул җитдиләнеп. – Икегез бармый булып чыкты, ә башкаларның җавабын иртәгә көтәм.

Амин торкач, урта яшьләрдәге Исмәгыйль исемле ир телгә килде:

– Иртәгәгә калдырмый да әйтә алам: мин риза.

– Мин дә... – дигән тавыш ишетелде табынның икенче башыннан.

Аңа тагын берничә кеше кушылды.

– Алайса, иртәгәгә калдырып торасы да булмады, – дип елмайды Надир. – Биш кеше булгач, җитә. Килгән барчагызга да рәхмәт. Ә риза булучылар сәфәргә әзерләнә торыгыз. Корылмаларны китергән олаулар белән юлга кузгалырсыз.

Балта осталары, ташчылар, чүлмәкчеләр... Болары билгеле иде инде. Алардан төркемнәр төзеп, тиешле күрсәтмәләр биреп, эшкә кушты да моңарчы булмаган гамәлгә тотынды. Монысы әле урыс заводчыларында да юк иде. Ләкин әледән-әле чыгып торган янгыннардан котылу өчен аны мотлак булдырырга кирәк иде.

Әлегә эшкә җәлеп ителмәгән ирләрнең егерме биш-утыз биш яшьләр тирәсендәгеләрен җыеп алды. Боларының теләген сорап тормады, тезеп бастырды да үзе белгән-күргән буенча «син... син...» дип кенә барлап чыкты. Шул рәвешле бер төркем туплагач, аларны тагын бер кат күздән кичерде. Тазаныклы ир-егетләр. Болар белән сугышка да барырга мөмкин.

– Сез янгын сүндерүчеләр буласыз, – диде ул артык сүзгә бирелмичә генә. – Кайда, нинди янгын чыга, сезнең бурыч – аны сүндерү. Аңлашыламы?

Кемдер иңен генә җыерып куйды, кемдер баш какты, ә берсе елмайды:

– Ә янгын булмаганда, нәрсә эшлибез?

– Ял итәбез, – дип шаяртты икенчесе.

– Янгын булмаганда, күнекмәләр ясыйсыз. Сүндерергә өйрәнәсез.

Күнекмәләр авылда гадәти күренеш булса да, ул, нигездә, ат белән, ук-җәя, кылыч-сөңге кебек кораллар һәм кул сугышы алымнары белән бәйле иде. Аеруча үсмерләр, егет-җилән пыр туза, авылның бер як читендәге аланлык көн саен җыендагы сыман шау-гөр килеп тора иде. Ә менә янгын сүндерү... аның буенча күнекмәләр... монысы ишеткән дә нәрсә түгел. Шуңа ир-егетләр беркадәр аптырап калды, әмма сүз озайтмадылар.

– Үз арагыздан берәүне башлык итеп сайлагыз, – диде Надир. – Мин тиздән килеп җитәрмен.

* * *

Янгын сүндерүчеләрнең эше каты иде. Алар балта осталары белән бергәләп, ун-унбиш аршын биеклегендә манара төзеде. Аның башына зур мичкә күтәреп куйдылар. Аннан соң, ул мичкәне су белән тутырдылар. Суны елгадан ат белән китерсәләр дә, манара башына мендерү бик җиңел түгел иде. Баштарак һәркайсы чиләк күтәреп үрмәләде. Бераздан кемнеңдер башы эшләп китте, ул чиләкне бау белән мендерергә тәкъдим итте.

Өстәге мичкәне тутыргач, манара астына нефть түгеп, ут кабыздылар. Мизгел эчендә ялкын тирә-юньгә сикерде. Озакламый ул манара баганаларына да кабынып китәргә мөмкин. Ут көчәеп, тотанаклы итеп яна башлагач, югарыдагы мичкәгә бәйләнгән бауны тартып җибәрделәр. Биектән, көчле басым белән төшкән су янгын чыганагын шундук юкка чыгарды.

Ул арада канәгать елмаеп янгын сүндерүчеләрнең башлыгы Надир янына килеп җитте:

– Ничек?

– Яхшы, – диде Надир уйчан гына. – Тагын кабатлагыз.

Башлык төркем янына йөгереп китте дә әмерләр бирә башлады. Янгын сүндерүчеләр арасында ыгы-зыгы купты. Бу һөнәр яңа булгангамы, алар өчен кызык, һәркайсы дәртләнеп, чәмләнеп, ярышта катнашкан кебек итеп эшли иде. Күп тә үтми, су алып килделәр, аны бау белән өскә мендерә башладылар. Бу юлы дүрт яктан дүрт чиләк эшли иде, шуңа мичкә тиз тулды. Ул арада манара төбенә ут төртергә әзерләнделәр. Ләкин Надир кул гына селтәде:

– Бүгенгә җитеп торыр, – аннары янгынчыларның күзендәге дәртне күреп өстәп куйды. – Хәер, үзегез карарсыз. Әлегә башлыгыгызга сүзем бар...

Манара астына тагын ут ягып җибәрделәр. Астагы берничә кеше аңа су сипте, ялкын телләре ныграк үргә сикерде, янгынның мәйданы артты. Һәм шунда мичкәне капладылар... Тәртип...

– Манара астына иске мичне урнаштырып карарга кирәк булыр, – диде Надир башлыкны читкәрәк алып киткәч. – Теге вакыттагы янгынны хәтерлисең бит. Шуны кабатлап карыйбыз.

Башлык беркадәр уйланып торды:

– Дөрес аңласам, без заводны яңадан төзергә тиеш?

– Әйе. Бары тик стеналарын гына күтәрәсе түгел.

– Хәзер башлыйбыз.

Янгынчы иптәшләре янына йөгерде. Надир завод булачак урынга юнәлде. Амбар биләмәсен казып бетергәннәр, елга буеннан комлы таш ташыйлар иде. Бу ташны нефть белән бутап тигезләп җәйсәң, ис китәрлек матур да уңайлы да була. Якынайгач, Надир тагын бер тапкыр күз алдына китерде. Менә бу

урында – мич бүлмәсе. Ул кирпечтән салынырга тиеш. Янгын-фәлән чыкса да, каза күрерлек булмасын. Ә суыткыч бүлмәсе... Анысын да кирпечтән күтәрергә мөмкин... Анысы артык мөһим түгел, нәрсә бар, шуннан ясалыр... Һәр бүлмәдә янгыннан саклау чаралары – ком, су, җәймә...

Әйбәт кенә эшләп китсә, янгын сүндерүчеләр төркеме бик яхшы нәрсә кебек әле ул. Моны һәр авылда, һәр төбәктә кулланылышка кертергә кирәк. Бигрәк тә нефть яткылыкларына бай җирләрдә янгын еш чыгучан. Вакытында күрелгән чара әллә күпме байлыкны саклап калырга мөмкин.

**5**

Елгада өермәгә эләккәнегез бармы? Дулкын сине үзенә суыра башлый, син йөзәргә тырышасың, бөтен көчеңне саласың, тик ул ниндидер бер җиңеллек белән сине тагы да эчкәрәк суыра... Ниндидер көч мине дә шулай кайдадыр суырып алды, карышырга гына түгел, ни булганын аңларга да өлгермичә калдым. Ниндидер өермә уртасына эләктем дә су төбенә китеп бөтенләй бүтән дөньяда калкып чыктым. Кайдандыр шомлы тавыш ишетелә иде: «Док-док-док...» Мин башта үземнең кем икәнемне, тавышның нәрсә булуын аңлый алмыйча яттым. Ә ул тагын кабатланды, көчлерәк, дәһшәтлерәк булып. Аңа кемнеңдер көр тавышы кушылды:

– Таһир!

Ниһаять, мин үземнең кем һәм кайда булуымны искә төшереп сикереп тордым да ишеккә юнәлдем. Ишек кагучы Хәсән абзый иде:

– Ну, ишеп тә карыйсың йокыны! – дип каршылады ул. – Мин инде курка башлаган идем. Юына тор, хәзер чәй алып киләм.

– Кофе, – дип төзәттем мин.

– Нәрсә?

– Кофе, – дип кабатладым. – Ә Зөһрә кайда?

– Монда. Ашарга әзерли.

Минем юыну әсбаплары юк иде. Шулай да мондагы бүлмәдә теш пастасы да, сабын да, хәтта чиста сөлге дә бар икән. Тешне бармак белән генә чистарттым, калганын озаклап, җиренә җиткереп юындым. Чыгуыма Хәсән абзый өстәл башында чәй чөмереп утыра иде инде.

– Акрын кыймылдыйсың, – дип шаян шелтәләде ул. – Чәең... Кофең суына...

– Рәхмәт! – Мин өстәл артына килеп утырдым. – Сәгать ничә?

Хәсән абзый чәен чөмереп куйды:

– Иртә әле. Кофеңны эч.

Берничә йотым уртлап куйгач, рәхәт булып калды.

– Таң тишеге белән йөри, дип тиргәмәсәң, сиңа бер соравым бар иде.

Мин тыңлыйм дигән кыяфәт чыгардым.

– Безнең Тарас килмәде бит. Күршеләрдән дә беркемне табалмадым.

Хәсән абзый миңа карап алды. Аңладым инде тел төбен. Бары тик ничек итеп баш тартырга гына сүзләр табасы калды.

– Шуннан?

– Кеше кирәк.

Мин кофе чөмердем.

– Ашыктыралар. – Ул өскә ишарә ясап алды. – Югарыдан.

Мин тагын кофе уртладым. Ә сүз барыбер табылмады.

– Син берәр көнгә калып эшләшсәң, бик яхшы булыр иде.

Мин аңа карадым да ни әйтергә белми катып калдым. Каласы килә иде,

әлбәттә. Тик эшлисе килми иде. Алай да түгел, Зөһрә, аның иптәшләре янында үзем бөтенләй белмәгән нәрсәгә тотынырга куркыта иде. Утын яручы булып, гомумән, балта остасы булып калырга кушсалар, бер хәл. Балта тота беләм. Бабай мәңге онытмаслык итеп өйрәтте. Ә монда... Миңа трактор ни, торба ни – икесе дә бер, икесе дә тимер. Шулай булгач...

– Уйларга кирәк, – дидем каршы килергә кыймаганлыктан гына.

– Уйларга вакыт юк, Таһир.

Кинәт мин тотып алдым... Бу гади мизгел түгел, алда тагын бер мөмкинлек – сайлау мөмкинлеге ачылган мизгел иде. Кайсы мин теләгәне? Калыргамы, әллә китәргәме? Калырга! Эшләргәме, әллә эш эзләргәме? «Эш эзләү» дигән сүз миңа «чир» дигән мәгънәне аңлаткан шикелле иде. Мин кофе уртладым.

– Эш рәтен белмим.

Бу сүзне әйтү шулкадәр оят иде. Ә икенче яктан карасаң, ник мин аны белергә тиеш әле? Аннан соң, мин эзләп килмәдем бит, мине эзләп килделәр – теләкләре булса, өйрәтерләр.

– Мин мөмкин кадәр җайлаштырдым инде, – диде ул үзалдына сөйләнгәндәй. – Әлегә сиңа иң гади нәрсә генә башкарырга кирәк.

– Нишләргә?

– Әйдә, вышкага. Күрсәтәм.

Без вышкага күтәрелдек. Башкалар уянганмы-юкмы, тик биләмәдә хәрәкәт күренми иде әле. Эчкә узгач, мин тирә-якка каранып алдым да тез буыннары йомшарып китте. Бер нәрсә дә таныш түгел иде. Хәер, бер читтәрәк утырган нәрсә двигатель булырга тиеш. Дизельдер инде. Болары – торба. Тегендәрәк – пульт. Шул рәвешле генә санасаң да, монда танышлары аз иде.

Хәсән абзый елмая биребрәк күзәтеп торды да аркадан кагып куйды:

– Иң мөһиме – курыкмаска. Монда бер катлаулы нәрсә дә юк.

Менә бу торба «шәм» дип атала. Бораулый-бораулый ул аска кадәр төшеп җитә. Шуннан менә бу торбаны, «шәмне» тоташтырырга кирәк. Аны өстән ну... махсус җайланма төшерә, син астан көйләп куясың... Һәм ул килеп җиткәнче астагы торба башын майлап, ике торбаны тәңгәлләштерергә кирәк. Менә болайрак. Ә менә бу нәрсә, ачкыч бу... Автоматик бораулау ачкычы дип атала... Шул борып ике торбаны тоташтырып куя. Син аңа эшне җайлап бирәсең, ул кыса. Бераз төшендеңме?

Төшендем, әлбәттә. Мин моны теләсә кемгә аңлатып бирә алыр идем. Бер торба җиргә төшеп беткәч, икенчесен алып, ялгарга әзерләп куясың, ә автоматик ачкыч аны борып тыгызлый. Аңлатуның бер кыенлыгы да юк. Тик менә эшли башласаң... Бер торбаның озынлыгы гына әллә ничә метр... Авырлыгы – гәүдәсенә карап...

– Катлаулы түгел ул, – дип тынычландырды Хәсән абзый. – Тик монда төгәллек кирәк. Игътибар. Бөтен нәрсәгә вакытында өлгерергә кирәк. Һәм иптәшеңне күзәтергә. Конвейер кебек бу. Син әзерме-юкмы, торба килә, җитешәсеңме-юкмы – ачкыч эшли башлый. Ныклап тотынганчы, бер кузгатып алырбыз әле. Син карап торырсың, шуннан үзең тотынып карарсың. Кулыңнан киләчәк синең.

– Рәхмәт, – дип аптыраулы елмайдым мин. – Ә гадирәк бүтән эш юкмы?

– Юк шул...

Мин тагын тирә-якка каранып алдым. Кичә бергә килгән кешеләрне күз алдына китердем. Берсенең дә миннән артык җире юк иде. Хәсән абзый кушканны тыңламыйча китеп барсам, Зөһрә дә начар уйлап калыр сыман тоелды. Ярдәм итә алмады, дип уйлау бер әле ул, ә ярдәм итәргә теләмәде дию – бүтән.

Аннан соң, гомер буе чиләнәсе нәрсә түгел бит – нибары бер көн. Ә бәлки, төшкә кадәр теге Тарас дигән кешеләре килеп җитәр дә, мин котылырмын. Аннан соң... Шайтан алгыры!.. Иң мөһиме, гомердә бер күрмәгән нәрсә булса да, катлаулы кебек тоелса да, минем бу эшкә тотынып карыйсым килә иде.

– Йә ничек? – Хәсән абзыйның соравы мине айнытып җибәргәндәй итте. – Ризамы?

Аңа беркадәр карап тордым. Ошый иде миңа бу абзый.

– Пес итеп килергә мөмкинме? – дидем, бик җитди кыяфәт чыгарып.

– Нәрсә? – Бу көтелмәгән сорауны ул башта аңламады, аңлагач, кычкырып көлеп җибәрде. – Мөмкин, мөмкин. Димәк, каласың?

– Әлбәттә, – дигән булдым. – Тик мин гаепле түгел.

– Бар да яхшы булыр. Бар, алайса, егетләр ашханәдәдер.

Бераздан яныма Зөһрә килеп утырды.

– Кичә кисәк кенә китәргә туры килде, – дип елмайды ул. – Сиңа юлда телефоннан шалтыратырмын дигән идем...

– Телефон да алышмаганбыз... – дип елмайдым мин. – Ничек соң, кичә?

– Ашка пешкән ул, «скорый» алып киткән... Син ачуланмагансыңдыр бит? – Мин дәшмәдем. Зөһрә үзенчә аңлап кулымны учына салды. – Ачуланма, яме.

Эчең тулы нәфрәт булса да, аның назлылыгыннан эреп, әллә кайчан таралган булыр иде. Мин елмайдым.

– Ә син кичә бөтен утынны ярып бетергәнсең, – диде ул бөтенләй көтмәгәндә. – Күргәч, Хәсән абыйның күзе маңгаена менде.

– Нәрсә?!.

– Мондый егетне кулыңнан ычкындыра күрмә, ди. – Зөһрә челтерәтеп көлеп җибәрде.

– Ә син?

– Ә мин нәрсә?!. – Зөһрә елмаеп миңа текәлде. – Ә син?

– Мин синең өчен калдым, – дидем дә бу сүз алдашу кебегрәк тоелгач, өстәп куйдым. – Бугай.

– Бу-гай, – дип эләктереп алды Зөһрә һәм урыныннан кузгалды. – Ярый, син иркенләп аша. Күрешербез.

* * *

Беренче ике торба белән этләнергә туры килде. Башны да бәреп алдым, торбаны чайкалдырып, икенчесенә туры китерәлми дә интектем, автоматик ачкычка үзем кысыла язып та калдым. Хәтта эшне туктатып, миңа кабаттан төшендереп бирергә мәҗбүр булдылар. Гарьлек иде, билләһи. Ләкин тирә-якта мине гаепләүче табылмады, ә Хәсән абзый хәтта мактап та алды: «Әле авария чыгара язган кешеләр була торган иде. Син молодец, тырышасың. Менә бу урында болайрак итсәң, тагын да яхшырак китәчәк». Өченчесе чынлап та яхшырак китте. Аннан соң, җаена төшенә башладым. Минем напарник Дядя Вова хәтта елмаеп, баш бармагын күрсәтеп куя торган булды.

Җаен алсаң, әллә ни кыенлыгы юк икән. Реакция кирәк. Анысы миндә бар. Гомумән, бу эшкә кирәкле нәрсәләрнең барысы да миндә бар иде, фәкать, җаена төшенергә, тәҗрибә тупларга гына кирәк. Төш җитүгә, ул миңа хәтта ошый да башлады. Монда торба тоташтыру гына түгел инде, бер арада изմә дә ташыйсың, бетсә, болгатасың да. Кыскасы, кайсы мәшәкатькә беренче туры киләсең, шуны эшлисең. Калганнары – пүчтәк. Көч кирәк, әлбәттә. Торбаның да җаен алгач, мин гомерем буена шушы

эштә эшләгәнмендер, шуның өчен туганмындыр кебек тоела башлады. Буыннарымның аруын тойсам да, әллә нинди бер рәхәтлек кичердем.

Хәсән абыйга ризалык биргәнче: «Бәлки, төшкә Тарас үзе дә килеп җитәр әле», – дип уйлаган идем. Ходайның «амин» дигән чагына эләккән бугай. Кичке аш якынлашканда, ул бер иптәшен ияртеп килде. Үзе әлегә эшли алмый, ниндидер мәшәкате чыккан, шуңа алмаш калдырып китәргә теләгән. Һәм мине азат иттеләр. Теге алмашның тәҗрибәсе минекеннән зуррак иде, тик артык түгел. Һәрхәлдә, мин шулай уйладым. Эш рәтен белсә дә, аңарда дәрт юк, тәмен тоеп эшләми. Ләкин бәхәсләшеп тормадым, мәңгелеккә дип килгән дөньям түгел ич инде бу. Барыбер иртәгә юлга кузгаласы.

Киемнәрне алыштырып, юынып алгач, ашханәгә кердем. Зөһрә камыр басып маташа иде.

– Икмәк пешерәсеңмени? – дидем мин сүзсез тормас өчен генә.

– Юк, пирожки, – дип елмайды ул. – Сине сыйлыйсым килә.

Мин аның янына ук... дөресрәге, урамнан кергән уңайга аш-су янына ук килергә кыенсынып, читтәрәк басып тордым. Якынрак бару теләге көчле иде. Якын килеп, нечкә билләреннән кочаклап...

– Ә син, – диде ул бераз гаҗәпләнеп, – эштә түгелмени?

– Азат иттеләр.

– Күрдем, Тарас кергән иде.

– Ә миңа ул эш ошады. Ошый башлагач кына китәргә туры килде.

– Нишлисең инде... – дип көрсенеп куйды ул.

– Син дә ошыйсың, – дип әрсезләндем мин. – Һәм моннан да китәргә туры килә...

Кинәт ул миңа текәлеп карады. Назлы, әрнүле, газаплы, ләззәтле итеп. Һәм җаныннан бер сүзне сыгып чыгарды:

– Та-һи-ир...

Мин бер мизгелгә әллә нишләп киттем. Бөтен хисеңне бары тик бер сүзгә сыйдырып бетереп буладыр, дип уйлаганым да юк иде. Ә ул сыйдырды. Монда аның өметләре дә, бәхете дә, әрнүе дә, шик-шөбһәләре дә бар иде.

Бу сөйләшү ни белән тәмамланыр иде, балга төшкән бер калак нефть сыман, Тарас килеп керде.

– Зөһрә, тиз генә капкалап аласы иде, Уфа поездына ашыгам...

– Уфа поезды? – дип элеп алдым мин. – Иртән генә булырга тиеш иде бит.

– Расписаниеләре үзгәргән.

– Үзең кара инде, Тарас абый, кулым камырлы, – дип акланды Зөһрә һәм миңа пышылдады. – Кит-мә-ә!..

Мин аңа баш кактым да ихатага чыктым. Кызык бу дөнья. Әле генә шушы урыннан, шушы кыздан да кадерлерәк бернәрсәм юк шикелле иде, ә үзебезнең якка барачак поезд турында ишетүгә, күңел кузгалды да китте. Хәер, шулай булырга тиештер дә. Монда вакытлыча гына, дип тукталган кеше ич мин. Ә максатым бөтенләй бүтән иде. Тукта, нәрсә иде әле ул? Авылда бераз торып, дус егетем Азамат белән Себер якларына чыгып китү? Тагын эш эзләү... Юк, монысы эш эзләү түгел, ә барып урнашу иде. Чөнки кичә генә хәбәрләштек, Азамат нәрсәдер тапкан. Ресторан белән бәйле бер эш. Телефон аша төпченеп тормадым – кайткач сөйләшербез, дип калдырдым. Кыскасы, анда кешеләр кирәк, минем дус, ышанычлы кеше, тәкъдим иткәч, мотлак алачаклар һәм син шәһәрнең төрле конторалары буйлап: «Сез мине эксплуатацияләргә риза булмассыз микән?» – дип теләнеп йөрүдән котыласың. Һәм бәхетле буласың.

Ләкин минем бүген үк китүем мөһим түгел иде. Азамат иртәгә дә авылда була. Хәтта китеп барса да, әлегә яшәп торырлык акча бар. Акча! Яшәп торырлык! Аена җитмешәр мең алып эшләсәң дә, бер елга җитә яза. Минем андыйны гомердә күргәнем юк. Әлегә бер тиенен тотынып карамасам да, беркадәр басымын тойсам да, аның булуы рәхәт иде.

Ашханәгә кабат кермәдем, Зөһрәнең эше күп, ә эш кешесе янында лыбырдап утыру минем өчен кыен тоела. Берәр шөгыль табылмасмы, дип сорарга Хәсән абыйны эзләп карадым да очрата алмагач, куст биләмәсеннән чыгып, агачлык ягына атладым.

Капкадан чыкканда ук йөрәкне нәрсәдер кысып алган сыман булган иде. Хушлашу якынлыгын тою бугай. Иртәгә мин шуннан чыгып китәчәкмен. Ә Зөһрә кала. Әлбәттә, монда кабат килермен, аның туган ягына да барырмын. Ә бара алмасам? Аны яңадан эзләп таба алмасам? Кусттан ераграк киткән саен үземне иң кадерле кешесеннән, мизгелләреннән ераклашып баручы кебек тойдым. Ә агачлыкка узып, нефтьчеләр биләмәсе бөтенләй күренми башлагач, бу тойгы тагын да ныграк көчәйде. Мин аны үз җилкәмдә күтәреп барган төсле хәлсезләндем һәм бер каенга барып сөялергә мәҗбүр булдым. Ләкин агачка сөялү белән бөтен булмышым аша нindидер дулкын үтте... Әллә үзем дулкын аша уздыммы... Белмим... Тик мин инде бүтән дөньяда идем... Колагыма тагын теге таныш тавыш ишетелде...

* * *

– Сиңа көндәшләр табыла, – диде Йосыф хәл-әхвәл сорашу белән. – Биләмәнең Сарытау ягында безнең аучылар бер төркемгә юлыккан. Егерме-утыз кешедән торган кораллы отряд. Крестьяннары да байтак икән. Һәм алар, беләсеңме, нәрсә эзләп йөриләр?

– Узып барышлый гынадыр, бәлки?

– Узып барышлый гына инде. – Йосыф елмайгандай итте. – Күченеп килмәгәннәр. Нефть эзләргә килгәннәр. Граф Яжугинский кешеләре.

– Анысы кем тагын?

– Уралга килергә җыена икән. Ике заводны сөйләшеп киткән, диделәр. Берсе Чуй, икенчесе Сылва буенда. Нефть белән шөгыльләнергә дә исәбе бар, ди.

Улының сүзләре Надирның кәефен күтәрмәсә дә, ул сер бирергә ашыкмады:

– Көндәшләр арта икән шул, – дип кенә куйды.

Ләкин Йосыфның сүзе моның белән генә бетмәде:

– Күршедәге башкорт старшиналарының да җирләрен күпләп тартып ала башлаганнар.

Надир елмаеп куйды:

– Аларны элек тә талыйлар иде бит инде.

– Элек азмы-күпме бәягә сатып алалар иде әле. Ә хәзер турыдан-туры талауга күчкәннәр. Кайбер урыннарда авыллары белән куып, заводка эшкә алып китәләр икән.

– Башкортларны котырту яхшы түгел, – дип көрсенде Надир. – Алар бер күтәрелсә, күзләренә ак-кара күренми. Барысын да кырып ташларга мөмкиннәр.

Йосыф баш какты. Бу халык кунакчыл һәм бераз беркатлы булса да, бер чыгырыннан чыктымы, барысын да пыр туздырып ташлый ала иде. Узганында әнә кораллы отрядларны пыран-заран туздырып, заводларның астын-өскә китереп ташлаганнар, хуҗалары чак качып котылган.

Ләкин байлык артыннан куып, күзе томаланган купецларга барыбер

акыл керми, алар бөтен мөмкинлектән файдаланып, мондагы байлыкны сыгып алырга тырышалар. Элегрәк төрле күчтәнәчләр, ялтыравыклы бүләкләр, арзанлы дан, грамоталар белән кызыктырып, бай җирләрне алырга тырышсалар, хәзер бөтенләй алдау, талау, куркыту юлына басканнар. Тегеләр законны бик аңлап бетермәгәч, бастыруның төрле әмәлен табалар. Хәер, законнарны белү дә артык ярдәм итми. Урыс сәүдәгәрләренең кулында байлык зур, патша тирәсендә элемтәләре көчле. Шуңа алар җирле халыкны бик санга сугып бармый, үзләрен монда басып алучылар кебек хис итә. Ничек кенә баш бирмәскә тырышсаң да, алардан узып, артыгын кылана алмыйсың.

– Монда да килеп җитмәгәйләре, – дип көрсенде Йосыф. – Соңгы арада бик әрсезләнделәр.

Надир беркадәр дәшми торды.

– Патша хәзрәтләре безне рәнҗетергә юл куймас, – диде аннары ниндидер бер эчке тантана белән. – Хөкүмәт алдында минем хезмәтләрем аз булмады. Һәртөрле сугышларга да иң алдан чаптым, җиңеп кайттым. Ил эчендәге фетнәләрне бастырырга кирәк булса да, читтә калмадым.

Йосыф инде мондый сүзләрне мең тапкыр ишеткән иде. Аның хак икәнен дә аңлый. Чынлап та, әтисе – төрле сугышларда катнашып, төрле бүләкләр алган кеше. Әллә ни майтармаса да, фетнәләрне бастыруда да читтә калмаган. Россия хөкүмәтенең аңа ышанычы зур. Ләкин бу юлы сүз алтын, корыч, бакыр, нефть ише җир асты хәзинәләре турында бара. Ә Урал-Идел буйларында үзләре аерым патшалык сыман булып, кечкенә армия, әллә ничәшәр мең бәйле эшче һәм крестьян тотып яшәгән сәүдәгәрләр өчен синең хөкүмәт алдындагы хезмәтләрең бар ни дә, юк ни. Табыш, акча өчен болар әллә нинди кабахәтлекләр эшләргә дә әзер икәнлекләрен күптән исбатлаган иде инде. Әтисенең бик акыллы, алдан күрүчән кеше булып та шуларны аңламавы Йосыфның эчен пошырды. Тик ул бәхәскә кермәде:

– Хәере белән булсын инде, – дип кенә куйды.

Әтисе шуны гына көтеп торгандай елмаеп җибәрде:

– Хәере белән булсын өчен ул отрядны куып җибәрергә кирәк.

Йосыф аңа гаҗәпләнеп карады. Иске авыздан яңа сүз.

– Боларын гына куып җибәрербез дә ул, тик алар күп бит. Күп һәм яхшы коралланган.

– Юк, улым, фетнә кирәкми. Алла сакласын. Ләкин боларны күчтәнәчләр, бүләкләр белән йомшартып җибәрергә туры килер, бу җирләр турында кирәкмәгәнне сөйләп йөрмәсеннәр.

Бу җирләрдә нефть тә, башка казылма байлыклар да барлыгын Петербурда яхшы беләләр иде инде. Шулай да махсус җибәрелгән төркемнәрнең кайберләре бернәрсә дә таба алмый кайта, һәм ул төбәк турында бераз вакытка онытып торалар. Бу ысулны урындагы старшиналарның барысы да диярлек яхшы белә һәм еш куллана иде. Шул исәптән, Йосыф та.

– Мин кешеләр җибәрдем инде, – дип елмайды Йосыф.

– Үзең бар. Соңгы килүләре булмас, танышып кал.

**6**

Кемдер битемне чәбәкләгәнгә уянып киткәндәй булдым... Тик күзләрне ачарлык хәл юк иде...

– Аракы исе килми, – диде кемдер һәм беләкләремне капшап карады, – Наркоман да түгел.

– Билләһи-валлаһи, бая гына бу урында беркем дә юк иде, – дип акланды икенчесе. – Күктән төшмәгәндер бит инде.

– Күрмәгәнсеңдер, – дип шелтәләде аны иптәше. – Больницага илтәбезме? Туктале, бу бит кичә безнең белән килгән егет...

– Точно, шул!

– Ә син күктән төшкән, дисең. Хәсән абзыйга илтәбез, димәк.

Мин күзләремне ачтым.

– Ул уянды! – дип кычкырды минем күктән төшүемне искәрткән тавыш. – Хәлең ничек?

– Мин кайда?

Аның җавабы аңыма барып җиткәнче үк урманда йөреп килергә дип чыгуым искә төште. Тик монда нишләп ятам?

– Сез кем?

– Күрше кусттан без.

Монысын инде чамалый идем. Торып өс-башымны каккалап алдым.

– Йоклап киткәнмен бугай...

– Йоклап?! – дип аптырады мине иснәп караганы. – Шушындый салкындамы?!.

Мин инде чынлап торып һушыма килдем. Егетләрне дә төсмерләдем, кичә бергә килгәнебез искә төште.

– Рәхмәт, егетләр, – дидем мин елмаерга тырышып. – Хәзер... Кайтам үзебезгә...

– Әйдә, без дә шул якка.

– Тик сез... Сөйләнмәгез инде, яме. Урманда йоклап киткән, димәсеннәр. Оят.

Егетләр көлешеп куйды.

– Ә без сине чирле, дип курыктык.

– Арыткан, – дип иснәнгән булдым мин. – Төнлә дә йоклап булмаган иде. Яңа урын...

Алар аңладылар. Башкача сөйләшмәдек. Кустка җитү белән мин үз вагончыгыма кереп качтым. Беркемне дә күрәсем килми иде. Каен төбендә аунап яткан хәлдә кеше күзенә чалынуым өчен беркадәр гарьләнү дә бар иде, әлбәттә. Бу хакта Зөһрә ишетсә, ни уйлар? Чирләшкә нәрсә икән дип читләшүе дә бар, кызларга тулысынча ышанып бетеп булмый, сыналган да кеше түгел. Башкалар алдында да кыен. Ләкин кеше күзеннән читкә китәргә теләвем моның өчен генә түгел иде.

Ни өчен иде соң?

Моңа да төгәл генә җавап таба алмадым. Ничек итеп агач төбенә егылганымны искә төшерү, моның сәбәпләрен ачыклау өчен. Тик мин аны хәтерли идем. Капкадан чыгу белән бөтен булмышымны сагыш басты, алда торган аерылышу турында уйлап борчылдым һәм хәлсезләнеп, бер каенга барып сөялдем. Шунда һушымны югалтканмынмы, йоклап киткәнменме?

Эшләгәндә, үзем сизмәсәм дә, соңыннан арыганлык баскан булырга да мөмкин. Соңгы вакытларда артык көч түгеп эшләгән юк иде бит. Арып йоклап алу – гайре табигый нәрсә түгел. Ә һушымны җуйсам... Зөһрәне шул кадәрле үк итеп, һушымны җуярлык итеп яратам микәнни?!. Соңгы вакытта тәэссоратлар, уйлар-хисләр-кичерешләр хәтсез булды шул. Кеше, бәлки, шулардан талчыгырга да мөмкиндер.

Мин бернинди фикергә дә килә алмадым. Моның тиз генә булмаячагын чамаласам да: «Врачларга күренергә кирәк?» – дигән нәтиҗәгә генә килдем.

Эшсезлекнең кыенлыгына үртәлеп, ишекле-түрле йөрендем дә диванга ятып, телефон актарырга тотындым.

Карале, монда вай-фай да бар икән! Бу бик яхшы нәрсә булып күренсә дә, әллә нинди мөмкинлекләр ачардай тоелса да, интернетта бер-ике битне ачып карауга ук күңел сүрелде. Әллә нишләдем әле мин. Соңгы вакытта телефонны кулга да алмас булдым.

Ашханәгә керү теләге тынгы бирми инде. Тик артык ешласам, ялкытып куярмын, дигән шик тыеп тора. Түзмәдем инде, ишек төбенә чыгып, күрше кусттан килүчеләр китәнме, дип карадым да, аларның машинасы күренмәгәч, Зөһрә янына атладым.

– Нәрсә моңаеп йөрисең?

Борылып караганчы ук чамаладым – Дядя Вова, тәмәке тартырга чыккан. Дәшми генә күзәтсә дә булыр иде, әмма эндәшүеннән күңел күтәрелеп китте.

– Йөрим әле аптырап, – дип елмайдым мин. – Эшсезлек туйдыра икән.

– Анысы шулай, – диде ул төтен суырып. – Элек, Себердә чакта, безнең дә атналар буена тик яткан бар иде. Әле синең ярты көн генә.

– Анысы да эш диярлек түгел инде, – дигән булдым мин. – Вакыт үткәрү.

– Юк, бырат, алай түгел ул. Кулың дөрес синең. Кеше белән кеше, беләсеңме, ничек аерыла?!. Синең тәҗрибәң дә юк, белеп тә бетермисең, ә бергә эшләү күңелле. Тарас үзе дә әлләни түгел иде, ә бу иптәше – бөтенләй бүтән.

– Ярый инде, – дип көлдем мин. – Эш белмәгән кеше кайдан рәхәт булсын.

– Юк, бырат, ялагайланып әйтмим бит. Минем гәүдә ялагайлануга мохтаҗ түгел. Белеп әйтәм.

– Рәхмәт.

– Минем онык аның сүзен дә әйтә иде әле. Энергия, электро... тика... Энергетика, вәт. Энергетика яхшы булырга тиеш. Мин аны беренче күрешкәндә үк тойдым.

Күрше вагон ишеге ачылып китте дә кемдер:

– Дядя Вова! – дип кычкырды. – Сине көтәбез!

– Хәзер, – Дядя Вова тәмәкесен сүндереп вагон янындагы чиләккә ыргытты, – безнекеләр кәрт суга, теләгең юкмы?

– Башка вакытта, – дип елмайдым мин.

Вагон ишегенә тотынгач кире борылды:

– Карале, күңелсез булып китсә, безгә кер.

– Рәхмәт, – дидем мин һәм ашханә ягына юнәлдем.

Ашханә бикле иде. Минем ачып маташуымны күрепме, үз вагончыгыннан Зөһрә атылып чыкты:

– Таһ-һир! – дип кычкырды ул бөтен тирә-якны яңгыратып. – Син!

Мин аңа каршы атладым. Кочаклаштык. Ниндидер могҗиза белән иреннәр иренгә кушылды.

– Киткәнсеңдер дип курыккан идем, – дип пышылдады Зөһрә. – Үпкәләгән идем. Ә син...

Һәм без тагын кушылдык...

Кинәт колак төбендә генә кемнеңдер тавышы ишетелде:

– Ачы!

Хәсән абый иде.

– Мин болай гавам алдында үбешеп, сыйпашып, назлашып торуны яратмыйм, – диде ул бик таләпчән итеп. – Җенем сөйми.

– Гафу итегез, өч көннән төзәлербез, – дигән булдым мин, уңайсызлыкны сыпырып ташларга теләп.

Хәсән абый кул селтәде:

– Ярый, сезгә гафу ителә.

Һәм бераздан өстәп куйды:

– Моны әйтү миңа бик авыр инде, тик Зөһрә... Зинһар, аңларга тырыш... Бүген дә алып китәргә мәҗбүр булам.

Зөһрә елардай булып мастерга төбәлде:

– Хәсән абый... – диде ялварулы тавыш белән. – Бәлки, монда гына пешереп илтербез, ә?

Мастер баш чайкады:

– Ниндидер зур кунаклар килергә тиеш, – диде ул гаепле кеше сыман. – Бөтенегезне дә җыярга куштылар.

– Бәлки, Таһир да барыр? – Зөһрә шундук кире уйлады. – Хәер... Без эштә булабыз, анда нишлисең инде син...

– Үзегез карагыз, – диде Хәсән абый. – Мин каршы түгел. Ун минуттан әзер булыгыз.

Зөһрәнең вагонына керү белән без бер-беребезнең куенына чумдык...

– Шалтыратып тор, – дип пышылдады Зөһрә. – Онытма. Кил.

– М-һм...

– Иртәгә сине озатырга кайтып җитә алмасам, ачуланма.

Мин аны үземә ныграк кыстым.

Бераздан Хәсән абый килеп җитте. Ул мине кочаклап читкәрәк алып китте.

– Рәхмәт сиңа, Таһир, – диде ул. – Килеп йөр. Эшкә килергә теләсәң – бигрәк яхшы. Ә Зөһрә өчен борчылма. Әйбәт бала ул.

Без Зөһрә белән тагын бер кат кочаклашып үбештек тә, ул машинага йөгерде. «УАЗ»ик капкадан чыгып китүгә бөтен дөнья бушап калды. Бераздан бөтен күңелгә газаплы да, татлы да, назлы да бер дулкын кереп тулды.

Мин озак кына басып тордым да салкынны сизә башлагач, вагонга юнәлдем. Үз бүлмәмә кергәч, арыган сыман булдым. Тыны чыккан туп сыман авыраеп, диванга сеңдем. Күзләремне йомуга ук, бөтенләй бүтән дөньяда уянып киттем.

Авыл ягыннан җан-фәрманга ниндидер ат чабып килә иде...

* * *

Надир завод төзегән урынга килеп берничә корылманы урап чыгарга да өлгермәде, авыл ягыннан бу табан чапкан җайдак күренде. Гадәттә, янгын чыкса яки баскынчылар күренсә, йә шуныңише тагын берәр афәт булса гына, шулкадәр ашыга торганнар иде. Эшчеләрнең барысы да диярлек шул якка төбәлеп туктап калды. Надир чапкынга каршы атлады.

Янгын чыгуы икеле иде. Теге вакытта оештырылган төркемнең бер өлеше даими рәвештә авылны саклый. Алар инде көн саен диярлек күнекмәләр үткәреп, чарланып беткәннәр, үз эшләрен яхшы беләләр. Янгын-фәлән булса, аны артык шау-шу тудырмыйча да сүндерә алырлар иде.

Баскынчылар күренүе дә икеле. Берничә тапкыр рудникларын пыр туздырып киткән башкорт күршеләр белән Йосыф үзе барып сөйләште. Үзара килешү сыман нәрсә кабул ителде. Алар сүзләрендә тора торган халык, бер дә юктан яу белән килмәсләр. Соңгы вакытта казаклар да, заводчылар оештырган коралды отрядлар да бу тирәдә еш күренә, баш күтәрүчеләр булса, тыныч кына үз шөгыле белән маташкан Надир җирләренә килгәнче, иң беренче шуларны таркату ягын каерырлар иде.

Аннан соң, Надир старшина булган вакытлардан алып, һәр авылда

көтелмәгән очраклар килеп туса, дип төзелгән яугирләр төркеме бар. Алар авылны да саклый, яшь җилкенчәкне дә сугыш алымнарына өйрәтә, бер ым кагу белән яуга ташланырга әзер торалар. Патшадан чакыру килсә дә, букчалары тутырылган, сугыш кирәк-яраклары әзер. Тыныч кына яшәп яткан авыл санаулы вакыт эчендә гаскәргә әйләнергә мөмкин. Шулай булгач, хәтта яу белән килсәләр дә, чапкын бу тиклем ашыкмас иде.

Ни булды икән? Гаилә әгъзаларының берәрсе авырып китмәгәе. Алай дисәң дә, бу мәсьәлә, нигездә, аналары иңендә. Надирның егерме дүрт баласын өч хатыны карый. Хатыннары авырып-нитеп китсә, бер-берсенә күз-колак булалар. Хәтта араларында азмы-күпме көндәшлек, низаг булган хәлдә дә, кайсыдыр авырып киткәндә татулашып торалар. Юк-бар мәсьәләләр белән ирне борчу гадәткә кермәгән иде.

Шулай ни уйларга белмичә, юл читенә җитүгә җайдак килеп тә туктады. Унбиш-уналты яшьләр тирәсендәге егет иде бу. Төс-кыяфәте бик таныш күренсә дә, Надир аның кем малае икәнен ачык кына билгели алмады. Егет яшь булса да, атын бик кызу куса да, үзен җитди тотты. Килгән уңайга атыннан төшеп, Надирның каршына атлап сәлам бирде, хәл-әхвәл сорашты, шуннан соң гына йомышын ачып салды:

– Писер чакырды. Бик ашыгыч, – диде. – Урыслар килгән, ыстаршыйны таптыралар.

Авыл уртасындагы мәйданга якынайгач кына, ул егетнең ник шултиклем ашыгуын аңлады. Урыслар дигәне утыз-кырыклап солдат булып чыкты, халык җыелган, уртада мулла белән писер әсиргә төшкән кыяфәттә бик мескен булып басып торалар, ә солдатларны башлыгы үз өендәге кебегрәк кыланып, нәрсәдер таптыра.

– Старшинагыз кайда?!

Надир нәрсә булганын бер караудан ук бик аңлап бетерә алмады. Килүчеләр кем генә булмасын, үзләрен бик итагатьле тоталар, авыл халкына тиң итеп карарга тырышалар иде.

– Монда! – дип кычкырды ул, мәйдан уртасына якынлашу белән. – Старшина эш белән китте. Аны мин алыштырам. Надир Уразмәтов. Ә сез кем буласыз?

Атын читкә җибәреп, ул башлык каршына атлады.

– Ха-ха-ха! – дип көлде башлык. – Минме кем булам?! Кемлегемне күрсәтегез әле.

Ул яраннарына ым какты, ике солдат бик кырыс кыяфәт белән Надир ягына атлады. Ләкин якында гына торган өч-дүрт егет аларның юлын бүлде. Надир башлык янына килеп җитәр-җитмәстән аның исерек икәнен абайлады.

– Син үзең күрсәт кемлегеңне, – диде ул бик вәкарь тавыш белән. – Документларың бармы?

Нигездә, ярарга тырышып, үзе тирәсендә бөтерелеп йөри торган урындагы ялагай түрәләрне өркетеп өйрәнгән башлык моны көтмәгән иде. Килүченең тавышы да, үз-үзен тотышы да бүтән төрле иде. Ул бер мәлгә аптырап калды.

– Нәрсә? Син нәрсә кыланасың?!.

Якын-тирәдәге заводчылар белән бәйле гаскәриләр, кайда гына үзләрен ничек тотсалар да, тирә-юньдәге вәзгыять белән яхшы таныш һәм кемнең кемлеген белеп торалар, ни дәрәҗәдә генә исерек булсалар да, болай кылану аларның башына да килмәс иде. Болар әле яңа килүчеләр булырга тиеш, бернәрсә белмиләр, шуңа урындагы халыкка бик өстән карыйлар һәм аны ничек кимсетсәң дә, ярый, дип уйлыйлар. Йосыф әйткән кораллы кешеләр шушы түгел микән әле...

– Сезнең халыкның бер яхшы сүзе бар, – диде Надир җан өшеткеч салкын канлылык белән. – Сәлам нинди – җавап шундый.

– Нинди җавап?.. – Офицер хәзер үзен ничек тотарга да белмәде. Ул солдатларына кычкырды. – Эләктерегез аны!

Солдатлар алга омтылыш ясадылар да туктап калдылар. Беренчедән, эләктерергә тиешле кешене бик җайлы гына итеп яраннары уратып алган һәм беркемне дә үткәрмиләр. Кул белән дә тими алар, каршы да төшми, бары тик гәүдә авырлыгын бер аяктан икенчесенә күчереп йә борылыш ясап үтәргә ирек бирмиләр, тигезлегеңне югалтырга мәҗбүр итәләр. Икенчедән, су өстенә чыккан шәре сыман тын гына итеп солдатларны коралллы җайдаклар уратып алган иде. Тавыш-тыннары да сизелмәде үзләренең, әйтерсең, күзгә күренмәс ишекләр аша башка дөньядан күчеп чыктылар.

Бу көтелмәгән сәер хәл гаскәриләрнең сугыш дәртен шундук сүндерде. Һәм алар башлыкларының кычкыруына да игътибар итмичә урыннарында басып калды.

– Эләктерегез, дим! – дип кычкырды офицер һәм үзләрен камап алган җайдакларга игътибар итте. Чынлапмы бу, күземә генә күренмиме, дигәндәй башын селкеп куйды. Һәм чынбарлык икәнен белгәч, күзләре шар булды.

– Нинди йомышлар белән килеп чыктыгыз? – диде Надир ягымлы тавыш белән. – Нинди дәгъваларыгыз бар?

Хәзер инде аның сүзе мәсхәрә булып ишетелде. Офицер үзен кечерәеп калган сыман тойды. Ул үзе дә, солдатлары да кечерәеп, уенчык солдатлар булып калды. Ә старшина алар белән уйный иде.

– Сезне берәрсе чакырып китердеме, үзегез килдегезме?

– Без экспедиция, – диярга ашыкты офицер үзенең чынбарлык икәнен исбатларга теләгәндәй. – Файдалы казылмалар эзлибез. Без сугыш белән килмәдек... Без граф Яжугинский кушуы буенча...

Надир сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйды. Йосыф алып киткән бүләкләр хәзер, димәк, янга калачак. Һәм мондый кеше белән төзелгән килешүгә беркайчан да ышанырга ярамый. Бу офицерның үзәге юк, ул үз җаен хәстәрләп кырык төрле кыяфәткә керергә мөмкин. Шуңа да Надирның тавышы кискенгә әйләнде.

– Ә сезнең графыгыз Россия кануннары буенча заводчыларның шәхси биләмәсендә башбаштаклык кылып йөрергә ярамаганын беләме?

Офицерның тагын аптырап калуын күргәч, Надирның башына кызык фикер килде.

– Графның адресын бирегез, – диде ул бик тәкәббер һәм катгый кыяфәт белән. – Мин аңа чапкын җибәрәм. Һәм чынлап та аның рөхсәте белән йөрүегез ачыкланганга кадәр, сез монда калып торачаксыз.

Офицер агарынды. Тирә-ягына каранып алды. Гади авыл кешеләре алдында зур көч сыман тоелган отряд коралллы җайдаклар камавында калгач, бик кечкенә булып шиңеп беткән иде. Әгәр сугышырга уйласаң, коралларына үрелергә өлгергәнче үк аларны кырып салачаклар иде. Карышу файдасыз. Ләкин старшинаның сүзе аннан да хәтәррәк иде. Граф аларның монда нәрсә кыланып йөргәннәрен белеп калса, эшнең ни белән бетәчәге дә билгесез.

– Сез шуңа ризамы?

– О, боже! – Офицер бу мизгелдә чынлап та Ходаена рәхмәтле иде. Старшина аларга сайлау мөмкинлеге куя түгелме соң? – Юк, юк... Зинһар өчен, безне тоткарламагыз. Кызулык белән килеп кергәнбез, исерек булганбыз. Зинһар өчен, безне гафу итегез. Ради бога!

Старшина дәшмәде. Тынлык урнашты.

Тынлык озакка сузылды.

Ниһаять, старшина сизелер-сизелмәс кенә хәрәкәт ясап алды. Һәм җайдакларның бер өлеше күчте. Офицер нәрсә булганын бераздан гына аңлады. Аларга авылдан чыгып китү өчен юлны ачканнар иде.

– Спасибо! Спасибо вам! – дип, ул шунда юнәлде. – Спасибо! Извините...

Авылдан чыгуга аларның атларын куып китерделәр. Беркадәр озата баргач, татар җайдаклары кинәт юкка чыкты. Ләкин моңа тулысынча ышанып бетмәделәр, алар теләсә нинди агач артыннан, теләсә кайсы чокырдан үсеп чыгар төсле тоелды. Кич җиткәндә генә, офицер беркадәр тынычлана төште.

– Федя! – дип кычкырды ул яраннарының берсенә. – Бутылку!

Тирән бокалга салып, шәраб эчкәч кенә, беркадәр һуш җыйгандай булды. Тагын берне түңкәреп куйды да йодрыкларын төйнәде:

– Я покажу ещё, – дигән тавыш сыгылып чыкты теш арасыннан. – Ты у меня ещё поплатишься!

**7**

– Таһир!

Дядя Вова тавышы иде. Мин тиз генә торып, ишеккә юнәлдем.

– Хәзер...

– Унбиш минуттан китәләр!

Ишекне ачып тормадым, юыну бүлмәсенә борылдым.

Күтәрер әйбереӊ булмагач, җыену җиңел икән. Бүлмәне әйбәтләп җыештырдым да ашханәгә атладым. Зөһрә әле кайтып җитмәгән иде. Эшчеләр дә керергә өлгермәгән. Ялгызым гына бер чынаяк кофе ясап эчтем. Үземне кызгану, тормышның аяусызлыгына зарлану теләге юк түгел иде, аны куып җибәрергә тырыштым. Ихатага чыккач та, күңелнең кайсыдыр почмагына кереп качкан яктылык чаткысын, җылылык тамчысын казып алырга маташтым. Кояш уянып килә. Көн матур. Дөнья да матур булырга тиеш.

Һәм үземнең шулай булырга тырышуыма үзем сөенеп куйдым. Бу минем соңгы вакытларда мыжыкланмый гына туган беренче таңым иде. Уйлап карасаң, шулай булырга тиеш тә иде. Әле кайчан гына язмышыма үртәлеп, мәхәббәттән дә, яшәүдән дә өмет өзеп төшенкелеккә бирелеп ята идем. Ә бүген...

Дөнья да, мин үзем дә бүтән сыман иде. Зарланырлык бер сәбәп тә юк бит! Мин монда тормышымның иң кадерле кешесен таптым, аның мине дә яратуын аңладым. Мин моннан китәм, тик бу вакытлыча гына, без Зөһрә белән кабат күрешәчәкбез, хәзер инде аны югалту юк.

Күрше вагончыкларга кереп барысы белән дә хушлашып чыктым. Дәшмитынмый гына, качып киткән кебек итеп булмый бит инде. Аларның да күңеле күтәрелде, соңгы биш минут йокыларын урласам да, бу игътибар күрсәтү, санга сугу кебек бит инде, ул үзенә күрә бер ләззәт бирә торган нәрсә. Үзем дә сөендем. Ә Дядя Вова тәмәкесен кабызып озата ук чыкты:

– Чәй эчтеңме? – дип кызыксынды. – Ашап ал, ач йөрмә, барыр юлың ерак.

Мин рәхмәт әйттем.

– Килеп йөр, – диде ул Зөһрә яшәгән вагончыкка ишарәләп. – Озак күрешми торсаң, сүреләсең ул.

Мин елмаеп баш кактым:

– Килеп йөрермен.

– Ә иң яхшысы – эшкә кил.

– Бәлки, шулай да итәрмен әле, – дип килештем мин. – Дөнья хәлен кем белә.

Машинага утыргач та, шушы уйлар белән ләззәтләнеп бардым, поезд көткәндә дә, аларны ычкындырмаска тырыштым. Казан яки Уфа вокзалы белән чагыштырганда, өтек кенә бер станция иде бу. Якындагы шәһәргә охшаш нәрсәсе дә әлләни түгел. Табигате матур, анысына сүз юк. Ләкин шушы кечкенә бер төбәктә мин үземне бәхетле итеп тойдым. Хикмәт аның зурмы-кечкенәме икәнендә түгел, хикмәт минем бәхетле булуымда иде.

Телефоннан шалтыратырга бик кулым кычытып торса да: «Төн буе эшләп арыгандыр, йокласын, ял итсен», – дип үземне тыеп тордым. Миңа сөйләшүдән бигрәк аның тынычлыгын саклау, ял иттерә алу кадерле иде.

Поезд кузгалып киткәч, тамбурга чыгып тәрәзә аша куст тарафына «воздушный поцелуй» җибәрдем дә урыныма кереп утырдым. Бу юлы да стена буена туры килгәнмен икән. Бу юлы да каршымда Зөһрә утырыр, мин аның белән ничек танышып китәргә белмичә газапланырмын сыман тоелды. Тик бу юлы анда юан гына бер марҗа кунаклаган иде.

Ул бик сүзчән кеше булып чыкмады. Минем дә сөйләшү теләге көчле түгел иде. Шул рәвешле беркадәр кагаеп бардык та, мин өстәге шүрлеккә менеп яттым. Уйлана-уйлана оеп барганда, тавыш көчәйткечтән станция исемен әйттеләр:

– Станция Надырово. Стоянка 5 минут.

Бу сүзне ишетүгә минем күңелдә ниндидер сәер хис уянды. Нәрсәседер таныш иде, бу сүз миндә ниндидер хатирәләрне кузгатып җибәрергә тиештер кебек тоелды. Тик бер хатирә дә калкып чыкмады, бары тик күңел генә тынгысызланды. Су өстенә таш ыргыткан шикелле дулкын тарала, ә бер файдасы юк.

– Надырово, надыр, надир, нәдер, нәзер, – дип, әллә ничекләр төрләндереп кабатлап та карадым, тик...

Димәк, Надир станциясе тирәсеннән узып барабыз. Карале, мин үзебезнең кустның кайсы станциядә икәнен дә белешмәдем. Башка да килмәде. Шайтан алгыры! Ярый... Димәк, ул Уфа ягыннан килгәндә, Надир станциясеннән соң. Бер төшкәндә, карарга кирәк – маршрут картасы була ул поездларда.

Бераздан телефон шалтырады:

– Матурым, минем елыйсым килә.

– Ник?

– Мин кайтып җиттем, ә син юк...

Аның тавышын ишетүгә бөтен булмышыма рәхәт дулкын таралды, күзләргә нур кайтты, иреннәр елмайды, хәтта бит очларым да алсуланып киткәндер сыман тоелды.

– Ә мин шатланып барам...

– Миннән котылуыңамы?

Пырхылдап көлеп җибәрдем.

– Юк, җаным, сине табуыма. Ә аерылышу – вакытлыча гына.

– Мин дә... синең белән табышуга шатланам да, аерылгач, барыбер кыен...

– Ә мин синең янга киләчәкмен.

– Кил син, яме. Мин инде сине сагындым.

– Мин яратам сине! – тел очына бу сүз кайдан килде дә, аны әйтерлек кыюлык кайдан табылды. Үзем дә сизми калдым. – Бергенәм син минем...

– Мин дә... Мин дә яратам сине...

Тагын аның ниндидер иҗеге ишетелде, тик ни икәнен аңлый алмадым,

элемтә өзелде, тотмый башлады. Иң кирәк урында өзелүе ачуны чыгарса да, миңа рәхәт иде. Әлбәттә, бер-беребезне яратуыбыз инде икебез өчен дә сер түгел, ләкин аны үз телең белән әйтү бөтенләй икенче нәрсә, бу инде яратышуны законлаштырган шикеллерәк. «Мин сине яратам», – дип әйтәсең икән, димәк, аның киләчәге өчен дә җаваплылык аласың.

Бераздан мин тагын оеп киттемме, йокыга талдыммы... Тагын икенче дөньяга күчтем... Бу юлы ниндидер чиновник бүлмәсендә идем...

* * *

Берг-офицер бик җитди кыяфәт белән бүлмәне әйләнеп чыкты да өстәл артындагы урынына барып утырды. Кәгазьләрен актарды. Һәм бераз кечерәеп калса да, үзен тыныч тотарга тырышып утырган абзыйга карады:

– Надир... Уразмәтов... – диде ул, үзалдына сөйләнгән кебек итеп. – Сез кая югалдыгыз?

Надир дәшмәде. Иңнәрен генә сикертеп куйды. Ул үзенең монда ни өчен чакырылуын яхшы аңлый иде.

Завод төзелеп беткән иде инде. Берничә тапкыр эшләтеп карадылар. Ак һәм кызыл нефтьнең югары сыйфатлы икәненә тәмам ышангач кына, Берг-коллегиягә хәбәр итәргә булдылар. Беркадәр кичегелде... Тик нәтиҗә уңай булган очракта моны гына гафу итәрләр шикелле иде...

Ләкин эш бөтенләй көтелмәгән юнәлеш алды. Көннәрнең берендә Андрей Самокрутов дигән кеше килеп төште дә кичекмәстән Оренбург тау начальствосына барырга кирәклеге турында хәбәр итте. Надир төрле сәбәп табып баш тартып караса да, ай-ваена карамады. Закон аның ягында иде. Өстәвенә, Йосыфны да, бу эштә компаньон булып исәпләнгән Асылгуҗа Мослыховны да алып килергә кушканнар. Йосыф старшиналык вазифалары белән, ә Асылгуҗа сәүдә юлларын эзләргә чыгып киткәнлектән, Надир үзе генә юлланды.

Әле менә шул мәсьәлә буенча сорау алалар.

Берг-офицер кәгазьләренә күз салды:

– Сезгә заводның төзелгәнме-юкмы, төзелеп бетмәсә, күпме эш башкарылганы турында рапорт бирүне сорап берничә тапкыр күрсәтмә җибәрелгән, – диде берг-офицер, Надирга сынаулы карап. – Ләкин алар җавапсыз калган.

– Гафу итегез, офицер, тик аларның берсе дә миңа килеп ирешмәде.

Офицер алдындагы кәгазьләрне актарды.

– Бер, ике, өч, дүрт...

– Мин аларның берсенә җавап язуны Йосыфка йөкләгән идем, ул язган булырга тиеш. Май аенда. Ә калганнары...

– Яхшы, – берг-офицер кәгазьләрне читкә алып куйды. – Килеп ирешмәве гаҗәп түгел. Тирә-якта тынгысызлык, әле фетнә күтәрәләр, әле качкыннар өере йөри. Ә бездә хезмәткәрләр җитеп бетми.

Моны ишеткәч, Надир җиңел сулап куйды.

– Ләкин завод төзелеп бетү белән сез үзегез хәбәр итәргә тиеш идегез. Эшкәртелгән нефть үрнәген безгә җибәрергә, сәүдә буенча исәп-хисап ясарга.

Надир дәшмәде. Мондый очракта уйламый әйтелгән сүздән дә дошманрак нәрсә юк иде.

– Хөкүмәт күрсәтмәләренә җавап бирмәгән өчен һәм заводтан килгән керемне яшергән өчен штраф каралган, – дип дәвам итте берг-офицер. – Сезнең өчегезгә дә хәтсез генә штраф түләргә туры киләчәк. Сез шуны аңлыйсызмы?

– Йосыф старшиналык вазифаларыннан бушамады... Фетнәләр күп булды бит, ә Йосыф йә Оренбург губернасыннан, йә Уфа канцеляриясеннән килгән указлар буенча йөрде. Завод белән шөгыльләнергә вакыты да, теләге дә булмады. Ә Асылгуҗа... Ул завод төзү түгел, ә сәүдә буенча иде... Нефть җитештерелмәгәч, ул нишләсен? Аларның гаебе юк, офицер әфәнде.

Офицер дәшмәде, тәрәзәгә төбәлеп уйга чумды. Бер як читтә утырган писарьнең кәгазе шыгырдаган тавыш кына ишетелде. Берг-офицер кинәт карашын Надирга күчерде, озак кына текәлеп торды. Һәм сорап куйды:

– Нефть җитештерелмәгәч, дисезме?

Бу офицер сорау ала белә иде. Әлеге сүзен дә ул бөтен нәрсәдән хәбәрдар булган, бөтен нәрсәне үтәдән-үтә күреп торган кеше кыяфәте белән әйтте.

– Әйе, офицер әфәнде.

Сорау алучы сизелер-сизелмәс кенә елмайды:

– Ә безнең белүебезчә, завод моннан бер ел элек диярлек эшли башлаган. Һәм сез эшкәртелгән нефтьне тирә-якта гына түгел, Санкт-Петербургта да, Мәскәүдә дә, хәтта Казакъстанда да сәүдәгә чыгаргансыз.

Надир дәшмәде. Офицерның күп нәрсәләрдән хәбәрдар булуы аптыратты.

– Ә безгә – Берг коллегиягә хәбәр итәргә оныткансыз.

– Гафу итегез, офицер әфәнде... – Надир бер мәлгә тынып торды. – Сез дөрес сөйлисез, тик аз гына белеп бетермисез. Заводны без беренче тапкыр ике ел элек үк эшләтеп җибәрдек. Ләкин ул бернинди нефть тә чыгармады, ул янды. Аннан соң, янгыннан саклау ысулларын уйлап табу өчен махсус корылма төзеп, аны әледән-әле эшләтеп тордык. Тик ул сатуга чыгарырлык дәрәҗәдә нефть бирмәде. Әйе, уңышлырак чыккан очракта әрәм булмасын дип, тирә-яктагыларга сатыштырдык. Тик бу бик сирәк кенә... Без нефтьне тотрыклы рәвештә эшкәртүне җайга сала алмадык. Әлегә завод әзер түгел.

– Ике ел вакыт үтте! – дип кинәт кызып китте берг-офицер. – Ә завод әзер түгел! Татарларның хәйләкәр икәнен беләм, әмма бу дәрәҗәдә дип уйламый идем.

Надир тынычлыгын җуймаска тырышты, хәтта аның сүзе дә әңгәмәдәшен тынычландырырга чакыру кебек ишетелде:

– Офицер әфәнде... Сүз нәрсәнедер төзеп кую турында гына бармый...

– Сезнең шәраб эшкәртү корылмалары сатып алуыгызга да ике елга якын вакыт үткән...

– Монда тагын берничә четерекле нәрсәне исәпкә алырга кирәк, – дип үзенекен дәвам итте Надир. – Беренчедән, узган ел безнең тирәдә ду килгән фетнәчеләр тиешенчә эшләргә мөмкинлек бирмәде. Икенчедән, без нефть тапкан урыннарда урыс сәүдәгәрләре килеп рудниклар ачып җибәрде. Нәтиҗәдә, нефть табу авырлашты.

– Туктап тор, – бу юлы берг-офицер писарьга ишарә ясады. – Бу сүзне мин: «рус сәүдәгәрләре комачаулады» дип аңларга тиешме? Рапортта шулай дип язаргамы?

Бер мәлгә чебен очкан тынлык урнашты. Надир офицерга күз атты. Моның өчен дөрес җавап кына түгел, ә рапортта да тырпаеп тормаслык, уңайлы җавап кирәк иде.

– Иң мөһим сәбәп минем үземдәдер, – диде ул бар гаепне үз өстенә алган кыяфәт белән. – Соңгы вакытта бик каты сырхаулап киттем. Сәламәтлегем җитмәгәч, үзем дә эшли алмадым, тиешенчә оештырып та булмады.

Берг-офицер бер тын аңа текәлеп торды.

– Димәк завод әлегә кадәр төзелеп бетмәгән һәм аның төп сәбәбе – сезнең чирләп китүегездә?

– Әйе. Нәкъ шулай.

– Кайчаннан бирле авырыйсыз?

– Завод төзергә рөхсәт килеп күп тә үтмәде инде. Арурак чагымда шәраб эшкәртү корылмаларын кайтарттым, бер амбарны төзеп куйдым. Һәм шуның белән бетте.

Сорау алучы ишекле-түрле йөреп әйләнде дә кабат урынына барып утырды.

– Заводның төзелеп бетмәве яхшы түгел, – диде ул ниндидер бер ягымлылык белән. – Авырып китүегез тагын да начаррак. Мин сезгә сәламәтлек телим.

Беркадәр тын утырдылар. Һәркем үз уйларына чумган иде. Бераздан Надир урыныннан кузгалды:

– Чыгарга мөмкиндер бит?

Берг-офицер баш какты. Ул арада писарь килеп язмаларга кул куярга кушты.

Ишек төбенә җиткәч, Надир кабат борылды:

– Ә штраф ничек?

– Штраф?

– Йосыф белән Асылгуҗаның бер гаебе дә юк бит.

Офицер аңа бертын текәлеп торды.

– Сез авыргач, штраф салмаслардыр. Һәрхәлдә, мин тырыштырырмын.

– Рәхмәт, офицер әфәнде.

– Ә заводны ашыктырырга кирәк.

Ләкин тикшерүләр моның белән генә бетмәде.

Авылга кайтканда ук, аңа завод эшчәнлеген, нефть яткылыкларын тикшерү өчен бер кешене ияртеп җибәрделәр. Бу бер дә ошамады. Оренбург тау начальствосы аның бөтен эшчәнлеген күзәтү астына алырга тырышадыр сыман тоелды. Җибәрелгән кеше дә сөйләшеп-килешеп булырлык адәм түгел, Надирдан күпкә кечерәк булса да, үзен тәкәббер тота. Гомер буена Россия хөкүмәтенә тугры хезмәт итеп олыгайган кешенең мин-минлегенә тия иде бу – фәлән яшеңә җиткәндә, ниндидер бер малайның күзәтүе астында йөр әле.

Аны озатып җибәрүгә тагын тикшерүчеләр килеп төште... Болары тәҗрибәле кешеләр иде. Нефтьнең барлыгын белеп, заводның эшләгәнен күреп, ак һәм кызыл нефть үрнәкләрен үзләре белән алып киттеләр. Оренбургка барып заводның эшли башлавы турында рәсми рәвештә рапорт кына язасы калды. Әлбәттә, вакытында түләп өлгермәгән бурычларны да искә төшерерләр. Аларны түләргә кирәк булачак. Шуңа күрә Надир сәфәрен аз гына кичектерергә булды. Бер кузгалгач, берничә мичкә эшкәртелгән нефть тә алып барырга кирәк, шулай яхшырак булыр.

Ләкин юлга җыенырга әзерләнеп беткәндә генә, авылга бер төркем солдат килеп төште. Аларның башлыгын шундук таныды Надир. Бу теге вакытта мәсхәрәгә калган исерек офицер иде. Бу юлы ул айнык иде һәм үзен бик тә итагатьле итеп тотты. Күрешкәндә үк түбәнчелек белән:

– Ассалямалейкум, Надир эфенди! – дип күреште.

Надир башта шомланыбрак калган иде. Берничә тапкыр тикшерү булганнан соң, кораллы кешеләрнең килүе шатлык өсти торган нәрсә түгел. Офицерның кәефлелеген күргәч, Надирның да шиге таралды:

– Рәхим итегез, – дип елмайды ул. – Исем-атыгызны белми калдым...

– Мөһим түгел, – дип кул селтәде тегесе.

– Ярый, табында танышырбыз. Әйдәгез, кунак булып китәрсез.

– Юк, юк, Надир әфәнде...

– Юл кешеләре бит. Сый-хөрмәтсез килешми.

– Без озак тормыйбыз. Бу тарафтагы тимер рудникларын тикшереп йөрибез,

– дип аңлатты офицер. – Юлыбыз шушы яктан узасы булгач, сезгә тапшырырга дип хат биреп җибәрделәр. Шуны кертеп чыгарга дип килдек.

Солдатларның берсе офицерга төргәк сузды. Офицер аны ике куллап тотып, бик канәгать кыяфәт белән Надирга сузды:

– Рәхим итегез, Надир әфәнде.

Надир төргәкне алды да куенына тыгып, офицерга текәлде. Аның тавышында яңгырап киткән кечелеклелек мәсхәрә дәрәҗәсендә иде. Шулай да карт сер бирмәскә тырышты:

– Рәхмәт, – диде ул. – Ә хәзер табынга рәхим итегез.

Офицерның бөтен кыяфәте тантана итә иде.

– Башка вакытта... Бу якларда хәзер еш булачакбыз. Безнең графның рудниклары монда. Нефть яткылыклары да. Очрашырбыз әле.

Һәм атына менеп атланды.

– Ә сез укыгыз, – дип елмайды ул. – Барысын да аңларсыз...

Һәм атын куалады.

Кызыксынуы көчле булса да, Надир хатны үзенең бүлмәсенә кергәч кенә ачты. Берг коллегиядән икән. Моны аңлауга йөрәге дәртләнебрәк тибәргә тотынды. Димәк, ул җибәргән үрнәкләр барып җиткән. Тикшергәннәр. Ә аларның сыйфаты югары дәрәҗәдә икәненә иманы камил иде. Саран гына рәхмәт сүзләрен, мактауларны күрергә өмет итеп укый башлады.

Тик бераздан аның күзләрендәге нур таралды, йөзе караңгылана барды... Ул чайкалып китте...

Берг коллегия завод төзүне тыю, Надирны заводчылык эшеннән мәхрүм итү турында карар чыгарган иде.

Аның башында берьюлы әллә күпме уй-хис бөтерелде...

«Россиягә шулкадәр хезмәт иткән кешене...»

«Заводны көйләп җибәргән идек бит...»

«Беренче завод бит ул... Россиядә, дөньяда беренче...»

«Бәлки, бу ялгышлыктыр...»

Уйлар акрынлап томанга уралды... Надир йөрәген тотып идәнгә чүгәләде. Аңа һава җитми иде...

* * *

– Юк, – дип кычкырдым мин. – Үлмә! Терел! Әй, кешеләр, коткарыгыз!

Ләкин минем сүземне беркем дә ишетмәде, хәтта Надир карт үзе дә мин барлыкны тоймый иде.

Ә мин бу картның бөтен тарихын беләм, ни өчендер ул миңа кадерле, мин аны аңлый һәм үлемен теләми идем.

– Коткарыгыз! Ярдәм! Йосыф!

Мин шул аваз белән торып утырдым һәм тирә-ягымдагыларның гаҗәпләнүле карашын күреп, үзем дә аптырап калдым. Ләкин шундук аларны күздән җуйдым, бер мизгелгә Надир картның хәлсез адымнар белән бүлмә буйлап йөренгәне чагылып калды. Мин бераз тынычлана төштем. Димәк, ул исән. Ул үлмәгән. Шушы уйдан бераз елмая биреп, тирә-якка тагын күз салдым.

– Хәлегез ничек? – бу проводница иде. – Ярдәм кирәкмиме?

– Юк, юк, – дияргә ашыктым мин һәм елмайдым. – Саташтым гына... Йоклап киткәнмен...

– Ярый алайса... – ул ашыгып чыгып китте дә, мин һуш җыюга бер стакан чәй тотып әйләнеп тә килде. – Мәгез, чәй эчеп алыгыз.

– Рәхмәт!

Бераздан гаҗәпләнеп караган күзләр үз дөньясына күчте, ә мин чәй чөмердем. Ләкин бу юлы мин Надир карт турында онытмаган идем. Алай гына да түгел, алда күргән төшләрем дә... Төшме? Мин моны ничек аңлатырга белмәгәнлектән генә шулай атыйм... Моңарчы күргән вакыйгалар да хәтеремә төшеп бер җепкә тезелгәннәр иде. Надир картның тарихын мин беләидем. Ул дөньяда беренче булып нефть заводы төзи, аны эшләтеп җибәрә, ләкин ниндидер интригалар туып, аны заводчы булу хокукыннан мәхрүм итәләр һәм карт чиргә уралып кала. Кыскасы шулай. Ә калганын... Мин аның заводындагы казаннарның нинди төстә икәненә кадәр белә идем.

Яки беләм, дип уйлый идем.

Төш кенә түгелдер бит инде бу. Моңа кадәр бу кеше турында бөтенләй хәбәрдар түгел идем ләбаса. Бер белмәгән кеше турында шундый аермачык төш күреп буламы? Кабат-кабат? Кино караган яки китап укыган шикелле? Була бугай. Белмим... шулай ук, мин бу төшләрнең миңа ни өчен керүен дә аңламый идем.

Кинәт нәрсәдер искә төшкән кебек булды...

Тамбурда үбешеп торган үсмерләрнең чырылдашып кереп йөгерүе...

Зөһрәнең: «Син тамбурда юк идең» – дигәне...

Урмандагы нефтьченең: «Валлаһи-билләһи, бая гына ул монда юк иде... күктән төшкән кебек...» – диюе...

Һәм мин сискәнеп киттем. Төш күргән... Әлеге күренешләр арасында булганымда югалып тормаганмындыр ич инде? Монысы вакыт буйлап күченеп йөрү булып чыга ич! Ә ул бары тик фантастик киноларда гына мөмкин... Хәер, кем белә... Хәзер ул хакта документаль язмалар да төшерәләр бугай. Галимнәр дә моның мөмкинлеген исбатлап сөйли. Кайберләре. Ә бәлки, мөмкиндер... Менә шушы поездның теге вагонында кемнәр утырганын, нинди хәлләр булганын да белмибез бит. Хәтта шуны да белмәгән көйгә: «Дөньяда мондый нәрсә була ала, ә мондые юк», – дип ышанып әйтеп буламы? Без бик аз беләбез һәм белгәнебезне күп дип уйлыйбыз.

Әмма барыбер бер дөньядан икенчесенә күчү мөмкинлегенә һәм ул күчеп йөрүче үзем булуына ышанасы килми иде. Димәк, күргәннәремнең барысы да төш булып чыга. Кинәт яхшы сыман фикер килде һәм мин күршегә эндәштем:

– Мин монда идемме?

– Нәрсә? – аптыраудан аның күзләре акайгандай булды. – Ничек?

– Сез, мин йоклаганда, бу якка карадыгызмы?

Теге иңнәрен генә җыерды. Күршесе ярдәмгә килде:

– Кем кемгә игътибар итә инде хәзер?! – дип елмайды ул. – Сез кычкыра башлагач кына күрдек. Үзегез кычкырмасагыз, барлыгыгызны да белми идек.

Ул хаклы иде. Үзең кычкырмасаң, барлыгыңны да белүче юк.

Хәтта күргәннәрем сәер бер төш булган хәлдә дә... Ник күрәм мин аларны? Кем миңа ни әйтергә тели?

Җавап юк иде. Юк нәрсәне уйлап табып булмый.

**8**

Поезддан төшкәч, тирә-ягыма каранып, озак кына басып тордым. Перрондагы кешеләр мине төрткәли-төрткәли узып, таралышып бетте. Поезд да кузгалып китте. Үземнең сорауларыма җавапны шушыннан табарга теләгән шикелле тоелсам да, артык зур үзгәреш сизелмәде...

Вокзал аша узып, автобус тукталышына атлаганда гына, кайдадыр адашып йөргән ниндидер фикер келт итеп үз урынына кереп утырды. Мин тагын тирә-юньгә күз салдым. Пластик тәрәзәләр, ишекләр, стеналар, стеналардагы буяулар... Боларның барысы да нефтьтән ясалган иде... Нәрсәгә генә күз салма, барысы да – нефть. Әгәр Надир карт кебекләр тумый калса, бернинди каршылыкларга карамыйча, үз эшен җиренә җиткерергә тырышып йөрмәсәләр, мондый күренеш булыр иде микән? Шундыйларның омтылышы нигезендә барлыкка килгән дөнья ич бу!

Надир карт миңа дөньяны үзгәртүче баһадир булып күренде. Ләкин бу мәсьәләнең бер өлеше генә иде. Бәлки, аны тулысынча колачлап бетерү мөмкин дә түгелдер. Бәлки, ул әнә шулай өлешләп-өлешләп кенә бөтен гомер буена ачыклар өчен бирелгәндер.

Белмим, бу уйлар мине кая илтеп җиткерер иде, ләкин дустымның тавышы чынбарлыкка кайтарды.

– Һәй, ә мин сине тукталышта көтәм!

Ул колачларын җәеп миңа атлады.

– Азамат! – Мин дә кулларымны җәйдем. – Каян белдең?

– Белмәдем, – дип елмайды ул. – Соңгы арада көн саен район үзәгенә киләм. Син кайтмасмы, дип, гел шушында сугылам. Кичә дә көткән идем. Бүген менә...

– Хәлләрең әйбәтме? Кайчан кайттың? – Сораулар күп иде...

– Әйбәт, – дип елмайды ул. – Синең сумка-фәләнең юкмыни?

– Юк, әйдә.

Без аның машинасына барып утырдык та юл уңаендагы кибеткә туктап, күчтәнәчләр хәстәрләгәч, авыл ягына кузгалдык. Юлда ул үз хәлләрен сөйләп алды:

– Ун көн элек кенә кайткан идем, тагын чакыралар әле. Иртәгә торырмын инде, син кайткач, аннан – юлга. Ә мин синең хакта әйттем. Килергә куштылар. Акчасы шәп, эше авыр түгел. Иртәгәдән соң бергә китәбез.

Мин дәшмәдем. Баштарак бик ымсындыргыч булып тоелса да, бу тәкъдим хәзер күңелне артык җылытмады.

– Китәбездер бит? – диде ул минем сәерлегемә бераз аптырап. – Син каршы түгелдер бит?

– Белмим әле. – Мин чынлап та ни дип җавап бирергә дә белми идем. – Әйдә, соңрак...

– Син гел шулай соңга калдырасың бөтен нәрсәне дә, – дип үзенекен итте ул. – Хәзер тизлек заманы, вакытында эләктереп калырга кирәк. Эләктерсәң – була, соңласаң – Аллаһу әкбәр.

Азаматның тәкъдиме чынлап та яхшы иде. Сөйләве буенча, ул анда бик бай бер кеше белән дуслашкан, рестораннар челтәре тота, ә Азамат, аның уң кулы, иң якын ярдәмчесе икән. Акча әйбәт килә, мөнәсәбәт яхшы, абруй да ихтирам да бар. Кыскасы, җәннәтнең үзе. Миңа да эш табылачак, яшәү урыны да, акчасы да әйбәт булачак икән. Ул әйткән сумма нефтьчеләр әйткәннән берничә тапкырга зуррак, һәм бу мине ымсындыра иде. Юк, мин шикләнмәдем. Азамат – дустым иде. Юк-барны сөйләп, корыга мактанып йөри торган кеше түгел. Әйтә икән, димәк, яшәү урыны да, эш тә сөйләшенгән, акчасы да бар. Тик мин никтер икеләндем. Күңелемнән аның тәкъдимен хупласам да, кырт кисеп кенә: «Әйе, брат. Китәбез!» – дип әйтүдән нидер тыйды.

Зөһрә генә түгел. Мин аның турында да күп уйладым. Очрашу өчен мөмкинлекләр табарга булыр иде. Инде соңгы чиктә, барып, матур гына итеп урнашкач, мин аны үз яныма да чакыртып ала алыр идем. Ресторан бизнесында ашнакчыга, әлбәттә, урын табылачак.

Мөгаен, минем куркаклыгым, тәвәккәл түгеллегем сәбәпче булгандыр. Шуның аркасында шушы яшемәчә аңгыраеп йөрим бит инде. Мин тагын төшенкелеккә тәгәрәп бара идем, бәхеткә, кайтып җиттек. Азамат өйгә кереп тормады, соңрак килермен әле, дип китеп барды.

Өйдә мине көтәләр иде инде. Әби әллә нинди тәмлүшкәләр пешергән, табыны әзер. Гөр килеп чәйләп алдык. Хәл-әхвәлләрне сөйләштек. Әти белән дә, әни белән дә алар көн саен диярлек телефоннан сөйләшеп торалар.

Шул рәвешле, сөйләшеп утырдык та бабай белән чыгып, мунча ягып җибәрдек. Ул әзер булганчы, мин анда-санда таралып яткан агачларны кисештереп, утын сараена керттем, бакча ягындагы койманың селкенеп торган бер баганасын алыштырдым. Шуның ише вак-төяк белән гомер уздыруга мунча да булды. «Син яшь кеше, беренче парга син бар», – дип, мине җибәрделәр. Юынып чыккач, тагын тәмләп чәй эчтек тә «бераз таянып тор, юлдан кайткан кеше бит» дип, миңа урын салып бирделәр.

– Бүлмә бүлеп куйдым бит, син күрмисең дә, – дип шелтәләп алды бабай.

– Өйгә күз салырга да ирек куймыйча алып чыгып киттең бит. – Әби тагын мине яклашты. – Үз эшләреңне эшләтергә.

Бабай көлеп кенә җавап бирде.

– Ярый, ят әле. Иртәгә күрсәтермен.

Мин ярымкараңгы бүлмәгә кереп яттым. Чынлап та юл хәлне алганмы, мунчаны бик каты итеп керү җебеткәнме – баш мендәр сорап тора иде. Бабайның бүлмәләрне күрсәтеп маташмавына сөенеп тә куйдым. Ләкин йокларга ирек бирмәделәр, оеп кына барганда өй телефоны шалтырады:

– Кайтты, кайтты, – дип пышылдады әби. – Исән-сау, Аллага шөкер. Әйе. Утыннарны кисеп ташып куйды. Әле мунча кереп чыкты. Йоклый бугай. Ярый, уятмыйм инде. Соңрак үзе эндәшер әле.

Мин үз телефонымны барладым. Зарядкасы беткән. Үземнең зарядник сумкада иде. Монда да булырга тиеш инде ул кайдадыр. Утны яндырдым. Стена буендагы кечкенә шкаф шүрлегендә икән. Кайтасымны белү белән: «Бу бүлмәдә Таһир йоклар, барысы да кул астында торсын әле», – дип әзерләп куйганнар бугай. Телефонны куйгач, бүлмәгә күз йөгерттем – матур итеп эшләгән бабай. Кулы алтын инде аның.

Шунда теге шкаф шүрлегендәге фотоальбомга күзем төште дә елмаеп куйдым. И-и, бар иде бит элек заманалар. Кемгә керсәң дә, чәй-фәлән әзерләгәнче: «Мә, карый тор», – дип шуны тоттырып куялар иде. Әти белән әни бер-ике битен актара да миңа бирә, мин начаррак береккәннәрен куптарырга маташа идем. Бәләкәй чакта. Үсә төшкәч, бетте ул, телефоннар чыкты. Хәзер мондый альбомнарның ни икәнен дә белгән кеше юк. Альбомны алып, кызык өчен генә бер-ике битен актарыйм, дисәм...

Моны күргәч, мин күзләремне ачып-йомып алдым. Тагын башка дөньяга күчмәдемме, төш күрмимме дип, тирә-ягыма күз йөгерттем. Юк, өн иде бу. Ләкин фотоальбомнан миңа карап торган картны мин белә идем. Бу Надир карт иде.

Өстемә ни эләгә шуны элдем дә бүлмәдән чыктым. Әби мунчага барырга җыена иде.

– Карале, әби...

– Нәрсә инде тагын...

– Бу кем ул?

– Соң, шуны да белмисеңмени, Әхмәтшакир бабаң бит. Әнә астына да язылган.

Охшаган гына булып чыкты.

– Ә мин аны Надир дигән кешегә охшаттым.

– Надир? – Әби мунчага җыенуын онытып, урындыкка утырды. – Надир ул менә шушы Әхмәтшакир картның бабасының бабасының бабасы була.

– Нефтьче Надирмы?

– Әйе инде... Безнең нәсел шуңа барып тоташа... Безнең дип, синең нәсел була инде, бабаң яклап ул.

– Ә нигә мин белмим?

– Соң, балам... – Әби ни әйтергә белми тынып калды. – Безнең ише кешегә бик кычкырып йөри торган нәрсә түгел бит инде. Ул бик зур түрәләргә генә килешә хәзер: «Безнең нәсел Чыңгызханнан башлана, менә шәҗәрәбез шуны раслый», – дип мактану. Ә безгә, гади кешегә, нигә хет Адәмнең үзеннән башланмый шәҗәрәң, бер аермасы да юк.

Мин ни әйтергә дә белмәдем. Әби хаклы иде. Менә мин, мәсәлән, беләм хәзер аның кем икәнен. Шуннан? Кемгәдер сөйли аламмы бу хакта? Сөйләп гаҗәпкә калдыра аламмы? «Минем бабам нефтьче Надир булган, миңа эш бирегез әле», – дип бараммы? Әби хаклы.

– Аннан соң, Надир картның балалары бик күп булган бит, егермедән артык булган, диләр, төрле якларга таралганнар. Зур бер тармак килеп чыга. Бабаң менә шуның бер чаткысы инде. Әхмәтшакир бабаң, менә бу рәсемдәгесе, Гитлер белән сугышта үлгән. Герой-фәлән түгел... Шул.

Әби кинәт урыныннан сикереп торды:

– Ярый, син мине болай утыртма, бабаң егылып ятмасын...

Әби – мунчага, мин үз бүлмәмә кереп киттем. Надир карт, димәк, минем фәлән буын бабам булып чыга. Хәзер нәрсәдер ачыкланган кебек булды, тик мин аның нәрсә икәнен генә белмәдем.

Кинәт телефон шалтырады. Мин дертләп киттем. Бу – әни иде. Ул хәбәр бирмәвем өчен шелтәләп алды, мин телефон тотмады, дип алдаштым. Аннан тизрәк үз хәлләрен белешергә ашыктым.

– Үзебез әйбәт кенә инде, – диде ул күңелсезләнеп. – Тик менә бер ахирәтемнең кызы акчасын талаткан. Машинасыннан төшеп подъездга кергән арада талап качканнар. Милиция дә ярдәм итә алмаган, аның бер абзыйсы ФСБда бик зур начальник булып эшли, ул да берни кылалмаган. Сумкасын тапканнар, акчасы юк, ди. Шуңа елашып утырабыз әле. Син дә алдыңны-артыңны карап йөр инде, бәла-казага юлыга күрмә. Бигрәк игътибарың юк.

Минем арка үзәгем буйлап салкын йөгерде:

– Кайчан булган бу хәл?

– Ике көн элек инде.

– Кем, дисең ул кызны? Кайда яши әле?

– Бездән ерак түгел инде... – Әни кызның исем-атын әйтте, мин аны белми идем. Ә адресы таныш иде. – Ә син ник сорыйсың?

– Болай гына. Әти ни хәлдә?

Әти турында соравым вакытны сузу өчен генә иде. Мин инде үземнең кулга эләккән акчаның кемнеке икәненә тамчы да шикләнмәдем. Эскәмиядәге сумка янына килеп туктаган машина, димәк, ФСБ булган. Мин аны берәр төрле мафия-фәлән дигән идем. Мин бу мәсьәләдә шикләнмәдем. Мин икенең берен сайларга белми этләндем: бирергәме, юкмы... Бирмәсәм, әни, ахирәте, аның кызы кызганыч иде. Бирсәм – үзем.

– Әни!.. – дип бүлдердем аны. – Акчасы күпме булган соң?

– Миллионга якын, ипотекага дип җыйган ул аны... Ник сорыйсың?

Тиз булырга кирәк иде. Һәм ялгышмаска. Мин тагын бер кат уйлап алдым да тәвәккәлләдем:

– Миндә ул акча.

– Нәрсә?!. – Әнинең гаҗәпләнүе, куркуы телефон трубкасы аша бөркелеп чыккандай булды. – Ни сөйлисең син?

– Барысын да кайткач аңлатырмын.

– Юк, хәзер аңлат!

Мин барысын да кыскача сөйләп бирдем:

– Калганы – соңыннан... – бу тиклем кистереп сөйләшә алу сәләтемне әле үзем дә белми идем. – Миңа аның карта номерын җибәрегез. Иртәгә акчасын күчерермен. Һәм берни өчен дә борчылмагыз.

– И, балакаем!.. – диде әни һәм трубканы куйды.

Бераздан карта номерын җибәрделәр. Һәм мин онлайн карта аша акча күчердем. Интернет – рәхәт нәрсә инде.

Ничек кенә гаҗәп тоелмасын, акчадан котылгач, җиңел булып калды. Рәхәт булып. Иң мөһиме, мин үземне ахмак итеп тә, ярлы итеп тә түгел, ә бер селтәнүдә кешеләрнең газапларын алып атучы могҗизави зат итеп тойдым.

Бераздан әни, тагын аз гына торгач, теге кыз шалтыратып, рәхмәт укыдылар. Ә алар артыннан... ФСБда зур начальник булып эшләүче туганнары шалтыратты. Ул да рәхмәт әйтте. Һәм үзләренә эшкә чакырды.

– Безгә синең кебек егетләр бик кирәк, – диде ул ягымлы җитди тавыш белән. – Абруйлы хезмәт, фатир мәсьәләләрендә дә, башкасында да льготалары бик күп. Лаеклы хезмәт хакы...

Мин уйлап карарга вәгъдә бирдем. Ләкин озак итеп уйлап утырырга туры килмәде – Азамат шалтыратты. Бүген килә алмый икән, ниндидер мәшәкате бар. Иртәгә очрашабыз, дип кисәтте. Һәм эш турында уйлавымны үтенде. Иртәгә конкрет җавап көтәләр икән.

– Азамат, – дидем мин, әллә кайдан килгән бер үҗәтлекне тавышыма ук чыгарып. – Рәхмәт, әлбәттә. Тик мин бармыйм.

– Ник?!. – ул кызып китте. – Башыңа тай типтеме әллә? Андый эштән кеше баш тартамыни?!

– Юк.

– Мин бит дустым булганың өчен генә тырыштым. Таһир, әйдә, иртәгәгә кадәр ныклап уйла әле.

Трубканы куйгач, мин чынлап та уйга калдым. Әле өч көн элек кенә кайда алсалар, шунда кереп эшләргә әзер булып йөри идем. Бүген менә ике урынга чакыралар, икесе дә акчалы, абруйлы. Ләкин берсенә дә барырга теләгем юк.

Чәйне кайнарлауга әби белән бабай мунчадан кайтты. Ух-ах килеп, бер-берсенә, миңа, илгә-көнгә, хөкүмәткә, бөтен дөньяга рәхмәт укый-укый чәй эчтеләр дә тирләрен сөртә-сөртә үз караватларына барып аудылар.

Савыт-саба юып бетерүгә тагын телефон шалтырады. Минеке.

– Гафу ит инде соң шалтыратуыма, – диде Хәсән абый. – Аптырадым тәмам.

– Хәлләрең ничек?!

– Хәле яхшы булса, кеше кояш баткач шалтыратмый, – дип көлде ул. – Вакыт ягы ничек синең?

– Әйт, – дидем мин шат күңел белән. – Вакыт бар.

– Ничә әйтсәң дә, шул бер балык башы инде... – дип көрсенде Хәсән абый.

– Теге кешебез китте бит. Ошатмады бугай безне... Ә сине бик яратып калган идек. Вакытың булса, кеше тапканчы гына хет...

– Иртәгә өлгерә алмыйм, – дидем мин. – Аннан соң... Пес итәргә рөхсәт итсәң, киләм.

Ул кычкырып көлеп җибәрде.

– Яхшы. Рәхмәт!

Күңелдә бернинди икеләнү дә калмады. Иртәгә кичкә барып җитәм. Берсекөнгә эштә булам. Барысы да көн кебек ачык иде. Һәм җанда нииндидер әйтеп бетергесез күтәренкелек иде. Мин иплəп кенә урыныма кереп яттым да Зөһрәнең номерын җыйдым.

Озак сөйләшмәдек. Шулай да күңелгә рәхәт булып калды. Мин шул рәхәтлеккә төренеп йоклап киттем.

* * *

Күземне ачканда, бүлмә эченә таң яктысы тулган иде. Тәрәзәләр юк иде ич, якты кайдан керә икән, дип уйлап алдым мин һәм аны күрдем. Түрдәге кечкенә өстәл янындагы урындыкта ул утыра иде. Надир карт. Күзләремнең ачылуын күргәч, елмайгандай итеп баш кагып куйды. Мин тирә-ягыма каранып алдым һәм үз бүлмәмдә икәнне белгәч, куркуым тирәнәя төште.

– Курыкма, олан, мин хәзер китәм, – дип елмайды карт. – Ата-бабалар рухы дип чакырганга гына килгән идем...

– Нәрсә?

– Юлың дөрес синең. – Карт мине ишетмәде дә, ул стенага ымлады. – Әнә күрәсеңме?..

Ул күрсәткән якта кечкенә экран сыман нәрсә хасил булды. Нииндидер зур түрәнең кабинетында җыелыш бара иде. Түрдә утырган җитәкче миңа таныш кебек тоелды, текәлеп карасам да, кем икәнен генә аера алмадым. Аннан соң карашымны, аның алдындагы ноутбукка юнәлттем, ручка савытына, һәм ничектер барысыннан да аерылып торган сынга. Һәйкәлчек инде бер. Әллә нинди затлы, ялтыравыклы нәрсә дә түгел иде үзе, тик игътибарымны суырып алды. Һәм тагын теге җитәкчегә карадым. Һәм... бу кеше мин идем... Олыгаеп баручы Таһир...

Картның кеткелдәп көлгәне ишетелде, һәм стенадагы сурәт юкка чыкты...

– Оныкларым өчен сөенеп китәм, – диде карт кулындагы һәйкәлчекне минем баш очына куеп. – Мин сине башкача борчымам. Йә, хуш...

Һәм ул юкка чыкты...

Мин торып аны табарга, әллә ниләр турында сораштырырга уйлаган идем... Тик нииндидер сихри дулкынга эләгеп, үзем дә юкка чыктым... Йокыга эредем...

Иртән уянганда, мин бу төш турында оныткан идем инде. Мунчага барып юынып килдем. Бабай җылы өстәп җибәргән, хәтта чабынырга да мөмкин, тик таң белән чабынырга ирендерде генә. Юынып чыккач, тәмләп чәй эчтек, ихата тирәсендәге вак-төяк эшләрне караштырдык. Аннан кереп яхшылап тамак туйдырдык та, мин юлга җыена башладым. Бары тик шунда гына әби теге сынны китереп тоттырды:

– Курчагыңны оныта күрмә, улым, – дип кеткелдәде ул. – Бигрәк сабый кебек инде, йоклаганда да курчак кочаклап ятасың.

– Нәрсә? – дип аптырадым мин. – Нинди курчак?

– Менә бит шуны биреп торам, – диде әби. – Мендәреңнән табып алып куйдым.

Мин карадым да тәнем эсселе-суыклы булып китте.

– Бәлки, ул сезнекедер?

– Юк, юк... Гомергә күргән нәрсәбез түгел, – диештеләр.

Мин төшемдә Надир карт кулында күргән һәйкәлчекне алып нәрсәгә охшатырга да белмичә бераз карап тордым да куртка кесәсенә салып куйдым. Бу могҗиза иде.

Ул арада Азамат килеп керде. Озакламый без юлга кузгалдык.

## Эпилог

Соңыннан минем бернинди гайре табигый күренешләргә юлыкканым булмады. Боларына, аңлавымча, әнинең догалары сәбәпче булгандыр. Аның ата-бабалар рухын ярдәмгә чакыруын ишетеп, аларның рухлары уянганнардыр да миңа үз юлымны табарга ярдәм иткәннәрдер. Бу, әлбәттә, әкияткә дә, мистикага да тартым. Ләкин башкача берничек тә аңлата алмыйм. Хәер, безнең тормышта моннан да хәйранрак могҗизалар булгалыйдыр әле, без генә барысын да белеп бетермибездер.

Ә ул төшләр-күренешләр аша мин нәрсәгә төшенергә тиеш булуымны тәгаен белә алмадым. Бәлки, анда кешенең гомере буена аз-азлап ачылырга тиешле сер ятадыр, бәлки, үрнәк яки сабак алыр өчен генәдер, ә бәлки, үткәннәрегезне онытмагыз, үткәнен онытканның киләчәге караңгы була, дигән гади ишарәдер. Әйтә алмыйм. Бәлки, нәрсәдер әйтергә, аңлатырга тырышу кирәкмидер дә. Үзең тою да җитәдер.

Мин нефть өлкәсендә эшләп йөрим. Укырга кердем. Хәсән абыйны югарырак үрләткәч, күптән түгел генә мастер итеп куйдылар. Хәзер кустта барысына да мин җавап бирәм, элекке мастерга охшатырга тырышып: «Пес итәргә дә минем рөхсәт белән генә чыгасыз!» – дип җиппәргән булам. Хөрмәт итәләр.

Эштә хөрмәт, өйдә мәхәббәт булгач, әти белән әни дә сөенеп туя алмый. Оныкларны сагындык дип, йә үзләре килеп җитәләр, йә кунакка чакыралар. Кыскасы, бар да яхшы.

Зөһрә белән ике кечкенә малай үстерәбез. Ул үзенә иптәш булырлык бер кыз да табарга хыяллана. Әле монысының кем булырын төгәл белмибез. УЗИ-да да күренми хәтта. Малай булса тагын: «Бу юлы да таба алмадым, дөрес җирдән эзләмим бугай», – дип елмаер инде.

Бер карасаң, дөньяда яшәгән кешегә бөтенесе дә кирәк: акчасы да, сәламәтлеге дә, вак-төяк мәшәкате дә... Ләкин шулар арасында иң мөһиме: яраткан кешең һәм яраткан эшең булу. Минем хәзер икесе дә бар. Сезнеке дә булсын. Сөенешеп яшәгез!



Рүзәл Мөхәмmәтша

# МИНЕМ ТАКТАШ

КЕЧКЕНӘ ОПЕРА ӨЧЕН ЛИБРЕТТО*

**Катнашалар:**
Һ а д и – карт шагыйрь
А д ю к – яшь шагыйрь
И д е я – рух (төп күренешләрдә Галя кыяфәтендә)
Г а в а м

1

*Вокзал. Перрон. Кичкырын. Узып китә торган поезд тавышлары. Әледән-әле диктор нидер игълан итә. Перрондагы эскәмиядә Һ а д и (кичнең шактый салкын булуына карамастан, җиңелчә киенгән, яланбаш) утыра. Янында – чемодан. Кулында таягы (трость) да бар. Туңганга күрә аягын-аякка бәрә, торып йөреп килә. Сәгатенә карап ала.*

Һ А Д И *(үзалдына)*. Мин сиңа язган хатларымны әллә ышандырырлык итеп язмаганмынмы, әллә син үзең шулай иманыңны минем сүзләргә югалттыңмы?

...Үз турымда язган сүзләремә ышанмыйсың төсле...

...Бүген дә менә ике хатыңны алдым. Алар, берсеннән-берсе уздырырга теләп, мине тиргиләр. Ниндидер ышанусыз хисләр белән тулы ул хатлар. *(Сәхнәгә пассажир кыяфәтендә Идея чыга.)*

...Биш ел синең белән үткән сансыз минутлар мине сиңа өзелмәслек бәйләгән. Аларны син дә, мин дә өзә алмабыз...[1]

*Ильяс Камал музыкасы.

[1] Һади Такташ. Әсәрләр: өч томда. III том. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1980. – 319 б.

Рүзәл МӨХӘММӘТША (1989) – *шагыйрь һәм прозаик; «Каралама», «Бүре мин» дигән китаплар авторы, М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты. Казанда яши.*

И д е я .
Урам шаулый-шаулый төн уздыра,
Кемнең монда кемдә эше бар,
Һәрбер җылы тунлы кешеләрнең
Җылы бүрке, торыр төше бар...[2]

*Һади урыныннан торып*
*аңа тартыла.*

Һ а д и .
Галя! Синме? Минем йөрәгемне
Кара күмер иткән утлы гөл?
*(Танымыйча.)*
Кичерегез, мин ялгыштым, ахры.

И д е я .
Мин сиңа дошман түгел.[3]

Һ а д и .
Кем соң?

И д е я .
Танып килгән табынучың,
Иҗатыңа синең мин гашыйк.
Күз төште дә, әллә нишләп киттем,
Хәл-әхвәлен, дидем, сорашыйм.
Бер килешме?

Һ а д и .
Сынатмыйбыз әле.
Чигәдә чәч кенә агара...

И д е я .
Әйт соң,
Такташ нигә язмый?
Әллә нәрсә булды аңарга...[4]

Һ а д и .
Бу – тукталу түгел,
Бу – тик болай,
Алга бару өчен тукталу,
Күтәренке тавыш алган чакта
Бераз гына туктап тын алу![5]

Менә артыр көчем йөрәгемдә,
Яшәрермен кайткан үчемнән –
Маңгаема төшкән ерым өчен,
Язылмаган җырым өчен дә!
Анык беләм:
Җиңүләрем алда,
Максатларым – бөек, югары.
Юл читендә хәл алырга туктау,
Бу – тукталу түгел,
Юк әле!

И д е я .
Арыдыңмы?..

Һ а д и .
...Үземә бурыч куям
Пушкиннарны узып китәргә...
Республика миңа әмер итә
Тулы килеш шуны үтәргә!..[6]

И д е я .
Рәхмәт сиңа.

Һ а д и .
Нәрсә өчен, сеңел?

И д е я .
Килгән өчен шушы дөньяга.
*(Елмая.)*
Йөрәкләрдә синең иҗатыңнан
Иң мөкаддәс хисләр уяна.

*Идея Һадины үбеп ала.*

Һ а д и *(канәгать елмаеп)*.
Кыз вакытта бары да матур була,
Кайдан чыга усал хатыннар?[7]

И д е я.
Белеп сөйләшкәндәй сөйләшәсең.

Һ а д и *(моңсу елмаеп)*.
Белеп сөйләшергә хакым бар.

И д е я .
Өлешеңә төштеме берәрсе?

Һ а д и .
Җавап бирә алам тик көлеп:
Үзе усал, үзе болай бер дә...

И д е я *(шигырьне танып, җырлап бетерә)*.
Усал түгел кебек шикелле.[8]

---

[2] Һади Такташ. Әсәрләр. Өч томда. Том I. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1983. – 321 б.
[3] Том I, 1983. – 61 б.
[4] Том I, 1980. – 499 б.
[5] Том I, 1980. – 440 б.
[6] Том I, 1980. – 440 б.
[7] Том I, 1980. – 437 б.
[8] Том I, 1980. – 321 б.

*Көләләр. Һади кулына өреп, җылытып ала.*

Һ а д и .
Ул Мәскәүдә.
Укый.
Мин, ниһаять,
Сәфәр чыктым аның янына.
Ачыклыйсы хисләр калган икән,
Аңлашасы сүзләр тагын да...
Китәм инде! –

Поезд yргып узар
Мәркәз белән мәркәз арасын!
*(Үзалдына.)*
Барысы да искитмәле булыр,
Искитмәле булмый карасын!

И д е я .
Поезд бүген килеп җитмәячәк...

Һ а д и . Андый борчулардан арала.

И д е я .
Әле генә игълан иттеләр бит,
Без сөйләшеп торган арада...

Һ а д и .
Булмас!
Башны түмәр салам – булмас!
Иртәгәгә калу – миңа соң...

*Һади, мөгаен, поезд расписаниесен ачыклар өчен, ашыгып чыгып китә.*

И д е я .
Һәрнәрсәнең үз вакыты җитәр,
Күңел канатларың сынмасын!
Поезд килер, иртән, җиденчедә,
Иртән, җиденчедә, килер поезд,
Юлдаш булып көнгә тагын да –
Дөньяларны саф хисләргә күмеп
Ак чәчәкләр яуган чагында,
Ак чәчәкләр яуган чагында.

*Һади үкенечле кыяфәттә кире керә.*

Һ а д и .
Иртә уңмаганнар кич уңамы? *(Колакларын тотып җылыта.)*
Кирәк чакта ничек килсен ул? *(Поезд килгән якка ишарәли.)*

И д е я *(икенче якка күрсәтә)*.
Залга үтәсеңме?

Һ а д и .
Өйгә кайтып,
Бу салкыннан качам. *(Китешли.)*
Хуш, сылу!

*Һади китә.*

И д е я .
Арыгансың...
Ашыкмыйча гына
Кайт үзеңә, таныш өйгә кер.
Уңны-сулны аңлап алыр өчен
Бераз минем ярдәм кирәгер...
Шагыйрь, шагыйрь!
Киләчәгең кинәт
Үткәннәргә табан борылыр...
– Харап иттең! – диярсең, тетрәнеп.
Ә мин коткаручың булырмын.

*Идея китә.*

**2**

*Фатир. Гадәти буйдак бүлмәсе. А д ю к нидер яза. Һ а д и керә. Танымыйча, тирә-юньне күзәтә. Барысы да шул ук югыйсә. Ләкин нәрсәдер үзгә сыман. Чор башка! Бу – 1924 нче ел, мөгаен.*

Һ а д и *(үзалдына)*. Сагыныр кешем – ерак. Шунда оча уйлар, йөрәк ярсуларын басалмыйм. Вәгъдәсез кыз, хатың кыска синең, җылы сүзләрең дә күренми...

...Кисеп таратма син өчлек гомерне... *(Башы авыртып куйгандай, чигәсенә җиңелчә орына. Әсәр азагына таба без аның баш авыртуына түзә алмас хәлгә җиткәнен күрергә тиешбез.)*

...Кара... вәгъдәсезлек итмә, төзәл, хәтереңдә тот биргән сүзеңне! Күбрәк аша, йокла, матур төшләр керсен

йокыңа! *(Дәшми тора. Җылыга тиенеп ләззәтләнә.)*

Бүлмә сине югалтуга моңсу хәзер[9]... *(Адюк янына килә. Адюкка.)*

Мин ялгышып кердемме бирегә,
Әллә синме? *(Сагышлы елмая.)*
Кайсыбыз явыз?

А д ю к *(кем икәнен күрмичә, рухланып урыныннан тора).*

Кара әле, яңа әсәр яздым! *(Һадины күреп өнсез кала.)*

Беребезгә беребез нинди
охшаганбыз...[10]

Һ а д и *(аңа карап тора).*
Нинди охшаганбыз.
Ничек охшаганбыз...
Бертуганнар дисәң,
Мин Тамбовтан, ә син...[11]

А д ю к *(кул суза.)*

Ә мин Такташ. Синең якташың. *(Күрешәләр.)*

Һ а д и *(уйга кала).*
Нәрсә дисең? Кем син? Такташмы?

А д ю к *(аны ишетмичә, кәгазьдән шигырь укый).*

Ике тормыш.
Берсе болай җырлый:
Кул сузып күзләрне тектек,
Әй, иляһи, алдыңа,
Рәхмәтең салган өчен,
Мең-мең шөкер сиңа.

Һ а д и .
Мөмкин түгел...
Бу хәл мөмкин түгел...

А д ю к .
Икенчесе:
Без черек йөкләрне өстән ташлыйбыз
(Кайгылар безне үлемдәй каплаган),
Ишетәсезме?
Без яңа юл башлыйбыз
Мәңге утларга, кояшларга табан![12]

Һ а д и .
Мөмкин түгел...
Мөмкин түгел кебек:
Мин таныдым сине,
Зәңгәр күзле уйчан яшь егет[13].
*(Паузадан соң такмаклый.)*

Дыр-дыр-дырабан,
Мокамай йомырка урлаган...

*Һади такмак әйтә башлауга*
*Адюк гаҗәпкә кала.*

Әйшә тәтәй тоткан...

А д ю к .
Караулны кычкырткан.[14] *(Пауза.)*
Бу – минем беренче чирканчык,
Беренче шигырем ләбаса.

Һ а д и .
Син барысын шунда ук аңларсың,
Йөземә тутырып карасаң.

А д ю к *(карый, өнсез кала).*
Мин көзгегә карап торам гүя,
Һәм танымыйм: чынлап, үземме?
Нәрсә булды сиңа, киләчәгем,
Җетелеге уңган күзеңнең?

Яшәгәндә һаман биеккәрәк,
Югарырак табан талпынып,
Нинди хәсрәт уты купты кинәт,
Чәчләреңне өтте ялкыны?

Килә иде синең хозурыңа
Атлап түгел, очып барасым,
Нәрсә булды сиңа, киләчәгем,
Ник шулкадәр моңлы карашың?

Онытылып карап торган саен
Һич танымыйм, чынлап, үземне.
Килбәтлерәк чагым, дип юанам,
Капма-каршысында көзгенең.

Һ а д и .
Бераз гына баш авыртып тора...
Ә калганы – түзсәң түзәрлек.

---

[9] Том III, 1983. – 317 б.
[10] Том I, 1980. – 289 б.
[11] Том I, 1980. – 289 б.
[12] Том I, 1980. – 469 б.
[13] Том I, 1980. – 168 б.
[14] Том III, 1983. – 33 б.

Адюк.
Минме соң бу?

Һади.
Әлбәттә, юк, синең
Адюк чагың гына, диярлек,
Адюк, сабый Адюк!

Адюк.
Синең белән
Шомлы халәт керде ияреп...

Һади.
Ничәнче ел монда?

Адюк.
Егерме дүрт.

Һади.
Ә мин – утыз бердән, өлкән бик...
Үзгәртәсең килсә киләчәкне,
Бөтен гомрең алда икән бит.

Адюк.
Нихәл анда әткәй, әнкәй ничек,
Туганнарым ничек?

Һади.
Исән-сау.

Адюк.
Ил-көн нишли?

Һади.
Дан иптәш Сталинга! *(Адюкның караламасын карый.)*

Адюк.
Артык сорау бирмим алайса.

Һади.
Ярый кебек. *(Каләм алып, кәгазьгә сыза-яза.)*
Иляһларын гына
Сызып ташла, җиргә төш, Адюк!
Гадиләрнең йөрәк җырын җырла!

Адюк.
Син тамырга үтмә алай ук:
Мин мәңгелек уйлар белән янам,
Бөек проблемалар үз миңа!

Һади.
Син заманнан киңрәк булалмыйсың,
Киңрәк булсаң,
Кирәк булалмыйсың заманга. *(Кәгазен бирә.)*

Адюк *(кәгазьне ала, карый, канәгать рәвештә баш селки).*
Ничек кенә килеп чыктың шулай?

Һади.
Белмим, Адюк.

Адюк. Гаҗәп хәл, чыннан.

Һади.
Таңга кадәр сыендыр бүлмәңдә,
Шуннан ары сине борчымам.

**3**

*Шул ук бүлмә. Һади, Адюк. Галя кыяфәтендә Идея керә.*

Идея *(керешкә Адюкка ташлана).*
Алар –
Кызлар –
Миңа ышанмыйлар!
Чәчләребез чәчкә бәйләнсен,
Хатыным бул, дип ялварды, дидем.
*(Иптәш кызларын мыскыллагандай.)*
Ул танылган шагыйрь, янәсе,
Аның тирәсендә чибәр-чибәр
Актрисалар йөри биешеп!
Андый кеше кәләш күрер өчен
Син кем, диләр? –
Рабфак чебеше...

Һади *(нишләргә белми).*
Галя? Синме? Төнге саташуның
Иң ләззәтле, татлы газабы?

*Һади Идеяне кочакламакчы була. Идея Адюк артына кача.*

Идея *(Адюкка).*
Кем бу, җанаш?

Адюк.
Чыбык очы туган...

Идея *(куркып).*
Акылыннан әллә язамы?

Һади *(Идеягә).*
Киләчәктә эзли идем, юкса,
Ә син үткәнемдә калгансың.

Моннан ары сине сагынып шыткан
Сыңар яшем җиргә таммасын!

И д е я *(Адюкка)*.
Мин аңардан куркам...

А д ю к *(Һадига)*.
Син, агайне,
Әтәчләнмә, күкрәк калкытып.
Тормыш иптәшең түгел ич әле,
Күзем төшкән сылу вакыты...
*(Идеягә.)*
Өйләнергә теләвемә, димәк,
Ышанмыйлар?

И д е я .
Күрмәгән килеш,
Ышанмыйлар, әйе, тәкъдимеңне
Минем белән барып, син аларга
Кабатларга тиеш.

Һ а д и *(Адюкка)*.
Сабыйлык бу.
Шушы адымыңнан
Инкыйразың синең башланыр.

*Адюк Идеяне алып китәргә җыена.*

А д ю к *(Һадига)*.
Бу турыда иркенләбрәк, бәлки,
Сөйләшербез әле башка бер.

Һ а д и *(Адюкны туктатмакчы)*.
Күрмәде ул минем күкрәгемдә
Бөек җырлар таңы атканын,
Сизмәде ул күңелем сахрасында
Арысланнар йоклап ятканын![15]
*(Адюкка.)*
Аңа тапшырасы йөрәгеңне
Эткә ташла –
Изге эш булыр!

И д е я *(Адюкка)*.
Тормышыңны җимерергә тели –
Туганлыгы аның шушымы?

Һ а д и (*Идеягә ташлана)*.
Син минеке инде! Ник аңарга
Ирдә булуыңны ачмыйсың?

*Идея куркып, янә Адюкка сыена.*

И д е я .
Нахак! Ялган!

*Һади янә Идеягә ябырыла.*
*Адюк Һадины Идеядән аерганда төртеп ега.*

А д ю к *(ачулы)*.
Баш миеңне өткән
Үз-үзеңнән көнләү ачысы!

*Һади егылган урынында башын тотып ята.*

И д е я *(Адюкка)*.
Кем булса да, китсен, югалсын!

А д ю к .
Ул аңлар ялгышын, уйланыр.

И д е я .
Кайсыбыз якынрак җаныңа –
Йә мине ку моннан, йә аны.

А д ю к .
Бу нинди мәгънәсез таләпләр? –
Ул миңа үз кеше, җәллимен.

И д е я .
Өстисе сүзем юк, кабатлыйм:
Йә аны сайлыйсың, йә мине.

Һ а д и *(тора, Идеягә)*.
Күзләреңдә иблис уты яна,
Ал иренең – оҗмах җимеше,
Күпме алдап, барыбер алданмадым –
Синнән, имеш, айнып килешем.

Син дөньямны тар-мар иткән көннән
Буш күңелдә тузан очына...
Баш очымнан кояш, алма сыман,
Өзелеп төште синең учыңа.

Мин караңгы чынбарлыкта яшим,
Сыңар тәрәзәсез, ишексез,
Якты төшәр иде – иренеңә
Якын китермәвең һичшиксез.

Күзләреңдә иблис уты яна.
Каршы торыр көчем юк хискә –
Агып төшеп гүзәл сының буйлап,
Итәгеңне үбим югыйсә.

[15] Том I, 1980. – 436 б.

*Һади Идея алдында тезләнә, аңа үреләд.*

Идея *(Адюкка).*
Күрәсеңме, нишли, күрәсеңме,
Җан авазын минем тыңла син!

Адюк.
Артып китте.
Чама хисен җуйдың.
*(Һадиның чемоданын алдына китереп куя.)*
Тормышымда эзең булмасын.

*Китәләр. Бераздан Һади тора. Әрле-бирле йөренә. Ачуланып, чемоданына китереп тибә. Эчендәге китап-кәгазьләр, журналлар, газеталар идәнгә сибелә.*

*Һади арадагы хатларның берсен ала.*

Һади *(укый).* Язлар килер. Бергә булалмабыз...

...Утын алдым. Ләкин күпкә җитмәс. Акча алып булмый. Аз алдым. Бер олау ул хәзер безнең өчен – бер атнага, Казан салкын. Утыз-утыз биштән төшми салкынлык. Ә мин туңмый йөрим. Өйрәндем дә инде салкынга.

Хат яз, көтәм. Тиз яз, озын булсын хатың![16]

...Үбәм сине!

*Һади хатны ташлап чыгып китәргә җыена. Аның хәле тагын да мөшкелләнгән.*

**4**

*Ул диварны, ишек турысын капшый. Чыгу юлын таба алмый йөренә.*

Һади.
Кая китим?
Ничек чыгыйм моннан?
Язмыш белән ничек ярышыйм? –
Мин бу чорга ялгыш килеп чыктым,
Киләчәккә үтеп барышлый.

Күпме йөртеп,
Яңа көн каршында
Элмәкләнеп калгач юлларым,
Мондагы бар кичерешем минем –
Баш авырту булды нибары.

*Ачылган чемодан эченнән барлык әсбапларны – китапларны, хатларны һ.б. – бүлмә буйлап тарата.*

Зурмыни соң дәгъвам? –
Күнәр идем –
Янартаудай дәррәү уянып,
Җанга ташкан кайнар сөюемә
Ихтыяҗы булса дөньяның.

Әмма җирне җырга күмгән чакта
Чыраема көннәр кан орды...
Әрнү тулы мәхәббәтем итеп
Бар галәмгә
Нәләт яудырдым!

Нәләт!
Нәләт!

*Башын кысып-кысып торткан килеш сыгылып төшә. Бүлмәне Гавам баса. Тәртипсез рәвештә бию башлана. Гавам Һадины бер тарткалый, бер кыса, бер күтәреп күккә чөя.*

Гавам.
Тормышны күзли
Тешләрен кысып,
Заман даһие,
Чорның намусы,
Җырлаган саен
Йөрәген тегә,
Такташ – мәңгегә,
Такташ – мәңгегә!

Миллионнарның
Күкрәк тавышы
Аңардан үткән
Җырда кавышыр:

[16] Том III, 1983. – 318 б.

Урман кисәбез,
Корыч коябыз,
Гөлбакча булыр
Корган оябыз!

Алланың дымлы
Керфеген өтеп,
Домна мичләре
Чыгара төтен! –
Басылсын гына
Бераз корымы,
Хәрабәләрдә
Җәннәт корылыр!

Искесен таптап,
Яңа чор килә,
Яңа сүз кирәк,
Яңа җыр кирәк!

Йодрыгы – йомры,
Каерып суксын
Заман даһие,
Чорның намусы! –
Җырлаган саен
Терелә үлеп, –
Такташ – мәңгелек,
Такташ – мәңгелек!

*Читкә китәләр.*
*Дөнья тынып кала.*

Һ а д и *(аларга).*
Нәләт!
Нәләт! *(Пауза.)*

Табут сыман кысып куйды дөнья –
Асты өстә! –
Көчкә үзләштем:
Баш очымда зыр әйләнде идән,
Һәм түшәмгә тамды күз яшем.

Тиле хисләр, авызлыгын җуеп,
Мин генәме юкка җилкенгән? –
Ил күзендә җылы сүнгән чакта
Салкын җырлар тансык ил-көнгә.

Г а в а м .
Искесен таптап,
Яңа чор килә,
Яңа сүз кирәк,
Яңа җыр кирәк!

Йодрыгы – йомры,
Каерып суксын
Заман даһие,
Чорның намусы! –
Җырлаган саен
Йөрәген тегә,
Такташ – мәңгегә,
Такташ – мәңгегә!

Һ а д и .
Тиле хисләр, авызлыгын җуеп,
Көтмәгәндә туфан кубарыр!..
Мондагы бар яшәешем минем
Баш авырту гына нибары.

*Гавам арасыннан Идея (Галя) чыгып, Һади әйләнәсендә бии.*

Шул сырхаудан мәңгелеккә арынып,
Җиңел атлап киткән бер көнне,
Тол хатынга охшап калыр дөнья,
Бушап калыр –
Табут шикелле...

Меңәр йөрәк куырылып куяр,
Әллә аңлап,
Әллә аңышмый:
Мин бу чорга ялгыш килеп чыктым,
Киләчәккә үтеп барышлый.

Г а в а м .
Искесен таптап,
Яңа чор килә,
Яңа сүз кирәк,
Яңа җыр кирәк!

Тормышны кузли
Тешләрен кысып
Заман даһие,
Чорның намусы! –
Җырлаган саен
Терелә үлеп, –
Такташ – мәңгелек,
Такташ – мәңгелек!

*Гавам тарала.*

Һ а д и *(игътибарын Идеягә күчерә, алар җиңелчә бии)*. Көрәшемдә, ялгыз минутларымда син генә мине аңлыйсың дигән уй юата. Тик ул уй да, тоты-

ныр әйбер, юатыр хисләр булмаганнан гына. Мин – революция художнигы.

...Минем рәсемемне миллионнар үзләре тудырды.[17]

*Һади бу биюдән тәмам*
*әлсери һәм, ниһаять,*
*аяктан язып егыла.*

**5**

*Идея Һадиның чемоданыннан коелган хатларны карый, китапларны, журналларны кулга ала. Һади аңа үрелә. Идея аның башыннан, иягеннән сыйпый, Һадины котырткандай итә, уйный.*

И д е я .
Кеше, кеше!
Ялгышучан уйлар,
Ышанучан хисләр төрмәсе.
Мин мәхәббәт булып килгән чакта
Хыянәтем барын белмәссең.

Карышмассың,
Фаҗигаңне күреп,
Җитте, диеп, чыгам уеннан! –
Мин бәхеткә охшармын шулкадәр,
Мин һәлакәт булып тоелмам.

Кеше, кеше!
Күз алдыңда, уйнап,
Чалымнарны чалым алышыр.
Мең мәртәбә танырсың син мине,
Һәм меңе дә булыр ялгышу.

*Һади аңын җуя.*

Фаш итәрсең,
Бушар вакыт җиткәч
Җирдә биләп торган урының.
– Син бит үлем! – диярсең, тетрәнеп...
Мин мәңгелек яшәү булырмын.

*Ул сүзен тәмамлауга бер кулына чемодан, бер кулына салам кәрҗин тоткан Адюк килеп керә.*

А д ю к .
Урнаштыңмы инде? *(Идеянең актарынганын күреп.)*
Ни эшлисең?

И д е я *(хәйләкәр)*.
Ул таратып ташлап дөньясын,
Киткән, ахры.

А д ю к .
Кагылма, барыбер!

И д е я .
Син дә караш ташлый аласың,
Кызык хәлләр монда...
Җыентыклар,
Хатлар, журналдагы хәбәрләр,
Җанын урталайга ярып кына,
Бөтен серен ачып бирәләр,
Кем ул?

А д ю к .
Чыбык очы туган миңа...

И д е я .
Күрәләтә ялган сөйләмә,
Ул – син үзең!

А д ю к .
Юк, ул – киләчәктә
Тоныклана төшкән күләгәм.

*Идея хатларны Адюкка күрсәтә.*

И д е я .
Кара, нинди садә хатлар язган.
*(Адюкны дикъкать белән күзәтә.)*
Ә гел үзгә читтән карасаң.
Нинди эпитетлар, күз яшьләре...
*(Хатларны Адюкка сона.)*

А д ю к .
Ул мин түгел, дидем ләбаса!

И д е я *(журнал ала, укый)*.
«Кутуй кебек пычрак
хамелеоннар»![18] –
Дустын шулай диеп кем атар?

А д ю к *(журналны ала)*.
Миннән андый сүзләр чыга алмый,

[17] Том III, 1983. – 329 б.
[18] Һади Такташ. С.Баттал иптәшнең ТАППка язган шигырь-хатына җавап. – Атака ж., – 1930. – № 4 – 5. – 19 б.

Бу – коточкыч ялгыш,
Бу – хата! *(Журналны ала, укый.)*
«Кутуй кебек пычрак хамелеоннар»...
*(Идеягә текәлә.)*
Бу – минем эш түгел, алай да...

И д е я .
Ни көтәсең инде синең кебек
Казлар кыйнап үскән малайдан?
*(Идәндә аунаган башка
китап-кәгазьләрне карый.)*
Монда гаҗәп хәлләр шактый әле...

А д ю к .
Мин һәрвакыт гадел яшәдем!

И д е я *(бер җыентык алып, Адюкка күрсәтә).*
Ул баш тарткан тәүге иҗатыннан,
Ул баш тарткан синнән,
Яшь әдип!

А д ю к *(җыентыкны ала, актара).*
Ул – мин түгел...
Йөрәгемдә нинди
Утлар дөрләгәнен аңласаң!

*Авырлык белән генә Һади тора.
Башын тота.*

Һ а д и .
Киләчәкне үзгә итәр өчен
Бөтен гомрең алда лабаса.

*Адюк белән Идея Һадига текәлә.
Идея астыртын елмая.*

**6**

*Адюк белән Идея Һадига төрле яктан гаеп-дәгъва ташлый.
Гаепләрнең, асылда, бер-берсенә каршы булуы музыкада да
чагылырга тиеш.*

А д ю к .
Яңа властька сатылганга күрә
Шундый каршылыклар хас сиңа!

И д е я .
Эшче-крестьян шагыйре түгел син,
Вак буржуаз шагыйрь, асылда!

*Һади әкренләп уртада кала. Идея
белән Адюк артка чигенеп, аның ике
ягына басалар. Вакыйга әдәби суд
утырышын хәтерләтә башлый.*

А д ю к .
Арзанайган синең шигъри сүзең!

И д е я .
Син тоймыйсың чорның яңасын!

А д ю к .
Гадиләшеп,
Урам көен көйләп,
Такмак язар көнгә калгансың!
*(Идеягә.)*
Ул данлаган көнлек җиңүләрне,
Бөек гамьнәр барын онытып!

И д е я .
Мыскыллаган совет чынбарлыгын!

А д ю к .
Кояш дигән совет болытын!

*Идея Һадиның җыентыкларын
алып күрсәтә.*

И д е я *(Һадига).*
Хөкем сиңа! Син правый эсерлар,
Меньшевиклар зарын язгансың!

А д ю к .
Кызылавыз булган өчен – статья
Һәм әдәби үлем җәзасы!

И д е я .
Соңгы сүзең әйтеп кал, теләсәң!

А д ю к .
Мондый форсат булмас аннары.

И д е я .
Яшьлегеңнең һәм мәхәббәтеңнең
Яңгырагач хөкем карары.

*Тынлык. Һади дәшми тора.
Аннары шигырь
итеп (музыкасыз!)
«Җир уллары трагедиясе»ннән
Кабил сүзләрен укый.*

Һ а д и .
Сөеклем!
Мин йоклый алмыйм,
Төн йокымнан уйганам, –
Уйганам да, нәкъ юләр-шашкан кеше,
Кан елыйм, беркем дә белми, –
Мин тәмугларда янам!
Куркыныч, һәр як караңгы,
Ниндидер өннәр килә
Дә, улап, төннәр буенча
Як-ягымда иштелә...
Гүя миңа бар ләгыйнь көчләр
Ерактан кулларын
Өстемә төртеп сузалар да
Укыйлар кычкырып
Язмышымның мәлганәтле,
Куркынычлы юлларын...
Укыйлар... – ишетеп торам мин –
Бар бөтен рухлар: тагын
Иштелә көлгән тавышлар;
Шунда чорнап дүрт ягым,
Газраиллар кулларымнан
Әллә кайда тарталар...
*(Шушы урыннан җырлауга күчә.)*

Тарталар...
Коткар, сөеклем!
Зур тәмугларга алар...[19]

*Идеягә сыенмакчы була.*

А д ю к .
Син – мин түгел, Такташ,
кит яныннан!

Һ а д и .
Нәрсә булыр, юкса?
А д ю к .
Күрерсең...

*Һади Идеяне үбеп ала.*

Бу эшеңә шаһит булган йортта
Инде артык каның түгелсен!

*Адюк Һади өстенә ташлана.*
*Шулвакыт Һади кулындагы*
*таягы белән селтәнеп,*
*Адюкның чигәсенә суга.*
*Адюк егыла.*

И д е я .
Син шашкансың. Син акылда түгел!

*Идея дулкынлана,*
*каушый.*

Һ а д и .
Ялгыз итмә мине, җан ярам!
И д е я .
Син үтердең аны, үтердең бит!

*Идеяне кочакларга үрелә. Идея*
*аннан читкә тартыла.*

Һ а д и .
Ялгыз итмә, зинһар, ялварам!
И д е я *(һушы киткәндәй)*.
Бу – чынбарлык түгел, бу – саташу,
Бу – авыру килеш төшләнү,
Китәм, китәм!

*Идея фатирдан*
*чыгып югала.*

Һ а д и .
Тукта! *(Үзалдына)*. Нишләдем мин?

*Адюкның мәете өстенә иелә.*
*Шыңшый.*

Нәрсә булды миңа? Нишләдем?
Ап-ак хисем ничек алсу таңда
Кап-кара кан булып түгелде?
*(Идеядән соң ишекнең*
*ачык калганын күрә.)*
Ишек ачык...
Вакыт күпме икән?
*(Сәгатенә карый.)*
Алты тулып килә түгелме?

*Урыныннан кузгала. Шикләнеп*
*кенә ишек янына килә.*
*Икеләнеп басып тора.*
*Аннары чыгып китә.*

[19] Том I, 1980.– 66 б.

**7**

*Вокзал. Перрон. Иртә. Узып китә торган поезд тавышлары. Әледән-әле диктор нидер игълан итә. Перрондагы эскәмиядә Һади утыра. Кулындагы таягы белән әле анда, әле монда суккалап уйный. Ул һаман туңа, билгеле. Ләкин... әллә күнеккән инде салкынга...*

Һади *(үзалдына)*. Минем хыялымда яшәгән Галя – ул усал түгел. Ул мин теләгән минутларда мине ярата. Чәчләремнән сөя. Ул хрусталь кебек саф. Тормыштагы Галя кебек юк нәрсәләр өчен ачуланмый да, тиргәми дә. Ташлап та китми. Һаман минем хыялымда елмая. Матур, хыянәтсез, йөрәкне дулкынлатып елмая ул.

...Ул Галя бары минеке генә, аны беркем дә күрми дә, беркем дә белми дә. Үлгәндә дә, ул минем белән үләчәк...

*Сәхнәгә пассажир кыяфәтендә Идея чыга.*

Идея *(җырлый)*.
Син утырткан ятим каеннарга
Күз яшьләрдән сулар сибәмен,
Таң алдында каен яфракларын
Җылы йөзең итеп үбәмен.[20]

*Һади Идеянең җырына колак сала. Кар ява. Һади карашын күккә төби. Идея белән Һади, бер-берсеннән аерым рәвештә, һәрберсе үзенең җырын башкара.*

Һади.
Ак чәчәкләр ява.
Дөнья матур,
Шундый матур булып тоела;
Күге зәңгәр, гүя йолдызлары
Ак кар булып җиргә коела...[21]

Идея.
Каеннарга сөйлим моңнарымны,
Аңлаган күк тып-тын торалар.
Синең кулың итеп ботакларын
Гүя миңа сузган булалар.[22]

*Һади Идеянең җырын игътибар белән тыңлый. Дулкынлана. Идеягә якынлаша.*

Һади.
Нинди җыр бу, үзәкләрне өзгеч
Моң тулы да үзе, шом тулы?

Идея.
Поезд якынлаша, ишетәсеңме?
Якынлаша, димәк, котылу.

*Пауза. Идея тимер юлга чыгып баса.*

Һади.
Ак чәчәкләр ява.
Дөнья матур,
Шундый матур булып тоела;
Күге зәңгәр, гүя йолдызлары
Ак кар булып җиргә коела...

Идея.
Сиңа монда һичбер нәрсә дә юк,
Һәм калмады ары бер эш тә...

Һади.
Ак чәчәкләр ява.
Дөнья матур... *(Җырын бүлә.)*
Мин таныдым сине, фәрештә.

Идея.
Якынлаша инде, ишетәсеңме?
Соңгы адымыңа кичекмә!
Яныма кил, инде бу поездга
Эләгәсе иде ничек тә...

Һади.
Ак чәчәкләр ява.
Дөнья матур,
Шундый матур булып тоела;

---

[20] Һади Такташ турында истәлекләр. Төзүчеләре Н.Юзиев, Н.Садыйкова. Казан: Татар.кит.нәшр., 1980. – 254 б.
[21] Том I, 1980. – 344 б.
[22] Истәлекләр, 1980. – 254 б.

Күге зәңгәр, гүя йолдызлары
Ак кар булып җиргә коела...

И д е я .
Таң җилләре, каен башын сыйпап,
Әкрен генә һаман исәрме?
Син үлгәчтен шаулап үскән каен
Мин үлгәчтен шулай үсәрме?..[23]

*Һади Идеянең бу җырын тыңлаганда әллә нишли. Дулкынлана. Каушый. Тынгысызлана.*

Һ а д и .
Күңелләрне тетрәндерер моңлы
Нинди җыр бу, әйтче, шулай да?

И д е я .
Шашкан ана иҗат итәр аны,
Озакламый, хәсрәтендә янып –
Газиз улын җуйган уңайдан.

*Еракта поезд гудогы ишетелеп ала.*

Һ а д и .
Минем әни – җырчы, бу турыда
Үзе генә белми бөтенләй.

И д е я .
Син бу җырны яздырырга тиеш! –
Калган эшең бетте бу төндә...

*Һади перрон читенә килеп утыра.*

Һ а д и .
Әллә нинди халәт...
Беләсеңме,
Мин шул тәмам тиле икәнмен,
Тау күчерер иҗат гомеремне
Юк бәягә харап иткәнмен.
*(Таягын тотып ата.)*

И д е я .
Агартырга теләп караны
Чигәләрең генә агарды...

Һ а д и .
Мин ышандым ныграк сөйгән саен
Басылыр, дип тормыш басымы...

*Һади тимер юлга төшеп Идеяне кулларыннан ала.*
*Алар җиңелчә бию хәрәкәтләре ясый.*

Ну и к чёрту,
Төптән үк уйласаң,
Бу бит башы гына барсының,
Үлем – башы гына барсының!

*Алар биегән чакта якынлашып килгән поездның тавышы көчәя. Гудок бирә. Тәгәрмәчләрнең сызгырып тимер юлны кыруы ишетелә. Шулвакыт арткы фонда (экранда) язу чыга: «Күренекле шагыйрь Һади Такташ 1931 елның 8 декабрендә иртәнге 6 сәгать 30 минутта, авыр газаплар кичереп, тимгелле тиф чиреннән вафат була».*

**Эпилог**

*Озакламый поезд тавышы алкышлар белән алышына. Арткы фонда (экранда) Һади Такташка Казанда һәйкәл ачу күренеше барлыкка килә. Чәчәкләр, алкышлар... Халык мәш килә: күрешә, кочаклаша, фотога төшә. Кинәт камера төркем эчендәге бер хатын-кызда туктала. Без аның Идея булуын таныйбыз. Ул безгә күз кыса.*

**Редакциядән:**

*Май аенда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтте. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

[23] Истәлекләр, 1980. – 254 б.

Ринат
Мөхәммәдиев

# АК КӘГАЗЬ НИДӘН САРГАЯ...

РОМАН

## ӨЧЕНЧЕ ТАРИХ

### 1

1930 нчы елның җәендә Казандагы Көнчыгыш педагогия институтына Ленинградтан, исеме һәм гыйльми хезмәтләре татар зыялылары даирәсендә шактыйдан ук билгеле галим кайтып төшә. Ленинградның Көнчыгыш институтын тәмамлаган, академик А.Самойлович җитәкчелегендә аспирантурада укыган. Күренекле тел белгече, академик Н.Я.Маррның хәерфатихасы белән җибәрелгән ул Казанга.

«Нигъмәт Хәким Казанга килгән, Көнчыгыш педагогия институтында укытачак икән...» дигән хәбәр тиз арада таралып өлгерә. Татар зыялылары арасында аның белән күрешергә, танышырга теләүчеләрнең исәбе-хисабы юк. Тик менә үзе генә артык тыйнаклыктанмы, бер дә кеше-кара күзенә чалынып йөрүне мәгъкуль күрми. Кайда урнашып, кайда яшәгәнлеген дә белүче юк, галим-голамә һәм язучы халкы белән дә элемтәдә тормый, шау-шу һәм ыгы-зыгылы тамаша һәм очрашуларга, гомумән, йөрми. Уртачадан бераз калку гәүдәле, чандыр йөзле бу ир уртасының институтка килгәнен һәм киткәнен күрсә дә, шул бик сирәк кеше күргәндер. Көннәр-төннәр буе ниләрдер эзләнә, яңа гыйльми хезмәтләр өстендә эшли икән... Дөрес булса, ул татар, рус, гарәп, фарсы, төрек һәм үзбәк телләрен су кебек эчү белән генә чикләнмичә, тагы утызбиш-кырык чамасы саналган төрки телләрнең барысында да иркен сөйләшә һәм аңлаша да белгән бердәнбер галим булып чыга. Ә татар, рус һәм үзбәк телләрендә дөнья күргән хезмәтләрен саный китсәң, санап бетерерлек түгел. «Борынгы Көнчыгыш коммунизмы», «Ислам диненең килеп чыгышы», «Дөньяның яралышы», «Исламда һәм Советлар илендә хатын-кыз хокуклары», «Ураза һәм аңарга гыйльми күзлектән караш», «Күңел музыкасы» – һәркайсы җитди эзләнүләр нәтиҗәсендә туган, колачлыйм дисәң, колачка сыймас олы хезмәт. Шуның белән генә бетсә икән, аның татар, үзбәк һәм төрек телләренең формалашу тарихы, орфографиясе һәм грамматикасына багышланган хезмәтләре ил күләмендә танылган һәм югары бәя алган.

Ә инде «Идегәй» дастаны – үзе бер дөнья... Нигъмәт Хәкимнең «Идегәй» дастанын халыкка кире кайтару юлында эзләнүләре байтак еллар дәвамына, бер

*Ахыры. Башы узган санда.*

легенда сыман телдән телгә күчеп йөри. Бу дастан хакында күпләр ишетеп белә, әмма аның тулы вариантын шушы көнгәчә һичкемнең күргәне дә, укыганы да юк. Татарның героик тарихын чагылдырган бәяләп бетергесез бу әдәби җәүһәр әле дә китап булып басылмаган, төрле төбәкләрдә үзгә вариантларда халык авыз иҗаты үрнәге буларак яшәвен дәвам итә. Күпме галим-голамәсе, бай тарихы булган әдәбият һәм мәдәниятне һич кенә дә бизәми торган күренеш. Нигъмәт Хәкимгә тынгылык бирмәгән, берөзлексез аның җанын әрнетеп торган хакыйкать иде бу. «Идегәй» дөнья күрми торып, бу әдәби җәүһәр халыкның үзенә әйләнеп кайтмый торып, тынычланачак түгел ул. Нигъмәт татарлар яшәгән бик күп төбәкләрдә йөреп, ерак Себер тарафларында, тайга эчендә урнашкан татар авылларына барып, бу мәдәни җәүһәребезнең дистәләгән вариантларын туплады. «Идегәй»нең кулъязма дәфтәрләрдә сакланган һәм өлкән яшьтәге әби-бабайлардан сөйләтеп, язып алынган дистәдән артык нөсхәләрен җыйды. Дәверләр дәвамына һичкемнең кулы һәм буе җитә алмаган зур хезмәт көтә татар дөньясын. Нигъмәт Хәкимнең якын араларда «Идегәй»не татар һәм рус телләрендә аерым китап буларак бастыру хыялы белән янып яшәгән көннәре. Казанга ашкынып кайтуының беренче һәм төп сәбәбе дә шуннан гыйбарәт иде бит...

Институтта үзен шактый ук рәсми, коры каршыладылар. Хуҗалык эшләре өчен җаваплы юан гына бер ханым аңарга кабинет һәм аның ерак почмагында урнашкан эш урынын, ягъни өстәлен күрсәтте. Укылачак лекцияләрнең тәртибе белән коридорда танышырга киңәш итте. Һәм шуның белән вәссәлам, китеп тә барды. Бер ялгызы зур, әмма салкынча һәм беркадәр шыксыз, караңгы да тоелган бүлмә уртасында басып калды Нигъмәт. Ул утырырга тиешле өстәл буп-буш, күзне җәлеп итәрлек, соң чиктә ник бер ак кәгазь кисәге булсын, шуңадырмы ул тарафка аягы тартмый торды.

Бәхетенә каршы, нәкъ шул мизгелдә ишек ачылды һәм аннан кулына шактый ук таушала төшкән портфель тоткан калку гәүдәле ир-ат килеп керде. Кабинетта кеше барын күрмәдеме, әллә күрмәмешкә салыштымы, ул ипле генә атлап тәрәз каршындагы икенче бер өстәл янына узды. Аның өстәле, киресенчә, китаплар, таудай өелеп яткан кәгазь һәм язу-сызу кирәк-яраклары белән шыплап тулган иде. Өстәл өстеннән күзлеген алып киде ул һәм шунда гына бер читтә дәшми-тынмый башка берәүнең басып торуын абайлады кебек.

– Гафу итегез, – диде, олы ихтирам белән башын ия төшеп. – Урамда якты, кояш, ә монда, кинәт килеп кергәч, караңгы. Күз ияләшеп өлгермәде кебек, күрүем болай да чамалы гына.

Һәм ипле генә атлап, әле булса баскан урынында тораташ кебек кымшанмый торып калган Нигъмәткә таба якынлашты ул. Сәлам биреп кулын сузды.

– Җамалетдин булам.

– Нигъмәт.

– Сез мине көтәсезме, әллә башка бер-бер йомышыгыз бармы? Утырыгыз, түрдән узыгыз, – дип, үзенең өстәле каршындагы кара күн белән тышланган кәнәфидән урын тәкъдим итте Җамалетдин.

Нигъмәт тартынып тормады, ул тәкъдим иткән урынга барып утырды. Күз чите белән аның өстәл читенә тезелгән китапларны барларга кереште. Тукай китаплары, Галимҗан Ибраһимов, Сәгыйть Рәмиев... Һәм шулардан бераз читтәрәк рус телендәге: «Очерк истории образованности татар» китабы. Җамал Вәлидинең бу хезмәте – аның да өстәл китабы ул. Чү... Башыннан бу кеше үзе түгелме соң, дигән уй йөгереп узды. Һәм ул кинәт утырган урыныннан сикереп торырга мәҗбүр булды.

– Инде мине гафу итегез, алай-болай сез Җамал Вәлиди түгелме? – дип сорарга җөрьәт итте.

– Әйе, үзе. Танышканда да үз исемем әйттем булса кирәк.

– Ә мин Нигъмәт Хәким булам.

– Нигъмәт Хәким... – дип, хәйран калып торды Вәлиди. – Без сезне дүрт күзләп көтәбез ич. Менә нинди икән сез. Ленинградның үзеннән кайттыгыз, димәк?

– Әйе, Ленинградтан.

Җамал Вәлиди ихлас куанган иде бу күрешүгә, хәтта кабалана төшеп сорауларын яудыра башлады ул. Ленинградта яшәүче үзе белгән галим-голамәләрне барлап чыкты, аннан танып белгән татар зыялыларын сораштырырга кереште.

Ә Нигъмәт бар белгәнен түкми-чәчми җавап бирде. Уйламаганда-көтмәгәндә килеп чыккан бу очрашуга чиксез бәхетле иде ул да. Әнә ич, кем белән бер кабинетта утырып эшләячәк, кем белән даими сөйләшә, киңәшә алачак. «Бирим дигән колына, чыгарып куяр юлына» дигәннәре шул була торгандыр инде. Җамал Вәлиди татар дөньясында гына түгел, үзенең хезмәтләре белән бөтен илгә мәгълүм шәхес. Аны күренекле тел белгече яисә тәнкыйтьче дип кенә чикләнү мөмкин түгел, Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Галимҗан Ибраһимовлар белән аралашып, сүз көрәштереп, бәхәсләшеп яшәгән һәм иҗат иткән олы абруйга ия галим бит ул. Озак еллар дәвамында халык авыз иҗаты әсәрләрен җыюы да җәмәгатьчелеккә яхшы мәгълүм. Алай гынамы, Оренбургта Риза Фәхретдинов, Дәрдемәнд, Шәриф Камал кебек дистәләгән фикер ияләре, әдипләр белән даими күрешеп, кулга-кул тотынышып милләткә аң һәм гыйлем тараткан күренекле мәгърифәтче...

Шул рәвешле ике олы галим бер институтта, бер бүлмәдә утырып, үзара киңәш-табыш итешеп эшли башладылар. Аларның дуслыгына соклану гына түгел, эчләре пошып һәм көнләшеп караучы хөсет җаннар да булгандыр, әлбәттә. Әмма бу ике шәхес андый ваклыклардан һәрчак югары торды. Үзенең гыйльми хезмәтләре белән бөтен төрки дөньяны колачлап алырга омтылган Нигъмәт Хәким үз эше, үз юлыннан башканы күрмәде һәм, гомумән, абайламады. Лекция арты лекция... Ару-талуның ни икәнлеген ул һич белми, фән һәм гыйлем – аның стихиясе. Студентлар бик тә кызыксынучан, үзләрен кызыксындырган бар сорауга да җавап көтәләр. Гыйльми дәрәҗәләр алып югары уку йортында укытырга алынгансың икән, яшь буынның күңелендә туган сорауларга җавапсыз калу ярамый. Шуның өчен дә бертөзлексез үз өстеңдә эшләргә, укырга, өйрәнергә туры килә. Гыйлем дөньясы «мин күп беләм» диючеләрне яратмый.

Уфада, Златоустта, Ташкентта, Ленинградта һәм тагы күпме шәһәр-авылларда укырга һәм укытырга туры килде аңа. Әмма Казан бөтенләй башка. Татар баласы кайда гына туып, кайда гына яшәмәсен, ул һәрвакыт Казанга омтылып, Казанга кайтырга ашкынып яши. Ниһаять, ул да менә Казанда! Габделнасыйр Курсави, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Хөсәен Фәезханов кебек гыйлем ияләрен дә кайчандыр үзенә әйдәп, тартып торган башкала ич бу. Ә Тукай!.. Тукайны кая куясың?.. «И, Казан, дәртле Казан, нурлы Казан!..» дип ашкынып кайткан монда шагыйрь. Казан урамнары буйлап йөргән чакларында бу юлларны бик еш күңеленнән кичерә һәм кабатлый иде ул соңгы араларда. Татарның күпме асыл затлары менә хәзер, шушы минутларда ул атлап бара торган урамнардан йөргән... Һәм йөриячәк!

Казанга кайтты кайтуын, әмма әле һич ияләнә алганы юк аның бу шәһәргә. Казан, бер карасаң, шундый үз дә, икенче карасаң, әле шактый ук ят та шәһәр

иде аның өчен. Аны монда танучы-белүче бик аз, бөтенләй юк диярлек. Очраганда кул биреп, әллә каян ук колач җәеп каршы килгән иске дуслары да, туган-тумачасы да юк. Гаиләсе дә еракта, Урал-тауның аргы тарафларында калды. Туып-үскән авылында, ямьле Әй елгасы буйларында...

Нигъмәт Хәким институттан көндәгечә шактый ук соңлап, эңгер-меңгер төшкәчтен генә кайтырга чыкты. «Кайтырга» дип әйттем әйтүен дә, ләкин әле җүнле-башлы фатир табып урнаша да алганы юк бит аның, кеше почмагында идәндә йоклап йөргән көне. Шуңадыр, бүген дә ашыгыр җире юк, үз уйларына бирелеп, ипле генә атлавын белә. Болак аша күпердән чыгып университет урамына илтүче калкулыктан күтәрелеп барганда, арка тарафтан килеп берәү аның җилкәсенә кулын салмасынмы!

– Нигъмәт абый, бу син булдың түгелме? – дигән тавышка борылды ул.

Ни күрсен, якташы, күрше авыл егете, элгәре елларда Уфада үзе укыткан шәкерте басып тора икән бит. Ялгызлык хакындагы уй-кичерешләре бер мизгелдә таралды да юкка чыкты.

– Якташ, – дип, көтелмәгән очрашуга хәйран калып, кычкырып җибәрә язды ул. Алар, гомер булмаганны, бер-берсен аркадан кага-кага кочаклап күрештеләр. – Нинди язмыш, нинди йомыш белән килеп чыктың әле бу тарафларга?..

– Шагыйрь кешенең, татар шагыйренең Казанга килеп чыгуы гаҗәп түгелдер, остазым, – дип җавап кайтарды якташы.

– Анысы шулай. Күптән килдеңме?

– Мин килгәндә буранлы һәм салкын кыш иде, инде күрәсез, җәйләр узып көзгә кереп барыш, Нигъмәт абый. Сез миңа шулай дәшкән өчен үпкәләми торгансыздыр ич?

– Юк-юк, син нәрсә, үпкә-сапкага урын юк, без якташлар!– дип, тагы бер мәртәбә бу күрешүгә ихлас куануын белдерде Нигъмәт Хәким.

– Кем белә бит, сез хәзер зур кеше... Ленинградның үзеннән кайткан галим... Бәлки, профессор әфәнде, дип дәшү кирәктер.

– Кирәкми. «Якташ» дип, үзебезчә «абый» дип дәшүгә җитәме соң!

– Мин үзем дә шулай уйлыйм, Нигъмәт абый, – дип аның каршысына ук чыгып басты шагыйрь. Ап-ак тешләрен елтыратып елмаеп җибәрде. – Юкса, бу Казандагы рәсмилектән тәмам гаҗиз булган идем.

– Бәй, нишләп болай урам уртасында басып торабыз соң әле без, – дип, кинәт бер фикергә килеп, тәкъдим кертте Нигъмәт Хәким. – Әйдә, булмаса, бер-бер ашханәгә кереп чәйләп алабыз, иркенләп сөйләшеп утырырбыз, туган якны, Уфа хәлләрен дә искә төшерербез... Вакытың булса, әлбәттә...

Шагыйрь бу тәкъдимне бик теләп кабул итте.

– Нәрсә-нәрсә, әмма вакыт бар инде ул бездә. Тик менә акча яклары гына, – дип, тартынган атлы булды ул. – Ашханәдә дим, чәйне акчасыз эчертмәсләр бит.

– Син нәрсә, якташ, – дип, үз итеп, Нигъмәт җиңелчә генә җилкәсенә кагылып алды аның. – Үзем сыйлыйм. Бер очтан тамак та ялгап алырбыз. Карыным да ачкан чакка туры килдең, минем иртән чәй эчкән көе йөрүем бит әле. Лекция дә лекция, үзебезчә әйтсәк, тын алыр ара да булмады бүген.

Әллә тәкъдимгә куанып, әллә остазының сүзләреннән кызык табып, кеткелдәп көлеп куйды шагыйрь. Сөйләшә-сөйләшә университет урамын кисеп чыгып, Черек күл тарафына үттеләр. Шунда урнашкан бер ашханәгә кереп, аулак почмакка барып утырдылар. Нигъмәт Хәким, сыйлаучы кеше буларак, поднос белән ике тәлинкә борчак ашы, ике стакан чәй һәм икмәк алып килде.

– Рәхәтләнеп бер сыйланыйк әле, якташ, – диде ул, нигъмәтләрне өстәлгә бушатып.

– Рәхмәт, Нигъмәт абый, бәйрәм итәбез инде болай булгач, – дип, уч төпләрен бер-берсенә ышкып, куануында дәвам итте шагыйрь. – Борчак ашының исләре генә дә ни тора бит аның, сезнең янда, гел туган якка кайткандай тоелып китте әле менә.

– Мин дә туган авылны, туган якларны оныта алмыйм, кая гына барып чыксам да, үзебезнең Әй буйларын сагынып яшим...

– Әй буйлары, аның тугайларын оныта торганмы соң, Нигъмәт абый! Минем дә күңелдә бик күп истәлекләр саклана...

– Шунда кайтырга иде дә менә хәзер, елга читендәге яшел чирәм өстеннән, көтү-көтү каз бәбкәләрен куркытып, яланаяк йөгереп китәргә иде бер...

– Шул йөгереп барган көйгә Әйнең җылы суына сикерергә иде, шулай бит, Нигъмәт абый, – дип күтәреп алды шагыйрь. – Учак ягып, яңа тоткан вак балыкларны тал чыбыгына элеп кыздырган чакларыгыз да искә төшә торгандыр әле...

– Төшмиме соң? – дип, пөхтә генә тарап куелган коңгырт-кара чәчләрен артка таба сыпырып куйды галим. – Минем үземә елганың Лачын-таш тавы каршында кинәт борылып киткән урыны аеруча ямьле тоела торган иде. Шундагы әрәмәлектә җиләк, бөрлегән җыйган чакларыбызны һич онытасым юк.

– Әйе, минем дә булганым бар ул урыннарда...

Шагыйрьне гүя ишетмәде галим, хыялында бала чакларына кайтып, Әй буйларында бар дөньясын онытып, йөгереп-уйнап йөри иде бугай ул.

– Җиләк белән савытларыбызны тутыргач та, бергә уйнап үскән малайлар белән йомшак келәм сыман күпереп торган тукранбашлар өстенә хәл алырга сузылып ята торган идек. Карашларыбыз Лачын-таш тавына төбәлгән. Аның мәһабәтлегенә, биеклегенә сокланып туймыйбыз. Шунда арабыздан берәү, күңелен биләп алган хисләренә түзә алмыйча, яткан җиреннән сикереп тора да «Лачын-та-а-аш» дип кычкырып җибәрә. Сулыш алырга да кыймый һәммәбез тынып калабыз, таудан җавап көтәбез. Бераздан таулар артыннан безгә тавышыбызның серле кайтавазы яңгырап ишетелә. «Ничек диде, нәрсә дип җавап бирде тау?» – дип сорап куя шунда арабыздан берәве. «Тау да Лачын т-а-аш» диде түгелме?..» Икенче беребез килешми мондый җавап белән: «Юк, Лачын-таш, димәде. Тау сиңа: «Бетле ба-а-аш» дип җавап бирде», – дип куя. Безгә нәрсә, бер-беребезгә бармак төртә-төртә көлешәбез рәхәтләнеп: «Сиңа әйтте, сиңа әйтте ул «бетле баш» дип. И-их, шул елларны кайтарып алырга иде ул хәзер... Нинди матур еллар булган! Балачак... Балача-а-ак», – дип, янә дә бер мәртәбә сузып кабатлап куйды Нигъмәт Хәким. Күзләре, каядыр, еракка-еракка төбәлгән иде аның бу мизгелдә.

– Матур истәлекләр, – дип җөпләп куйды шагыйрь. Ни сәбәпледер, ерак балачак сәхифәләрен барлаудан ерак иде кебек ул. Шуны раслагандай, борын астыннан гына дигәндәй, мыгырданып алды тагы. – Истәлекләр белән генә яшәп булса икән...

– Истәлекләр күңелгә дәрт, йөрәккә гайрәт өсти, якташым. Сагындыра шул... Әмма шунысы яман – ара ерак, гел-гел кайтып йөреп булмый.

– Анда кайтып ни эшлисең?..

Якташының туган якларына мөнәсәбәтле бу битарафлыгы галимнең күңеленә хуш килмәде, әлбәттә. Әмма аның белән бәхәс кузгатуны да кирәк санамады. Вакыты да, урыны да ул түгел. «Һәркемнең үз язмышы, үз фикере инде» дип уйлап куйды үзалдына. Сүз сөрешен икенчегә борды:

– Синең дә гаилә һәм балаларың әлегә анда калгандыр ич?

– Сез нәрсә, хатынны, балаларны калдырып йөри торган вакытмы?! Шөкер, барысы да монда, үзем белән, – дип җавап кайтарды шагыйрь.

– Ә менә минекеләр авылда. Әлегә иң кадерле кешеләрем – гаиләмнән аерым яшәргә мәҗбүрмен, – дип, көрсенеп куйды галим. Ул гына да түгел, гаепле кеше сыман моңсулана төшеп башын түбән иде ул. – Синең торырга урының бардыр бит?..

– Бер марҗа хатынга фатирга кердек. Зур бүлмәсендә үзе яши, икенчесендә – без.

– Ул яктан син бәхетле икән...

– Зарланмыйм. Марҗасы да ялгыз, хатын да янда, – дип, кызык ясап кеткелдәп көлеп тә алды ул үзалдына.

– Ә менә мин, гаиләмә түгел, үземә дә кулай бер фатир таба алмый йөрим. Хатынга – Бәдринурыма рәхмәт инде, әле дә түзә, дүрт бала белән авылда яши. Аның игелеген, кешелеклеген һичничек һәм һичбервакыт бәяләп бетереп булмас... Авызыннан кара кан китсә дә кеше алдында төкермәс, «миңа авыр, аеры-чөере яшәүдән туйдым» дип әйтәсе кеше түгел. Бәхетемә туган фәрештәм ул минем...

– Хатын-кызны ул кадәрле мактау ярамас, остазым, артыгын очындырып куюыгыз бар.

– Бәдринур очына торганнардан түгел, – дип кистереп әйтте Нигъмәт. Борчак ашы чөмерү белән мәшгуль якташы дәшмәгәч, үзе сорау бирергә булды. – Мин бит синең гаиләне белмим, якташ, кемгә, кем кызына өйләндең диимме?

– Ишетмәдеңме, минем өйләнү бик тавышлы, имеш-мимешләргә бай булды бит ул, – диде шагыйрь башын аш тәлинкәсе өстеннән күтәрә төшеп.

– Тукта-тукта, бу тарих минем дә колакка чалынган иде кебек... Бик күпләребезнең остазы булган хәзрәтнең яшь хатынын, үз йортына кертеп улы кебек тәрбияләп тоткан, ашаткан-эчерткән бер шәкерте урлап алып киткән, дип ишеткән идем. Ышанмадым. Шул дөрес булып чыгамы әллә? «Берәү» дигәннәре син буласыңмы инде?..

Сорауны ошатмыйчамы, кулындагы тимер кашыкны бушап калган тәлинкәгә ыргытты шагыйрь. Кашыкның шалтырап төшкән авазына күрше өстәл артында утыручылар да сискәнеп куйды.

– Беренчедән, – дип, бик төпле рәвешкә китереп аңлатырга кереште шагыйрь. – Әйе, беренчедән, мин аны урламадым. Хәзер бит Сәвит влачы хатын урлаганны хупламый. Икенчедән, хәзрәтнең хатыннары берәү генә түгел иде, аңарга – карт кешегә, болай да җитәрлек калды әле. Ә без бер-беребезне яратышып өйләнештек. Гомер буе качып-посып очрашып йөреп булмый бит...

– Анысы шулайдыр да... Әмма хәзрәт «Галия»дә безгә гыйлем биргән, күпме татар-башкорт яшьләренә изге юл күрсәткән кеше, бик тә игелекле, укымышлы бер остазыбыз иде бит... Ай-һай, аңарга шул тикле дә борчу, кайгы-хәсрәт китерүең бер дә яхшы булмаган икән. Шуның өстенә бит әле мондый тарих күпме имеш-мимеш, гайбәт тудыра... – дип искәртергә кирәк тапты Нигъмәт. – Хәтерем ялгышмаса, остазыбызның ул яшь хатыныннан бер улы да бар иде түгелме соң? Ул бала кем белән?..

– Туганда аныкы булса, хәзер минеке. Аллага шөкер, өч малай үстерәбез, – дип, бер горурлык хисе белән иркен сулыш алып куйды шагыйрь. – Орлыгы Бохарада түгел бит, тукталырга исәбебез юк әлегә...

– Бәхетләре булсын, ниятләрең зурдан икән, – диде Нигъмәт. – Балалар – милләтебезнең киләчәге. Еллар гына имин тора күрсен.

– Шулай, – дип, бу юлы да коры гына җөпләп куйды шагыйрь. Һәм кабалана төшеп, сүзне башкага борырга ашыкты. – Гел минем турыда гына сөйләшмик әле. Ә үзегез, үзегез ничек урнаштыгыз соң, Нигъмәт абый? Казан ничек, институтта ничек каршыладылар үзегезне?

– Институтта барысы да яхшы. Ә менә тору урыны булмау гына... Үзем бер хәл, китапларым шушы көнгәчә тимер юл вокзалында ята, аларны куяр, урнаштырыр урын юк. Кешеләрне дә аз беләм әлегә, шәһәрне дә дигәндәй...

Кинәт шагыйрь, зур ачыш ясагандай кулларын киң җәеп, бар тавышка кычкырып җибәрмәсенме шунда:

– Нигъмәт абый, таптым, мин сезгә менә дигән фатир тәкъдим итәм хәзер. Вакытыгыз булса, әйдәгез, киттек, хәзер үк бара алабыз. Мин яшәгән йортның күршесендә бер бүлмә тапшырыла, дигән язу бар иде. Сезнең өчен бер дигән булачак. Институтка да алай бик ерак түгел, миңа да якын гына. Күршедә генә торачакбыз. Ризамы?

– Риза булмый хәлем юк. Һич кая ашыкмыйм. Киттек, алайса, барыйк... Сөйләшеп карыйк, – дип, Нигъмәт Хәким дә урыныннан кузгалды.

– Ничек моңарчы хәтергә килмәгән, шәп булачак бу! – дип, Нигъмәтнең үзеннән бигрәк, аның якташы куана иде шикелле.

...Шул рәвешле ике якташ җәһәт-җәһәт атлап, Кекин йорты каршыннан Аркадия бакчасына таба китеп бардылар. Ашыгуларының сәбәбе бик җитди: шәһәрдә фатир табу җиңел эш түгел, башка берәүләр өлгергәнче барып күрергә кирәк иде бит теге йортның хуҗасын. Шәһәр үзәгеннән дә ерак түгел икән, урыны да кулай булырга охшаган.

**2**

«Кадерлем Бәдринур! Менә тагы сезгә хат язарга утырдым. Сиңа һәм балакайларымның һәммәсенә Казан каласыннан күптин күп, чуктыйн чук ялкынлы кайнар сәламнәр юллыйм. Элгәреге хатыма Сезләрдән җавап килгәнне дә көтмәенчә язарга булдым әле. Үзегезне ничек сагынуым һәм юксынуымны аңлатыр өчен сүзләр табып җиткерә алмам кебек.

Ничек яшисез, авылда хәлләр бер көеме, барыгыз да исән-саулармы? Ләбибә белән Мөбәширнең хәлләре ничек, авылга еш кайталармы? Йөргән җирләрендә яхшы кешеләр генә очрасын иде инде. Аларның укуга, белемгә тартылулары бик яхшы күренеш, мине чиксез куандыра. Фәһимә белән кечкенә кызыбыз Әдибәнең синең янда, авылда укулары да яхшы әле. Үзләре өчен дә, синең өчен дә дип әйтүем. Ашау-эчү якларыгыз ничек, бик җиңел түгелдер инде? Берәүгә дә җиңел түгел шул хәзер. Дөньяның бик тә болганган чагы, шәһәрләрдә дә тынычлык юк соңгы араларда. Илдәге ыгы-зыгының шаукымы Урал-тау тарафларына да барып җиткән булса кирәк. Мондый елларда барыбызга да иминлек һәм баш исәнлекләре теләргә кала.

Мин җибәргән посылканы алдыгызмы? Чәй һәм ярма янына бераз шикәр дә тыктым бу юлы, авыл өчен бик тә кадерле күчтәнәч булыр, дидем. Ярма эченә кәгазьгә төреп беркадәр акча да куйган идем. Балалар тиз үсә, аларның өс-башларын карарга бераз ярдәм булыр.

Үземнең хәлләргә килгәндә, куанычлы яңалыгым бар: ярымподвалда гына булса да, ниһаять, фатирга урнаштым. Өч метрга ике метр ярым зурлыгындагы аерым бүлмә, суы һәм башка кирәк-яраклары һәммәсе ишегалдында. Институтка да бик ерак түгел, шәһәрнең үзәгендә дип әйтерлек. Бер кешелек тимер карават, кечкенә генә өстәл һәм аркасыз ике урындык – табуреткасы да

бар. Китапларым өчен шкаф-фәлән булмаса да аларны бер як стенага терәп идәннән-түшәмгәчә тәртип белән тезеп чыктым. Эш өчен, иҗат өчен, ниһаять, бөтен шартларым да бар, дип әйтергә мөмкин.

Бу фатирны табуда үзебезнең якташ, үзем кебек үк Златоуст өязендә туып-үскән бер шагыйрь ярдәмче булды. Ул да соңгы араларда гына Казанга күчеп килгән. Мин аны Уфада мөгаллимлек иткән елларымнан ук танып белә идем, үз вакытында шәкертем булган зыялы егет. Аның белән даими күрешеп һәм аралашып яшәвемә дә куанып бетә алмыйм. Туган якларны сагынган чакларда «якташ» дип бер эндәшүче табылса, күңелгә җылылык иңә икән ул...

Институттан тыш язу-сызу эшләрем дә бик күп. Иң мөһиме, әлбәттә, «Идегәй» дастаны. Шул әсәрне татар һәм рус телләрендә аерым китап итеп бастыру хыялын тормышка ашырсам, боерган булса, якын елларда үзегезне дә Казанга күчерә алырмын дигән өмет-хыял белән яшим, Бәдринурым. Балаларның кирәк-яракларын язарга онытма, аларны һич кенә дә ким-хур яшәтәсем килми. Үзеңә бер күлмәклек комач табып җибәрү дигән уем да бар әле.

Яңа елга кергәч, янызга кайтып китү хыялы белән дә яшим. Сагынып һәм барчагызны өзелеп яратып калучы Нигъмәт дип белерсез. Казан, 1930 ел, 2 ноябрь.»

***

«Нигъмәт! Хатыңны һәм посылка белән җибәргән күчтәнәчләреңне алдык. Бик зур рәхмәт... Син безнең өчен алай бик борчылма инде, илдә чыпчык үлмәс, дигән кебек, Аллага шөкер, бар җиребез дә җитешле, бөтен. Акча малы түгел, бакча малы белән тукланып яшибез ич без. Син кеше арасында үзеңне кайгырт, өс-башыңны кара, ачлы-туклы йөри күрмә. Ничә ел инде өстеңдә һаман шул бер күлмәк белән бер пинжәк, онытма, мөгаллим кешене киеменә карап каршы алалар.

Балалар барысы да исән-сау, Аллага шөкер! Ләбибә Колмәт авылында башлангыч мәктәптә укытучы булып эшли. Ял көннәрендә кайтып-китеп йөри, аз булса да аның да ярдәме тия хәзер. Мөбәшир, әүвәлгечә, Уфада укый. «Укудан бушаган вакытларыбызда пристаньда күмер һәм тоз бушатабыз, акчага кытлыгым юк» дип яза. Фәһимә белән Әдибә дә тырышып укыйлар. Өй һәм бакча эшләрендә дә ярдәм итәләр үземә. Әдибә аеруча юксына, сагына үзеңне. Әти кайчан кайта, Казан каласына әти янына кайчан барабыз инде, дип, гел сораштырып кына тора.

Бакча эшләрен төгәлләдек. Боерган булса, бәрәңге һәм суган җитәрлек, кайтсаң, берәр капчык син дә алып китәрсең, дип уйлыйм. Үзең беләсең, сыерны сатарга туры килде. Кәҗә сөтенә ияләнеп киләбез, аны бик сихәтле, диләр бит. Кышка ике сарык калдырырга булдык, икесе дә буаз күренә... Бездә әлегә менә шундый яңалыклар, бер дә борчылырлык сәбәп юк.

Хезмәтеңдә уңышлар теләп, җавап хатларыңны көтеп, исәнлектә-саулыкта күрешүләргә өмет баглап үзеңне зарыгып көтеп калучы кызларың Ләбибә, Фәһимә, Әдибә, улың Мөбәшир һәм Бәдринур дип белерсең. 29 ноябрь, Еланлы авылы».

...Еланлы авылы белән Казан арасында хатлар йөреп кенә тора, йөрәк җылысын һәм туганлык җепләрен тоташтырган элемтә ике арада һич өзелми. Кызлары һәм улыннан да әледән-әле хатлар килеп тора. Ай саен институттан хезмәт хакы алган көнне үк ул авылга посылка һәм беркадәр акча җибәрә. Әмма шул ягы начар, еш кайтып-китеп йөри алмый. Беренчедән, эштән арына алганы

юк, институтта эше муеннан. Икенчедән, аралар да якын түгел. Кайтыйм дисә, иң элек тимер юлда бер тәүлек чамасы селкенергә кирәк. Авыл саен туктый торган паровозлар белән әллә кая китеп булмый. Әле аннан соң да, иң якын дигән тимер юл станциясеннән, утыз чакрым җәяүләп кайтасы бар. Ярый да бер-бер атлы кеше яисә юлаучы очраса. Соңгы араларда аның юлга чыгучысы, юл йөрүчеләре дә сирәкләнде, кешеләр бер-берсеннән ераклашты, җәмгыять, кыл урталай дигәндәй, икегә бүленде. Юлда хәвеф-хәтәр күзгә күренеп арта, анда берәүне талаганнар, тегендә кемнедер үтереп ташлаганнар дигән сүзләрнең өзелеп торганы юк. Йә, Ходаем, үзең сакла...

### 3

...1931 елның җәй урталарында, укыту эшләре тәмамланып, студентлар каникулга таралгач та, Нигъмәт Хәким туган авылы Еланлыга кайтырга чыкты. Әтисенең кайтуы турындагы хәбәрне ишеткән кече кызы Әдибә көннәр буе авыл башындагы басу капкасы янында булды. Авыл читеннән урманга таба калкулык һәм үзәннәрне урап сүтелгән тасма кебек сузылган юлда бер-бер җәяүле кеше яисә җигүле ат күренсә, ул кулларын болгый-болгый аңарга каршы торып йөгерде. Килүченең әтисе түгел, чит-ят кеше булуына инангачтын инде менә ничәнче кат кәефе кырылудан башын салындырып, кире авыл читенә борылып кайтты. Шул рәвешле җиде-сигез мәртәбә алданып, тәмам өметен өзеп, инде өйгә кайтып китәргә җыенганда, каенлыкка барып тоташкан калкулыклар артындагы борылыштан тагы бер җигүле ат күренде. Әтисенең әлеге атта булуына бигүк өметләнмәсә дә көтәргә булды кыз. Әмма каршы йөгермәде, көнозын арлы-бирле чабулап йөри торгач, шактый ук талчыккан һәм ачыккан да иде инде ул, юл читендә үскән бәбкә үләннәре өстендә үз уйларына бирелеп битараф кына утыра бирде. Ат ничек юыртып килгән булса, башкалары кебек үк аның яныннан үз көе белән юыртып китеп барды, арбадагы кешеләр аңарга борылып та карамады булса кирәк.

Күңелсезләнеп, урыныннан торды кыз һәм кайтыр юлга борылды. Ул да түгел, берәүнең бик тә таныш, бик тә җылы һәм ягымлы тавышы яңгырап ишетелмәсенме шунда:

– Кызым, Әдибә, син түгелме соң бу?..

Сискәнеп куйды кыз. Ул арада атның туктаганын да көтеп тормыйча, әле генә узып киткән арбадан аның әтисе сикереп төште. Бер-берсенә каршы гүя атлап түгел, очып килде кебек алар. Әтисенең кочагына ташланды кыз һәм шатлыгыннанмы, әллә үзе теләгәнчә каршылый алмавыннан уңайсызланыпмы, күзенә килеп тыгылган яшьләрен тыя алмыйча елап ук җибәрде.

– Әтием! – дип әйтә алды ул нибары.

– Кызым, минем сөйкемле кызым Әдибә. Танымый да торам, күр инде ничек дәү кыз булып үскәнсең син... Елама, кызым, елама.

– Мин болай гына, шатлыгымнан. Бик тә сагынганга... – дип, башлаган җөмләсен тәмамлый алмыйча сулкылдады ул.

– Кайттым ич, кызым. Инде елама... Әйдә, утыр атка, бергә кайтып керик өйгә, – дип, үзләрен көтеп торган җигүле атка якынлашты алар.

Ул да түгел, бөтерчек сыман, елгыр гына әтисе кочагыннан ничектер шуып төшеп авылга таба җан-фәрман торып йөгермәсенме кыз. Нигъмәтнең: «Кызым, син кая болай...» – дигән сүзләренә каршы:

– Сөенче алырга, – дигән тавышы гына ишетелеп калды аның. Кай арада зур урамнан борылып үз тыкрыкларына кереп тә югалды.

...Балалар барысы да өйгә җыелган. Әниләре Бәдринурның самавыры өстәл уртасында түбәтәйләрен биетеп кайнап утыра, ә үзе мич тирәсендә кайнаша. Өйгә тәмле аш, тавык шулпасы исе чыккан. Ул да түгел өлкән кызлары Ләбибә, зур табак белән яңа пешеп чыккан, пар бөркеп торган бәрәңге китереп утыртты. Табадан яңа төшкән кайнар кыстыбый да өстәл уртасыннан урын алды. Бәдринур чоланнан сөт, ире кайтуына дип алдан ук хәстәрләп куелган башкорт балы һәм каймак алып керде. Уртанчы кызлары Фәһимә, болындагы үлән, урман чәчкәләреннән чәй ясарга кереште.

– Ниһаять, без дә бөтен гаиләбез белән бергә җыелырбыз икән, – дип, үзенең куанычын җиткеререгә ашыкты әниләре. Бу аның кинаяләп зарлануы түгел, үзенә күрә куанычы белән уртаклашуы иде. Кай арада рәешкә генә дип тегелгән зәңгәр чәчәкле күлмәген киеп өлгергәндер. Аның өстеннән җыйнак алъяпкыч та кигәчтен, ул бүген яшәреп, яктырып киткән иде. Бер дә авыл мәшәкатьләре белән тулы тормыш арбасын бер ялгызы тартып яшәгән дүрт бала анасы, димәссең үзен. Моны беренче булып күреп алучы, әлбәттә, аны сагынып ерак җирдән кайткан ире Нигъмәт иде.

– Ай-һай, танырлык та түгел, минем хатынмы соң бу, бигрәкләр дә чибәр, – дигән сүзләр чыгып очты аның тел очыннан. Әмма шундук янәшәдә буй җиткергән кызлары һәм улы булуны искә төшереп, күкрәгеН биләп алган ярсу хисләрен йомшарта төште. – Балалар, әниегезне таныйсызмы соң бүген?..

– Безнең әни һәрчак шулай матур ул, – дип күтәреп алды Әдибә. Аның кече кызы бу юлы да, гадәттәгечә, һәммәсеннән өлгеррәк булып чыкты.

Тыйнаклардан да тыйнаграк Бәдринур, үзенә булган игътибардан тартынып, уңайсызланып куйды. Бит очлары алсуланып чыкты, кулларын кая куярга белмәде.

– Әтиегезгә рәхмәт инде, – диде сүзсез торуыннан уңайсызланып, – бу күлмәкнең комачын ул Һиндстаннан бүләк итеп алып кайткан иде бит...

– Әтинең зәвыгы әйбәт, ул матурлыкны таный да, бәяли дә белә шул, – дип, бу юлы Фәһимә сүз кыстырды.

– Матурлыкны таный белмәсә, безнең әниебезне табып алыр идеме...

– Кызлар, җитте сезгә, – дияргә мәҗбүр булды әниләре.

Нигъмәт тә кушылды аңарга:

– Җитәр, кызым, макташып утыра торган вакыт түгел, бергә җыелган минутларның кадерен белик. Әйдәгез, өстәл янына. Шул рәвешле, бергә җыелышып булмый бит гел-гел, – диде ул, уч төпләрен бер-беренә сыпырып. Үзе бер читкә кысыла төшеп, Бәдринурга янәшәсеннән урын тәкъдим итте.

Шау-гөр килеп, хәл-әхвәлләр белешеп, тирләп-пешеп чәй эчте алар. Хәзинәдә бары – һәммәсе өстәлдә, сүзләре дә сөйләшеп кенә бетәрлек түгел иде. Һәркайсының үз тормышы, үз яңалыклары бар, барысын да ачыктан-ачык уртага салып тагы кайда һәм кем белән сөйләшергә, киңәшергә мөмкин?! Ә монда барысы да үз һәм якын кешеләр. Бер-берен сүзсез дә аңлыйлар, аңлау гынамы соң, йөрәкләре бер үк дулкында тибә ич аларның... Дөнья хәлләре дә читтә калмады, әлбәттә. Һәр көн үзгәрешләр һәм берсеннән-берсе катлаулы һәм каршылыклы яңалыклар китереп торган дәвердә яшиләр ич. Уллары Мөбәшир һәм күрше авылда укытучы Ләбибә инде Совет хакимиятенең ялкынлы тарафдарлары булып киткән, илдәге үзгәрешләрне тулаем хуплыйлар икән. Фәһимә дә ата-ана оясыннан очып китеп, укуын дәвам иттерү хыялы белән яши. Ә авылда яшәп яткан әниләрен тормыш авырлыклары баскан. Авылда «влач» кайгысымы соң?! Авыл кешесенә анысы да ярамый, монысы да ярамый

торган чак. Шуның өстенә гомер буе җыйган мал-туар, бар хуҗалыгыңны тартып алырга җыеналар. «Колхуз» дигәннәрен дә һич аңларлык түгел. Теләгең бармы, юкмы, син шунда керергә тиеш икән... Кешеләрне куркыту дисеңме, мал-туарыңны тартып алу дисеңме, ниләр генә уйлап чыгармый бу яңа власть...

Нигъмәт күбрәк тыңлап утырды. Һичкемгә үзенең фикерләрен тагарга теләмәде әлегә... Үзенең дә төгәл генә ни дияргә белми икеләнгән, көн-төн уйланган чагы. Шулай да бәхәстән читтә кала алмады ул да:

– Беләм, Бәдринур, сиңа җиңел түгел, тормышның бар авырлыгы синең җилкәдә, – дип, хатынын тынычландырырга омтылды ул иң элек.

– Ә улың Мөбәшир, әнә, бәлшәвик булып киткән, – дип бүлдерде аны әниләре.

– Бу хәбәр сиңа да килеп ирештеме инде? – дип, сорарга мәҗбүр булды уллары. Ул ата-ана сүзенә артык кысылмыйча, үзалдына тыныч кына тыңлап утырырга исәпләгән иде дә бит. Үзенә кагылгач, җавапсыз кала алмады.

– Бөтен авыл сөйли. Чукрак булсам, ишетмәс идем дә бит...

– Мин дә беләм, абый, – дип, ул арада сеңелләре Әдибә дә сүз кыстырырга өлгерде. – Миңа да бармак төртеп күрсәтәләр авылда. «Әдибәнең абыйсы шәһәрдә бәлшәвик булып йөри икән» дип үчекли сыйныфташларым.

– Әдибә, кызым, – дип дәште Нигъмәт, – «большевик» сүзе үчек була алмый. Алар илне үзгәртергә, гади халыкның – эшче сыйныфы һәм крәстияннарның тормышын яхшыртырга вәгъдә биреп килгән кешеләр. Күпмедер вакыт үтәр, син дә менә үсеп җитәрсең, кем белә, бәлки әле үзең дә шул фиркага кереп коммунар булып китәрсең.

– Вәгъдә бирү җиңел дә, аны үтәү турында онытмадылармы икән? – дип әйтеп куйды шунда әниләре. Бу аның сүз арасында гына әйтелгән фикере иде булса кирәк.

– Әнием аларны яратмый, – дип әйтеп салмасынмы кечкенә Әдибә. Сораулы карашын, ни әйтерләр дигән сыман, бер әтисенә, бер әнисенә төшереп торды кыз. Һәм тәмам кызып, чын күңелдән тынгысызланып дәвам итте сүзен. – Әтием, син бит үзең дә бәлшәвик түгел. Юк, мин бәлшәвик булырга җыенмыйм, әтием белән әниемнән аерылырга теләмимм...

– Кызым, тынычлан, бер дә исең китмәсен, «бәлшәвик»лек мәҗбүри түгел, язмыш җилләре кая гына ташламасын, кеше булып калырга кирәк иң әүвәле. Үз иманыңа һәм туган халкыңа тугрылыклы кеше булып...

Сүзен шул урында өзеп, Нигъмәт уйга калып торды бер тын. Илдә барган вакыйгаларга һәм аның башына килгән хакимияткә үз карашы, үз бәясе бар иде, әлбәттә. Икеләнүләр һәм каршылыклардан гыйбарәт иде ул мөнәсәбәт. Әмма нибарысы атна-ун көн торып китү өчен гаиләсе янына сагынып кайткан җирендә үзенә дә тулаем аңлашылып бетмәгән сәяси проблемаларга кереп буталасы килми иде аның. Ярый да гомер иткән хатыны белән күзгә-күз карашып серләшү булса. Ә монда аның өчен бик тә газиз балалары: аларның этиләре авызыннан чыккан һәр сүзне, һәр яңалыкны хакыйкатькә тиңләп кабул итүләре ихтимал. Акылсызлар түгел, тормыш авырлыкларын күреп, эшләп үстеләр, инде үз язмышларын үзләре сайларга сәләтлеләр, дип күрә иде ул аларны. Улы Мөбәшир бит, әнә, аның белән киңәшмәде, ә нинди җаваплы һәм җитди карарга килгән. Ләбибә дә, сүз сөрешләренә карасаң, шул ук юлда. Хәерлегә генә булсын, ни өчен дип әле ул балаларының бу тормышта үз юлларын эзләвенә каршы килергә тиеш. Белә, күреп тора ич, күпләр ул фиркага ианудан түгел, заманга яраклашу максатыннан керәләр...

Аннан килеп, балалары белән аяк терәп сөйләшергә, алардан нидер таләп итәргә беркадәр уңайсыз да. Менә ничә еллар инде ул чит-ят җирләрдә йөрергә мәҗбүр, әле Уфада, әле Ташкентта яисә Ленинградта. Һәм ниһаять – Казанда, татарның Мәккәсе һәм Мәдинәсе дә булган пайтәхеттә. Өенә, гаиләсе янына бит ул кайтса да кунакка гына кайтып китә. Авылда, гаиләсеннән һич аерылмый гына яшәр иде дә, гомер кыска, кешегә ул бер генә бирелгән. Күпме еллар дәвамына, күпме кыенлыклар кичереп алган белемне, зур фидакярлек нәтиҗәсендә ирешелгән табышларын яшь буынга, сөекле халкына кайтарасы бар ич аның. Ничек кенә булса да, нинди кыенлыклар кичерергә туры килсә дә, ул үз җилкәсенә салган бу миссияне башкарып чыгарга тиеш. Казанга кайтуының төп максаты әнә шуңарда. Аның сөекле һәм кадерле халкы мәңге кимсетү һәм җәбер-золым кичереп яшәргә тиешме? Юк, әлбәттә. Моның белән һич кенә дә килешәчәк түгел. Татарның бай тарихы, күпләрне көнләштерерлек мәдәнияте һәм әдәби җәүһәрләре бар. Ә ул, гүя адашкан бер милләт кеби, үз кадерен үзе белмичә, Көнчыгыш белән Көнбатыш арасында бәргәләнә. Аларны күрә, аларныкын ишетә яисә укый да «аһ» итә, «ваһ» итә – башыннан түбәтәе төшеп китә. Менә бит башкалар, имеш, ә бездә, имеш, боларның берсе дә юк. Үзенең туган халкын наданлыкта да гаепләп куя әле ул. Шулай уйлап, үзе дә белешмәстән үзенең наданлыгынраслый.

Ә бит затлы акыл һәм фикер ияләребез аз булмаган, аз түгел безнең дә. Халкыбызның әүвәл дәверләрдәге казанышлары, телебезнең хәзинәләре, әдәбиятыбызның энҗе-мәрҗәннәре һич кенә дә тарих сазлыгында калып югалырга тиеш түгел. Алар әлегә бездән бик ерак яшерелмәгән, максат куеп эзләсәң табу, яңадан торгызу мөмкин үзләрен – халыкның күңелендә һәм телендә, татарның яшәү рәвешендә, холык-фигылендә саклананалар... Юк, Нигъмәт үзе сайлаган юлыннан һич кенә дә читкә тайпылмас, нинди генә кимсенү һәм югалтулар кичерергә туры килмәсен, максатына ирешәчәк. Үз халкыңа хезмәткә сарыф ителгән гомер, ул заяга узган саналмас. Моны аның сөекле хатыны, дүрт бала анасы Бәдринур да яхшы белә, һәрчак аңлап яшәде. Ул бит аның хатыны гына түгел, элек-электән иң ышанычлы таянычы да. Боерган булса, балалары да аңлар. Аларның да күзләре аңарга текәлгән, әнә, ни рәвешле үз итеп, яратып һәм горурланып та карыйлар алар үз әтиләренә. Күңеле йомшап китте аның шунда, балаларына бирергә теләп тә бирә алмаган ярдәме өчен уңайсызланды. Балакайлар... Олысы, кечесе һәркайсы бер дәрәҗәдә үз һәм кадерле аның өчен. Аларның да, башкалар кебек, әти-әни янында үсәсе килмәгәндерме әллә? Ә ул берөзлексез юлда, укуда һәм гыйльми эзләнүләрдә булды. Эшләгән, тапкан акчасының да күп өлеше гыйльми китаплар сатып алуга, гыйлем эзләп узган юл масрафларына китеп барды. Ә гаиләсен һәм балакайларын бит ул һичкайчан онытмады, алар һәрчак истә, аның күңеле түрендә булдылар. Үзләрен тиешле дәрәҗәдә кайгырта алмавы һәм даими рәвештә яннарында булып, киңәш-табыш итешеп яши алмавына аз өзгәләнгәндер дип уйлыйсызмы әллә аны?.. Шундый уй һәм кичерешләр бу юлы да, инде үзләре каршысында утырганда, ургылып аның бугаз төбенә килеп тыгылдылар. Карашын читкә алды ул, әмма үз балаларың каршында җебеп төшәргә ярамаганлыкны да яхшы аңлый иде. Сер бирмәскә, сиздермәскә тырышты.

Чираттагы мәртәбә бер йотым чәй кабып куйды да тирән сулыш алып, сүзне бөтенләй башкага борды Нигъмәт. Бу балалар, хатыны бит аңардан бер-бер җылы сүз көтә торганнардыр.

– Боерган булса, минә якын елларда зур хезмәтләрем дөнья күрәчәк. Казан шәһәренең уртасыннан зур бер фатир бирерләр үзебезгә. Барыбыз да шунда җыелырбыз, бергә-бергә зур һәм бәхетле гаилә булып яши башларбыз...

– Әй, этием, шул Казан дигән шәһәрне бер күрсәм дә, риза булыр идем әле мин.

– Әдибә, кызым, – дип, урыныннан торып басып кызының аркасыннан сөеп килде үз хыялыннан үзе канатланып киткән галим, – күрү генә түгел, син ул шәһәрдә яшәрсең, боерган булса, укырсың, данлыклы Казан университетында белем алырсың...

– Әнине дә алып барырбызмы соң ул Казанга?

– Әниеңнән башка буламы? Ул беренче булып бара, әлбәттә.

– Ә ул анда ни эшләр? Бәрәңге бакчасы, тавыклар, кәҗә булырмы соң анда?..

– Шәһәрдә бәрәңгене базардан гына алалар, кызым.

– Кәҗәбез дә булмагач, әни ни эшләр соң анда?

– Көндезләрен кулына чәчәкле шәмсия тотып паркларда йөрер. Ә кичләрен бергәләшеп театрга барырбыз...

– Минә бит, ә-ә... – дип, кулларын чәбәкләп, бу әңгәмәне тын гына тыңлап утырган апаларына, абыйсына карап куйды кыз.

– Әтиегез гомер-гомергә шундый хыялый булды инде ул, – дип, әниләре Әдибәне матур хыялларыннан бүлдерде. Аннан иренә таба борылып өстәп куйды: – Нигъмәт, авылда синең кебек хыялыйлар турында, беләсеңме, ничек диләр: «Алмаган ат, тумаган колын, атланма, улым, билен сындырырсың». Ташкентларда, Петроградларда йөри торгач, әллә оныткан да инде...

Әниләре сүзеннән кызык табып, кызлар, сүз берләшкәндәй кеткелдәп көлешеп алдылар.

– Петроград түгел, әни, Ленинград дип сөйләш, ярыймы? – дип, Мөбәшир дә елмаеп куйды. Нигъмәтнең генә исе китмәде.

– Көлегез, көл... Барыбыз бергәләшеп Казанга җыелгач, яңа фатирның ачык террасасында шау-гөр килеп чәй эчеп утырганда мин сездән көләрмен... Профессор булып киткәчтен, боерган булса, машина да алырбыз әле менә. Күрерсез, ял көннәрендә үзебезнең җилкәнле көймәгә утырып Идел өстендә кәеф-сафа корып, ял итеп, гизеп тә йөрербез, боерган булса...

Бу юлы инде каршы сүз әйтүче булмады. Ачылган авызларын йомарга да онытып, һәммәсе тыңлау белән мәшгуль иде.

– Әти, син чынлап сөйлисеңме боларны, әллә шаяртуыңмы? – дип, Мөбәшир дә сүз катты.

– Улым, әллә син дә ышанмыйсыңмы? Уйнап сөйлиләр димени?.. Чынлап сөйлим. Татиздатта минем бөтен татар халкын, алай гына да түгел, бөтен илне сокландырырга сәләтле зур хезмәтем аерым китап булып басылачак. Остазым академик Самойлович аны Мәскәүдә һәм Ленинградта да зур тиражлар белән басачаклар, дип вәгъдә итә. Аның сүз башы белән, әлбәттә. «Идегәй», улым, мине генә түгел, татар халкының үзен дә бер башка, юк, ике башка югары күтәрәчәк. Менә күрерсең, ул көнгә күп калмады инде.

– Ышанмаска хакым юк, син күп укыган, күпне күргән кеше, синең һәр сүзеңә ышанам мин, әти. Тик менә... – Шул урында әйтергәме, юкмы, дигәндәй, икеләнә калды ул бер мәлгә.

– Йә, башлагансың икән, әйтеп бетер, улым. Сиңа кай җире ошамады?

– Ошамады, дип әйтмим. Тик менә «шәмсияләр тотып паркларда йөрү», «җилкәнле көймәләргә утырып, Идел өстендә гизү» кебек нәрсәләрне

эшче-крәстияннәр фиркасе хупламый бит. Алай йөрү ул буржуйларга гына килешкән...

– Тукта-тукта, ә безнең ул буржуйлардан кайсы төшебез ким?

– Ә без җиң сызганып эшләргә, яңа тормыш нигезләрен төзергә тиешбез, эти...

– Соң без, улым, эшләмибезмени, кул кушырып кына утырабызмы? Әтиеңне син ялкауга чыгарасыңмы инде шулай итеп?.. Эшләгән кешенең матур итеп яшәргә һәм ялга да хокукы булырга тиештер, миңа калса.

– Безнең әле искене җимереп, яңаны төзисебез бар, эти, моңарга байтак еллар китәчәк...

– Ә җимермичә генә яңаны төзеп булмыймы?

– Булмый торгандыр шул, – дип бераз уйга калып торды Мөбәшир.– Иптәш Сталин белә инде, ул шулай куша.

–Ниләр майтарырга, нәрсәләрне җимерергә уйлыйсыз инде, улым?

– Мәчет һәм чиркәүләрне, буржуйларның завод-фабрикаларын, кулакларны...

Шул урында тынгысызланып, ике ир-ат арасында кузгалырга торган бу бәхәскә Бәдринур килеп кушылды.

– Менә, Нигъмәт, улың ни сөйләгәнне ишетәсеңме инде, аның телендә гел шул сүзләр хәзер: «җимерәбез дә төзибез, җимерәбез дә төзибез». Ни эшләтергә бу баланы? Шәһәргә киткәнче, менә дигән малай иде бит. Инсафлы, тыйнак иде, динле... Урамга чыкса, бар кеше белән бүреген салып, кулын күкрәгенә куеп исәнләшә торган иде. Авыл картларына тикле исләре китеп мактап сөйли торганнар иде үзе турында. Әллә җеннәр алыштырды шул шәһәр дигән җирдә...

– Борчылма, Бәдринур, берни эшләтеп булмый. Заманасы шундый. Мөбәширгә ышанам, акылсызлык эшли торган егет түгел ул. Ир кешенең илдә барган вакыйгаларның уртасында булуы хәерле...

– Рәхмәт, эти! – дип әйтеп куйды улы. Әтисенең хуплау сүзләрен үзенә бирелгән хәер-фатихадай кабул итте.

– Шулай да, улым, минем сиңа бер киңәшем бар. Тыңларсыңмы, колак салырсыңмы сүземә?

– Тыңлыйм, эти...

– Булдыра алсаң, улым, син ул «җимерәбез» дигән сүзне файдаланмаска тырыш, ярыймы? Җимерәләр икән, башкалар җимерсен, син катышма. Ә менә яңаны булдыру, төзү, илне төзекләндерү, кешеләрнең тормыш-көнкүрешен яхшырту – игелекле эш, ул эшнең башында торсаң да, бер сүзем юк, хуплармын гына.

Мөбәшир уйга калып торды бер тын, җавап бирер сүз тапмадымы, икеләнә идеме, әйтеп булмый. Бу тынлыкны әнисе бүлдерде.

– Нигә дәшмисең, йә, «ярар, эти, киңәшеңне истән чыгармам», диген. Әтиең дә шәһәрдә яши бит, әнә, Казанда. Ул Петроградның үзендә гыйлем алган кеше, мине тыңламасаң, аны тыңла ичмасам...

– Петроград түгел, әни, Ленинград... Ярар, – диде Мөбәшир. Зур авырлык белән генә әйтте ул бу сүзләрне, авызыннан көч-хәл белән тартып алдылар диярсең. – Йөзегезгә кызыллык китермәм. Әмма сез дә мине аңларга тырышыгыз, соңгы сулышымача партия сызган юл белән барачакмын.

– Колхозга кер, дип үгетлисе булма мине, ярыймы! – дигән шарты да бар икән әле әнисенең. – Соңгы кәҗәмне илтеп бирәсем юк, ишеттеңме, Мөбәшир.

Сеңелләреңне ачтан үтерәсең килмәсә, башкача кабатлама ул хакта. Мин сине табып үстергән анаң да бит әле...

– Колхозга керергә кирәк, әни... Юкса, мин авылдашларымның күзенә ничек күренермен, фикердәшләремә җитсә, ни әйтермен?

– Бернишләтеп тә булмый, минем әни шундый киребеткән бер авыл карчыгы инде диярсең..., – дип, елмая төшеп кулын селтәде Бәдринур.

Кызлары, бер-берсенә карашып, үзара көлешеп куйдылар.

– Нинди «карчык» дигән сүз ул, син безнең әниебез. Әни кеше картаймый, – дип, төзәтмә кертергә ашыкты өлкән апалары Ләбибә. Сеңелләреннән дә хуплау көтте ул берочтан. – Шулай бит, Фая, шулай бит, Әдибә...

– Ярар, дөнья һәм вакыт үзе юлын күрсәтер, юк өчен баш ватып, кадерле очрашу минутларының ямен җибәреп утырмыйк әле, – дип, барын да түгәрәкләп, очраклы рәвештә туган бу фикер алышуны йомгакларга ашыкты Нигъмәт. Ләбибәгә дә искәртергә кирәк тапты. – Кызым, сеңлеңнең исеме Фая түгел, аның мулла кушкан исеме Фәһимә, аны бозып әйтү кирәкмәс.

Дөрес сүзгә җавап юк, дигәндәй, каршы сүз дәшүче булмады. Ул арада балалар, әниләренә рәхмәт әйтеп, өстәл артыннан кайсы кая тарала ук башлады. Нигъмәт, күптән кабул ителгән гадәте буенча, аларның һәркайсына бүләккә китаплар алып кайткан иде бит. Ә яңа китап кулларына кергәч, таныша башлауны иртәгесе көнгә калдырырга күнекмәгән алар.

Аш-су өстәле артында Бәдринур белән икесе генә утыра бирделәр.

– Балаларның үскәнен күрми дә калганмын, – дип әйтеп куйды Нигъмәт.

– Инде менә тарала да башладылар. Мөбәшир белән Ләбибәне мин дә әллә нигә бер генә күрәм. Атна саен кайтып-китеп йөри алмыйлар шул, – дип уфтанып алды Бәдринур.

– Син, әнисе, алар белән бәхәскә кермәскә тырыш инде хәзер, ярыймы? Алар зурлар, бу тормышта үз урыннарын эзләгән чаклары.

– Минем өчен барыбер балалар шул...

– Әмма бу яшьтә өйрәткәнне яратмыйлар. Үз-үзләрен шәхес итеп раслый торган заманнары.

– Фаяның да уе шәһәр тарафында күренә.

– Фая түгел, Фәһимә, җанкисәгем Бәдринур!

– Әй, яшьтәшләре шулай дәшкәч әйтелә инде. Хәзер бит шулай, исемнәрне бозып-кыскартып әйтү китте.

– Бүген исем үзгәртерләр, иртәгә ата-бабаларын онытсалар, аннан ары иманын, динен һәм милләтен алыштырырга да күп сорамаслар. Начар гадәт бу, үз-үзен хөрмәт иткән кеше, үз-үзен хөрмәт иткән милләт, ишетсен колагыгыз, балалар, исем алыштыруга юл куймас!

– Шулаен шулайдыр да, авыл кешесе сөйләшкәндә аны-моны уйлап тормый шул, Нигъмәт. Әйтергә ничек җайлы – шулай кыскарта...

– Бәдринур, кеше нәрсә әйтер?.. Юкса, Нигъмәт Хәким татар халкының әдәби җәүһәрләрен җыя, тел белгече санала, ә үз кызына җүнле-башлы татарча исем дә куштыра белмәгән, диярләр.

– Ярар, – дип, тирән сулыш алып куйды Бәдринур. Нигъмәтнең ихлас борчылып сөйләгән сүзләреннән аңарга уңайсыз булып китте, әлбәттә. – Үзеңнең хәлләрең ничек соң? Берни сөйләмисең.

– Барысы да яхшыга таба бара, Бәдринурым. Бар хыялым Казанга кайту иде. Кайттым. Эшкә урнаштым. Яшь буынга белем бирәм. Инде тагы да зуррак теләгем – Казанда үз фатирыбызны булдырып, сине, балаларны

халкыбызның пайтәхетенә алып килү. Юкса, гомеребез аеры-чөере яшәп уза...

Дөрес фикергә җавап юк, дигәндәй, Бәдринур бу сүзләрне җавапсыз калдырды, хуплавын белдереп башын гына какты.

– Бер дә өстең-башыңны карамыйсың, дип әйтимме... Ничә ел инде менә, һаман шул бер үк кәчтүм, шул бер күлмәк белән йөрисең. Аягыңа кигән нәмәрсәнең дә табаны ашалган күренә.

Бәхетле елмаеп, башын сак кына янтайта төшеп, хәләл җефетенең җилкәсенә салды Нигъмәт. Бу аның рәхмәте дә, хөрмәте дә, хатыны белән тулаем килешүен аңлатуы да иде. Җылы, йомшак һәм шул тиклем якын кешесе бар ич аның...

– «Җаныкаем» диден түгелме, тагы бер генә тапкыр булса да кабатла әле шул сүзеңне. Сиңа әйтәм, әй, Бәдринурым – нурым минем...

– Йә-йә, җитәр сиңа, балалар барын онытасың, телеңә салынып утырма әле, яме... – дип, тыйнак кына ирен читкә этәрде хатын. – Минем киңәшләрне хәтереңә киртләп куй, кара аны, онытма.

– Бәдринурым... – дип куйды Нигъмәт. Тагы ни әйтсен соң ул?

## 4

Нигъмәтнең Еланлыга кайтуына ике-өч көн уздымы-юкмы, авыл капкасыннан затлы тарантаска җигелгән юртак чабып килеп керде. Аны күреп калучылар, һичшиксез, кызыл байрак эленгән советлар бинасы каршысына тукталыр, дип фаразлаганнардыр. Әмма алар ялгышкан булып чыкты, юртак ул бинаны гүя абайламады, тузан туздырып ары узып китте. Бераз баргач, каршысына йөгереп чыккан малай-шалайлар янына барып туктады. Тарантаска җәелеп утырган өлкән яшьләрдәге абзыйның карлыккан тавышы ишетелде:

– Яшь коммунарлар, – дип дәште ул яланаяклы малайларга, – Хәкимовларның өе кайсы урамда, шуны күрсәтмәссезме?

– Хәкимовлар... – дип кабатлый-кабатлый бер-берсенә карашып алды бала-чага. Чөнки авылда кешеләрне фамилияләре белән түгел, нәсел кушаматлары яисә исемнәре белән бер-берсеннән аеру гадәткә кергән. – Белмибез шул, абзый...

– Авылыгызны илгә таныткан Нигъмәт Хәкимне дә белмисез, оят түгелме, ә, яшь коммунарлар? Сездән сорыйм?..

Малайлар һаман аптыраушта. Бу мыеклы абзый тәмам табышмак чиштерә бит, җавап табучы гына күренми. Үзләренә күрә гөманларга ук керештеләр.

– Ә ул, нәрсә, Сабан туе батырымы әллә?

– Сабантуй батыры Нигъмәт түгел бит, Рәхмәтулла...

– Соң, Казанның үзеннән кунакка кайткан Нигъмәт Хәкимне дә белмисез, ыштан төбендәге кыңгырауларыгыз төшеп калмагандыр бит?

Күңелләре булып рәхәтләнеп көлешеп алды малай-шалай, «кара әле, синеке төшеп калмаганмы» дип, бер-берләренә төртешеп, үзара кызык таптылар.

– Казаннан дидегезме? Казан тикле Казанга безнең Еланлыдан кем барып җитте икән?..

– Абзый, ә ул Әдибәләрнең әтисе түгелме икән?.. Алар, әнә, теге тыкрыкның башындагы соңгы өйдә яшиләр. Бәләкәй генә өй булыр...

– Белгәч, ник басып торасың, утыр тарантаска, күрсәтерсең, – диде шаян абзыйлары.

Юл күрсәтүче ялындырып тормады, кемгә әле шундый бәхет тәтегән, үз дәрәҗәсен белеп, бер мәртәбә борынын тартып алды да дилбегә тотып алда

утыручы ат хуҗасы янына менеп кунаклады. Тегесе дилбегәне какты, ат юртып китеп тә барды. Малай-шалай дәррәү торып, ат артыннан калышмаска тырышып, йөгерергә кереште. Юл күрсәтүче «ташбаш»ның исә авызы колакта, юл күрсәтү белән генә чикләнеп калмыйча, дус-ишләренә дә берөзлексез кулын изәде.

***

– Өй каршына ниндидер җигүле ат килеп туктады, әтисе, – дип куйды, ишегалдында тавык-чебешкә җим сибеп йөргән Бәдринур.

Ул да түгел, болдырда Нигъмәтнең ипле һәм тыйнак авазы яңгырады.

– Ходаем, Мәҗит абзый Гафури үзе килеп чыккан түгелме соң?.. – Йөгереп диярлек барып капканы ачып җибәрде ул. – Әйе, Мәҗит абзый! Хуш киләсең, Мәҗит абзый... Безнең якларга нинди җилләр ташлады үзеңне?..

– Синең белән көрешергә дип махсус килдем. Качып кына ятарга уйлаган идеңме әллә, булмас. Кайда-кайда, әмма Башкортстанда миннән кача алмассың, Нигъмәт туган.

Бер-берсенә җәт-җәт атлап якынлашты алар. Иң элек куш уч биреп күрештеләр, аннан бер-берсенең аркаларыннан кага-кага кочаклашып алдылар.

– Килеп чыгуың бик тә яхшы булган бит әле, Мәҗит абзый.

– Гомер уза, Нигъмәт, бер күрешү – үзе бер гомер, диләр бит... Тәндә җан барында күрешмәсәк, хәл белешмәсәк, оятын кая куярбыз?

– Хуш киләсез, әйдә, өйгә керик. Юлда арыгансыздыр...

– Сабыр ит, иң элек юл күрсәтүчене төшерим тарантастан, – дип, әле булса ат хуҗасы белән янәшәдә утырган малайны күтәреп җиргә төшерде ул. – Күрмисеңме әллә, әнә минем нинди дусларым бар сезнең авылда. Рәхмәт яшь коммунарларга!

Аннан ат артыннан йөгереп килеп әле булса мыш-мыш сулыш алып торган малайлар төркеменә игътибарын юнәлтте. Кулындагы юл сумкасыннан малайларның һәркайсына берәр кәнфит өләшеп чыкты.

Ә тегеләрнең исә, кәнфиттән бигрәк, әле генә колаклары белән ишеткән яңалыкка ышаныргa-ышанмаска белми, телләрен йотып, аптырашта калып торган мәле. «Мәҗит Гафури» дип эндәштеләр түгелме соң бу абзыйга?! Гафуриның үзен танымасалар да, аның исемен ишетмәгән кеше юктыр. Малайлар тәмам җитдиләнә төште. Соңгы арада өлкәннәрнең телендә гел Гафури исеме бит...

– Абый, сез әллә Мәҗит Гафуриның үзен беләсезме? – дип сорап куймасынмы, тарантасның түрендә утырып килгән малай.

Шагыйрь, мөлаем елмаеп, аның такыр башыннан сыйпады.

– Ә синең исемең ничек соң?

– Сәми...

– Андый исем буламы? Тутырып әйт, исемеңне бозма, – диде аңарга Гафури.

– Каян белдең, абзый? – дип, авызын ачып, хәйран калып торды малай. – Бабам миңа Сәмигулла дип исем куштырган.

– Шуннан белдем, «Сәми» дигән исем булмый, ә менә Сәмигулла – исем дисәң дә исем ичмасам! Җырлап тора бит. Сә-ми-гул-ла... Нинди матур исем! Карагыз аны, икенче юлы исемнәрегезне бозып сөйләшсәгез, колагыгызны борырмын. Ул малайларның барысына да ишетелерлек итеп әйтте. Һәм кулын болгап хушлашты да:

– Ә хәзер барыгыз, уйнагыз, үз юлыгызда булыгыз, – диде.

Өйгә узып, хәл-әхвәл белешеп чәйләп тә алгачтын, Мәҗит Гафури тәкъдим кертте.

– Нигъмәт, хәтерлисеңме, без синең белән теге вакытта, кайсы елда булды соң әле ул, Әй елгасы буенда, Лачын-таш каршындагы бер матур тугайда утырган идек. Гомернең андый мизгелләре сирәк була, шул күңелгә уелып калган.

– Безнең тыкрыкны, өйне онытсаң да, Мәҗит абый, Лачын-ташны онытмагансың, кызык килеп чыга бит әле. Ул күрешү, ялгышмасам, 26нчы елның җәй урталарында иде булса кирәк. Авыл халкының печәнгә төшәргә әзерләнгән чагы. Мин шул көннәрдә генә Ташкенттан кайтып төшкән идем кебек.

– Әйе, болында чалгы кайраган авазлар ишетелеп торганы хәтергә уелып калган. Әй гомерләр...

– Юкка гына ул гомерне аккан суларга тиңләмәгәннәрдер, күрәсең... – дип, тирән көрсенеп куйды Нигъмәт.

– Анысы шулай, – дип килеште Гафури. – Әмма онытылмаслык бер хатирә буларак күңелгә уелып калган ул урын. Андагы табигатьнең матурлыгы төшләремә кереп йөдәтә кайчак.

– Килешәм, мин үзем дә туган авылны, авылда узган бала чакларымны сагынган минутларда яшел чирәм өсләренә сузылып ятып Лачын-ташка сокланып туймаган чакларымны искә төшерәм... Әйтеп бетергесез матур бит безнең яклар!

– Һәркемнең туган ягы, туган авылы үзенә күрә ямьле һәм кадерледер. Нигъмәт, булмаса, алып бар син мине шул Лачын тавы янына.

– Бүген үкме?

– Әйе, бүген, менә хәзер үк. Икәүдән икәү генә сөхбәт итеп тә утырырбыз шунда. Теге, тешләрне сындырырлык салкын чишмәнең суларын авыз итәрбез...

– Сез өлкән кеше, Уфа якын түгел, ерак юлдан килгәнсез, Мәҗит агай, бәлки ятып, бераз ял итеп алырсыз. Ә Лачын-ташка иртәгә барырбыз.

– Юк, Нигъмәт, бүген ниятләгән эшне иртәгесе көнгә калдырмыйбыз. Беренчедән, мине иртәгә Уфада көтәләр. Икенчедән, табигать кочагында утырудан да матуррак ял булырга мөмкинме?.. Самавырың белән чәйнегеңне тарантаска сал да киттек. Ә мин үзем белән гармун да алып килдем. Онытылмаслык итеп тагы бер утырыйк әле, булмаса...

***

Өйлә вакыты әле яңа узып, көннең кичкә авышырга-авышмаска белми икеләнеп калган бер мәле иде. Көн җылы, рәхәт, әмма, артык кыздырмый да. Баш өстендә, анда-санда ак болытлар йөзеп йөри, гүя кояштан сакланыр өчен махсус күтәрелгән шәмсияләр, диярсең. Хәтфә сыман җәелгән яшел үләннән җиләк исләре кушылган салкынча рәхәтлек күтәрелә. Ул гына аз, дисәгез, Лачын-таш тарафыннан әллә нигә бер булса да талгын җиләс җил исеп куя. Әй елгасының өсте тып-тын, балыклар көн кызуыннан су төбенә качкан, ә бакалар яр читендәге камышлар арасында йокыга талган булса кирәк. Аратирә сизелер-сизелмәс кенә чишмә челтерәгән аваз колакка чалынып китә.

Нигъмәт, хуҗаларча, җәт кенә яшел чирәм өстенә өйдән алып килгән җәймәне җәеп куйды. Чишмәдән су китереп самавырын көйрәтеп җибәрде. Уртадагы бакыр подноска яңа аертылган башкорт балы һәм Бәдринур пешереп җибәргән җылы коймак килеп кунаклады. Бәхет өчен, күңелләре бер дулкында тибрәнгән, бер-берсен ярты сүздән аңлый белгән, бер-берсен сагынган зыялы ир-атлар өчен тагы ни кирәк?!.

– Йә, – диде җәймә өстенә бер кулына таянып кырын сузылып яткан шагыйрь. – Дөньяда ниләр бар? Казан ничек? Казанда нинди яңалыклар, кемнәр белән күрешәсең, кемнәр белән аралашасың, сөйлә... Байтак гомер инде Казанга барып чыга алганым юк...

Нигъмәт иң элек бөтнек, карлыган яфрагы һәм әйләнә-тирәдә үскән тагы ниндидер чәчәкләр салып әзерләгән чәй тәкъдим итте кунагына. Шуннан соң гына Гафуриның сорауларына җавап сүзен башлады.

– Казан кайный, Мәҗит агай. Үземнең дә аңлап бетерә алганым юк әле ул шәһәрне. Анда сугылып, монда бәрелеп йөрергә яратмыйм. Минем вакытым да юк. Таныган кеше белән күрешәм, сораганга җавап бирәм. Һәркемнең үз эше, үз мәшәкатьләре, үз дөньясы. Кешеләр бер-беренә ачылып та бетми кебек, әллә ышанмыйлар да инде, аңламассың. Мин моны үземчә заман шаукымыннандыр дип уйлыйм. Чөнки, дөньялары да бигүк тотрыклы түгел бит әле. Ил генә түгел, милләт һәм аның зыялылары да икегә, өчкә бүленде.

– Дөньяны гаепләмә, хикмәт анда түгел, – дип сүзгә кушылды Гафури. – Кешеләр үзләре үзгәрде, миңа калса. Сезнең даирәдә, зыялы һәм укымышлы кешеләр арасында бу аеруча күзгә ташлана торгандыр. Казанны сагынып яшәсәм дә, минем үземә Уфа күпкә якын һәм аңлаешлырак шәһәр. Бездә ничектер, тыныч, тормышның агышлары да иплерәк, дип әйтимме икән...

– Сез хаклы булсагыз кирәк, Мәҗит агай. Минем дә Уфаны сагынган чакларым бик еш кабатланып тора.

– Нигъмәт, тукта әле, болай булмый, – дип, кинәт ни беләндер килешеп бетмичә, башын күтәрә төште шагыйрь. – Мин сине аңлый алмыйм бүген, син нәрсә, миңа әле «агай», әле «абзый», әле «абый» дип эндәшәсең, инде «сез» дип тә сөйләшә башладың кебек. Безнең, бу беренче күрешүебезме, әллә чит итә башладыңмы инде?.. Буржуйлар сыман «Әфәнде» дип кенә әйтәсең калды... «Мәҗит абый» дип, үзебезчә – саф татарча эндәшә идең кебек «Галия»дә укыган чакларыңда. Шул җитмәгәнме?..

– Дулкынланудан булса кирәк, Мәҗит абый. Байтактан күрешкәнебез дә юк ласа. Сез Башкортстанның аксакалы, олы әдибе һәм шагыйре дә бит әле...

– Ә син – төрки дөньяның күренекле тел галиме, бөтен илгә мәгълүм әдәбият белгече.

– Теге, Крыловның «Кәккүк белән әтәч» мәсәлендәге кебек макташып та алдык менә, – дип елмаеп җибәрде Нигъмәт.

Гафури да аңарга кушылып мыек астыннан гына кеткелдәп куйды һәм үзен кызыксындырган чираттагы сорауга күчте.

– Теге елгы очрашуыбызда, Нигъмәт, син «Идегәй» дастанын матбугатка хәзерләү өстендә эшләвең хакында сөйләгән идең. Ул эшнең очына чыга алдыңмы? «Идегәй»не уку бәхете насыйп булырмы безгә дә?

– Эш төгәлләнде дип әйтергә була, Мәҗит абый, тагы бер кат карап чыгасым калды. Остазым Самойлович та ашыктыра. Боерган булса, якын араларда, дип ышандырам.

– Менә монысы өчен рәхмәт үзеңә, һичкемнең кодрәте җитмәгән зур эшкә алындың. Аны тәмамлап чыгуыңа да шигем юк, ышанам.

– Китап булып басылып чыккач, беренче нөсхәсен үк сезгә юллаячакмын, Мәҗит абый.

– Вәгъдәме?..

– Вәгъдә!

Килешүне теркәп, кул бирештеләр үзара. Гафуриның йөзе балкып китте.

Дус-ишләренең, милләтенең һәр уңышы өчен ихлас куанып яшәгән риясыз һәм олы җанлы бер зат иде ул.

– Инде тагы башка сорау. Әдәбият дөньясыннан кемнәр белән аралашасың Казанда, Галимҗан Ибраһимов белән күрешергә туры килмәдеме?

– Казанга килүемне ишеткәч тә үзе кереп чыкты институтка. Хәлләремне сорашып утырды. Ярдәм кулы сузарга әзер булуын әйтте.

– Бик яхшы, Галимҗан – олы язучы һәм дәрәҗәле шәхес. Аның белән аралашуыңны хуплыйм.

– Институтта ел дәвамында Җамал Вәлиди белән бер кабинетта утырдык.

– Чү, колагым ялгыш ишеттеме? «Утырдык» диден түгелме. Җамал белән бер-бер хәл булмагандыр бит?

– Ишетелмәдеме? Аны соңгы араларда гына кулга алдылар.

– Нәрсә булды икән, сәясәт белән шөгыльләнми иде кебек. Төпле акылга ия, бик тә зыялы кеше иде бит югыйсә...

– Үзегез беләсез, хәзер күбрәк акыллы һәм зыялыларны эзәрлекләү китте.

– Андый нәтиҗә ясама, большевикларга тел-теш тидергәнне мин өнәп бетермим, – диде Гафури. Үзе һаман әле генә ишеткән яңалыкка ышанырга да, ышанмаска да белми аптыраошта калган, шул хәбәрдән айный алмый тынгысызланды. – Тукайның иң авыр чакларында аны яклап чыккан кеше Җамал Вәлиди булды. Шигырьне такмактан һәм назымнан аерырга өйрәтүче дә ул. Тел гыйлеме өлкәсендә һәм, тагы да килеп, халык авыз иҗатын туплап аны халыкның үзенә кайтару өлкәсендә кылган хезмәтләре дә бихисап... Кызганыч, бик тә кызганыч. Ишетмәдеңме, нидә гаепләделәр икән үзен?

– «Буржуаз-милли идеяләр таратуда» гаеплиләр кебек. Институтның астын-өскә китерделәр соңгы арада, мине дә чакыртып йөдәттеләр. Җамал Вәлидине «фаш итәргә» димлиләр. Яла яктырмакчы булалар. Юк, дидем, фаш итәрлек һичбер нәрсә белмим, дидем.

– Дөрес эшләгәнсең. Гаепсезне гаепләү ярамый!

– Әмма кемнәрдер шул эш белән көн күрә, – дип, борчылуын белдерми кала алмады Нигъмәт Хәким. – Алладан да курыкмыйлар, имансызлар.

– Хөсетлектән эшләнә бу, – дип нәтиҗә ясады Гафури. – Кулыннан эш килмәгән кеше башкалар белән булышучан. Ярар, тирәнгә кермик әлегә, Җамал әфәнденең гаепсез булуына иманым камил. Озак тотмаслар, чыгарырлар.

– Гали Рәхим һәм Газиз Гобәйдуллиннар белән дә еш кына күрешеп, сөхбәт итеп утырырга туры килә торган иде. Алар Җамалетдин әфәнденең күптәнге дуслары, фикердәшләре, – дип, бая ук бирелгән сорауга җавабын дәвам итте Нигъмәт.

– Менә бит, менә бит, нинди шәхесләр белән аралашасың, – дип, соклануын белдереп башын чайкап утырды Гафури. – Һәркайсы милләтнең каймагы саналган фикер ияләре. Казанның шул ягы бар, Тукай әйтмешли, анда мәгърифәт һәм анда нур... Төрки дөньяның иң затлы гыйлем ияләре тупланган «гыйлем казаны» бит ул. Бу яктан син бәхетлесең, Нигъмәт.

– Анысы шулай. Әмма төрле имеш-мимеш сүзләр йөри. Бу олуг затларның да җаны тыныч түгел дип беләм. Алар артыннан да бүген булмаса, иртәгә килеп җитүләре бик ихтимал.

Башын чайкап куйды Гафури. Бу хәбәрләрдән кәефе шактый кырылган иде аның. Ләкин сүз куертырга теләмәде.

– Ә шагыйрьләрдән Такташны, Хәсән Туфанны очратканың булмадымы?

– Такташның сәламәтлеге бигүк яхшы түгел, диләр. Шигырьләрен укырга керешсәң, аерыла алмаслык, шөбһәсез, сирәк туа торгандыр андый талант.

Кызганычка каршы, үзе белән әлегә очрашырга туры килмәде. Ә Хәсән Туфан белән еш кына күрешәбез, уй-фикерләребез дә килешә. Бик тә тыйнак, нечкә хисле һәм нәфис шигъри каләмгә ия бер шагыйрь дип уйлыйм аны.

– Яшьләрнең күбесен белеп тә бетермисеңдер инде. Анда «җидегәнчеләр»нең колакларыннан борганнар, дигән хәбәрләр йөри.

– Шулай булуы бик тә ихтимал, Мәҗит абый. Әмма, Хәсән Туфан үзе ул хакта сүз кузгатмагач, сораштырырга уңайсызланам. Гадел Кутуй да шаярып кына сөйләшә, зарланганын ишетмәдем. Хәер, аларның гаепләре нидә булуы белән кызыксынганым да юк. Үзләре белә торганнардыр. Үземә калса, әдәбиятта төркемнәр оешуны мин җитди эш дип санамыйм. Аерым-аерым алсаң, һәммәсе, иҗат ягыннан да, шәхес буларак та йолдыздай балкырга сәләтле егетләр, дип беләм.

– Каш ясыйм, дип, күз чыгара күрмәгәйләре тагы...

– Миңа да шулай күренә. Араларында минем бер якташым да бар. Шигырьләре алай бигүк күңелгә ятышлы булмаса да, актив, эзләнүчән һәм өметле генә егет күренә үзе. Мин сезгә аның хакында соңгы хатымда язган да идем кебек.

– Әйе, язган идең. Шигырьләрен белмәсәм дә, исеме колакка чалынган кебек. Шигырь язучы аз түгел инде ул безнең татарда... Тукай милләтне уятты. Уятты һәм китеп барды, – дип, үзалдына моңсуланып та алды кебек Гафури. – Әмма чын шагыйрьләр күп булмый, санарга кулдагы бармаклар да җитә торгандыр.

– Мин дә шул ук фикердә бит, Мәҗит абый. Куанып бетә алмыйм, шигырь белән мавыгуымны да вакытында ташладым. Тукайлар, Сәгыйть Рәмиев, Такташ һәм Дәрдемәндләр сирәк туа торгандыр шул.

Бераз үз уйларына бирелә төшеп, шул урында тамак кырып куйды Гафури. Бу аның нәрсә беләндер килешеп бетмәве турында сөйли иде булса кирәк.

– Килешәм, Нигъмәт, син шигырьне тирәнтен аңлый һәм бәһали белә торган кеше. Әмма... – дип, әйтергәме-әйтмәскәме дигәндәй, икеләнеп торды ул бераз. – Шуны әйтәсем килә, алтын приискалары тоткан Дәрдемәндне Тукай, Сәгыйть һәм Такташлар белән янәшә куеп сөйләшүеңне һич кенә дә кабул итә алмыйм.

– Мин аларның шагыйрьлек кабилиятләрен күздә тотып әйтәм, Мәҗит абый.

– Менә бу урында, Нигъмәт туган, син нык ялгышасың, дип уйлыйм. Илдә сыйнфый көрәш әле тәмамланмаган, сыйнфый көрәш әле дәвам итә. Буржуйлар белән эшче-крәстиян вәкилләрен янәшә куеп сөйләшүдән сак булырга кирәк. Мин сиңа шуны киңәш итәм, башкача һичкайда кабатлый күрмә бу хатаңны.

– Мәҗит абый, мин сезне ихлас күңелдән хөрмәт итәм һәм олылыйм. Шулай да үз фикеремне бераз шәрехләргә рөхсәт итәрсез бит?..

– Йә, тыңлап карыйк, – дип, әле генә үзенә яңартып бирелгән чәйне тәмләп куйды Гафури.

– Әдәбиятта, аеруча аның шигырь дигән үтә нечкә вә нәфис бер бабында сыйнфыйлык төшенчәсен алга чыгару дөрес булмастыр ул. Дәрдеменд фәлсәфи шагыйрь, үз халкын, үз милләтен ихлас сөйгән, аны укымышлы һәм зыялы итеп күрергә бөтен көчен, кабилиятен куйган шагыйрь. Мин үзем әдәбиятыбызда аның да лаеклы урыны бар һәм булырга тиеш дип саныйм.

– Чү, кардәшем, мин һәм минем кебекләр бер кабым ипи хакына ялланып эшләп, тузанлы шахталарда кан түкереп, бөкреләре чыкканчы бил бөгеп эшләгән бер дәвердә алар – алтын приискасы хуҗалары – ак күлмәк якаларына күбәләк тагып, күкрәк киереп, табын артында акча санап утырды. Революцияне без шуның өчен ясадыкмы? Һичбервакыт килешәчәк түгелмен бу фикерең белән...

– Ярый, хуш, Мәҗит абый, мин үзем дә күп балалы ярлы гаиләдә туып үскән кеше. Сезнең сыйнфый көрәш рухы белән иҗат ителгән әсәрләрегез минем өчен һич кенә дә ят түгел. Әмма, Закир һәм Шакир Рәмиевләрнең татар-башкорт һәм казакъ халыкларының белемен күтәрүгә, тарихын өйрәнүгә, дөньяга карашларын киңәйтүгә керткән өлеше бәяләп бетергесез. Алар акчасына чыккан «Вакыт» газетасы һәм «Шура» журналы безнең милли мәсләкле академиябез саналырга лаек. Риза хәзрәт Фәхретдинов, Йосыф Акчура, әле генә үзебез олылап искә алган Җамал Вәлиди, Шәриф Камал, Борһан Шәрәф кебек дистәләгән зыялы фикер ияләребез – һәммәсе дә «Вакыт» һәм «Шура»да язышып бөтен төрки дөньяга танылдылар. Монда Рәмиевләрнең фидакярлеген һич кенә дә инкарь итеп булмастыр кебек...

Шагыйрь тыңламады түгел, тыңлады Нигъмәтнең сүзләрен. Нигезле һәм дәлилле итеп сөйли иде ул. Әмма аны бүлдерергә форсат чыгуга ук, үзенекен дәвам итте.

– Син, Нигъмәт, нинди дәвердә һәм нинди илдә яшәгәнлегеңне онытасың кебек. Үткәнгә кайту юк! Алга карап эш итәргә кирәк... Ә Дәрдемәндкә минем үз мөнәсәбәтем һәм һичбервакыт үзгәрәчәк түгел. Ул – буржуазия вәкиле. Димәк, минем дошманым. Ул үз сыйныфын гына кайгыртты, үз сыйныфы өчен язды.

– Мин килешмим, – дип җавап кайтарды Нигъмәт шундук. – Әмма сезнең белән тарткалашу түгел иде уемда. Бәлки, шушы урында туктатып торырбыз бу бәхәсне.

– Әйе, бик рәхәтләнеп килешәм, – дип күтәреп алды Гафури. – Каршыбызда, әнә, мине онытa күрмәгез, дигән сыман, самавыр кайнап утыра. Гармунның да җырлыйсы килә торгандыр. Дөньялар матур, Нигъмәт туган, күр син ул болындагы чәчәкләрне, күр син ул күбәләкләрне... Лачын-таш әйләнәсендә, әнә, карлыгачлар бер-берсен куышып уйный.

– Тартып җибәрәсезме соң әллә, Мәҗит абый, шул гармунны, дим?..

– Нәрсә уйныйм икән соң, – дип, кырын яткан җиреннән торып утырып, кулындагы гармунның телләренә баскалап уйга бирелеп торды Гафури.

– Уйнап җибәрегез булмаса, «Бер матурның балдагын, йә калфагын»...

– Килештек. Мин уйнармын, син җырларсың, күңелең тулса, еларсың... Шулай бит, Нигъмәт!

Һәм артык уйлап, ни уйныйм икән, дип баш ватып тормый гына борынгы җырларның да иң моңлысын – «Зөлхиҗҗә»не сыздырып уйнап җибәрмәсенме Гафури. Бу минутта аны һич кенә дә үтә тыйнак, сабыр холыклы олпат шагыйрь димәссең, гүя кичке уенга чыккан шаян һәм җор табигатьле, баскан җирендә ут уйнатырга сәләтле авыл егете иде ул. Гармун аңа елдан-ел ерагая барган яшьлеген кайтарды кебек, чалара төшкән кашларын сикертеп куйды ул, чаяланып, күзләрен кыскалап алган булды. Күз алдында балкып, яктырып китте ул. Кем дә булса шагыйрь Мәҗит Гафуриның шул халәтен тасвирлауны укыса, әлеге мизгелне үз күзләре белән күрмәгән кеше, һич ышанмас иде. Көйнең аккордын тәмамлагач та, кинәт кенә үзгәреп, моңсуланып калды, башын кыңгыр сала төшеп, үзе уйнаган көйгә бераз карлыга башлаган тавышы белән тын гына, ипле генә кушылып җырлап та җибәрде:

Ялан да гына җирдән лә болан килә... Зөлхиҗҗә...
Уйсу да гына җирдән лә, әй, түтә дип, Зөлхиҗҗә..
Төн уртасы җиткәч тә, бер кыз елый, Зөлхиҗҗә...
Яшь гомерем заяга, әй, үтә, дип, Зөлхиҗҗә...

Каян килә бу моң?!. Тальян гармуны төймәләре тудырамы аны?.. Гафуриның тын гына, талгын гына яңгыраган тавышыннанмы ул?.. Урал тау итәгенә елышкан Лачын-таш тарафыннанмы... Башкорт иленең таулар, үзәннәр аша офыкларга барып тоташкан очсыз-кырыйсыз киңлекләреннәнме?.. Ерак тарихларга барып тоташкан халык күңеленнән, аның бәгыреннән саркып агыламы соң әллә бу моң?..

Сызылып та таңнар ла аткан чакта, Зөлхиҗҗә,
Сандугачлар сайрый ла, ай чут-чут дип, Зөлхиҗҗә.
Мендәркәен кочаклап бер кыз җылый, Зөлхиҗҗә,
Җанкай ла җанаш, кем, ай юк-юк дип, Зөлхиҗҗә.

Күңеленнән генә кушылып үзалдына Нигъмәт тә җырламый булдыра алмады. Әмма тавышын Гафуриның үзенә сиздермәскә тырышты ул. Аңарга кушылып җырлау һичшиксез артык булыр иде. Чөнки тальян уйный, шагыйрь җырлый... Шул гына булса икән дә бит, тальян моңына, шагыйрь җырына кушылып, Мәҗит Гафури мышык-мышык елый да иде...

Нигъмәт Хәким дә йөзен читкә борды. Әллә Мәҗит абыйсын уңайсыз хәлгә куюдан читенсенде ул, әллә үзенең күңел йомшаклыгын яшерергә уйлады, аңламассың... Озак кына сүзсез калып, уйлары һәм кичерешләре чоңгылына иңеп, күкрәк тутырып бер сулыш алырга да кыймый тынып торды алар.

– Эх, бу татар-башкортның җырлары! – дип, үзалдына әйтеп куйды Нигъмәт. Тынлыкның артык озынга сузылуына эче пошып әйтте кебек ул моны.

– Кая гына барып чыкма, моң каршы ала, моң озатып кала шул безне. Туган-үскән ил, туып-үскән авылларыбызга да моң чакырып кайтара...

– Безнең халык моңнан яралдымы икән әллә, дип уйланган чакларым була минем дә. Ә сез, Мәҗит абый, халык җырларын үзәкләрне өздерерлек итеп уйный да, җырлый да беләсез.

– Моңның ни икәнлеген аңламаган кеше булмас. Булса, андыйларны туган иленнән, туган җиреннән читкә җибәреп тотар идем. Моң – яратудан гына түгел, ул сагыштан һәм юксынудан да яраладыр кебек тоела миңа...

– Кызыклы күзәтү, тәү кабат ишетүем, – диде Нигъмәт.

– Миңа бәхет эзләп чит җирләргә киткән шахтёрлар арасында байтак йөрергә туры килде. Аларның җырларын, аларның моңлануын ишетсәң иде син, Нигъмәт. Берәү сузып җырлап җибәргәндә, унар-унбишәр әзмәвердәй ир-атның такта караватларына йөз белән капланып мышкылдап елаганын күреп хәйран калган чакларым булды. Күз алдыңа китерә аласыңмы шуны?..

– Кайда гына яшәсә дә, җырсыз-моңсыз яши алмый торгандыр шул безнең халык.

– Казакъ авылларында да мөгаллимлек итәргә туры килде бит миңа. Алар да нәкъ безнең кебек. Дус-иш җыелса да, ялгызы калса да, казакъ кешесе кулына думбрасын ала. Һәм дөньясын онытып уйнарга керешә. Ул да үзе уйный, үзе җырлый һәм шул ук вакытта елый да...

– Тамырларыбыз уртак, җаннарыбыз уртак, шуңардандыр ул, Мәҗит абый...

– Килешәм, бик килешәм, – дип, башын читкә бора төшеп, йөткеренеп алды шагыйрь.

Үзе сиздермәскә, сер бирмәскә тырышса да, аның сәламәтлеге шактый ук какшаган күренә. Моны Нигъмәт байтактан тоеп утыра. Ул да түгел, йөткеренүеннән арынып, бөтенләй икенче яңа бер көй уйнарга керешмәсенме!

Яхшы хәтерли Нигъмәт, бу җырны теге чактагы очрашуларында да яратып һәм онытылып җырлаганнар иде бит алар.

Ул җырның сүзләрен гармун телләре гүя үзләре үк көй белән бергә яңгырата башлады кебек. Көй белән моң, моң белән җырның сүзләре бергә, тасма-тасма булып үрелгән иде, диярсең...

Олы юлның тузанын ла
Үзем күрдем тузганын;
Белми калдым, сизми калдым
Яшь гомремнең узганын...

Шул рәвешле, җырлый-җырлый, җыр тәмамланмас борын елый-елый язмыш юллары һәм хис дәрьясында йөзде алар. Һәр икесе үз язмышы, башларыннан кичкән һәм кичәчәк вакыйгаларны барлады, күзаллады булса кирәк. Җырдан туктап торган мәлләрендә үзара фикерләшеп алырга да онытмадылар. Җыр артыннан яңа җыр көйләп, эчкерсез сөйләшүләр арасында бер самавыр чәйне эчеп бетергәнче, әйләнә-тирәгә караңгылык төшеп, күктә йолдызлар калыкканчы, дөньяларын онытып утырды алар. Бар дөнья, Лачынташ һәм Әй буйлары тәмам тынып, тынычланып калган иде. Шул тынлыкта зәңгәр күк йөзендә атылган йолдызлар аларның мәңгелеккә үтеп барышы булмадымы икән?..

**5**

Казанга әйләнеп кайткан көнендә үк, кай арада күреп алган диген, аның янына әлеге дә баягы шигырьләр язгалап йөрүче якташы килеп керде. Килеп керүе булды, рөхсәт-фәлән дә сорап тормый гына, тәрәздә каршында торган табуреткага барып утырды. Остазы янына керсә дә, үзен монда хуҗа кебек хис итә иде ул.

– Нигъмәт абый, һай озак та йөрдең туып-үскән якларыңда, – дигән яңгыравык тавышы ишетелде.

– Туып-үскән якларда күпме генә торсаң да, озакка саналмый, якташ. Күргән кебек тә булмадым, санаулы көннәр узды да китте, – дип җавап кайтарды ул аңа.

– Сез югында монда үзегезне ике мәртәбә эзләп килделәр.

– Кемгә кирәгем чыкты икән? Ял вакытым бит...

– Черек күлдән, теге оешмадан.

– Ул халык белән алыш-бирешем юк иде кебек, нигә кирәгем чыкты икән?

– Җамал Вәлиди белән бер кабинетта утыргансыз лабаса. Ә ул – корткыч – үзе артыннан башкаларны да өстерәргә җыена түгелме икән?.. Сезне күрсәткән булса кирәк.

– Телең ни сөйләгәнне колагың ишетәме? – дип, тавышын күтәрде Нигъмәт Хәким. – Олуг галим турында андый сүз сөйләргә оялмыйсыңмы?

– Кайчандыр галим дә булгандыр, бәлки, әмма бүген – халык дошманы, буржуаз милләтче. Бу мин уйлап чыгарган ярлык түгел. Әллә сез аны якларга җыенасызмы?..

– Мин гаепләүче дә, яклаучы да түгел, якташым. Ләкин Җамалетдин әфәнде Вәлидинең милләтебез тәрәккыяте өчен гомере буе үз-үзен аямыйча эшләгән фидакяр зат булуында һич шигем юк. Менә күрерсең, аның гаепсез икәнлеге ачыкланачак. Киресенчә, яла ягучыларның үзләренә җавап бирергә туры килмәгәе әле...

Нигъмәт Хәкимнең соңгы сүзләреннән якташы сискәнеп киткәндәй тоелды, кинәт колак очларына кызыллык йөгерде. Бер сәбәпсезгә, ни дияргә белмичә, гаепле кеше сыман як-ягына карангалап торды ул. Һәм җавапсыз калуыннан уңайсызланып, кабалана-кабалана очы очка ялганмаган сүзләрен тезде.

– Яла ягучыларын белмим. Чыгарсалар, әйбәт булыр иде анысы. Гаебе бик зур икән бит, Солтангалиев белән дә элемтәдә торган, диләр үзен, өендә Троцкий китапларын да тапканнар. Кулъязмаларын да каядыр яшереп өлгергән, диләр. Сезгә бирмәгәндер бит ул аларны?

– Ә нигә әле сине аның кулъязмалары кызыксындыра? – дип сорап куймасынмы шунда Нигъмәт.

Бит очларына янә кызыллык йөгерде тегенең. Нигъмәт моны абайламады түгел, әлбәттә. Ләкин якташыннан шикләнергә яисә аңарга мөнәсәбәттә шөбһә белдерергә нигезе юк иде.

– Җамал әфәнденең архивы бик бай булган, диләр, шуңа соравым. Югалмасын иде, дим. Китаплары да күп булгандыр, Тукайның үзе белән, Риза Фәхретдиновлар белән дус булып, аралашып яшәгән кеше.

– Татар дөньясында, зыялылар даирәсендә Җамал әфәндене белмәгән, аны олыламаган кеше аз булгандыр ул... Хәтереңә киртләп куй, якташ, Җамал әфәнде милләтебезнең тәрәккыяте юлында Шиһабетдин Мәрҗани һәм Риза Фәхретдиновлар кебек үк бәяләп бетергесез хезмәт куйган кеше.

– Сезнең хакта да шулай, дип сөйлиләр, остазым, ишеткәнегез бармы-юкмы, ул кадәресен белмим, яшьләр арасында сезгә «академик» дигән кушамат тагылган. «Академик» дисәләр, бу Нигъмәт Хәким дигәнне аңлата икән Казанда.

– Юкны сөйләмә, без синең белән Крылов җәнапларының кәккүк белән әтәче түгел!

– Ишеткәнемне әйтәм, Нигъмәт абый, халык арасында шундый сүзләр йөри. Аннан килеп «Идегәй»не көтә Казан, ул дастанның дистәләгән вариантларын туплап, эшкәртеп бастырырга ниятлисез икән. Мин бит әдәбият-мәдәният әһелләре белән көн-төн аралашам, остазым. Барын да ишетәм, бар җиргә өлгерәм. Сезнең хакта легендалар йөри, күзгә күренми торган бер илаһи зат, ягъни фәрештәгә тиңләп сөйлиләр үзегезне. Институтта укыган лекцияләрегезгә керү мөмкин түгел, актлар залы шыгрым тулы, диләр.

Бу кайчан туктар икән дип түзде-түзде дә чамасын онытып юхаланырга керешкән якташын бүлдерергә мәҗбүр булды Нигъмәт.

– Җитте! Мактанышып утыруны җенем сөйми, – диде һәм өстәлгә махсус шапылдатып, яңа кайнап чыккан чәйнекне китереп куйды. – Әйдә, якынрак кил, туган як үләннәрен кушып чәй хәзерләдем менә. Бавырсак белән балны да авылдан алып килдем. Сүз сөйләп тамак туймас, чәйләп алыйк башта, аннан ашыгыч эшләрем дә бар.

Ашау-эчү дигәндә кыстата торган гадәте юк иде якташының, Нигъмәт моны яхшы белә. Аның бу гадәтен үз итүе, читләшмәве, якташ буларак якын күрүе дип кабул итә торган иде галим. Нигә кәнфитләнеп маташырга, икесе дә авылда туып үскән малайлар ич, өстәвенә якташлар...

Бер-ике бавырсакны авызга ыргытып йотып та куйгач, шагыйрь өрә-өрә чәй эчәргә керешкән иде, әмма авызын пешерде булса кирәк, пыяла тустаганын кире өстәлнең уртасына таба этәреп куйды.

– Минем бит, Нигъмәт абый, сезнең белән киңәшәсе җитди сүзем дә бар иде. Әйләнеп кайтуыгызны көтә-көтә зарыгып беттем.

– Тыңлыйм. Сөйләп кара.

– Сөйлим. Сез менә, Нигъмәт абый, «Идегәй»не бастырырга җыенасыз, Гали Рәхим белән Җамал Вәлидиләр халык авыз иҗатын туплаган, кайсылары тарих яза, сүзлекләр төзиләр, калын-калын китаплар чыгаралар. Һәм шул хезмәтләре белән танылалар, халык теленә керәләр. Ә мин менә шигырь язып йөрим. Аны бастырмыйлар, бассалар да, шул дәфтәр калынлыгы китапчык инде. Такташлар, Туфаннар барында шагыйрьгә дә санамыйлар безне, ыбыр-чыбырга саныйлар, бар дип тә белмиләр. Ә бит минем дә башкалар кебек гавам теленә керәсем, танылысым килә, Нигъмәт абый. Беләсез, гаиләм дә ишле... Миңа ни эшләргә, нәрсәгә алынырга кирәк, дип уйлыйсыз, бирегез, булмаса, бер киңәш...

– Эшләргә кирәк! – дип, шундук кистереп җавап кайтарды Нигъмәт Хәким.

Башын кашып алды киңәш сораучы.

– «Эшләргә» дип әйтү җиңел анысы, – дип сүз башлады ул бераз кичегә төшеп. – Ул кадәресен мин үзем дә яхшы беләм... Әмма нәрсә эшләргә, ни нәмәрсәдән башлап китәргә кирәк ул «эш» дигәннәрен?

– Халкыбыз озак еллар дәвамында үз мирасын, тарихын барлау хокукыннан да файдалана алмый яшәргә мәҗбүр ителгән. Шөкер, хәзер офыклар ачыла төште, дип әйтергә була. Тел белеменең, әдәбият вә мәдәният дөньясының кай тарафына баксаң, анда өйрәнәсе, тәртипкә салынасы, дөньяга чыгарыласы эшләр үз фидакярләрен көтеп тора. Тарихыбыз турында әйтәсе дә юк... Боларны сез, яңа, яшь буын вәкилләре башкарырга тиеш... Аңлашыламы?

– Аңлашылуын аңлашыла... – дип суза төште шагыйрь. – Ләкин нидән башларга, ул эшне башкарырга күпме вакыт кирәк, аңардан мин нинди файда күрәчәкмен һәм кайчан?.. Боларга җавап бармы соң, әллә ул җаваплар барысы да суга сәнәк белән язылганга охшашмы? Шуларны ачыкламый торып, ничек андый эшкә алынырга мөмкин?

– Якташ, – дип үз итеп, шагыйрьнең җилкәсенә кулын салды Нигъмәт Хәким. – Милләткә хезмәт итү, ул базарда сату итү түгел. Сату-алу, файда һәм керем кебек төшенчәләр базар өчен генә яраклы дип беләм. Халкыңа хезмәт итү фидакярлек сорый, алай итсәм, күпме алырмын, болай итсәм, күпме керер, дип яшәсәң, берни майтара алмассың.

– Юк-юк, сез миңа дөрес киңәш бирмисез! – дип чәбәләнеп каршы төшмәсенме шунда якташы. Һәм берочтан шактый ук кыюланып та китте. Тавышы күзгә күренеп, бермә-бер көрәя төште. – Мин, нәрсә, сезнең кебек картаеп, чәчләремә чал төшкәнче ачлы-туклы кеше почмагында, шушындый хәерчелектә, марҗа подвалында яшәргә тиешме?! Әллә гаиләмне, балаларымны, сезнең кебек, авылга кайтарып куярга киңәш итәсезме?.. Булмас...

Шул мәлдә күңеленнән генә нәтиҗә ясап куйды Нигъмәт: «Менә ничек! Мин уйлаганча беркатлы һәм эчкерсез зат түгел икән бит бу «якташ» дигәнем. Моның белән саграк булганда һәм тора-бара араларны ерагайта төшкәндә дә бик таманга киләчәк икән». Ул бит аның иң авырткан җиренә, күңелендә берөзлексез сыкрап торган ярага – гаиләсенә кагылды. Әмма бәхәсләшәсе, юктан давыл чыгарып тавыш күтәрәсе килмәде әлегә, ни генә әйтмәсен, ул аны барыбер аңламаячак. Ана сөте белән кермәгән, тана сөте белән кермәс, диләр андыйлар хакында. Шуңа да берни булмагандай, һични аңламаганга сабышып, тыныч һәмипле генә әңгәмәне йомгаклап куярга кирәк тапты.

– Син хаклысың, гаилә белән аеры-чөере яшәү бик авыр һәм дөрес тә түгел. Сүзләрең бик дөрес, балаларга, әни генә түгел, эти дә кирәк... Син

хаклы! Ә менә минем язмыш шундый булып чыкты. Укырга кирәк иде башта. Петербургка дүрт бала һәм хатынны ияртеп китеп булмый бит. Һиндстанга да алып китү мөмкин түгел. Әлегә, үзең күрәсең, менә Казанда да чакырып кайтарсалар да, бик көтеп тормаганнар, бер дә мактаныр урын юк. Тора-бара җайга салыныр дип уйлыйм анысы. Хәзергә менә шулай, үзең күрәсең...

Синең белән сөйләшер сүзем шуның белән тәмамланды дигәнне аңлатып, эш өстәле янына барып кулына китап алды Нигъмәт. Беренче очраган китапны алуы, кирәк булганы өчен түгел иде. «Бар чыгып кит инде» дип әйтәсе бик килсә дә, әйтә алмады.

Ә тегенең китәргә уенда да юк. Әрсезләнеп аның янәшәсенә, өстәл читенә үк килеп басты.

– Дөрес аңласам, сез, Нигъмәт әфәнде, мине куып чыгарырга җыенасыз кебек...

– Алай димәдем. Әмма үпкәләмә, якташ, ашыгыч эшләрем бик күп. Тавык та чүпләп бетерә алмаслык.

– Эшегез күп булуын беләм. Менә шуңа күрә дә тәкъдимем бар сезгә. Кайбер эшләрегезне миңа тапшыра аласыз.

– Ничек? Аңламадым... – дип, гаҗәпсенү катыш сорарга мәҗбүр булды Нигъмәт.

– Менә болай. Сезнең тел өлкәсендәге эшләрегездә мин ярдәмче була алмам. Ә менә әдәбият, шигырь кырында тәҗрибәм сезнекеннән аз түгел дип беләм. Шул уңайдан сезгә тәгаен тәкъдимем бар.

– Кызык, ул тәкъдим нидән гыйбарәт була инде? – дип, кинәт борылып әңгәмәдәшенең күзләренә текәлде галим.

– Бирегез миңа «Идегәйне»...

Телсез кала язды Нигъмәт. Бу дөньяда аз яшәмәгән югыйсә, кешеләрнең дә ниндиләрен генә күрергә, очратырга туры килмәде. Әмма бу кадәр, моның кадәрне очратканы яисә ишеткәне юк иде әлегәчә. Әллә соң ул аны үз акылында түгел дип саныймы?.. Ләкин бу юлы да ул якташына каты бәрелергә базмады. Ипле генә җавап кайтарды.

– «Идегәй»не мин ничек бирим, ул минеке яисә башка берәүнеке түгел бит, «Идегәй» – халыкныкы, аны безнең татар халкы иҗат иткән.

– Шуңа әйтүем дә, ул халыкныкы. Сезнеке түгел! Аны дөньяга мин чыгарырга тиеш, шагыйрь кеше! Ул миңа дан, дәрәҗә китерәчәк. Ә сез болай да билгеле кеше, сезнең хезмәтләрегез болай да чамасыз күп. Сез илгә, дөньяга мәгълүм тюрколог! Шул җитмәгәнме?..

«Инде бу сүзләренә нинди җавап табарга икән соң моның? Егет бит тәмам җитди рәвештә сөйләшә. Үзенә күрә логикасы да бар төсле... Әнә ич, күзләре уттай яна, иреннәре кысылган, йодрыклар йомарланган... Ризалашмасаң, хәзер үк көч белән тартып алырга, өстеңә арыслан булып ташланырга әзер...»

– Соң, алай бик чыгарасың килгән икән, чыгар, – дими чарасы юк иде галимнең.

Җанланып китмәсенме теге, шул арада бар кырыслыгын онытып, елмаю төсмере йөгерде аның күзләренә. Ике кулын канат урынына җәеп кочаклашмакчы да түгелме соң тагы... Ә сүзләре, сүзләре нинди...

– Килештек, димәк... Бирәсез, димәк... Бүген үкме? Әйе-әйе, бүген үк алам...

– Аңламадым, – дип әйтергә мәҗбүр булды Нигъмәт. – Чын-чынлап, мин сиңа нәрсә бирергә тиешлегемне аңламадым...

– «Идегәй»не, әнә теге өстәл читендәге папкаларны.

– Һәммәсен дәме?..

– Әйе, барысын да!

Бик гаҗәп сөйләшә бит әле бу... Усал итеп, артына утыртырлык итеп җавап бирергә иде дә бит үзенә. Шулай да ашыкмаска кирәк тапты.

– Ә син «Идегәй»нең ничә папкада саклануын беләсеңме соң? – дип сорап куйды ул, көтмәгәндә, беркатлыга салынган булып.

– Беләм. Сигез папкада. Әнә анда өелеп тора алар, өстәлнең сул ягында...

– Дөрес сөйлисең бит син, белмәгәнең юк ахры, – дип, үзалдына чираттагы мәртәбә хәйран калып башын чайкап куйды Нигъмәт Хәким. – Ул папкаларга күзең байтактан ук төшкән булса кирәк...

– Бирегез сез аларны миңа!

– Ә ни өчен дип әле мин аларны бирергә тиеш сиңа? – диде Нигъмәт, булдыра алганча тыныч һәм ипле тавыш белән. Әмма бер үк вакытта сизелер-сизелмәс кенә ирония төсмере дә салырга тырышты ул соңгы сүзләренә.

Тегесе бу сорауны көтмәгән иде булса кирәк.

– Аңлаштык бит инде. Сөйләштек... Килештек тә кебек, – диде ул. Бу сүзләре аның, Нигъмәткә адресланган булудан бигрәк, үзалдына мыгырдануга кайтып калды. – Үзе риза булды башта... Хәзер башкача сөйли. Бирәм, диден... Ир-ат сүзе бер булырга тиеш түгелме?!

– Менә ничек, мин сиңа күпме юллар үтеп, күпме кыенлыклар кичереп гомерем буе җыйган хезмәтләремне биреп чыгарырга тиеш булып чыгаммыни инде? Өндәме соң бу, әллә төш кенәме?.. Син үз акылыңдамы соң, якташ?!.

– Мин бурычлы булып калмам, бирегез. Яхшылык белән бирегез... Юкса...

– «Юкса»? Бу ни дигән сүз, син яный да беләсеңме әллә?

Максатка ирешү юлында нинди генә хәйлә һәм мәкерле алымнарга сәләтле кешеләр бар бит бу дөньяда. Шуларның берсе басып тора икән бит Нигъмәтнең каршында. Ә ул аны якташы буларак үз иткән, якын иткән иде. Аңа элек-электән, шәкертлек елларыннан ук ярдәм итеп килде, хәзер дә кулыннан килгән бар яхшылыкны эшләргә әзер.

– Янамыйм... Шулай да «Идегәй»не миңа бирүегез хәерле булыр, дип саныйм...

– «Идегәй»ле буласың килә, димәк?

– Дөресен әйтергәме?..

– Дөресен. Һәм турысын!

– Дөресе шул, Нигъмәт абый, «Идегәй» бик тә, бик тә кирәк миңа. Аны китап итеп бастырып чыгарсам, кеше теленә, кеше арасына керәчәкмен, киң җәмәгатьчелек каршында күтәреләчәкмен, аңлагыз шуны...

– Аңладым, – дип коры гына әйтеп куйды Нигъмәт Хәким. – Инде хәзер син мине тыңла, ярыймы?.. «Идегәй» – минеке түгел. Син халык арасына чык, аягыңа чабата киеп, җәяүләп авылдан-авылларга йөр, эзлә, тайга эчендә югалып яшәгән ерак авылларга бар, якташым. Ак сакаллы картлар һәм карчыклар сиңа аның төрле вариантларын сөйләр. Шуларны язып ал. Бәхетеңә туры килсә, кульязма хәлендә сакланганнарын да очратырсың. Шуларны тупла, анализла һәм тулы бер шигъри эпос хәленә китер... Аннан соң инде китап итеп бастырырсың. Мине аңладыңмы?

Җавап тегенең бугазына килеп тыгылды булса кирәк, колак очларына тикле кызарып чыкты. Үз-үзен кулга ала алмый торды бермәл, аннан һәр сүзендә төртелә-төртелә мыгырданырга керешсте.

– Миннән көләргә җыенасыз кебек, Нигъмәт әфәнде! Тайгага озатмакчы буласызмы?.. Барып чыкмас!..

– Көлмим, киңәш бирәм. Хезмәт куймый гына зур эшләр башкару мөмкин түгел, якташ.

– Карарбыз... Ярар... Тайгаларга барып чыгарга киңәш итәсез инде, ә?.. – дип, мыгырдана-мыгырдана ишеккә таба атлады шагыйрь. – Барып чыкмас! Карарбыз әле, кайсыбыз тайгага китәр дә, кайсыбыз Казанда калыр һәм «Идегәй»ле булыр... Карарбыз, – дип тагы бер мәртәбә кабатлады да ишекне тышкы яктан каты бәреп, хушлашырга да теләмичә, үз юлы белән китеп барды ул. Әллә ишек җиленнән, әллә тетрәнүдән шул мизгелдә ишек катында идәндә торган кәстрүлнең капкачы шалтырап идәнгә килеп төште. Аның яңгырап чыккан тавышыннан Нигъмәтнең йөрәге «жу-у» итеп куйды... Ә идәнгә төшкән кәстрүл капкачы туктарга, тынычланырга һич ашыкмый, иләмсез аваз чыгаруын дәвам итеп, әйләнепме әйләнә, зыр бөтерелә...

Көттереп кенә, ниһаять, бүлмәгә тынлык инде. Шомлы тынлык... Нигъмәт ярымкараңгы һәм кечкенә бүлмәдә бер ялгызы торып калды. Өстәл артына килеп кулына әле бер китап, әле икенче кәгазьне алды ул... Алды һәм кире куйды... Папкаларын актарган атлы булды. Укыйм, дисә, укыганы башына кермәде, кулына каләм алса, язар сүз тапмады... Эш кайгысы идеме соң, ни уйларга да белми, тынгысызланды ул берөзлексез. Урын җәеп йокларга да тырышып карады. Юлдан килгән көне иде ич, арылган... Әмма барыбер күзенә йокы эленмәде. Әле бер уй, әле икенче уй килде аның башына. Төн ката үз-үзен кая куярга белми изаланып чыкты ул.

«Изаланмаслыкмы соң! Дөнья болай да тыныч түгел... Кешеләр бер-береннән читләшкәннән-читләшә бара, бер-беренә ышанмыйлар. Таныш-белеш кенә түгел, дус-ишләр дә бер-береннән шикләнүчән булып китте соңгы араларда. Кемгә ышанырга белмәссең! Күр инде, «якташым» дигәне, инде күпме гомер туганнарча аралашып яшәгән күршесе дә аңарга янап чыгып китте түгелме? Күз алдына да китерү мөмкин түгел бу хәлне, кайчандыр синең киңәшең һәм ярдәмең белән мәдрәсәгә укырга кергән, үзең укыткан, авыр чакларында ашаткан-эчерткән шәкертең шундый сүзләр әйтсен инде...»

## 6

Көн арты көн уза торды... Көндәлек мәшәкатьләр белән атналар һәм айларның узып киткәнен дә абайламый каласың. Татар теленең үсеш проблемалары, аның грамматикасы һәм орфография мәсьәләләре – һәркайсы гыйльми нигезгә салынырга тиеш. Мәгариф эшләре буенча халык комиссариаты да ашыктыра бу эшләрне. Җирле партия һәм дәүләт органнары, теләге бармы-юкмы, сорамый, кызыксынмый гына, ислам диненең килеп чыгышы һәм тарихын диалектик материализм нигезендә яктырткан хезмәтләр язуны аның җилкәсенә салды. Агымдагы тел һәм әдәбият проблемаларына кагылган хезмәтләре дә әледән-әле чыгып торды. Әдәбият һәм тел мәсьәләләре буенча яңа дәреслекләр яисә бер-бер хезмәт нәшриятка килеп керә икән, аларга объектив бәя бирү өчен шулай ук аңарга мөрәҗәгать иттеләр. Берсеннән дә баш тарта торган түгел, телисеңме-теләмисеңме, алынырга туры килә. Тюркологларның Бөтенсоюз корылтаена делегат булып сайланды, әлеге тарихи җыенның документларын хәзерләүгә дә җәлеп иттеләр үзен. Көнчыгыш педагогия институтында укый торган лекцияләре дә чамадан артып китте. Шулар өстенә Казан дәүләт университетында да лекция курслары башлап җибәрде, гыйльми эшләр алып барырга туры килә. Ректор үзе үтенеп сорагачтын, баш тартып булмый. Ул гына да җитмәгән, Коммуналь төзелеш инженерлары хәзерләү

институтында лекцияләр курсын укуны көчләп диярлек тактылар үзенә. Партия органнарыннан төшкән боерыктан баш тарта торган заман түгел, булмаган вакытыңны табып, буйсынырга туры килә.

Кыскасы, Нигъмәт Хәким бер караңгыдан икенчесенә кадәр тоташ эш белән мәшгуль. Исеме яңгырап торган заман, кайсы аудиториягә килеп кермәсен – зарыгып көтеп алалар. Студентлар һәм яшь галимнәр аңа берөзлексез тартыла, лекцияләр тәмамлангач та, сорау арты сорау яудырып, сәгатьләр дәвамында җибәрми торган чаклары була. Аннан, дөресен әйтергә кирәк, студентлар белән аралашу үзе өчен дә шактый мавыктыргыч һәм файдалы. Нинди генә сораулар кызыксындырмый аларны, һәркайсына җавап табарга кирәк, җавап эзләргә. Кай юнәлештә эзләнергә, тагыниләр өйрәнергә һәм нинди хезмәтләр өстендә эшләргә кирәклеген ачыклый иде ул әлеге әңгәмәләр вакытында.

Шунысы яман, башлаган хезмәтләрен тәмамлау өчен вакыты җитми, вакыт ягы кысан. Шулар өстенә бит әле ярымподвалдагы юеш һәм тар бүлмәсенә кайткачтын, аш-су хәстәрләү, кер-фәлән юу кебек мәшәкатьләр дә үз өстендә... Суны күршедәге йортның ишегалдыннан алып кайта, бәдрәф ишегалдының ерак почмагында... Утын табу, утын юнәтү дә үз җилкәсендә...

Боларына гына түзәр идең, соңгы арада әледән-әле Черек күл янында урнашкан оешмага чакырып аптырата башладылар. Монысы җанга тынгылык бирми. Менә тагы, университетта лекция укып чыккачтын да, ул шул тарафка узып бара. Аяклары тартмый, әмма барырга мәҗбүр. Ни телиләр, нигә кирәге чыккан, һич аңлармын димә... Тагы кырык-илле минуттан Педагогия институтының актлар залында аны тыңларга дип студентлар җыелачак, әйе, көтеп утырачаклар, ә ул менә, кая барганлыгын кеше-кара күрмәсен дигәндәй, сагаеп кына, гаепле кеше сыман як-ягына карангалап Черек күл тарафына бара.

...Ишеген шакып кергәчтен дә чакыручы, канәгатьсезлеген белдереп, сәгатенә карап куйды. Дөньяның кендеге диярсең үзен, ни кыяфәт, ни гәүдә, утызы тулыр-тулмас борын түрә булып алган. Синең өлкән кеше икәнлегеңне дә искә алмый, урынлы-урынсыз дип тормый, дорфа сүзләр кыстырып сүгенергә дә өйрәнгән әнә.

– Соңга калып йөрисең, ... шулай иткере, иптәш Хәкимов.

– Вакытында килдем кебек.

– Бер минут та илле секундка соңга калдың! Соңгы тапкыр кисәтәм, тагы бер мәртәбә бу хәл кабатланса, мин сине соңармый торган урынга ябып куячакмын.

– Ни сәбәпле икәнен сорарга мөмкинме?

– Монда син түгел, мин сорау алам. Кайда булуыңны онытмаска киңәш итәм! Бу сиңа халык дошманнары мыжгып торган институтыгыз түгел...

– Тыңлыйм, ни өчен чакыруыгызны белергә мөмкинме, иптәш..., – дигәч, ни дияргә дә белми төртелеп торды Нигъмәт Хәким. Сорау алучы үзе белән таныштырмады, аның исем-фамилиясен белми иде ул. Әмма үзе сорарга кыймады. Хәер, кирәге дә булмагандыр...

– Совет хөкүмәтенең явыз дошманы Җамал Вәлидинең әшнәсе, значыт, – дип мыгырданды ул борын астыннан.

– Җамалетдин әфәнде һичкемнең дошманы түгел. Ул күренекле тел һәм әдәбият белгече...

Аңа башлаган сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәде сорау алучы, булыр-булмас зәгыйфь йодрыгы белән өстәлгә китереп сукты.

– Кемнең дошман, кемнең түгеллеген без ачыклыйбыз. Бу экиятеңне кайткач әбиеңә сөйлә, ярыймы?

– Бик сөйләр идем дә, әбием исән түгел, – дип әйтеп куймасынмы Нигъмәт.

Алдын-артын уйлап сөйләшкәндә дә таман буласы югыйсә, ялгышрак ычкындырды кебек монысын. Хәер, каршысында басып торган бу кешегә тагы нинди җавап табарга мөмкин булды икән соң...

– Син, иптәш Хәкимов, телеңә салынудан туктыйсыңмы, юкмы? – дип, тагы өстәлгә китереп сукты чакыртып китерүче.

– Уемда да юк... Ә Җамал әфәнде Вәлидигә килсәк, мин аны яхшы беләм. Шуңа да аның хакында яман сүз әйтү хаксызлык булыр. Җамал әфәнде милләтебезнең йөзек кашы саналган зыялы затларның берсе һәм иң күренеклесе. Мин дә, сез дә шул ук бер милләт балалары...

– Сафсата!.. – дип кычкырды тегесе, Нигъмәт Хәкимне тыңларга теләмичә. – Милләт имеш, зыялы зат, имеш... Ул сүзләрне күптән онытырга вакыт! Советлар илендә яшисең, совет икмәген ашап черетәсең... Буржуаз милләтче дип, бик урынлы язалар икән синең хакта.

– Җамал әфәндегә ярдәм итү кирәк...

– Тукта, дидем... Җамалыңны онын, Вәлидинең эше тәмам, ул инде синең яклауга мохтаҗ түгел! Бер киңәшем бар, син миңа үзегезнең институтта оялаган Советларга каршы булган корткыч элементларның, чит ил шпионнарының исемлеген язып китерергә тиеш, аңладыңмы!..

– Институтта һәм, гомумән, татар зыялылары арасында андый кешеләр булуын мин белмим.

– Беләсең!.. Кара аны, иң беренче булып үз исемеңне язарга онытма! Ха-ха... – дип, кеткелдәп тә алды үзен дөньяның кендеге дип хис иткән тикшерүче. – Аңлашылдымы?..

– Берни аңламадым. Мин үз эшемне беләм, шуннан тыш һичбер нәрсә белән кызыксынганым юк, иптәш... кем.

– Аңладың! Аңламасаң, аңлатырбыз...

– Һични вәгъдә итә алмыйм үзегезгә. Булмаганны бар дип язып булмый, иптәш...

– Язарсың! Алай бик үҗәтләнмәскә киңәш итәм, иптәш Хәкимов. Безгә синең Ленинградтагы элемтәләрең, Һиндстанданиләр кылып йөрүең, Башкорт тарафларында кемнәр белән аралашуың – һәммәсе дә мәгълүм. Кара аны, без шаярып сөйләшмибез. Аңладыңмы?..

– Аңладым... Инде китәргә рөхсәтме? Институтта лекциям бар, кичегергә ярамый, өлгерергә кирәк...

– Лекциясе бар имеш, эшем кешесе, – дип мыгырданды теге үзалдына. – Уйланырга киңәш итәм, кара аны, озакка сузма...

– Нәрсәне сузмаска?

– Халык дошманнары исемлеген...

– Чынлап әйттем: мин аларны белмим, дидем бит...

– Белмисеңме?.. Вәлиди белән бер кабинетта утыргансың. Гали Рәхимне белмисеңме?.. Галимҗан Шәрәф, Габдрахман Сәгъди, Бикбулатовларны да күргәнең юкмы? Дәвам итәргәме тагы?..

– Кирәкмәс. Мин аларның барысын да танып беләм, бүгенге татар мәдәниятенең асыл затлары буларак...

– Молчать... – дип, тагы өстәлне төеп алмасынмы теге, һәм бар булган тавышына җикеренеп җибәрде ул: – Асыл затлар, имеш... Чыгып кит, күземнән югал тизрәк. Мин аның белән кешечә, ә ул... Нишләтергә белербез сине! Күземнән югал, дидем ич...

– Хушыгыз, иптәш... – дип, тыныч кына саубуллашып чыгып китүдән башка чарасы калмаган иде Нигъмәтнең.

...Институтка ашыкты ул. Аяклары шул тарафка атлый, ә үзе әле һаман теге кабинетта булган мәхшәрдән аерыла алмый изалана. «Каян тапкан һәм ни өчен чакырган ул аны?.. Каян килеп һәм ни сәбәпле әле нәкъ менә аны чакырганнар?.. Нинди дошманнар таптырырга җыеналар аңардан... Булмаган дошманны бар дип әйтә алмый бит инде. Ни өчен милләтнең иң асыл ир-атларын, талантлыларын, укымышлыларын кулга алу китте? Милләт язмышы өчен мөһим эш башкаручыларны... Аларны зинданнарга бикләп, юк итү кемгә кирәк?.. Югыйсә менә бу, аны чакыртып алган адәмне генә алыйк. Ул да үзебезнең татар кешесе бит. Нигә шул тиклем дорфалык һәм нәфрәт белән ташланды соң әле аңарга?.. Минем дә барлык эшләгән эшем, кылган хезмәтләрем үз милләтем – татар халкы өчен бит. Ул адәм өчен дә чит булмаган, аңарга да ана сөте белән кергән татар телен гыйльми нигездә өйрәнү һәм камилләштерү юлында җан атып йөргән көнем... Ярар, тел гыйлемен санга да сукмасын ди, андыйлар бер ул гына түгел. Ә әдәбият һәм халык авыз иҗатын өйрәнүдән нинди дошманлык эзләргә мөмкин?..

Әле ярый, иректә менә, үз аяклары белән Казан урамнары буйлап атлап институтка кайтып килә. Ә Җамал Вәлиди ничек икән анда, ул ничек түзә икән бу мәсхәрәләргә... Уйласаң, исең-акылың китәрлек бит, Җамал Вәлидидән халык дошманы ясарга җыеналар!.. Гали Рәхимне, Газиз Гобәйдуллинны, Габдрахман Сәгъдине, Галимҗан Шәрәфне эзәрлеклиләр. Галим-голамәгә, шагыйрь һәм язучыларыбызга тынгы бирмиләр... Фәнсез, әдәбиятсыз һәм тарихсыз җәмгыять төзү мөмкинме? Юк, әлбәттә! Шулай икән, кая барабыз соң без? Кай тарафка тәгәри бу дөнья дигәннәре?.. Башка сыймый торган хәлләр...»

## 7

Дөнья кайный, илдә ыгы-зыгы, урамнарда кызыл байрак. Ораторлар баш очында йодрыкларын болгый-болгый менә ничәнче ел инде буржуазияне дөмбәсли, дөнья революциясе хакында сөйләп, төкерек чәчә. Гәҗитләрдә берөзлексез эшче һәм ярлы крәстияннарны кайгырталар. Ә хезмәт кешесенең тамагы туйганы юк, «анысы ярамый, монысы тыелган» кебек боерыклар югарыдан явып кына тора, ни эшләргә, кая барып бәрелергә белмәссең. Нигъмәт Хәкимнең дә җанында тынгылык юк. Менә тынычланыр, менә иркенләп, матур итеп яши башларбыз дигән өмет-хыяллары да инде сүрелгәннән сүрелә бара. Гаиләсе була торып, һаман япа-ялгызы яшәгән көне. Күңелендәге хыялларының, соң чиктә, ник берсе тормышка ашарга охшаса икән. Казанда булсын, институтта булсын, өмет чаткысы күренми... Соңгы араларда ул, гомумән, үз-үзенә бикләнде дип әйтергә була, әдәби кичәләргә, клубларга йөрми, хәер, дус-иш белән кунакка йөрешә торган чак та түгел. Гыйльми утырышларны да хәтта өнәмәс булды, мөмкинлек чыкса, әле бер, әле икенче сәбәп табып, аларда катнашмау җаен карый. Чөнки хак сөйлисеңме син, ялгышасыңмы, күңелдә булганны ачыктан-ачык әйтеп салу ярамый, шундук «кирәкле җиргә» илтеп җиткерәләр. Беткән баш – беткән, дип бер тәвәккәлләр дә идең, булмый, милләт алдында башкарып чыгарга алынган берсеннән икенчесе әһәмиятлерәк хезмәтләрне ярты юлда ташларга ярамый. Гаилә бар бит әле тагы, балалар бар... Үз-үзеңне, чаптар атың кебек, тезгенләми, авызлыкламый чараң юк. Көне буе институтта, студентлар арасында, аудиторияләрдә уза аның гомере... Эш сәгатең чыктымы, кысан

һәм юеш ярымподвалда урнашкан булса да, үз бүлмәңә кайтып бикләнүең хәерле... Башка һичкайда иркен сулыш алып, тыныч кына ял итә яисә аралаша торган түгел.

Менә тагы Казан урамнарына кичке караңгылык төшкәч тә башын түбән иеп, үз уйларына, борчуларына бирелеп, институттан фатирына таба берьялгызы ашыга-кабалана кайтып килеше. Кышы шулай суыкмы соң бу 1933 нче елның, әллә җанда дөрләп янган учак пыскый башлагангамы, белмәссең... Өстендәге бишмәт чабуларын каерып салкын җил исә, бүрек колакчаннарын йолкып алырга теләгәндәй әрсезләнә җил. Аяк адымнарын санаган кебек берөзлексез шыгыр-шыгыр кар шыгырдый. Иртән бер телем кара икмәк белән чәй эчеп киткәннән бирле көн буена авызына тәгам ризык капканы юк...

Фатирында көтеп, аш-су хәстәрләп торучысы булса икән. Шуның өстенә әле бүлмәне җылытырга кирәк, мондый салкыннарда иртә-кич якмасаң чәйнектәге суың бозланып ката. Инде кайтып җиттем дип, бер кулы белән салкын ишек тоткасына үрелеп, икенчесе белән кесәдән ачкыч эзләп маташкан мизгелдә үз итеп, җилкәсенә кемдер кулын китереп салмасынмы!..

Кем булырга мөмкин, дип сискәнеп куйды ул. Бакса, анда кем булгандыр, дисез...

– Бу мин, Нигъмәт абый, алай ук курыкма инде, – дип, соңгы араларда эзе суынган әлеге дә баягы шул якташы көтеп торган икән. Икенче кулына ниндидер төргәк тоткан.

Кемне-кемне, әмма бу кешене һич кенә дә күрәсе килми иде аның. Теге чакта нинди сүзләр әйтеп чыгып киткәнен онытырлыкмы соң?.. Шуның өстенә, үзе турында каләмдәшләре арасында һәм галим-голамә даирәсендә төрле имеш-мимешләр дә ишетелеп тора соңгы араларда. Дөрес, ул сүзләрнең урынлы булуын күз алдына да китерә алмый иде ул. Башкалар өчен ул әдәбият даирәсендә соңгы араларда гына чуала башлаган чит бер кеше булса, Нигъмәт өчен алай түгел бит. Нигъмәт Хәким аның нәсел-ыруын, ата-бабаларын белә, үз вакытында әтисенең сүзен тыңлап аны мәдрәсәгә тәкъдим итте, соңгы вакытларгача кулыннан килгәнчә кайгыртып, хәерхаһ булып, киңәш-табыш итеп яшәргә тырышты. Шулай да сүзләр йөри, колак салмыйм дисәң дә керә бит алар колакка. Сакланганны гына саклыйм, дигән бит Алла да...

– Кем дип торам, син икәнсең, – диде ул һәм килүчене, табигый ки, үзе артыннан бүлмәгә чакырды. Кире бора алмады Нигъмәт Хәким: элек-электән таш атканга да аш атарга күнеккән.

Хәер, бу очракта алай дию урынсыз да була торгандыр. Якташы, соңгы елларда беренче мәртәбә бик тә ярарга тырышып, җылы итеп, хөрмәт күрсәтеп күреште ич аның белән бүген. Шул гына булса икән, аннан кулындагы төргәкне өстәлгә китереп куйды һәм ачып җибәрде. Кәефе шәп, теле телгә йокмый, әнә...

– Менә, Нигъмәт абый, әле генә табадан төшкән кайнар пәрәмәчләр алып кердем үзегезгә. Минем хатын бик тәмле пешерә. Эштән арып, ачыгып кайткансыздыр, тамак ялгап алыгыз, булмаса...

– Тамагым тук, бер дә кирәкмәс иде, юкка мәшәкатьләгәнсең киленне, – диде галим сер бирергә теләмичә. Ә чынында кайнар пәрәмәчләрдән бөркелгән тәмле хуш истән авыз суларың килерлек. – Ярар инде, алай булгач, өстәлгә куелган ризыктан баш тартуны мактамый бит безнең халык. Чәй куеп җибәрим дә, бергәләп сыйланырбыз... Ә син түрдән уз, әнә теге артсыз урындыктагы китапларны тәрәзә төбенә урнаштыр да утыр.

Нигъмәт иң элек керосинканы кабызып чәй куеп җибәрде, аннан өстәлгә ике

тимер кружка һәм прәннекләр, авырый-нитә калсаң, кирәге чыгар дип саклап тоткан соңгы балын китереп куйды. Ә кунак, гадәтенчә, үз өендәмени, бер дә тартынмый, рөхсәт-фәлән сорап тормый гына тәрәз төбендә таудай өелеп торган китапларны барлау белән мәшгуль иде, билгеле бер тәртип белән өеп куелган кәгазьләрдә актарынды. Нидер эзләгәнгә охшамаган, эзләсә, сорарга була бит, хуҗа кеше янәшәдә генә. Эч пошканнан гына актарынуы, дияр идең, шактый ук тырыша һәм кабалана да түгелме соң әнә...

Күзәтеп торды-торды да Нигъмәт:

– Якташ, нидер эзлисең дип әйтимме, нигә шулай кабаланасың? – дип сорап куйды.

– Ә, – дип, яман эштә тотылган кеше сыман кинәт борылырга мәҗбүр булды кунак. – Болай гына... Сездә нинди генә китаплар юк икән бит... Боларны кай арада һәм кайдан җыеп бетердегез соң? Мин сезне тел галиме дип кенә белә идем, ә сез дөньяда нинди гыйлем булса, барысы белән дә кызыксынасыз икән. Монда тарих та, дин дә, сәясәт тә – ни генә юк, һәммәсе бар! Әллә ниткән чит телдә язылган төрле-төрле буржуй китаплары да күренә...

– Галим кеше барыннан да хәбәрдар булып торырга тиеш, якташ. Мин һәр көн студентлар каршына чыгам бит, аларны нинди генә сораулар кызыксындырмый. Укытырга алынгансың икән, «белмим» дигән җавап бирергә синең хакың юк.

Ә теге һаман актарына, әллә махсус, әллә кызык итеп, үзалдына китапларның авторларын да игълан итә башлады: «Самойлович... Радлов... Бухарин... Троцкий... Охо, Мирсәет Солтангалиев!..» Ул да түгел, Солтангалиевнең милли республикалар төзү уңаеннан язылган бер юка гына китапчыгын тотып, дөресрәге, аны болгый-болгый Нигъмәтнең борын төбенә килеп басты кунак.

– Бу китапны өйдә тотарга ничек курыкмыйсыз, Нигъмәт абый?..

– Ә нигә әле мин куркырга тиеш, китап Москвада, Үзәк басмаханәләрнең берсендә нәшер кылынган. Шуның өстенә бик җитди һәм безнең өчен шактый кыйммәтле хезмәт. Ә тагы шунысын да онытмыйк, ул безне республикалы иткән хезмәт! Россия империясендә бик күп хокуклардан мәхрүм булып яшәргә мәҗбүр милләтләрне ихлас кайгыртып язылган хезмәт. Игътибар иттеңме-юкмы, китап авторның миңа имза куеп биргән бүләге дә бит әле. Имзасын күрмәдеңме әллә?..

– Ә-ә, күрми торам икән, – дип, Солтангалиевнең үз кулы белән язылган автографын укырга кереште ул. – «Милләтебезнең мөхтәрәм фикер иясе һәм галиме Нигъмәт Хәкимгә – якташыма! Бер истәлек булсын, диеп... Мирсәеттән». Кара инде, язуы матур, имзасы ничек зәвыклы булган икән үзенең, – дип тә өстәп куярга кирәк тапты.

– Язуы һәм имзасы гына түгел, үзе дә искиткеч мөлаем, тышкы яктан гына түгел, бөтен барлыгы һәм күңеле белән дә асыл затларыбызның берсе ул Мирсәет әфәнде.

– Бәлки асыл кеше булгандыр да бит... – дип мыгырданды тегесе.

Ә үзе, нидер эзләгәндәй, берөзлексез әлеге дә баягы шул китапны актаруында иде. Тагы нәрсә күрергә теләгәндер анда?..

– Нигә «булган икән» дисең? Солтангалиев – бүген дә бар! Халкыбыз яшәгәндә ул яшәячәк, һичкайчан онытылмас. Милләтебезнең каһарман уллары кулдагы бармаклар санында гына, алар күп түгел. Кызганыч, кадерләрен белеп бетермибез. Әллә килешмисеңме, якташ, син башкача уйлыйсыңмы?..

Җавап бирергә ашыкмады якташы, кулындагы китапны ничек әлекте шулай

тәрәз төбендәге кәгазьләр өстенә кадерсезләп тотып ыргытты да Нигъмәтнең каршына килеп басты. Күзләрен түгәрәкләндереп, иреннәренә көлемсерәү төсе чыгарып текәлеп карап тора иде ул. Аның үз-үзен тотышын нәрсәгә дә юрарга белмәде галим.

– Сорау биргән идем кебек, – диде ул, ниһаять, җавап-фәлән ишетмәгәч.

Тагы бераз көттерә төшкәчтен, ишетмәсәң ишет дигән сыман, телгә килде чакырылмаган кунак. Бөеренә таянып, муенны текә тотып, тавышын рәсмиләштереп сөйләвен күрсәгез иде сез аның.

– Нигъмәт абый, буржуаз коткыга бирелеп Совет хөкүмәтенең милли сәясәтен бозучы, милли төбәкләрнең лидерларын үз әйләнәсенә туплап пантюркистик оешма төзегән Солтан...галиевне сез «каһарман» дидегез түгелме?

– Дөрес ишеткәнсең, «каһарман», дидем. Мин кешеләрне кылган хезмәтләреннән чыгып бәяләргә күнеккән, якташым, – дип, шулай ук рәсми төстә җавап кайтарды галим. Соравына күрә җавабы, дигән сыман чыкты инде бу. Һич кенә дә кеше белән сүзгә керү яисә ачуланышу уе юк иде аңарда бүген.

– Алай бик яхшы кеше булгач, ә ни өчен соң аны кулга алганнар? Һәм атарга хөкем иткәннәр...

– Белүемчә, Мирсәет әфәнде әлегә исән. Һәм ул һичшиксез акланачак.

– Белмим, белми-им...

– Безнең көннәрдә кулга алынучылар бик күп, якташым, үзең беләсең. Ялгышулар да очрый, көнләшү, яла ягулар... Өлкәннәр «яхшы атка гына кыңгырау тагалар» дигәннәр. Кешеләр яшәгән җәмгыятьтә андый хәлләр әүвәле дә булган, кызганычка каршы, бүген дә дәвам итә. Ни эшләмәк кирәк...

– Сез Солтангалиевне күреп һәм танып та белә идегезме?

– Бер мәртәбә Уфада очрашырга туры килде... Ул зур һәм дәрәҗәле кеше, аның чыгышларын тыңларга иде сиңа. Тыңласаң, бөтенләй башкача сайрар идең.

Бу юлы да башын артка чөя төшеп, үзенә генә хас бер вәкарьлек аша телен шартлатып, әлеге дә баягы шул буш сүзләр белән җавап кайтарды ул.

– Белмим, белми-им...

– Ә менә мин беләм! Ленин һәм Сталин янәшәсендә эшләп, алар белән үзен тигез санап, сөйләшә һәм бәхәсләшә алган бердәнбер милләттәшебез ул безнең. Һәм аларга үзенең сәяси идеяләрен аңлата, кабул иттерә белгән кеше. Шунысы кызганыч, әлегәчә үзе белән күзгә-күз очрашып сөйләшү, фикер алышу форсаты чыкмады... Мин шул хакта хыялланам... Бу хыялым тормышка ашмаса, бик тә кызганыч булачак...

– Кызганмагыз, куанырга кирәк, Нигъмәт абый...

Бу юлы инде галим аңа башлаган сүзен тәмамларга ирек куймады. Дорфарак чыкса чыккандыр, ярты юлда ук бүлдерде:

– Юкны сөйләп башны катырма, ярыймы, якташ...

– Ярар-ярар, сезнеңчә булсын. Сезнең үз фикерегез, минем үземнеке дигәндәй, ниндидер Солтан...галиев өчен һич кенә дә бәхәскә керәсем килми.

Үзенә күрә остазына хөрмәт күрсәтүе идеме бу аның, белмәссең. Әмма Мирсәетнең фамилиясен, мыскыл итәргә теләгәндәй, махсус икегә бүлеп сөйләшүе ачуын чыгарды Нигъмәтнең. Әмма җавап бирергә, үзенә каты бәрелергә ашыкмады ул. Күрә ич, файда булмаячак, тегенең үз туксаны туксан!

Ул арада чәй кайнап чыкты. Өстәл янына утырдылар. Пәрәмәчләрдән авыз иттеләр... Нигъмәт аларны бик тә яратып, кат-кат рәхмәтләрен кызганмыйча,

мактый-мактый ашады. Мактау сүзләре кунакка да ошамады түгел, әлбәттә. Һәм бары шуннан соң гына, шактый кичегә төшеп, инде икесе дә тынычлана төшкәчтен генә баягы сөйләшүне йомгаклап куярга кирәк тапты Нигъмәт.

– Якташ, сиңа шундый киңәш бирәсем килә: һичкайчан, урынлы-урынсызга башкаларга хөкем чыгарырга ашыкма, ярыймы? Күңелеңнән шулай уйласаң да, ул кешене ни сәбәпледер ошатып бетермәсәң дә, ашыкма. Дәшмәвең – алтын, дигәнне ишеткәнең бардыр...

– Ә мин ашыкмыйм, каян алдыгыз аны?!. Сезнең Мирсәет атлы дустыгызга килсәк, аңа хөкем күптән чыгарылган, баш ватып торасы юк, көннәре санаулы гына калгандыр дип беләм...

Ипле генә чәй эчүен дәвам итте Нигъмәт. Ә күңелендә төрле уйлар. Бу егет чын-чынлап аның киңәшен тыңлаудан узган күренә бит. Ул аның сүзләренә колак та салмый... Һәм салмаячак! Ни өчен соң әле бу шулай? Акылсыз егет түгел иде бит югыйсә. Белеме бар, сәләте бар, яхшы нәселдән чыгып, яхшы тәрбия алган кеше. Мөстәкыйль фикер йөртергә, үз тәҗрибәләреннән чыгып нәтиҗә ясарга сәләтле итеп күрә иде ул аны. Нәрсә булган моңа, соңгы араларда күз алдында үзгәрде түгелме?.. Җен алыштырган, диярсең үзен...

Бу сөйләшүне шул урында туктатырга карар кылды галим. Чөнки дәвам итү файдасыз булачак.

Әмма шагыйрьнең сөйләшәсе, бу әңгәмәне әле дәвам итәсе килә икән бит. Көтеп-көтеп тә үзенең соңгы сүзләренә җавап ишетмәгәч, икенче баштан тотынырга булды. Ипле һәм шактый ук басынкы иде ул бу юлы.

– Нигъмәт абый, сез зур галим, әлбәттә. Үз өлкәгездә зур хезмәт куйган кеше. Ләкин менә агымдагы сәясәттә заманнан шактый ук артта калгансыз. Хәтерлисезме, моннан ике-өч ел әүвәл безнең арада Җамал Вәлиди уңаеннан бәхәс чыга язган иде. Аны яклап утка-суга ташланырга әзер идегез... Нәтиҗәдә, йә әйтегез, кем хаклы, кемнең сүзләре өскә чыкты? Җамал Вәлиди кайда хәзер?..

Ни тыныч булырга тырышмасын, дәшми кала алмады Нигъмәт. Менә ничәнче ел инде аның күңеле түрендә йөргән төзәлмәс ярага тоз салырга җыена түгелме соң бу? Шул тикле дә мәкер һәм явызлык каян килә икән моңа?!

– Җамал әфәндегә кагылма, – диде ул шактый кырыс тавыш белән.

– Юк-юк, мин бары тик сезнең ялгышуларны гына искә төшерергә теләгән идем. Сез күкләргә күтәреп мактаган идегез. Ә хәзер ул юк, аны искә алучы да юк. Белүемчә, хәтта үзе эшләгән институтта да оныттылар. Солтан... галиев белән дә шулай булачак...

Шул мизгелдә бүлмәсенә чакырылмаган кунак булып килеп кергән бу кешене Нигъмәт куып чыгарырга тиеш иде. Әмма бу теләген җиңәрлек көч тапты ул үзендә, тешләрен һәм йодрыкларын кысып булса да түзде. Тагы бер-ике йотым чәй кабып куйды. Якташына да тәкъдим итте.

– Әйдә, суынганчы тагы бераз чәй эчеп алыйк, – дип, тегенең чәен яңартып җибәрде. Әмма кунак бая үзе кузгаткан әңгәмәне кабат-кабат дәвам итәргә омтылып карады. Ләкин хуҗа барыбер ишетмәмешкә салышты. Аның сүзләренә җавапсыз калу җиңел булмагандыр, моны Нигъмәт үзе генә белә. Һәр сүзе, һәр җөмләсеннән соң, үз-үзен тынычландырырга тырышып, тирән сулыш алып куя иде ул.

Тегенең исә, җен ачулары чыга.

– Сөйләшергә теләмисез, димәк... Мине санга сукмыйсыз... Ялгышларыгызны танымыйсыз... Хәтта ишетергә дә теләмисез...

– Якташым, – диде ул аңа ниһаять, – пәрәмәчләр тәмле булды. Тагы бер кат бик зур рәхмәт инде үзегезгә.

– Пәрәмәчләр... Ә-ә, пә-рә-мәч-ләр... – дип сузып куйды кунак, әйтерсең, алар турында ул инде бөтенләй онытkan иде.

– Башкача йомышларың булмагандыр?

Кунак бу сүзләрне дөрес аңлагандыр: «Сиңа чыгып китәргә вакыт җитте», диделәр түгелме соң... Ләкин үз максатына ирешү юлында аны туктатырлык көч табарга кирәк әле. Андый гына ишарәләр белән куркыттың ди, бар...

– Йомыш... Ә-ә, йомышымны һаман әйтми торам икән бит әле, – дип башлады ул, моңа кадәр араларында һичнинди киеренкелек булмагандай, ипле һәм йомшак тавыш белән. – Мин бит сезнең белән киңәш-табыш итәргә дип кергән идем.

– Тыңлыйм...

– Хәтерегездәдер, Нигъмәт абый, сез миңа бер-бер зур хезмәткә алынырга киңәш иткән идегез. Мин бит, сезнең киңәшне тотып, башладым бу эшне.

– Тыңлыйм. Сөйлә, ул нинди эш?

– Халкыбызның мәкаль вә әйтемнәрен, табышмакларын, кыска җырларын җыя башладым. Ни әйтерсез?.. – дип, инде кай арада башка кешегә әверелеп, тыңлаулы шәкерт кыяфәтенә кереп, остазының авызына текәлеп карап катты ул.

– Бик игелекле эшкә алынгансың, хуплыйм, – диде галим. Бу аның чып-чын, ихлас күңелдән әйтелгән сүзләре иде. Бераз уйга калып торды аннан һәм нидер әйтергә теләп тә тукталып калды. – Әмма...

– Бу «әмма»сы нәрсә диюегез булды, остазым?

– Күп хезмәт сорый, байтак заман кирәк булачак бу эшне башкарып чыгу өчен дип әйтергә теләгән идем...

– Ә мин аларны инде җыеп та бетердем, дип әйтә алам.

Колагы ялгыш ишеттеме әллә, хәйран калды Нигъмәт.

– Кай арада?

– Мин башлаган эшне озакка сузуны яратмыйм, тау-тау җыелды алар. Матбугатка бүген үк тәкъдим итәргә мөмкин.

Үзалдына уйлана, икеләнә калды галим: әле һаман булса «Кай арада?» дигән сорау эленеп торды аның тел очында. Җамал Вәлидинең, нигездә, халык авыз иҗаты жанрлары буенча дистә еллар буена җыелган һәм тупланган мирасы эзсез югалган, дип сөйләгәннәрен ишеткәне бар иде... Юк-юк, алай булырга мөмкин түгел. Якташы турында да начар уйларга нигезе юк иде аның. Нәсел-нәсәбендә күрелмәгән хәл. Шулай да уйландыра, бер ел эчендә башкарыла торган эш түгел бу. Дәшми кала алмады, ипле генә сорап куйды:

– Син ул хезмәтләреңне миңа күрсәтә алмассыңмы?

– Ә нигә күрсәтмәскә, – дип әйтеп ташлады шагыйрь. Әмма шундук үзенең ашыкканлыгын аңлап, боргаланырга-сыргаланырга кереште. – Күрсәтүен күрсәтер идем дә, бәлки, ашыкмау хәерледер... Эш болай тора бит, Нигъмәт абый. Алар бик күп – бу беренчедән. Бер ишеләре картотекаларда, ә күбесе зур-зур папкаларга тәртип белән тупланган. Аларны күтәреп йөреп булмас. Икенчедән, сез укый да алмассыз, ашык-пошык һәм кеше танымаслык итеп язылган. Тәртипкә китерәсе җирләре дә бар. Соңрак күрсәтермен, ярыймы, соңрак...

– Алай икән, – диюдән башка сүз тапмады галим. – Үзең беләсең... Күрсәтергә теләмәгәч, мин нинди киңәш бирә алам икән соң?..

– Бу хезмәтләрне дим, кайчан дөньяга чыгара башлау кулай булыр икән? Шул хакта киңәшергә кирәк санаган идем.

– Халык авыз иҗаты әсәрләрен нәшер кылу кайчан да кулай булачак.

– Анысын аңлыйм. Ләкин бу хезмәтләрне дәррәү күтәреп алырлармы икән соң бүген? Минем өчен аларны бастыру кайчан файдалы булачак?

– Аңламадым... Нинди файда, милләт өчен дисеңме?.. Фән өченме?..

– Ташла әле, Нигъмәт абый, фән кайгысымыни соң миндә! Матди файда турында кызыксынуым, дан һәм дәрәҗә турында... Юккамы әллә аларны җыю һәм юнәтү өчен күпме вакыт һәм көч сарыф иттем.

Колагы дөрес ишеттеме соң, нинди дан, нинди дәрәҗә? Иң элек син хезмәтеңне күрсәт. Ләкин, бу юлы инде күңелендәген әйтмәде ул аңарга. Барыбер аңламаячак...

– Матди файда, дан-дәрәҗә, дисең инде... Кызганыч, ул кадәресен мин белеп бетермим шул, чөнки күргән-белгән нәрсәләрем түгел, – дип кенә куйды.

Ә якташының исә әйтәсе сүзләре гүя, буылып торган, күп җыелган күренә, тыела алмый сөйләргә кереште ич әнә, һич тә үзен туктатырмын, димә.

– Минем бит, Нигъмәт абый, сездән аермалы буларак, мул тормышта, бал-май эчендә йөзәсем, аякны киң җәеп, күкрәкне киереп яшисем килә. Данга-шөһрәткә күмелеп, әйләнә-тирәдәгеләрнең һәммәсен көнләштереп, шагыйрь-шөгрәләрнең артына тибеп, галим-голамәнең буе җитмәслек кеше булып яшисем килә... Милләткә хезмәт итәм дип йөрүчеләр белән дөнья тулган әнә... Йөрсеннәр шунда кесәдәге тиеннәрен санап, ачлы-туклы, чит кешенең почмакларында көн күрү ошый икән, яши бирсеннәр. Йә, әйтегез, кайсы татар язучысы, кайсы шагыйрь, кайсы гыйлем адәме яшәгән бездә кешечә?.. Ялгышмасам, һәммәсе милләт өчен дип үз-үзләрен аямыйча хезмәт иткән, күпләренең матур итеп яшәү турында уйлар аралары да булмаган. Ә милләт алар турында уйлаганмы, кайгырткан дисезме?.. Ю-у-ук, мин һич кенә дә аларның язмышын кабатларга җыенмыйм. Фән дип, әдәбият дип, алар кебек мескенлектә, фәкыйрьлектә яшәргәме, үз кадереңне үзең белмичә эт типкесендә өстерәлеп йөрергәме?.. Юк, дигәч, юк!.. Без бит бер генә киләбез бу дөньяга! Яшәр өчен, бәхетле булыр өчен туа адәм баласы...

Башын чайкап, шактый ара ни дияргә дә белми хәйран калып тыңларга мәҗбүр булды Нигъмәт Хәким. Шаярып түгел, уйнап түгел, чынлап сөйли түгелме соң бу?.. Ничек моны җиргә төшерергә икән, юкса, менә-менә очып китәчәк. Очып китә калса, һич тотармын, димә үзен...

– Якташым, – дип, үз итеп, аның җилкәсенә кулын салды хуҗа. – Әллә нинди тузга язмаган сүзләр сөйли башладың түгелме? Син бит зыялы яшь кеше, шуның өстенә әле ничә буын мулла нәселеннән. Кешедән курыкмасаң, Ходайдан куркыр идең...

Бу юлы авыз ачып бер сүз әйтмәде, аның сүзләренә җавап бирмәде якташы. Үзалдына елмая төшеп, кеткелдәп кенә алды. Нигъмәт нәрсәгә юрарга да белмәде болай тотышын.

– Зур эшләргә алынуың яхшы булган, хуплыйм, – диде фикерен дәвам итеп. – Матур итеп яшәргә хыяллануыңны да аңлыйм. Кем теләми икән андый тормышны? Әллә минем менә шушындый шартларда, чит-ят бер кешенең юеш һәм салкын ярымподвалында, гаиләмнән аеры яшәүгә эчем пошмый торгандыр дип уйлыйсыңмы?.. Пошу гынамы соң... Ләкин беркая да китеп булмый, вакытлыча дия-дия түзәргә туры килә. Башкаларны түбәнсетеп, кимсетеп әйткән бу сүзләрең ошап бетмәде миңа. Алай гына да түгел, башыма сыйдыра алмадым ул сүзләреңне. Син әйттеңме, уйлап әйттеңме? Ышанасым килми хәтта.

– Максатым сезне ышандыру түгел иде, – дип куйды кунак. – Сез бөтенләй

башка. Әйттең ни дә әйтмәдең ни, сез мине аңлаячак кеше түгел, Нигъмәт абый. Карагыз инде, кайда, нинди шартларда яшисез!.. Сез... Сез – сирәк очрый торган бер фанатик... Фанатикларның да төрлесе була. Ә сез фанатикларның мескене!

Нигъмәт Хәким кирәк чакта үз-үзен тота белә, бу юлы якташы авызыннан чыккан соңгы сүзләрне гүя ишетмәде ул.

– Якташым, халкыбызның авыз иҗатын элек-электән фидакарьләр туплый килгән. Каюм Насыйри, Риза Фәхретдиннәр, мәсәлән... Безнең заманда Җамал Вәлиди, Гали Рәхим кебек затлы адәмнәребез күп көч куйды бу юлда. Берсе дә байлык артыннан кумаган, дөньясының артына тибеп алтын сарайларда яшәү турында хыялланмаган.

– Юкны сөйләмәгез, остазым, Вәлидинең, Рәхимнең, йә әйтегез, халык авыз иҗатын өйрәнүдә ни хезмәтләре булсын да, ни эш майтарганнары бар?.. Алар сөйләнеп йөрүдән узмаган. Хезмәт ул йә бар, йә – юк. Хезмәт – китап киштәләрендә, тузып беткән капчыкларда яисә таушалган папкаларда түгел...

– Алар туплаган бихисап зур хезмәтне мин үз күзләрем белән күргән кеше...

– Буш сүз! Күрсәтегез, кайда ул хезмәтләр?..

– Әйтә алмыйм, әмма эзсез югалмаслар, дип уйлыйм...

– Аларны сез, Нигъмәт абый, эзсез югалдылар, дип саный аласыз. Үзләре дә юк, хезмәтләре дә. Киңәшем шул, онытырга вакыт үзләрен...

– Белүемчә, Гали Рәхим әлегә исән-сау. Җамалның да хезмәтләре табылыр, боерган булса... Хәләл җефете Ләйлиҗиһанны гына күрә алмыйм менә. Аның хезмәтләрен дөньяга чыгару юлында мин һичшиксез кулымнан килгән ярдәмне күрсәтәчәкмен.

Кинәт сагаеп калды, дип әйтергәме, якташы күзләрен зур ачып, аның каршысына ук килеп басты.

– Менә бу хатаны ясый күрмәгез, остазым! Мин сезгә чын күңелдән киңәш итәм, Нигъмәт абый, кара тамга тагылган кешеләрдән һәм аларның гаиләләреннән мөмкин кадәр ерак торырга тырышыгыз. Онытыгыз, юк дип санагыз сез аларны, зинһар өчен, дип сорыйм...

– Ярар, бу – минем эш. Үзем белермен, – дип йомгакларга ашыкты галим.

– Юк, сезнең эш кенә түгел! Сәяси хата ясаудан сак булыгыз, остазым! Аңлыйсызмы, заманасы шундый...

– Ярар, синең хезмәтләрең дә эзсез югалмас, якташ. Халык авыз иҗаты очсыз-кырыйсыз бер дәрья бит ул, һәммәбезгә колач җәеп эшләргә, эзләнергә мәйдан җитә анда. Эшлә генә, эзлән генә. Габдулла Тукай сүзләрен хәтерлисең булса кирәк, бер дә юкка гына «Халык зур ул...» дип язмаган, сөйләмәгән шагыйрь.

Ниһаять, «сабыр төбе – сары алтын» дигәнне искә төшердеме, бу бәхәсне дәвам итүдән кинәт кенә туктала белде якташы. Ләкин китәргә җыенуы түгел, тагы бер үтенече калган булып чыкты аның.

– Нигъмәт абый, – дип дәште ул чираттагы мәртәбә ипле сөйләшүгә күчеп, – мөмкин булса, инде соңгы үтенечемне дә әйтергә рөхсәт итәрсезме?

– Сөйлә, тыңлыйм...

– Сез үз эшегездә булырсыз, миңа сезнең картотекалар, кульязмалар белән танышырга рөхсәт итсәгез иде?.. Эш тәртибен, гыйльми эзләнүләрне туплау принципларын да белү иде теләгем. Тәртипле генә, тыныч кына актарып утырырмын... Һәр нәрсә, кайда яткан булса – шунда, үз урыннарында калыр.

Шул гына җитмәгән, дип әйтергә иде дә бит... Икенче уйласаң, теләге изге

ич, фән белән элек-электән шөгыльләнгән кеше түгел, аны аңлап була – тәҗрибә тупласын, өйрәнсен. Ризалашырга туры килде.

Өстәл артына утырып, Ленинградка остазы академик Самойловичка хат язарга кереште Нигъмәт Хәким. Хат алганына ничә көн, җавап язар арасы булмады моңарчы. Ә якташы кыштыр-кыштыр аның папкаларындагы кәгазьләрдә актарына. Үзенә сиздерми генә күз дә төшергәләп алды ул аңа. Борчылыр сәбәп юк кебек, тәртип белән генә актарына, сорау-фәлән биреп тә аптыратмады... Шактый озак утырдылар ул кичне. Төн уртасы җиткәндә генә җылы хушлашып, гаиләсе янына кайтып китте якташ дигәне.

**8**

Икенче көнне таң белән ишегенә шак та шок кун итек белән типкән тавышка уянып китте Нигъмәт Хәким. Ишекне барып ачса, үз күзләренә ышанмый югалып калды: бер үк төрле колакчынлы бүрек, җылы тун киеп алган ике хәрби кеше басып тора иде каршында. Ул авызын ачып, кемне эзләүләре турында кызыксынырга да өлгермәде, рөхсәт-фәлән сорамый гына бүлмәгә бәреп тә керделәр.

– Сез кемгә? Ялгыштыгыз булса кирәк, – дип авыз ачуы булды, башлаган сүзен ярты юлда бүлдерделәр.

– Без ялгышмыйбыз. Киен... Сине – Нигъмәт Хәкимовны алырга килдек.

– Ничек... Минем кемгә кирәгем бар? – дип сорый алды галим, калтырана төшеп. Суыктан гына түгел, куркудан да булгандыр аның бу халәте.

– Киен диделәр бит сиңа. Юкса...

– Менә хәзер үкме? – дип гаҗәпсенүендә иде әле ул һаман. – Әйтегез, мин кемгә кирәк? Кайда, кем көтә, кем чакырды? Чакырган җиргә үзем дә киләм. Әле таң да атмаган... Бу вакытта кем мине көтеп торсын икән...

– Күп сөйләшәсең, абзый. Җыенырга тагы өч минут вакытың бар, – дип, кул сәгатенә күз төшереп, шактый ук кырыс тавыш белән кисәтеп куйды килүчеләрнең берсе. – Без уен уйнарга килмәдек. Тиз бул. Юкса, ыштансыз көе дә алып китәргә күп сорамабыз.

Бары шунда гына барып җитте аңарга, йөрәге күкрәк читлеген бәреп чыгардай булып ярсып тибәргә кереште. Тар һәм кысан бүлмәсендә анда барып бәрелде, монда килеп сугылды, ни эшләргә белмәде. Әле дә аннан-моннан киенергә өлгерде.

***

Черек күлгә китереп яптылар Нигъмәт Хәкимне. Суык һәм тар таш капчыкка төртеп керткәчтен үзе артыннан шалтыр-шолтыр китереп, бер түгел, әллә ничә йозак бикләделәр. Таш капчык дигәннәрендә утырыйм, дисәң, урындык юк, карыйм дисәң – тәрәзәсе. Чарасыз калды. Көтте. Болар һич кенә дә аның белән уен уйнаганга охшамаган. Ныклап тотынганнары күренә. Шактый вакыттан соң тышкы якта якынлашып килүче берничә кешенең тимер шпорлы күнитек авазы ишетелде, ул бикләнгән тимер ишек каршында тукталды килүчеләр. Шалтыр-шолтыр ачкычлар зеңгелдәде аргы тарафта, аннан тимер йозак сыкрап аваз бирде. Эченә җылы керде, аны алырга килгәннәр. Бәлки, азат итәргә җыенуларыдыр... Кулларын аркасына куйдырып, тоткын сыман җилкәсенә мылтык терәп сорау алучыга озаттылар үзен.

Сорау алучы дигәннәре чит-ят кеше булып чыкмады, теге чакта

үзеннән шикаятьләр таләп итеп теңкәсенә тигән адәм икән. Иске танышын сәламләгәндәй кет-кет көлемсерәп каршы алды ул.

– Нәрсә булды, абзый, безгә кучеп килдеңмени? Гелгә килдеңме инде?.. Безгә вакытлыча гына килмиләр шул. Лекцияләрең бар идеме соң бүген?.. – дип, аны мыскыл итүдән башлады ул сүзен.

Нигъмәт дәшмәде.

– Нәрсә, «академик» абзый, телеңне йоттыңмы әллә? Тел ачкычларын таптыра торган егетләрне чакырта алам. Керсеннәрме?..

– Белмим. Әйтегез әле, мине нигә монда китерделәр? Нинди гаебем бар?

– Ә син монда гаебе булмаганнарны китерәләр, дип уйлыйсыңмы? Безнең башка эшебез юк дип уйлыйсыңмы?

– Уйламыйм. Әмма минем Совет хөкүмәте каршында бер гаебем дә юк. Монда ниндидер ялгышлык бар...

– Тукта, молчать. Без ялгышмыйбыз, – дип акырды теге адәм. Аның өчен таныш булган зәгыйфь кенә йодрык имән өстәлгә китереп сукты. – Син Советларга каршы агитация алып баруда гаепләнәсең. Гаебеңне таныйсыңмы?

– Юк, танымыйм.

– Нәрсә белән шөгыльләнәсең?

– Мин Совет хөкүмәте корган уку йортында студентларга туган тел, тарих һәм фольклордан лекция курслары укыйм.

– Ничек укыганлыгың безгә мәгълүм. Инде сөйлә, кемнәр белән аралашасың, кемнәрне совет хөкүмәтенә каршы күтәрергә җыендың?

– Минем эшем пропаганда түгел. Институтта студентлар белән, аспирантларым һәм коллегаларым – укытучылар белән аралашам...

– Тагы кемнәр белән очрашасың?.. Кемнәргә һәм кайчан Совет хөкүмәте алып барган сәясәтне сүгеп, иптәш Сталинны гаепләп сөйләдең?

– Мондый хәлнең булганы юк, бу – яла. Кем уйлап чыгарды мондый яланы?..

– Беркем дә уйлап чыгармаган, булганны язалар. Менә монда барысы да ачыктан-ачык күрсәтелгән һәм теркәлгән, – дип, кул астындагы кәгазьләрне селкеп күрсәтте ул.

– Булмаганны булды дип кем язарга мөмкин, иптәш тикшерүче?..

– Сине яхшы белгән кешеләр, һәр адымыңны күреп торган кешеләр яза.

– Күрсәтә алмыйсызмы аларны? Бу бит ачыктан-ачык яла!

– Сүзләрегезне уйлап сөйләшергә киңәш итәм, Хәкимов. Без яла ягучылар белән эш итмибез, ышанычлы кешеләр һәм ышанычлы чыганакларга таянабыз. Аңлыйсыңмы, Хәкимов? Менә ак кәгазь, менә ручка, ничек булган, барысын да бәйнә-бәйнә язып бирергә киңәш итәм. Юкса, моннан чыгу юлы юк синең өчен. Монда кергән кеше кире чыкмый...

Шул рәвешле һәр көн... Көненә әллә ничә кабат... Берничә айлар дәвамына сузылды сорау алулар. Янау һәм кул күтәрүләр дә өзлексез кабатланып торды. Борынын сугып сындырдылар, алгы тешләреннән колак какты... Тышкы дөнья белән һич элемтәсе булмады аның, янына да һичкемне кертмәделәр. Шунысы гаҗәп, инде иреккә чыгу өмете тәмам югалды, дип йөргән көннәренең берсендә, сәбәпләрен аңлатмый-нитми генә үзен шәһәргә чыгарып җибәрмәсеннәрме...

Үзе өчен генә түгел, хәтта берөзлексез сорау алу, кимсетү, түбәнсетүләр белән мәшгуль тикшерүчеләр өчен дә көтелмәгән хәл иде булса кирәк.

Ул гына да түгел, институтка үз эшенә кайтты. Һәм, әйтерсең лә берни булмаган, элеккечә үк лекция курсларын алып барды, гыйльми

конференцияләргә чакырылды, аспирантлары белән эшләвен дәвам итте. Үз заманы өчен дә башка сыймаслык гайре табигый бер хәл иде бу.

Тора-бара: «Анда бер кергәнне чыгармый торганнар иде... Нигъмәтне сындырганнар... Аның белән саграк эш иткәнең, сөйләшкәнең хәерле булыр...» дип чышын-пышын сөйләшкәннәрен дә ишетергә туры килде. Хезмәттәшләре, хәтта институт җитәкчеләре арасында да булмады түгел аңарга шикләнеп караучылар. Боларны тоеп, ишетеп яшәү аның өчен икеләтә-өчләтә авыр җәза иде.

Үзен иреккә чыгаруны институт ректорлыгы һәм Татарстан автономияле республикасы җитәкчелеге инициативасы булгандыр дип гөманлаган иде ул. Чөнки алар кушкан бар эшне, һәр үтенечне җиренә җиткереп башкара, һәммәсенә төн йокыларын онытып докладлар, чыгышлар әзерләшә иде бит ул. Ләкин ялгышкан булып чыкты. Ә хакыйкатьтә ничек икәнлекне үзе дә шактый кичегә төшеп кенә аңлады. Нигъмәт Хәкимнең кулга алынуы турындагы хәбәр чыбыксыз телефоннар аша тиз арада аның Ленинград һәм Мәскәүдәге танышларына барып ирешкән булып чыкты. Күренекле академиклардан бер төркем – Самойлович, Радлов, Марр һәм башкалар – Ленинград шәһәрендәге партия оешмасы җитәкчесе Сергей Миронович Кировка мөрәҗәгать иткән, ә ул – Мәскәүгә. Ул елларда РСФСРның Мәгариф эшләре буенча халык комиссариатында җаваплы урын биләгән, Нигъмәт Хәкимне шәхсән яхшы белгән Хаҗи Габидуллин да үз каналлары аша югарыдагы җитәкчелеккә юл тапкан булып чыга.

Тик менә тормышында барысы да ал да гөл, элеккечә дәвам итте, дип әйтү хата булыр иде. Иреккә чыккачтын да фатирына кайтмый, кая барсын. Ишекне ачып керүе булды, шундук югалып калды. Стена читләп бер тәртип белән өелгән китаплар ишелеп, анда-монда аяк астында аунап ята. Кайсыларының бите ачылган, кайсылары ертылган. Өстәл һәм тәрәзә төбендәге кәгазьләрдә, папкаларда да актарынганнар. Табыйм дисәң, һичбер нәрсә үз урынында түгел. Барысын да тәртипкә китерә башлагач кына ачыкланды: «Идегә-ә-әй», – дип кычкырып җибәрде ул үз-үзен белешмичә. Арка яктан килеп башка китереп суктылар, диярсең... Әйе, чын-чынлап «Идегәй» дастаны һәм аңарга мөнәсәбәте булган бер кәгазь дә калмаган иде фатирда. Ничәмә папкага тупланган вариантлар, кульъязмалар, рецензия һәм бәяләмәләр – соң чиктә ник берсе ялгышып кына калсын икән...

Фатирны тапшырган хуҗабикәгә мөрәҗәгать итте ул иң элек. Һичкем ачкыч сорап килмәгән, ул берәүне дә күрмәгән. Ишек-тәрәзләр дә ватык түгел, читятларга ачкыч биргән кеше юк. Сөйләшә-аңлаша торгач, тагы шул кадәресе ачыкланды, хуҗабикә хәтта аның югалып торуыннан да хәбәрдар түгел.

Ә «Идегәй» дастаны юк... Бик күрәсе килмәсә дә, ошбу хакта кызыксынып «орган»нарга барырга мәҗбүр булды ул. Анда җилкә генә сикерттеләр: «Протокол һәм теркәүсез без һичкемнән һичбер нәрсә алмыйбыз. Без дәүләт оешмасы, андый эшкә хокукыбыз юк. Ә менә безгә шик белдергәнегез өчен статья элеп куя алабыз үзеңә», дип җавап кайтардылар.

Шулай итеп, Нигъмәт Хәким «Идегәй»сез калды булып чыгамы инде?.. Бу бит аның ничә еллар буена, күпме җирләр гизеп, күпме кешенең күңеленә һәм теленә ачкыч, ышаныч табып җыйган хәзинәсе! Ерак себер тайгалары эчендә югалып утырган татар авылларын эзләп ничәмә-ничә йөз чакрым юллар үтәргә туры килде аңа, күпме аяк киеме туздырырга. Күпме гомерен сарыф итте, моны белсә дә тик үзе генә белә... «Идегәй» аның яшәү мәгънәсенә әверелгән иде

бит инде. Бөтен хыялы татарны «Идегәй»ле итүдә иде. Ул гына да түгел, бөтен илгә, дөньяга таныту иде татар халкы иҗат иткән бу гүзәл эпосны. Дөньяда тиңдәше булмаган уникаль әсәр ич ул...

Шул көннән башлап, Нигъмәт Хәкимне көндез эшкә барса, төнлә йокыга ятса да, үзенә һич тынгылык бирми, бер генә минутка да уеннан, хәтереннән чыкмый, аны берөзлексез борчып, тынгысызлап торган проблема – «Идегәй» булды. Казан урамнарында таныш-белешләрен очратамы, Мәскәүдән бер-бер галим килеп чыгамы, Ленинградтан, Ташкенттан яисә Уфадан хат аламы, һәркайсын исәнлек-саулык белешмәс борын, «Идегәй» дастаны кызыксындыра торган иде. «Идегәй» кайчан басылып чыга?.. «Идегәй» ни хәлдә? «Идегәй»не нигә сузасың?» кебек сораулар берөзлексез аның колак төбендә генә түгел, күңеле түрендә эленеп торды.

Кем?.. Берөзлексез шушы сорау бимазалады үзен. Дәлилләре булмый торып кемнедер гаепләргә, кемгәдер нахак гаеп тагарга һич нигезе юк. Аннан, монда яшәгәнлеген белүче һәм ул хакта кызыксынучы да бик аз иде. Янына килеп-китеп йөрүче булмады, кунак чакырырлык урыны да юк. Булса да шул институтта, кадрлар бүлегендә теркәлүе ихтимал әлеге адресның. Һәм тагы, әлеге дә баягы якташы, шәкерте... Аңарга да шик ташлар урын юк. Үзе яшәгән бүлмәнең ачкычын аңарга бирмәде. Ачкыч каян тапсын, ат башы кадәр йозак ватылмаган, ничек бикләп киткән булса – шулай, үз урынында. Үзеннән сораштырыр иде дә, ни сәбәпледер, соңгы араларда күренми башлады. Бер булмаса, бер күренер, килеп чыгар әле, дип көтте ул аны. Атна арты атна, айлар бер-бер артлы узды. Ә якташ күренми, якташның эзе суынды... Әллә бер-бер якка чыгып киткәнме яисә күченгәнме, белмәссең.

Дөрес, соңгы араларда китап нәшрияты ашыктырмады. Көннәрнең берендә нәшриятта редактор булып эшләгән бер танышы, сүз ара сүз чыгып әйтеп тә куйды:

– Бездә «Идегәй» кайгысы түгел әлегә. Тикшерү арты тикшерү килеп тора, «милләтчелек, үткәндәге буржуаз тарих белән мавыгасыз» дип кисәтеп киттеләр җитәкчелекне...

– «Идегәй»нең буржуаз тарихка, милләтчелеккә мөнәсәбәте юк, – дип җавап бирде ул аңа. Җавабын бирде бирүен, әмма ашыктырсалар, ни эшләр идең? Басарга әзерләп куелган папкаларны табарга кирәк иде бит әле иң элек.

Шул көннәрдә Ленинградтан академик Самойловичның чираттагы хаты килеп төште. Ул «Идегәй»нең кайчан чыгуы белән кызыксына, сузмаска киңәш итә. Рус теленә тәрҗемә итә башларга кирәк, дигән тәкъдиме дә бар. Тәрҗемәчесен дә тапкан, бу эшкә талантлы яшь шагыйрь Семен Липкин алынса, бик яхшы булыр иде, дигән. Эпосның рус теленә юлга-юл тәрҗемәсен сораткан. Чөнки Нигъмәт Хәким, узган хатларының берсендә, бу эшне үзенең башкарып чыгуы турында хәбәр итеп өлгергән иде инде.

Хәбәр итте итүен дә, ул кульязмадан да җилләр искән.

Шулай да, бу югалту турында башкача тавыш-гауга кузгатмаска кирәк дигән фикергә килде галим. Самойловичка язган җавап хатында да сүз кузгатмады. «Якын араларда, кайбер төзәтү һәм камилләштерүләрне башкарып чыккачтын да җибәрермен», дигән ялган язарга мәҗбүр булды. Угры фаш ителер, кульязмалар табылыр, дигән өмет белән яшәде. Аның тавыш-гауга кузгатмавы иртәме-соңмы кайберәүләрне тынгысызлый башлар, дип нәтиҗә ясады ул үзенчә. Һәм хаклы булып чыкты.

...Югалтулардан соң бер ел чамасы вакыт узган иде инде. Гел көтмәгән-

уйламаган бер вакытта Аркадия бакчасында очраклы рәвештә якташы белән очраштылар. Нигъмәтнең, гадәтенчә, үз уйларына бирелеп, ипле генә узып барышы иде. Сукмак читендә урнаштырылган эскәмиядә нидер укып утырган ир-атка күзе төште. Игътибар белән караса, бу аның якташы...

– Мин сине бөтенләй югалткан идем, якташ – диде ул, аның каршысында тукталып.

Теге сискәнеп куйды, укып утырган китабын кулыннан төшереп җибәрә язды.

– Ә-ә, кем дип торам, бу сез икән... Бу бакчага ничек килеп чыгарга булдыгыз? – диде, үз-үзен тынычландыра төшеп. Бер читкәрәк тайпыла төшеп, янәшәсеннән урын тәкъдим итте. – Утырып бераз хәл алыгыз, Нигъмәт абый, күптән күрешкәнебез юк...

– Анысы дөрес, күптән күрешкәнебез юк, – дип кабатлады аның артыннан Нигъмәт, һәм урыннан баш тартмады. – Соңгы араларда бер дә күренмисең, оныттың. Әллә кирәгем калмады инде?..

– Алай түгел, Нигъмәт абый, ничек онытыйм. Эшем дә күп, вакыт та җитми торгандыр инде... Аннан бит, сезне тоту җиңел түгел, кайчан карама, ишегегез бикле.

– Гел фатирда гына яту мөмкин түгел шул. Анысы бар, монысы дигәндәй, эштән бушый алган юк бер дә, – диде галим һәм бер мәл уйга калып торды. Аннан тәвәккәлләп, хәйләгә керешергә булды. – Үзең беләсең, «Идегәй»не бастыру мәшәкатьләре белән йөгереп йөргән көнем.

Шагыйрьнең артына ут төртттеләрмени, утырган җиреннән сикереп куйды. Һәм сораулы карашын остазына юнәлтте.

– «Идегәй... Идегәй...», – дип кабатлады берничә кат. – Кульязмаларны сез, нәрсә, икешәр нөсхәдә хәзерләгән идегезмени?..

Ни булды соң аның белән, нигә шундый хата ясады соң әле ул?.. Ул бу сүзләрнең ни рәвешле авызыннан чыгып очканлыгын үзе дә сизми калган иде булса кирәк. Әмма әйткән сүз – аткан ук дигәндәй, ул сүзләрне кире кайтарып булмый иде.

Ә Нигъмәт Хәкимнең гүя исе дә китмәде бу хәбәргә. Әллә ишетте, әллә юк... Әллә бу хакта ул инде күптән хәбәрдар. Хәйлә катыш ялганга тотынгансың икән, әлбәттә, аны дәвам итәргә кирәк. Нигъмәт югалып калмады.

– Сиңа да киңәш итәм: җитди хезмәт һәм документларыңны икешәр нөсхәдә әзерләп, икесен ике урында тотуың хәерле. Белеп булмый, дус бар, дошман дигәндәй... Аннан бит әле ут-күз чыгу ихтималы да бар. Саклангánны гына саклыйм дигән...

– Шулай... Шулай... – дип, балтасы суга төшкәндәй югалып калды, ни әйтергә белми байтак кына икеләнеп торды якташы. Бөтенләй көтелмәгән хәвефле яңа хәбәр килеп иреште бит әле аңарга. Авыр хәлдә торып калды түгелме?.. Бу хәлдән ничек тә исән-имин, буялмый гына чыгарга иде бит... Кем-кем, әмма ул юлын таба белә, тыныч кына аңлатырга керешмәсенме шунда. – Мин бит, Нигъмәт абый, сезнең кулга алынуыгыз турындагы хәбәрне ишеткәч тә, «Идегәй»не коткарырга кирәк дигән фикергә килдем. Сезнең өчен никадәрле кыйммәтле... кадерле хезмәт булуын яхшы беләм. Күпме көч куйгансыз, башка сыйдырырлык түгел. Ә бит икенче көнне үк килеп, барын пыран-заран китереп алып китүләре ихтимал иде. Алып китәләр дә яндыралар, үзегез беләсез... Шуны күздә тотып, ни итсәм иттем, тавыш-тын чыгармый гына җыеп чыккан идем «Идегәй»гә мөнәсәбәтле бар хезмәтләрегезне. Алар

миндә саклана. Миндә булган әйбер югалмас ул, Нигъмәт абый, шулай бит, әйеме...

Инде Нигъмәт телсез кала язды. Менә бит ничек... Юк, белми... Һич кенә дә бәяләп бетерми икән бит ул үзенең якташын. Утта янмый, суда батмый торган зат булып чыкты түгелме соң әле бу?.. Әнә ничек тапты юлын. Угры түгел, игелек кылучы, аның кульязмаларын коткару юлында үз-үзен аямый утка ташланган каһарманга тиң икән ич ул!

Килешүен белдергән атлы булып, баш кагып тыңлап утырды галим. Иң элек хәйран калды. Һәм шунда ук дулкын булып күңеленә шатлык, куаныч бәреп керде. Табылды... «Идегәй» табылды, дигән хәбәр иде бит бу! Үз-үзен кулга алырга кирәклекне аңлады Нигъмәт, шул мизгелдәге хис һәм тойгыларын һич кенә дә бу иптәшкә сиздерергә ярамый иде.

– Шулай да, ничек керә алдың? Ничек тавышсыз-тынсыз гына барысын җыеп чыга алдың? – дип, бераз кичегә төшеп булса да сорап куйды аңардан.

– Сез сорамагыз, мин әйтмим, остазым, – диде «коткаручы» тирән сулыш алган атлы булып. – Җиңел булмады, билгеле, үзем генә беләм... Ләкин сез бит минем өчен бик тә кадерле һәм үз кеше...

Үз кеше имеш «бик тә кадерле»... Тешен кысып түзде галим, моның каршында сер бирергә ярамый. Йомшаклыгыңны сизсә, ике дә уйламаячак, «эһ» тә итми таптап, сытып китәчәк үзеңне...

– Кульязмаларны кайчан кайтарырга уйлыйсың инде?

– Ашыкмаска киңәш итәм, остазым, – диде ул ягымлы һәм шул ук вакытта ихлас кайгырткан атлы булып. – Үзегез күреп торасыз, сезнең институт әйләнәсендә тагы болытлар куерырга тора. Бераз сабыр итик. Миндә булган нөсхәләрне сез тимер сандык эчендә дип саный аласыз. Алар утта янмас, суда батмас, һич кенә дә югалмаслар...

– Шулай да аларны кайдан алсаң, шунда кайтарып куярга кирәк булыр!

– Әлбәттә, кайтарырмын, әлбәттә, – дип килешкән атлы булды ул. Ә үзен инде икенче нөсхә кызыксындыра башлады түгелме. – Үзегездәгеләрне, икенче нөсхәләрен югалта күрмәгез, Нигъмәт абый. Аларны кайда саклыйсыз соң?

Тын да алмый җавап көтә иде ул. Нигъмәт Хәкимнән җавап ишетмәгәч, үзенчә киңәш биргән атлы булды тагы.

– Кеше-кара кулына эләгә күрмәсен тагы, дип әйтүем.

Нигъмәтнең урыныннан торып китәргә җыенуын күргәч, «сүз булмаганда сүз булсын, өч көн үткәч «исәнме кодагый» дигәндәй, шагыйрь тагы үзе тел тибрәтте:

– Ярый, мин сезгә килеп чыгармын. Борчылмагыз, сез дигәнчә булыр, барысын да хәл итәрбез, Нигъмәт абый, – дип, озатып калды ул. Әйтеләсе сүзләре әйтелгән иде инде, Нигъмәт Хәким үз юлында булды.

## 9

Кульязмаларны кайтарырга ашыкмады аның якташы. Бер ай көтте, ике ай – юк! Күршедә генә яшиләр югыйсә, бер булмаса бер очрар дип көтте ул аны. Әмма күзенә чалынмады. Әдәбият һәм шигырь мәйданына мөнәсәбәте булган таныш-белешләреннән дә сораштырып торды аның хакында. «Аратирә күренеп китә үзе. Әмма бик эреләнде «Нәкис», эшлекле затка әверелеп китте соңгы араларда, Черек күл тарафында еш чуала, имеш...», дип җавап кайтардылар.

– Нәкис... Ул ниткән Нәкис тагы, аның үз исеме бар ич, – дип, колагы ишеткәнгә ышанмыйча торды галим бертын.

– Ишеткәнегез юк идеме, гаҗәп, аңарга бу кушаматны байтактан тактылар кебек инде...

Нигъмәт сүзне озынга сузып тормады, баш какты да үз юлында булды.

Көннәрдән бер көнне, башка чарасы калмагач, фатир хуҗасына мөрәҗәгать итеп карарга җыенды Нигъмәт Хәким.

– Ул моннан күптән күчте, фатир алганына биш былтыр, ишетмәдегезмени, үзенә фатир бирделәр ич аның, – дигән җавап ишетте ул.

Боларны ишеткәчтен, чираттагы мәртәбә хәйран калды. Үз сүзләренә караганда, һичкайда җүнле-башлы эшләмәгән килеш фатир алган, фатирлы булган... Анысы яхшы, әлбәттә. Ишле гаиләсе, балалары бар. Әмма шунысы гаҗәп, күпме очрашып, аралашып та шушы көнгә кадәр бу хакта ләм-мим бер сүз кузгатканы булмады бит.

– Кайда икәнлеген белмисезме, адресын калдырмадымы?

– Мин сорамадым, ул калдырмады... Шушы тирәдә генә булырга тиеш, малайлары безнең ишегалдында еш күренә. Иптәшләре монда ич, уйнарга киләләр... Тәрбиялеләр, әллә каян танып, «Здрастуйте, тётя Марфа» дип килеп исәнләшәләр минем белән. Хатыны да шундый тыйнак һәм сөйкемле иде... Алар киткәчтен ишегалды гел ятим булып калды...

Бер сөйләшә башласа, Марфа ханымны һич туктатам, димә, ул әле иркенләп дәвам итәргә әзер иде бу әңгәмәне. Ләкин Нигъмәтнең институтка ашыгып китеп барган чагы, шул сәбәпле, гафу үтенеп, юлын дәвам итәргә мәҗбүр иде...

***

Көннәрдән бер көнне бөтен илгә Ленинградтан кайгылы хәбәр таралды. Газеталарның беренче битендә атналар-айлар буена гел шул хәбәр булды: күренекле революционер, Сталинның көрәштәше, өлкә партия оешмасы лидеры Сергей Миронович Кировны вәхшиләрчә атып үтергәннәр. Гәрчә Кировның үзен танып белмәсә дә, күпмедер гомерен шул шәһәрдә уздырган, халык массаларының аңарга җылы мөнәсәбәтен күргән кеше буларак, Нигъмәт Хәким дә битараф кала алмады бу хәбәргә. Үзеннән сораштырган танышбелешләренә һәм шул исәптән студентлар каршында да бу вакыйгага үзенең мөнәсәбәтен белдерүдән тайчанмады.

Анысы бер хәл, әмма иң элек Ленинградта, аннан бөтен ил күләмендә яңабаштан Совет иленең дошманнарын эзләү һәм фаш итү кампаниясе башланып китүгә дә сәбәпче була шул вакыйга. Җинаять кылучы, үтерүче һичшиксез җавап бирергә тиеш, анысы бәхәссез. Әмма сәясәттән шактый ерак торган фән эшлеклеләре, академиклар, профессорларның, тел белгечләренең бу җинаятькә нинди мөнәсәбәте булырга мөмкин, шунысы аңлашылмый. Бик күп башка гыйлем ияләре исәбендә Нигъмәт Хәкимнең остазы, академик Самойлович та кулга алына шул көннәрдә. Билгеле инде көне-сәгате белән бу хәбәр Казанга да килеп җитә. Ә Казанда Самойловичның шәкерте, Ленинград интеллигенциясе белән тыгыз элемтәдә торган Нигъмәт Хәким бар түгелме?!

Күптән теш кайрап йөрүчеләргә шул җитә кала. Чираттагы шикаятьләр Татарстанның партия һәм куркынычсызлык органнарына барып ирешә. Нигъмәтне, сәбәпләрен аңлатып тормый-нитми генә институттагы эшеннән куалар... Күпмедер гомер эшсез йөрергә мәҗбүр була ул. Газета-журналларга юл ябыла, кара-каршы очрашканда урамның аргы ягына чыгып китә башлый

кайбер таныш-белешләре. Аның артыннан көн-төн күзәтәләр, бер-бер урында, чарасызлыктан, тормышыннан зарланып яисә кемнәрне дә булса гаепләп чыгыш ясаганын көтәләр. Әмма болар Нигъмәт Хәким холкына хас сыйфат түгел, ул тешен кысып булса да түзәргә, авызы тулы кара кан булса да, кеше алдында төкермәскә өйрәнгән зат. Бу хакта дус-ишләре һәм гаиләсенә язган хатларында да ләм-мим сүз кузгатмый галим, кадерле һәм якын кешеләрен борчуга саласы килми аның.

Гомеренең бу дәверендә фән эшлеклесе булырга омтылган әрсезләргә гыйльми хезмәтләр язышып, кайсыларына файдалы киңәшләр биреп көн күрергә мәҗбүр була ул. Аның язмышы турындагы хәбәр Казан дәүләт университеты ректоры Гыйлем Камайга барып ирешә. Ике дә уйлап тормый ректор, Нигъмәт Хәкимне үзенә чакырып китерә һәм университетның гыйльми китапханәсенә эшкә ала. Әмма анда да тынычлап эшләргә бирмиләр. 1936нчы елда НКВД милли зыялылар арасында террорчы төркемнәрне юк итү буенча яңа акция башлап җибәрә. Һәм, аңлашыла ки, «Ленинград эшенә», имеш, бәйләнеше мәгълүм «дошман элемент» Нигъмәт Хәким, һәрвакыттагыча илдә беренче булырга омтылган Казан чекистлары тарафыннан, шундук кулга алына. Бу очракта да берсеннән икенчесе хәтәррәк гаепләүләр белән өстеннән шикаять язучыларга мохтаҗлык тумый.

Кем язды икән, дисезме?.. Әлбәттә, үзенә кайчандыр «остазым» дип дәшкән, берөзлексез әйләнәсендә бөтерелгән якташы тора бу эшнең башында. Архивларда ул язган, үз имзасын куеп язган дистәләрчә документлар саклана әле дә. Ул кәгазьләр күп вакыт узудан түгел, андагы яла, ялган һәм башка сыймаслык нахак тагылган гаеп һәм һич булмаган җинаятьләрдә гаепләүләрдән саргайган. Ак кәгазь ничек түзсен бу кадәрле нәҗес һәм пычраклыкка! Тел галименең, татар халык авыз иҗатын җыючы остазының кайсы буржуаз илләрнең шпионы булуын, нинди террорчы оешмаларны җитәкләвен, фашистик идеологияне ничек пропагандалавын, даһи Сталинны кем очраса, шуңа көн-төн сүгеп йөрүен һәммәсенә караганда да ул күбрәк белгән булып чыга. Яшереп, качып-посып түгел, үз кулы белән яза әлеге шикаятьләрне. Гаепләүләр саллы һәм «дәлилле», сүз сөрешенә, терминнар белән эш итүенә караганда бу эштә шактый зур тәҗрибә туплап өлгергән күренә боларны язучы. Имзасын да бит әнә, каләмен өр-яңа баштан карага чумырып алып, матурлап, җиренә җиткереп куярга онытмый.

Ул елларда адәм баласын кулга алу өчен бу кадәр гаеп эзләү кирәк тә булмагандыр югыйсә. Аларның берсе дә җиткәндер... Юк, монда ныклап тотынганнары күренә. Кулга алу турындагы документка да Дәүләт куркынычсызлыгы органы бүлек мөдире капитан Веверс үзе кул куя. Комиссариатский дип исемләнгән урамдагы кысан һәм тар бүлмәсеннән аны 3нче бүлек оперуполномоченные кече лейтенант Каменьщиков җитәкчелегендә килеп кулга алалар.

Кулга алу һәм яшәгән бүлмәсендә үткәрелгән тикшерү вакытында нинди документлар табылуы кызыксындырса, беркетмәгә күз төшереп китә алабыз.

Тентү ясаучыларның игътибарын, беренче чиратта, галимнең «Ислам диненең килеп чыгышы» дигән китабы үзенә җәлеп итә. Аннан килеп Көнчыгыш халыклары институты студенты Аббасовның диплом эше табыла аның эш өстәлендә. Икенче бер галимгә язылган хатның караламасы. Үзен «марксизм дошманы» дип гаепләгән стена газетасы редакторына җавабы. Төрле адресларга язылган тагы 11 хат. Һәм нindидер билгесез бер гүзәлгә

багышлап язылган шигырьләр бәйләме табылган. Менә сиңа чит ил шпионына «компромат»лар!..

«Ә кулъязмалар кайда?» – дип сораучы булыр. Галимнең татар халкының авыз иҗаты өлкәсендә гомере буе җыйган хезмәтләре кайда? Әдәбият, тел һәм фольклор өлкәсендә чыккан һәм китап нәшриятында бастыру өчен әзерләнгән кулъязма хезмәтләре кайда? Уникаль һәм бай китапханәсе... Болар хакында ләм-мим сүз юк! Димәк, кемдер берәү дәүләт куркынычсызлык органнарыннан да өлгеррәк булып чыккан. Алар һәммәсе дә «Идегәй» юлыннан китеп, башка бер-бер затның кабинетына күчмәгәндер дип, йәгез, кайсыгыз әйтә ала?..

Сорау алуны әлеге дә баягы Каменьщиков һәм тикшерүче Якубовлар алып бара. Беренче беркетмәләр Нигъмәт Хәкимнең барлык гаепләрдән дә катгый төстә баш тартуы турында сөйли. Шактый ук саргая төшкән кайбер кәгазьләргә караганда, инде тора-бара үзенә тагылган гаепләрне аз-маз таный башларга да мәҗбүр итәләр аны. Халкыбызның «һич тә тутыкмас саф вә раушан көзгесе» булган рухи мирасын эзләп, татарлар яшәгән барлык төбәкләрне диярлек җәяүләп йөреп чыккан фидакарь зат, ак күлмәк һәм галстуклар тагып хөкем залларына килгән «бөек»ләргә ышансаң, «чит ил шпионы» булган икән бит! Бер түгел, берничә ил шпионы... Үз гаебен тану дигәннән, аларның нинди ысул белән һәм ничек алынуын күз алдына китерәсез булса кирәк... Әмма соңгы көннәренәчә, хәтта үзен гаепле дип таныган сәгатьтә дә, таныш-белешләреннән һичкемгә аз гына күләгә төшерерлек тә сүз тартып ала алмыйлар Нигъмәт Хәким авызыннан. Галимҗан Шәрәф, Габдрахман Сәгъди, Галимҗан Нигъмәти, Гали Рәхим кебек күренекле галимнәргә, язучы Галимҗан Ибраһимовка, драматург Кәрим Тинчуринга гаеп тактырасылары килә сорау алучыларның. Рәмиев, Вахитов, Сәйфуллин фамилияләре кызыксындыра... Нигъмәт Хәким кайтып-кайтып аларны бары тик яхшы яктан гына белүе турында җавап бирә.

Төрлечә куркыту һәм янау ысуллары белән аның таныш-белешләрен чакырталар. Сезнең хакта ул менә шулай дип әйтте, дип, Нигъмәт Хәкимгә яла яга-яга да сораштырырга тырышалар. Нуркин, Вахитов, Нигъмәтуллин, Шәрәф, Сәйфуллин һәм Бурнашев фамилияләре теркәлә бу уңайдан. Һәм аларның һәркайсы каршында хөрмәт белән баш иярга кирәк. Араларыннан ник берсе куркыту һәм провокацияләр каршында югалып калсын икән! Нигъмәт Хәкимне, үзләренә мөнәсәбәттә төрле янауларга да карамастан, алар бары уңай яктан гына һәм олылап искә алалар.

Нибарысы бер беркетмәгә күз төшереп узыйк. Тикшерүче Якубов күренекле галим Галимҗан Шәрәфне чакырта:

– Нигъмәт Хәкимовны беләсеңме? – дип сорый тикшерүче.

– Беләм. Яхшы беләм, бер институтта эшләдек...

– Аның советлар хакимиятенә каршы эшләгән гамәлләрен дә белә идегезме?

– Бу дөрес түгел, Нигъмәт Хәким советларга каршы авыз ачып сүз әйткән кеше түгел.

– Иптәш Сталинны аты-юлы белән сүккәнен дә ишетмәдегезме?

– Андый сүз чыкканы булмады аның авызыннан. Бу да ялган...

– Авызыңны үлчәп ачарга киңәш итәм! Без синеңчә, нәрсә, ялган сөйләп, гаепсезләргә яла ягып утыручылар булып чыгабызмы?..

– Алай димәдем. Әмма булмаганны булды, дип тә раслый алмыйм.

– Буржуаз милләтчеләрнең Хәкимов оештырган, совет хакимиятенә каршы яшерен оешма утырышларында катнашканыгыз булдымы?

– Сез нәрсә, иптәш Якубов, татар теле белгечләренең башка эше юк дип беләсезме әллә?.. Каян килгән яшерен оешма ул, бу хакта да беренче тапкыр ишетүем.

– Тукта, дим... Молчать! – дип җикеренә тикшерүче Якубов. Һәм тиз арада тынычлана төшеп, сүз арасында гына янәсе, тыныч кына әйтеп куя. – Ә менә минем кулдагы бу кәгазьне күрәсеңме, анда, бик беләсең килсә, Хәкимов сине бу оешманың аеруча актив әгъзасы буларак искә ала...

– Ышанмыйм, күрсәтегез, булмаганны булды, дип язмас Нигъмәт әфәнде...

– Язды шул, ничек кенә язды әле.

– Ышанмыйм, күрсәтегез...

– Вакыты җиткәч, күрсәтербез дә, әмма әлегә ул хакта белеп торуың да җитәр. Ярар, – дип, өстәл тартмасыннан алдан әзерләп куелган чираттагы кәгазь битләрен тартып чыгара Якубов. – Менә шушы беркетмәгә кулыңны куй да мин сине җибәрермен, теге ни дип әйтәләр әле... Биш ягың кыйбла!

– Биш як түгел, «дүрт ягың кыйбла» дип әйтәләр, – дигән төзәтү кертеп, кулына тикшерүче сузган кәгазьне алып укырга керешә Галимҗан Шәрәф. Җентекләп укый башласа да, тора-бара күз йөгертеп чыгуга күчә. – Монда бит бер дөрес сүз дә язылмаган, ничек итеп моңарга кул куярга мөмкин?

Һәм ике уйлап тормастан ул кәгазьләрне икегә бөкләп ерта да тикшерүченең каршысына өстәл өстенә ыргыта.

Тикшерүче Якубов урыныннан сикереп үк тора һәм йодрыкларын болгый-болгый тамагын киереп кычкырырга керешә:

– Син ни эшләгәнеңне беләсеңме?.. Кем дип белдең үзеңне! Кайда икәнлегеңне оныттыңмы?.. Мин сине ни эшләтергә белермен... Ун тапкыр, илле тапкыр килерсең... Подвалга утыртырмын... Әмма кул куярсың!

Ничек кенә куркытмасыннар, ничә тапкыр чакыртмасыннар, Галимҗан Шәрәф барыбер башкаларны гаепләгән андый кәгазьләргә кул куюдан баш тарта...

Әмма юкны бар итеп, бүрттерә-бүрттерә нахак гаеп тагучыны табалар. Хәер, аны эзләп тә торасы булмагандыр... Үзен Нигъмәт Хәкимнең якташы дип санаган, әлеге дә баягы шул безгә бик тә таныш булган иптәш белән сорау алучы арасындагы протоколга күз салып узыйк:

«1936 нчы елның 2 декабре.

– Сез Хәкимов Нигъмәтне күптән беләсезме?

– Февраль революциясе көннәреннән үк беләм. 1918-1919нчы елларда ул Уфа шәһәрендә аклар тарафында булды, аларга хезмәт итте... Гомумән, ул һәрвакытта буржуаз-милләтче лидерлар тарафдары булды... Шул карашларыннан ул һичкайчан арынмады, әле дә мин аны революция эшенә каршы бер милләтче дип саныйм... Ул һәрчак совет хакимиятенә каршы сүзләр сөйләп йөрде... Күрешкән саен Совет хөкүмәте һәм партиябез җитәкчеләрен, аеруча иптәш Сталинны гаепли, яман сүзләр әйтеп сүгә торган иде... Аның өчен Троцкий һәм Солтангалиев кына авторитет санала...

– Ярар, аңлашылды, җитәр – дип аны бүлдерергә омтылып карый тикшерүче.

– Юк-юк, мин әле сөйләп бетермәдем, – дип, әрсезләнеп, теге – авыз өчен чит булган нәрсәне чәйнәвен дәвам итә.

– Йә, тагы ни бар, әмма кыскарак тотарга тырышыгыз.

– Онытā язганмын. Нигъмәт Хәкимов бит әле тагы иптәш Кировны явызларча үтерүне тормышка ашырган, партия һәм Совет хөкүмәте җитәкчеләренә каршы

яңа терактлар әзерләгән троцкийчы-зиновьевчы террористик үзәк белән тыгыз элемтәдә тора иде...

– Фактлар һәм дәлилләр бармы?..

– Дәлилләр күп. Иптәш Кировны үтерүчеләр исәбендә кулга алынган Самойлович һәм теге... академик Марр белән хат язышып, гел хәбәрләшеп торды ул. Хатларын күргәнем бар. Әмма ул аларны миңа укытмады, миннән яшерә торган иде. Яшерерлек серләре булган, димәк...

Тел сөяксез... Шул рәвешле, нинди гаеп тагу кирәксә, шуны раслый килә, теле телгә йокмый үзенең остазын гаепләргә керешкән бәндәнең. Күпме еллар кеше-кара күзенә чалынмыйча архивларда яткан ул кәгазьләрнең йөзенә сары каян төшкән, дисез?!. Үз күзләреңә үзең ышанмас буласың аларны укыганда. Минем дә, мөмкин түгел, чынлап та боларны ул үзе сөйләгән, үзе язганмы икән, дип гаҗәпләнеп, ышанырга-ышанмаска белми икеләнә калып утырган минутларым аз булмады...

...Максат куелган. Гаепләр тагылган. Нинди генә бит әле гаепләре дә... Шаһитлар шуларны раслап тора. Кем-кем, үзенең якташы китергән төп дәлилләрне! Шул рәвешле Советлар иле һәм иптәш Сталинның куркыныч дошманын фаш иттек дип, зур эш майтарган атлы булып, Татарстан НКВДсы Мәскәүгә хәбәр юллый.

Үрнәк эш башкарганнар бит, әнә буржуаз милләтчеләрнең дә иң зурысын фаш иткәннәр, өстәвенә, үзе югары уку йортына кереп оялаган чит ил шпионы да икән бит әле. Бу «үтә мөһим» эшне Мәскәүгә соратып алалар. СССР Югары судының хәрби коллегиясе карый Хәкимов эшен. Кемнәр диген әле... Ульрих, Плавнек һәм Кандыбин – тоташтан «ату турында хөкем чыгаручы» группа. Эш 1937 елның 3 августында карала. Җиде минут эчендә барысын ачыклап, хөкем дә чыгарып куялар: «Атарга!»

Хөкем карары шул ук көнне Мәскәүнең нәкъ уртасында, Кремльдан бер чакрым чамасы да ераклыкта булмаган калкулыкта утырган зур һәм шомлы бинаның подвалында җиренә җиткерелә.

***

Башкортстан Автономияле Совет Социалистик республикасының ерак бер почмагында урнашкан Еланлы авылында нәкъ шул кичне унҗиде яшьлек бер кыз бала тәрәзәдән сүрән генә төшеп торган алсу шәфәкъ яктысында Казанга этисенә хат язарга утыра:

«Кадерле этием, соңгы араларда хатларың бик сирәк килә. Аңлыйм, эшең һәм мәшәкатьләрең күп булса кирәк. Мин сиңа, Златоустта фабрика-завод җидееллык мәктәбен тәмамлагач та, Уфадагы кооперация техникумына керүем турында хәбәр иткән идем инде. Укуым уңышлы гына бара анысы, бер дә кыен түгел. Абыем һәм апаларым белән күрешеп, хәбәрләшеп торабыз. Җәйге каникулда авылда, әнием янында булдым. Менә кайтыр, менә кайтыр дип, сине дә бик көткән идек тә... Вакытың булмадымы, бу җәйдә кайта алмадың. Сине бик тә, бик тә сагындык, этием...

Аннан килеп, узган елны син миңа үзең эшли торган институтка укырга керерсең, татар теле һәм әдәбиятын җентекләп өйрәнеп укытучы яисә галимә булырсың, дигән идең. Бу кыз оныткандыр, дип уйлыйсыңдыр, онытмадым, этием... Мин көтәм, нигәдер, чакырмыйсың һаман... Казанга киеп бару өчен күлмәклек тә алдык инде. Шул күлмәкне тектергән арада, күңелем сизә, синнән чакыру да килеп җитәр төсле. Әтием, шул тикле күрәсем килә шул Казан

дигән шәһәрне, шунда укыйсым килә... Әллә инде син миңа ышанмыйсыңмы? Бу кыз булдыра алмас, дип уйлыйсың булса кирәк... Тырышыр идем, синең йөзеңә кызыллык китермәс идем әле. Белем алып, әтием, сиңа авыр хезмәтеңдә ярдәмче буласым килә минем. Әнине дә үзебезнең янга чакырыр идек. Шәһәр үзәгеннән зур фатир биргәннәрен көтәсеңдер инде, мине тар бүлмәгә китерүдән уңайсызлана торгансыңдыр. Әни шулай дип әйтә... Уңайсызланма син, әтием. Бергә-бергә булсак, мин идәндә яисә мич башында да йокларга риза булыр идем әле. Шул яңа фатир өчен дип, мин тәрәзә өленгеләре чиктем, әни ашъяулыклар хәстәрләп куйды, сөекле әтиемә дип кенә чиккән кулъяулыкларым да күптән китаплар астында. Тик чакырмыйсың һаман. Ә без синең чакыруыңны көтәбез, әти. Белсәң иде син, минем шундый да, шундый да әтиле һәм әниле булып, әтием һәм әнием янында торып укыйсым, яшисем килә бит. Өйгә кайтып кергән чакларымда синең: «Кызым, хәлләрең ничек?..» дигән ягымлы сүзләреңне ишетәсем килә...

Төшләремдә берөзлексез Казан урамнары буйлап йөримен, әтием, Казанга таба китеп баручы поезд вагонының тәрәзәсенә капланып барган җирдән кинәт уянып киткән чакларым еш кабатлана. Аннан килеп, син сөйләгән ак җилкәнле көймә төшкә кереп йөдәтә. Синең белән икәү шул җилкәнле көймәдә Идел елгасының уртасына ук кереп, Казан Кремлен күзәтәбез, Сөембикә манарасының сылулыгына сокланып гизеп йөрибез икән... Белсәң иде, әтием, боларның өнемдә түгел, бары тик төштә генә икәнлеген аңлагач, шул тикле дә моңсу һәм ямансу булып китә. Ирексездән елап җибәргән чакларым була. Күз яшьләремне әниемә сиздермим, билгеле. Озын сүзнең кыскасы шул, әтием, мин Казанга синең яныңа киләм, дип хыяллана-хыяллана хыялыйга әверелеп бетәм бугай инде...

Туган якларыбыздан, Әй буйлары, Лачын-таш тугайларыннан, әнидән, абый һәм апаларымнан чуктин-чук сәламнәр үзеңә, әтием. Җавап хатыңны зарыгып көтеп калучы кызың Әдибә дип белерсең!

Еланлы авылы, 1937 ел, 3 август киче,

Кояш баеп килгән мизгел».

## Йомгак урынына

Шушы урында нокта куйган идем. Әмма, күңелне тырнап торган сораулар кала икән бит. Аларны бүген кузгатмасак, иртәгесен кем дә булса башка берәү күтәреп чыгармы? Белмим...

Узган гасырның егерменче-утызынчы елларыннан соң инде күпме вакыт, күпме сулар аккан. Бер гасыр чамасы вакыт узып бара. Дистәләгән әдипләребез, галим һәм фикер ияләребезнең каберләре кайда икәнлеген шушы көнгәчә ачыклый алганыбыз юк. Ерак тайгаларда эзсез югалган һәм төньяк диңгез төпләренә батырылган меңәрләгән дин әһелләребез һәм мөгаллимнәр, илне ашаткан-эчергән, киендергән, җиң сызганып эшләгән авыл һәм шәһәр хезмәт ияләренең язмышы да шул ук хәлдә. Алай гына да түгел, гаепсез гаепләнгәннәрнең гаиләләре ниләр күргән, балалары нинди җәбер-золым кичереп яшәргә мәҗбүр ителгән?.. Аларның оныклары кайда? Әби-баба кочагы җылысын, назын күрми үскән оныкларның язмышлары нидән гыйбарәт? Башка сыйдыра алмаслык фаҗига...

Гаеплене без җиңел таптык, ике уйлап тормадык, илне өч дистә еллар дәвамына җитәкләгән юлбашчы өстенә өйдек тә куйдык барысын. Ул боерык

биргән, юл куйган, янәсе... Ә кем оештырган, кем гаеп таккан, кем гаепләне ачыклаган, кем хөкем чыгарган һәм кем башкарган тарихта тиңе булмаган бу террорны?!. Ачыклап торырга кирәк санамадык. Гыйбрәт алганбыздыр, бәлки. Анысы да юк, гыйбрәт алмадык! Менә шул хәл, бу авыр һәм четерекле вакыйгалар өстендә уйлану каләмгә үрелергә мәҗбүр итте мине. Болар безне сагаерга мәҗбүр итәргә тиешле хакыйкать!.. Димәк, югарыдан әмер төшә-нитә калса, әле дә яла ягучылар, хөкем чыгаручылар һәм шул хөкемне тормышка ашыручылар табылачак, алар форсат көтеп арабызда йөри булса кирәк. Сызгыр гына, бүген үк көне-сәгате белән җиң сызганып «эшкә» тотынырлар кебек...

Егерменче-утызынчы елларда гаепсезгә гаепләнеп юк ителгән яисә еллар дәвамына газап чигүләргә дучар булган татар зыялыларына яла ягу эше белән безнең Казаныбызда, профессиональ рәвештә (әйе, шулай диеп әйтергә туры килә) күпме адәм заты шөгыльләнгән дип уйлыйсыз? Күп түгел, нибарысы җиде-сигез адәм актыгы. Аларның берсе дә ил белән бергә ачлык-ялангачлык кичермәгән, Бөек Ватан сугышына китеп үлеп калмаган, хәтта яраланмаган. Нигездә, һәммәсе дә үзләренә күрә матур гаилә корып, балалар үстереп, җәмгыять каршында хөрмәт һәм ихтирамга лаек кеше буларак, сиксәнгә-туксанга җитеп дөнья куйганнар. Архивларда боларның һәркайсының үз исем-фамилияләре һәм уйлап чыгарылган кушаматлары, ягъни псевдонимнары астында язылган шикаятьләр әле дә булса саклана. Кызганычка каршы, ябык ишекләр артында саклана.

Җиде-сигез адәм актыгы, дидек... Йөзәрләгән шикаять! Милләтнең иң затлы һәм асыл затлары, чын каһарманнары өстеннән язылган алар. Шул шикаятьләр нигезендә күпме гомерләр киселгән. «Нәкис» шуларның берсе һәм аеруча куркыныч, үтә мәкерлесе, төлкедән дә болайрак хәйләкәре. Юк-юк, ул псевдоним фәлән артына качып, яшеренеп маташмаган, пычрак эшләрендә дә тормышта һәм әдәбияттагы үз исем-фамилиясе белән эш иткән. Иртәме-соңмы хакыйкатьнең өскә калкып чыгу очрагын, бу эшләре өчен җавап бирү ихтималын күз алдына да китермәгән, күрәсең. «Нәкис» дигән псевдонимны аңарга үзенең замандашлары биргән. Әмма аның үзенә әлеге кушамат белән дәшүче булгандыр, дип уйламыйм. Милли әдәбият һәм сәнгать даирәсендә эшләгән шәхесләрнең үзара язышканда, качып-посып кына фикерләшкән минутларында файдаланылган кушамат ул.

Тагы шунысын да искәртми узу ярамас, ул дистәләрчә әдип һәм фикер ияләребезнең гомерен юк итүгә хәлиткеч өлеш кертkән мәкерле шикаятьче генә түгел. Ул кеше хезмәтен үзенеке санап дөньяга чыгарган әдәби карак, ягъни плагиат та әле. Җамал Вәлиди, Нигъмәт Хәким, Гали Рәхим һәм тагы күпме зыялыларыбызның гыйльми хезмәтләре, кульязмалары, һәм тупланган картотекалары аның кулына күчүе мәгълүм. Ә башка берәүнең иҗат җимешен яисә гыйльми хезмәтен үзләштерү, ягъни әдәби караклык – иҗат кешеләре даирәсендә элек-электән иң чиркангыч җинаять саналган. Бүген дә шулай саналырга тиешле, киләчәктә дә шулай булып калачак.

Аның бу «эшчәнлеге» турында сүзләр элек-электән булган һәм бар иде. Узган гасырның җитмешенче еллары башында ук хөр фикерле татар зыялылары, халык авыз иҗатын өйрәнүчеләр авызыннан еш ишетергә туры килә иде аларны. Ләкин бу проблеманы кузгату, йә булмаса күтәреп чыгу ул елларда мөмкин түгел иде. Чыш-пышның туктап торганы булмады. «Чыш-пыш», табигый ки, елдан-ел басыла төшә... Чөнки бу хакта шактый киң мәгълүматлы зыялыларыбызның күбесе, ни кызганыч, мәңгелек йортларына китеп барды...

Әмма Җамал Вәлиди гомере һәм аның гаиләсе күргән җәбер-золым, Нигъмәт Хәким гомере һәм аның нәселе кичергән фаҗига өчен кем җавап бирер икән?.. Мулла кушкан үз исемен онытып, нәсел шәҗәрәсен һәм милләтен яшереп көн күрергә мәҗбүр ителгән Александр Ивановичның кичерешләре һәм аның әти-әнисе язмышларына битараф калып буламы?.. Алар еллар буена фидакарьләрчә җыйган һәм туплаган мирас кая? Ул хезмәтләрне барлау яисә дөньяга чыгару түгел, масштабларын да күз алдына китерә алмыйбыз бүген...

Безне ул еллар белән бәйләп торган күп җепләр чуалган, бик күп нәрсәләр кайтарып алмаслык булып ерагайган һәм югалган. Әмма болар, барыбер, хакыйкатькә кул селтәү өчен сәбәп була алмый. Без бик тиз онытырга күнегеп барабыз. Онытумы бу, әллә үзебезнең куркаклык һәм битарафлыкны аклау өчен онытканга сабышумы? Хәтерсезлек чиреннән арынырга күптән вакыт иде инде!..

Халкыбызның гасырлар буена тупланып килгән мөбарәк тәсбихын хәтерләткән дистәләгән фидакарьләрнең гомере һәм эзсез югалган мирасы турында сүз бара... Шул мираска таянып без килер буыннарыбызны тәрбияләп үстерергә җыенабыз. Халык авыз иҗаты әсәрләре, милли әхлак һәм рухи мирас ялган һәм җинаять белән янәшә тора аламы икән?!

Үз-үзеңне фаш итү, ул пычрану түгел, ә чистарынуга илтә булса кирәк. Киләчәктә мондый хәлләр кабатланмасын өчен, үзебезгә һәм килер буыннарга гыйбрәт булсын өчен дип фаш итү кирәк җинаятьне.

Архивларда казынганда, хәтта ак кәгазьнең йөзе хыянәттән, икейөзлелектән, гаепсезләр өстенә ташланган тау-тау пычрактан саргая дигән нәтиҗәгә килдем мин. Безнең битарафлыктан да саргая торгандыр ул ак кәгазь... Вакытны гаепләү урынсыз, миңа калса...

Дөрес аңлашылсын, мин һичкемне юкка чыгарырга җыенмыйм. Һәм моңарга хакым да юк. Максатым тарихи хакыйкатьне күзгату гына иде бары. Безнең язмыш, безнең тарих шул тикле дә катлаулы ки, вакыт-вакыт асыл затларыбызның эш-гамәлләрен дә яңадан кайтып-кайтып барларга туры килә. Милләтнең асыл затларын онытырга ярамаганлыкны, алдыбызда аларның мирасын, язмышын, якты исемен торгызу юлында гаять зур бурычлар торганлыгын искәртергә теләвем. Кайчак бит, алтын дигәнебезнең дә очраклы бер сары таш булып чыгуы ихтимал.

Килешәм, бик күп вакыт узган. Әмма әлегә хәтер яши, хәтер онытырга, кул кушырып утырырга ирек бирми. Җитмешенче еллар башында миңа Казан автовокзалы каршындагы ике катлы ярымҗимерек сары йортның бер бүлмәсендә тоташ кайгы-хәсрәттән гыйбарәт гомерләрен йомгаклау алдында торган Ләйлиҗиһан ханым һәм аның фашист тоткынлыгын кичеп, хаста хәлендә әйләнеп кайткан кызы Әминә апа белән очрашып күрешү насыйп булган иде. Ләйлиҗиһан – Җамал Вәлидинең хатыны, Әминә – аның кызы. Берничә кич дәвамына сузылган бу эчкерсез сөйләшүләрне һич онытырлык түгел. Җилгә элеп киптерелгәндәй тире белән сөяктән генә торып калган ана белән кыздан үз колагым белән ишеткән ул хатирәләрне күз алдына китерергә дә куркыныч хәтта. Боларны ничек онытырга мөмкин?!.

Урта мәктәпне тәмамлагач та Әминә Вәлитова биология факультетында уку теләге белән кайчандыр әтисе эшләгән институтта кабул итү имтиханнары тапшыра. Фәкать бишле билгеләренә... Әмма аны кабул итмиләр, туып-үскән шәһәрендә уку турында хыялланырга да ярамаганлыкны аңлаталар үзенә. Кызның югары белем алу теләге шулкадәрле дә зур була ки, ул моңарчы

күрмәгән-ишетмәгән ераклыктагы Харьков шәһәренә барып университетка имтиханнар бирә. Кабул итәләр. Әмма беренче курсны тәмамлап йөргән көннәрендә илгә фашист илбасарлары бәреп керә. Студент кызларны кулга алып, Германиягә озаталар. Әминә – шулар арасында. Дүрт ел дәвамында инде фашистлар тарафыннан мәсхәрәгә дучар ителә кыз бала. Бары сугыш тәмамлангач кына, үз әнисе танымаслык дәрәҗәгә төшерелгән чал чәчле инвалид кыз Казанга кайтып төшә... Белгәнебезчә, бер абыйсының юеш һәм салкын подвалда гомере киселә. Икенче абыйсы язмышын да тыныч кына сөйләү мөмкин түгел...

Шул ук җитмешенче елларның ахырында Уфадан «Казан утлары» журналына Нигъмәт Хәкимнең кызы Әдибә апа килеп чыккан иде. Аңарга алтмыш яшьләр чамасы булгандыр. Бу аның Казанга беренче килүе иде кебек. Әйе, унҗиде яшендә Казанны бер күрергә хыялланып төшләр күргән, әтисе укыткан педагогия институтында югары белем алу турында хыялланып хатлар язган кыз шул була инде.

Журналның баш редакторы Зәки Нури аның белән җентекләп сөйләшүне минем өскә йөкләде. Әдибә ханым сөйләгәннәрне, аларның гаиләсе күргәннәрне тыңлаганда чәчләрең үрә торырлык. Җирдә яшәү һәм туган төбәкләрендә эшләү мөмкинлеге өчен, төрле янау һәм куркытулар белән аның ике апасын әтиләреннән ваз кичәргә мәҗбүр итәләр. Әмма Әдибә, нинди генә кыенлыклар күрмәсен, андый килешүгә бармый. Нигъмәт Хәким балаларының Ватан алдында намуслары чиста. Аның бердәнбер улы Мөбәшир туган илебезне саклап, Бөек Ватан сугышы кырларында һәлак була. Дистә еллар дәвамында тоташ түбәнсетү, җәбер-золым астында көн күргән ул гаиләнең ил каршында ни гаебе булды икән?!.

Онытылырга тиешле тарих түгел болар. Һәркемгә гомер бер генә бирелә. Һәм ул гомер бәхет өчен, тулы канлы имин тормыш, ата-аналы бөтен гаиләдә яшәү өчен бирелә булса кирәк. Бу очракта хәтерсезлектән дә зур җинаять юк миңа калса...

Александр Иванович уйлап чыгарылган шәхес түгел. Ул тамырларыннан өзеп йолкып атылган агач үрентесе хәлендә калганда да кипмәгән, корымаган, үсүен дәвам иткән, юктан бар булып дигәндәй, аякка баскан, күтәрелгән шәхес. Ватан каршында зур дәрәҗәләргә ирешкән кеше Александр Иванович. Кызганыч, аның хакыйкатьтә кем улы һәм соңыннан кем булуын, төрле юллар белән эзләп-эзләп тә, мин әлегәчә ачыклый алмадым. Таныш-белешләрен таба алмадым, белмим. Архивларда аның үзе хакында һичбер мәгълүмат юк. Күрәсең, аның тормыш юлы һәм башкарган хезмәтләре дәүләт тарафыннан әле дә җитди сер булып саклана...

Ә бит Александр Ивановичның да бәхетсезлеге әлеге дә баягы шул шикаятьләрдән башланган. Шундый аянычлы язмышка дучар ителгән Александр Ивановичлар безнең халыкта, илебездә аз булгандыр дип уйлыйсызмы?.. Без аларны күрмәмешкә салышабыз... «Күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе – ботак тишеге» дип әйткән түгелме ерак бабаларыбыз?..

*Мәскәү – Казан,*
*2018-2019.*



Рухия
Ахунҗанова

# БИШЕК ҖЫРЫ КӨЙЛӘП ТИРБӘТӘ ҖИЛ...

## Ходай биргән гомер берәү генә

Ходай биргән гомер берәү генә...
Өйрәт, Коръән, дөрес яшәргә:
Кирәк икән тымызык кич булып,
Кирәккәндә күкрәп яшьнәргә.

Ходай биргән гомер берәү генә...
Насыйп булсын инде яшьләргә,
Гомеркәйнең кадерләрен белеп,
Изге гамәл кылып яшәргә.

Ходай биргән гомер берәү генә...
Фани дөньялар бит өч көнлек!
Изге хисләрдән дә кайчакларда
Кабына алмый икән очкын ник?!

Ходай биргән гомер берәү генә...
Ярдәм сорап, аңа дәшәм дә:
– Зая гомер бирмә милләтемә,
Кәеф корып кына яшәргә.

Дога итеп кабатлаган сүзем
Әйтерсең лә имән турында.
Имән ныклыклары булган халкым
Мәңге яшәр иман нурында.

Рухия АХУНҖАНОВА (1959) – *шагыйрә; «Җырлы чишмә», «Олуг шәһәрдә кунакта» һ.б. китаплар авторы. Ш.Маннур исемендәге әдәби премия лауреаты. Сарман районы Җәлил бистәсендә яши.*

## Балачак

Вакытсыз киттең, балачак...
Ашыктың соң, әйт, нигә?
Үсеп тә җитмәгән идем,
Үлем тиде әнигә...

Балачагым – гамьсез чагым!
Нигә сиңа тартылам?
Әле дә ияреп йөрим күк
Әниемнең артыннан.

Кайтыр юл табып булмасмы?
Бик тә кайтасым килә...
Нәрсә биреп кайтып була
Әниле рәхәт илгә?..

## Нәсел гөлләре

*Әбием истәлегенә*

Истәлегең булып, исле гөлләр
Балкып утыралар шау чәчәктә,
Безгә – синең нәсел гөлләреңә –
Бәхет-тәүфыйк теләп киләчәктә.

Шәҗәрәдәй тамырланган гөлнең
Сине оныттырмас исе гелме?!.
...Бишек җыры көйләп тирбәтә җил
Мин болынга чәчкән исле гөлне.

Синең кебек сыйпап-назлап кына
Үстерәсем килә һәрбер гөлне.
Берсе генә чәчәк атмаса да,
Сагыш биләп алыр йөрәгемне.

Ирек сөяр холкыбызга безнең
Җил иркендә үскән гөлләр үрнәк!
Алар аша нәселемне барлыйм,
Тыштан боздай туңып, эчтән дөрләп...

## Татар кызы судан кайта

Татар кызы судан кайта,
Басмалар чайкала шул.
Өлгереп килгән хисләре
Сулардай чайпала шул.

Күкрәгенә алып салган
Озын калын толымнар.
Шомырт кара толымнарга
Үреләсе җырым бар.

Татар кызы судан кайта,
Атлаулары бик җиңел.
Су юлында бәхетеңне
Табарсың әле, сеңел.

## Язмышлар кабатлана

Аллаһтан да өстен итеп,
Кемне дә сөймә икән!
Изге канунны бозганнар –
Корабсыз калган җилкән...

Әйттеләр: «Кызый, әниең
Ялгышын кабатлама!»
Йөрәгем – әнкәйдән мирас,
Язмышлар кабатлана...

## Чынлап сөйсәң...

Чынлап сөйсәң, сөю яман икән:
Гыйшык утларында янам, иркәм.
Әйтерсең лә унсигездә яшем,
Һаман янып, сөеп, көеп яшим...

Сөйләсәм дә – синең хакта сүзем,
Бер Аллаһым бирсен миңа түзем.
Сине уйлап түгелә күз яшем,
Син юкта да синең белән яшим...

Чынлап сөйсәң, сөю шундый икән...
Миңа сиздермичә генә, иркәм,
Янасыңдыр эчтән, көясеңдер –
Син дә, бәлки, шулай сөясеңдер...

## Кыр казлары

Кыр казлары безгә таныш инде,
Алар китү  безгә сагыш инде.
Җилпи күкне ап-ак канатлары –
Җанга кага китү набатлары.

Һаваларны кисә кайтавазы:
«Киткәннәрнең мөмкин кайталмавы!..»
Болытларга бәрелеп килә бер сүз:
«Ничек яшәрсез соң инде безсез?!.»

Киткән казлар кире кайтыр микән?
Яшьлек таңым чәчәк атыр микән?
Бәргәләнәм шушы уйларымда,
Күк чәчәкле инеш буйларында...

## Син кайда?

Кайчандыр бүлмәң бик тә тар,
Күңелең, һай, киң иде.
Эзләмәдең баерак пар,
Дусларыңа тиң идең.

Хәзер менә болын кебек,
Катлы-катлы киң бүлмә.
Ләкин синең күңелкәең
Тарайгандай күренә.

Ясалма елмаю белән
Эзлисең дустан файда.
Тар бүлмәле, киң күңелле
Яшьлек дустым, син кайда?!

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Ркаил
Зәйдулла

# КОЛ ШӘРИФ

РОМАННАН ӨЗЕК

958 елның кышында Үтәмеш Гәрәй хан исеменнән Мәскәүгә илчелек юлладык. Иванга язган ярлыкта без ике арадагы сугышның беркемгә дә кирәк булмавын, Мәскәүдә Казан качакларының безгә каршы коткы таратып ятуын, юкса үзебезнең элеккечә барышып яшәргә теләвебезне аңлатырга тырыштык. Аңламадылар. Башында Дәүләтьяр морза торган илчелек буш кул белән әйләнеп кайтты. Аларны Архангил чиркәвенә барып җиткәнче үк аттан төшергәннәр. Казначы Хүәдер Сукин гына каршы алган. Иван илчеләрне кабул итмәсә дә, алар аша ярлыгын юллаган. Ул ярлыкны диванда укырга тиешләр иде. Ләкин болай да билгеле: Мәскәүләргә солых кирәкми, алар Казанны басып алырга җыена. Казан качаклары арасында кырымнарны күралмый ничарадан бичара Мәскәү тарафына чыккан, әмма ватан язмышы өчен чын-чынлап җан аткан бәкләр дә бар иде. Шулардан Галикәй бәк миңа яшерен хәбәр итте: кяфер Казан өстенә килергә биниһая гаскәр туплый, иң әүвәл Зөя тамагына кала салып, Тау ягын үз биләмәсе итәргә әзерләнә. Һәм иң аянычы, без аның бу ниятенә һич тә каршы тора алмыйбыз! Ачык кырда андый зур гаскәр белән сугышырлык көчебез юк.

Диванга җыелыр алдыннан эчке казак килеп, агам Кол Мөхәммәд сәйед белән мине Кузычак угъланның күрәсе килүен җиткерде. Икебез дә намаздан соң җәмигъ мәчетендә гәпләшеп утыра идек. Агам, олуг сәйед, миңа Кырымнан килгән хәбәрләрне сөйләп, юаныч җиләнен иңгә салып торган мизгелләр иде. Аңа шанлы Сәхиб Гәрәй ханның сүзен җиткергәннәр. Казаннар күңелләрен төшермичә нык торсын, җәйгә, Аллаһ боерса, аларның хәлен җиңеләйтер өчен Мәскәүгә яу чабам, дигән ул. Сәхиб хан һәрвакыт Казанның арка таянычы булды, ул кузгалса, әлбәттә, без кяфер камалышыннан котылырбыз. Тәңре аңа исәнлек, йөрәгенә җегәр бирсен. Ул көч-гайрәт йолдызы сүнгән Чыңгыз йортының шанын кабат кайтарырга алгысына. Элгәре заманда Казанда үзе хан булган кеше, безне мондый аяныч хәлдә ялгыз калдырмас.

– Йосыф би дә Иванның мондый оятсыз басымчаклыгы белән һич тә риза түгел, безгә чирүе белән ярдәмгә килергә җыена. Үзе килә алмаса, бәлки Галине, йә Юныс морзаны җибәрер.

---

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА (1962) – *шагыйрь, драматург һәм прозаик; «Ил», «Мәгарә», «Ташка ордым башны» һ.б. китаплар авторы, Татарстанның халык шагыйре. Казанда яши.*

– Кичер, агам, – дидем мин. – Һәр сүзең коргаксыган күңелемә зәм-зәм суы булып тамса да, нугайларның ярдәмгә килүенә ышанып бетмим. Йосыф бинең теләге яхшы, ләкин ул энесе Исмәгыйль морзадан уза алмый шул. Аның ризалыгыннан башка эше чыкмас аның. Исмәгыйльне беләсең бит, ул Иванның тугрылыклы көчеге, муенына хач кына асасы калган.

– Анысы шулай, – дип килеште агам. – Юныс морза да Казанга үчлекле, теге вакытта, Сафа ханга булышып йөргәндә, бирегә килеп бәкләрибәк булмакчы иде бит. Хан сүзендә тормады.

– Ничарадан бичара биргән сүз. Казан бәкләре Юныcның олуг бәк булуына ничек килешсеннәр? Сафа хан кабат тәхеткә менүгә үк, алар белән ачулышлы була алмый иде.

– Бәкләр бәге Юныс булса, Казан йорты белән Сафа түгел, мангытлар идарә итәчәк иде, – дип, агам сәйед сүзне йомгаклап куйды. – Шулай да Йосыф бигә дә кичекмәстән илчеләр җибәрергә кирәк. Аның Исмәгыйльдән башка да чирүе җитәрлек.

– Кузычак угълан безнең белән кайда көрешергә тели? – дип сорадым мин эчке казактан.

Казак йөгенде. Кылыч кыны идәнгә тиеп яңгыравык тавыш чыкты, казакның каратут йөзендәге зур күзләре яктырып алгандай булды.

– Анысы сез олугларның ихтыярында... – дип әйтергә боерды.

– Без хәзер килеп җитәбез, – диде Кол Мөхәммәд сәйед.

Тышта салмак кына кар явып тора. Табигатьнең бездә бер гаме юк. Кар ява – үзе бер могҗиза бит! Инде Казанда шактый еллар торсам да, җиһанны ап-ак кар күмеп китүенә күнегеп җитә алганым юк. Гаҗәп! Әйтерсең, җиргә ниндидер бер сәмавилек иңә, кар төшкәндә син, киресенчә, үзең дә сизмичә күккә аша башлыйсың сыман. Ә бураннары?! Караңгы төннәрдә өй почмагын тырнап, эчкә керергә дәгъва иткәндәй улаган буран гүя синең дә күңелеңне биләп ала, күптән онытылган хатирәләрне актарып ташлый. Күңелгә ниндидер хәвеф керә, йа Рабби, дисең, шушы буранда юлда калган мосафирларга дәрман бир, өметләренә ут өстәп җибәр. Шундый уйлар белән йоклап китәсең, төшеңә яшел болын – Хан Болыны керә, аллы-гөлле чәчәкләрнең исен һавага аңкытып үлән кайный, кечкенә-кечкенә күлләр көзгедәй ялтырап күренә. Ниндидер шатлык белән уянып китәсең, буран тынган, урамдагы кар көртләрендә әле бер эз юк, дөнья яңа яралган төсле... Һава зыңлап тора! И Тәңре, мин бит шушында, шушы илдә торам, бу минем ил, күпсенмә син аны миннән...

– Сәхиб Гәрәй ханга олы бүләкләр белән илчеләр дә җибәрә алмыйбыз, – дип уфтандым мин. – Йортның камалышта булуына һич күнегеп булмый.

– Кырымны искә төшердең, ахрысы, – дип елмайды агам.

Мин шикләнеп аның йөзенә карадым. Юк, сүзләрендә төрттерү юк иде бугай. Хәер, кем белә... Минем тирәдә ошакчылар җитәрлек. Берничә көн элек минем хозурыма Кырымнан бер дәрвиш килгән иде. Сәхиб Гәрәй ханның сүзен алып килгән. Агам әллә шул хакта беләме, дип шөбһәләнгән идем дә... юктыр, үзе үк кояш нурында коенган Кырымны искә төшергәндер дә... әнә ничек балкып елмайды. Без бит аның белән икебез дә Бакчасарайда тудык, шунда атлап киттек, бала чагыбыз шунда үтте.

– Өлкәнәйгән саен хатирәләр атавына ешрак йөзеп чыгасың. Кырым да еш искә төшә, Хаҗи Тархан да... Ләкин Казан инде соңгы бишегебез булыр.

– Шулай, – дип килеште агам. – Тәкъдирнең ни язганын белеп булмаса да, шулай булыр сыман тоела.

Әгәр дә агама Кырым дәрвишенең килүе, миңа нинди сүз җиткерүе мәгълүм булса, мин аның әйтелмәгән соравына җавап бирдем.

Сәхиб Гәрәй хан мине Кырымга чакырган иде.

Мәчеткә соры хиркалы дәрвиш килеп кергәч – тунын ул, күрәсең, ишек төбендә үк салып калдырган – мин башта сагаеп калган идем. Мондагы дәрвиш-суфыйларның барысы да миңа таныш, ә моның озын юл үтеп килгәне әллә кайдан күренеп тора: чәче-сакалы җиткән, йөзендә күзләре генә утырып калган... Кайдан ул? Нинди юл үткән? Казанда Мәскәү шымчылары, җасуслар мыжлап тора.Читегемә йөзен тидергәч:

– Әссәламегаләйкүм! – дип сәламләде ул.

– Вәгаләйкүм әссәлам...

– Тәкъсир. Мин Кырымнан Сөендек дәрвиш булам. Сиңа галиҗәнап сүз алып килдем.

Кичүләр урыс казаклары кулында, Кырым белән һич барыш юк, ничек монда үтә алган ул? Минем шикләнгәнне аңлагач, ул тыныч кына әйтте:

– Борчылмагыз, хәзрәт. Арыслан искәрмәгән тишектән тычкан җиңел үтә. Безнең һәр җирдә үз кешеләребез бар.

– Пир-и сөхбәтең кем?

– Кутби әл-актаба Сәйед Атаның лаеклы варисы Баба шәехнең угълы Насыйрулла шәех, Тәңре аңа бакый дөнья рәхәтләрен бирсен.

Мин сынауны дәвам иттем:

– Әбү Йазид әл-Бистами әйткән: «Остазы булмаган кешене Иблис өйрәтә башлый».

– Валлаһи, шулай, – дип мине җөпләде дәрвиш, хәзер аңа ышаныч күрсәтүем җавабына бәйле иде: – Тәкъсир, шәех Әбү Гали әд-Даккакның сүзен кабатларга җөрьәт итәм: «Беркем дә утыртмаган кыргый агачның җимеше түгел, яфраклары гына була».

– Утыр! – дидем мин дәрвишкә һәм хезмәтчемә тәгам китерергә куштым.

Дәрвиш, никадәр генә ач булмасын, ризыкка сузылырга ашыкмады. Догага дип ике кулын җәйде. Куллары зур, сөякчел, күренеп тора, сугышларда чыныккан... Илле яшьләрдәге карт булса да, үзеннән гайрәт сирпелеп тора, моңа дошман булырга язмасын.

– Сәхиб Гәрәй хан – даны еракларга таралсын! – Казанның нинди аянычлы хәлдә калганын яхшы белә, – диде ул ширбәт уртлап куйгач. – Үзегез генә кяфергә каршы тора алмасыгызны да белә. Йодрык булып укмашсагыз, бер хәл... Тик сез бит таркау, арагызда кяфер арбасына утыручылар күп.

– Без дошманны куып җибәрдек, – дидем мин, аның сүзен өнәмичә. Туры әйткән туганына ярамый! – Хаиннәр кайда да бар.

– Синең тиңдәшсез Сөләйман Канунига атап язылган «Зафәрнамә»нең күчермәсе Кырымга да килеп иреште, урысның бу юлы Казанны алмыйча китүен беләбез, – диде дәрвиш. – Аллага шөкер, котылгансыз. Тик бит дошман кабат киләчәк. Тагын да олырак гаскәр белән киләчәк.

«Галиҗәнап сүзе шулмы?» – дип үртәлеп сүзен бүлмәкче идем, телне тешләдем – дәрвишнең тавышы, үз-үзен тотышы тыңларга мәҗбүр итә иде.

– Җәйгә Сәхиб Гәрәй хан Мәскәүгә һөҗүм итәргә җыена, иншалла. Аңа каршы торыр өчен Иван Казаннан чирүен алыр, иншалла. Шуңа күрә хәзер ул нугай морзасы Исмәгыйльне Кырымга каршы котырта, Кырымнар нугайлар белән сугышканда Казанны җиңел генә басып алмакчы...

– Казанда Йосыф бинең торыны хан санала. Кызы Сөембикә монда.

– Атна-ун көн элек Арслан морза үз кешеләре белән Рәзәнгә яу чапкан иде, ишеткәнсездер инде...

Ишеткән идек. Биш меңләп чирү белән киткән морза кырык-илле кеше белән чак йортына кайтып егылган. Урыс гөрзиеннән котылганнары, карга батып, туңып үлгән.

– Терелергә теләмәгән кешене иң оста табиб та аякка бастыра алмый, – диде дәрвиш, бераз тын торгач. – Казан халкының үзендә исән калу дәрте көчле булырга тиеш.

Мин көлемсерәп куйдым.

– Бар ул бездә андый дәрт. Тик төрлечә исән калып була. Хаиннәрне дә исән калу дәрте йөртә.

Дәрвиш, алдында торган касәдә кулын чайкап, тастымал белән озаклап сөрткәч, мәрткә киткәндәй беравык тын утырды.

– Мин җавапның нинди икәнен беләм инде, – диде ул авыр сулап. – Тик галиҗәнап ханның дәгъватен тапшырырга тиешмен. Ул сезне үзенә чакыра. Сез таныш икәнсез бит?

– Мин ул чакта томшыгы яшел чеби генә идем әле.

– Сәхиб хан мөрәүвәтле кеше, галимнәрне, шагыйрьләрне хөрмәтли белә торган зат.

– Безгә аның ул сыйфатлары билгеле, – дидем мин коры гына.

Ханның кыяфәтен күз алдына китерергә тырыштым. Нәкъ утыз ел элек, Казан тәхетен яуларга китәр алдыннан, ул минем мәрхүм атама, Мансур сәйедкә – бакыйлыкта җәннәткә тиенсен! – фатиха алырга килгән иде. Атамның кушуы белән мин аңа юл догасы укыган идем. Онытмаган. Мин дә аны төшемдәге кебек кенә хәтерлим. Җыйнак гәүдәле, ачык чырайлы булып истә калган. Галимнәр остазы, йолдызларга карап, илләр язмышын билгеләргә сәләтле Рәммәл Хуҗа да миңа юллаган хатында Сәхиб хан җәһәтеннән: «Мөлаемлык йолдызлыгында нур сибә торган мөкәммәл ай ул, андыйлар бик сирәк туа», – дип мәдхия язган иде. Ханның шөһрәте Казан йортында да зур – Мәхмүд хаҗи улы аңа атап бер кыйсса да иҗат итте.

Сәхиб хан Казанга килгәч, Кырым ханы Мөхәммәд агасы белән берләшеп, Мәскәүгә үк барып җиткәннәр иде. Мәскәү кенәзе, гадәттәгечә, төн ягына чыгып качкан. Кяфер сүзеннән чыкмаска мәхкүм ителгән Казан йорты шул яудан соң тәмам азатлык яулаган иде. Ләкин, Хаҗи Тарханны үз кул астына алып, нугайлар тарафыннан хыянәтчел рәвештә үтерелгәннән соң, без җилнең кайсы яктан исүен чамаладык! Кырым тәхетенә Сәгадәт хан менгәч, Казан тагын комсыз күршесе белән бергә-бер калды. Үз урынына энесе Сафаны калдырып, Сәхиб хан, Сөләйман Канунидан ярдәм өметләнеп, Истанбулга чыгып китә. Чынлыкта ул кодрәтле солтан бусагасына сыгынып, Кырым тәхетенә дәгъва итә башлый.

Казан тәхетенә күтәргәндә, Сафага ундүрт тулып килә иде. Егетлек кушагын билгә баглаган чагы. Сәхиб хан дилбегәне кемгә тапшырасын яхшы белгән. Сафа белән без бергә уйнап үстек, ул шундый – сабый чагында ук тешләгәнен өзми калмый иде.

Кырым тәхетендә ныгуга ук Сәхиб хан Иванга ярлык юллый. Аның күчермәсе безнең көтебханәдә дә саклана. «Әгәр дә син минем Казаным белән барышлыкта булсаң һәм аның халкыннан салым дауламасаң, мин синең белән дуслыкта яшәргә әзер; ләкин Казанга яу чапсаң, синең илчеләреңне дә, чапкыннарыңны да күрергә теләмибез; урыс җиренә бәреп керәчәкбез һәм аны вәйран итәчәкбез!»

Сәхиб солтанны Казанга ханлык тәхетенә озатуны хәтерлим мин. Хан

сараена атам мине дә ияртеп барган иде. Йортның олуглары каршында Мөхәммәд ибне Миңле Гәрәй хан энесен Казанга хан итеп җибәрү карарын игълан итте. Угъланнар, бәкләр, ханны хуплап башларын селеккәләде, үзара пышылдап, шул ук вакытта ханның да колагына чалынырлык итеп сөйләнделәр:

– Һай, яхшы булган!

– Казан йортыбызны баскыннар кулыннан алырга кирәк.

– Мөхәммәд ханга афәрин!

– Басилины әйтер идем, кара йөрәк, Казанга безнең дошманның токымын утыртты бит.

– Хаҗи Тарханны да алсак...

– Чыңгыз бабабыздан калган кодрәтне кайтарыр Мөхәммәд хан, булдырыр, иншалла!

Исемдә, исемдә... Мөхәммәд ханның янәшәседә атам Мансур сәйед утыра, аңардан соң Агыш, Гази, Апак бәкләр, икенче якта – Мамыш Сәҗәут, Мамыш угълан, Габдулла угълан, Хәлил, Япанчы бәкләр, Мәмеш морза...

– Син үз йортыбызга хан булырга китәсең, – диде мәрхүм атам Мансур, сәйед Сәхиб солтанга фатихасын биреп. – Барлык татар йортларын бер түбә астына җыяр вакыт җитте. Син шул алтын түбәнең алтын баганасы булырга тиеш! Юкса безне берәм-берәм аждаһа йотачак.

– Казан йорты аның авыз төбендә үк... Алтын түбә монда, Кырымда. Агам Мөхәммәд хан барыбызга да түбә булыр, иншалла.

Сәхиб солтанның, яшь булса да, һәр сүзе үлчәнгән, кайда ни сөйлисен ул яхшы белә иде. Буласының, әйе... яшьтән үк билгеле. Ләкин агасын ул, мөгаен, чын күңелдән мактагандыр... Ул чакта Сәхиб – дистәләгән солтаннарның берсе, беркем әле аны белми, сәләтен чамаламый – юкса ул үзен зур бәяли! Соңыннан беленгәнчә, Казанда хан булуны сөргенгә олактыру дип кабул иткән... – ә Мөхәммәд ханның даны җиһанга таралган, дуслары аны ныклы таянычка саный, дошманнары шүрли.

Мөхәммәд Гәрәй хан, чыннан да, фәһемле, кодрәтле падишаһ иде, тик аркадашларына артык ышануы үзен дә, улы Баһадир солтанны да харап итте, татар йортларын бер түбәгә җыю нияте дә пыран-заран килде.

Хыянәт!

Хыянәт башына җитте шөһрәтле Мөхәммәд ханның. Хыянәт татар йортының терәкләрен берәм-берәм аудара. Мин җиргә егылган түбә астында сытылырга тиеш микәнни? Тәңрем...

Аннан соң күпме сулар акты. Сәхиб ханны Казанга озатканда, мин ун яшьләрдәге вафасыз бер бала, хәзер талчыккан чал ир булып киләчәкне юрарга җөрьәт итми торам. Хәер, юраудан ни мәгънә? Бичара булып тудым, бичара булып китәрмен.

– Хан сине Кырымда нәкыйбел әшрәф итмәкче була. – Дәрвиш мине сагышлы уйларымнан аерды. Мин аның тел төбен күптән аңлаган идем инде.

– Минем ише мискин бер суфыйга игътибар иткәне өчен Аллаһның аңа мең шөкере яусын. Ләкин мин йортны мондый хәлдә ташлап китә алмыйм. Минем монда булуым – Аллаһ хөкеме ул. Мәрхәмәте. Димәк, ул мине газага лаек дип тапкан.

– Әйе, мин дә шулай уйлыйм, – диде Сөендек дәрвиш. – Минем дә хан йомышы белән бирегә килүем юкка түгел, Аллаһ мәрхәмәте. Арагызга кабул итәсездер бит, тәкъсир?

– Хуш килдең! – Һәм без икебез дә бердәм торып кочаклаштык.

Әлбәттә, агам Кол Мөхәммәд сәйедкә мин бу очрашу хакында сөйләмәдем.

Иманым камил, минем урында булса, ул да нәкъ шундый ук җавапны бирер иде. Мондый карарны без биш-алты еллар элгәре, атабыз Мансур сәйед белән Казанга килгәндә үк, кабул иттек. Шул заманда ук безне монда ниләр көтәсен чамалый идек инде. Ул чакта ук кяфер Казанның якасыннан алган иде.

Уйлыйм-уйлыйм да шаккатам: ул яка ятлар тотар өчен генә тегелгән дә кебек!

Кырымда Сәгадәт хан бер ел да идарә итә алмады, тәхетне Ислам солтан яулап алды. Без бу вакытта җәйләүдә идек. Кояш инде баеп килә, тирә-як тын, атларның гына пошкыруы ишетелә, күңелләрнең рәхәт оеган чагы, табигать тә гүя сихри чиксезлек каршында сәҗдәгә китәргә җыена. Шул илаһи тынлыкны чәлпәрәмә китереп, талгын һава дулкыннарын өереп, тояк тавышы ишетелде. Атабыз безгә Җәләлетдин Руминың мәснәвиләрен сөйләп тора иде, аптырап туктады. Кем йөрер болай кичкә каршы? Без, балалар, чатырдан йөгереп чыктык. Бераздан җайдагат үзе дә күренде. Анамның туганы Мәмеш морза иде ул. Атыннан җәһәт кенә сикереп төште дә тезгенен минем кулга ыргытып, чатырга – атам хозурына ашыкты.

– Олуг туганыбыз сәйед хәзрәтләре!

Мәмеш морзаның тавышы киселде. Мин чатырда алар янәшәсендә булмасам да, тәгаен белә идем, атам кулын күтәреп чакырылмаган кунакны туктатты. Кабаланганны өнәми иде ул. Өең яна башласа да, син аңа бу хакта вәкарь белән, сүзеңне җебен җепкә китереп хәбәр ит. Остазыңның дикъкатенә тәкъдим иткәнче, син үзең ул әхвәлнең серенә төшен, күңелең белән аңла. Әйтелмәгән сүзнең яктысы йөрәккә тизрәк барып җитә. Тик Мәмеш морза, гаскәри тупаслыгы аркасында мондый нечкәлекләрне белми идеме, әллә санга сукмадымы, ярып салды:

– Тәкъсир! Сәгадәт хан бүген Бакчасарайдан качып китте. Тәхеттә Ислам солтан. Инде синең урынга олуг сәйед билгеләнде.

– Курткамы?

Куртка сәйед атамның берадәре Солтангали сәйеднең улы иде...

– Әйе. Тиздән фетнәчеләр монда килеп җитәчәк.

Без тиз генә җыенып юлга кузгалдык. Юл безгә генә билгесез иде. Мәрхүм атабыз Мансур сәйед өчен билгесез һәм ябык юллар юк, соңыннан белдек: ул безне – хатыннарын, балаларын, якыннарын, чураларын – Хаҗи Тарханга алып киткән икән. Хаҗи Тарханда мин егет булдым, мөрәкябага ирештем, тәхәллүсемне дә Хаҗи Тархани дип белерсез.

...Кузычак угълан безне бик гасаби каршы алды. Дөрес, ул эчке халәтен яшерергә тырыша иде, сәламләве дә гадәттәгечә табигый, тик тавышы утырган, гүя тирән коедан ишетелгәндәй тонык. Аякларны бөкләп фарсы келәменә утырдык. Алдыбызга хезмәтче җиләк-җимеш тулы көмеш савытлар китерде. Дога кылганнан соң Кузычак сүз башлады:

– Иван безнең илчелекне санламаган. Башында Нургали карачы торган илчелек таләп итә. Анда өч-дүрт угълан һәм бәк тә булырга тиеш, дигән. Шулар килгәндә генә, янәсе, ул барышлык хосусында бездән ни тиешлене белдерәчәк. Йә, могътәбәр сәйед хәзрәтләре, бу турыда ни уйлыйсыз? – дип, ул агам Кол Мөхәммәд сәйедкә карады.

Озак кына уйланып торганнан соң ул:

– Аларга илчелек кирәкми, алар сугышырга җыена.

– Казан олугларыннан торган илчелекне Иван үзендә тоткарларга тели, – дип өстәдем мин.

– Мин дә шулай уйлыйм, – диде Кузычак. – Гаскәрен бу тарафка куалагач, ул аларны безгә каршы куячак.

Кол Мөхәммәд өзеп әйтте:

– Утлы күмерне кем кулы белән көрәргә белә ул!

Нургали бәкнең хәйләкәр чыраен күз алдына китереп, мин ирексездән елмаеп куйдым. Гәрчә бу шартларда елмаю һич урынлы булмаса да... Карачы, әлбәттә, Иванны алдыйм, дип алданачак иде. Артында көчле гаскәр тормаса, иң нечкә хәйлә дә мескенгә әйләнә. Хәер, без монда барыбыз да шул хәлдә түгелме соң?

Ләкин суда батучы саламга да ябыша, дигәндәй, без һәр мөмкинлектән файдалана белергә тиеш. Нургали бәкнең тасма теле Иванның ихтыярын йөгәнли алыр, бәлки?

– Шулай да, – дидем мин, сүзем Кузычак угъланга ошамасын алдан ук белеп, – бөек илчелекне Мәскәүгә юлларга кирәк. Иванның шартлары авыр булса да, йортның исән калуы хакына...

Кузычакның йөзе тагын да каралып китте.

– Кичер, хәзрәт... Аның төп шарты шул: Казан йортын үз биләмәсе итү...

– Үти алмаслык шартлар була. Ул инде сугыш игълан итү.

Кол Мөхәммәд сәйед идәнгә караган килеш әйтеп куйды:

– Безнең өчен бүген ике генә тараф бар: йә бәйсез булу, йә сугышу. Без озак еллар шул ике тараф арасында бәргәләндек. Ниһаять, сайлау көне килеп җитте...

Кузычак урыныннан торды.

– Калганын диванда сөйләшеп хәл итәрбез.

Ул Мәскәүгә кабат илчеләр юлларга җыенмый, ул гамәлне һич файдасызга саный, безнең кылны тартып карарга гына чакырган иде. Әлбәттә, әлеге фикерен Казан олугларына җиткергәндә, ул бездән булышлык көтә, нәкыйбел әшрәфнең хуплавы аңа зур таяныч иде. Минем белән исә ул салкын хушлашты. Бу очрашудан соң, мин инде аңа кирәкле кеше түгел идем. Бернишләп тә булмый. Кузычак угъланны мин Казанның иң фидакяр күңелем асманының җиденче катына күтәрәм, тик ил язмышы хәл ителгәндә, моның ни әһәмияте бар? Иван үзенә тугрылыклы Шаһгали ханны тәхеткә күтәрүне таләп итсә – ул шулай булачак та! Әгәр бөтенләй урыс калгаен китереп куярга теләмәсә! – Сафа Гәрәй тарафдарларын, иң беренче нәүбәттә Кузычак угъланны, ул үз кулына тапшырырга кушачак. Кузычак бит катыйле нәфсә (?) түгел. Ул Казан өчен дә, үзе өчен дә ахыргы тамчы канына кадәр сугышачак. Әгәр Иванның шартлары безнең тарафтан йортны исән калдыру хакына кабул ителсә, кем аңа андый хокукны бирер? Сугышып шәһид китү хокукын... Ә баскыннар кулына төшү аңа да, аркадашларына да үлем белән бәрабәр. Ул денен дә, илен дә сата торган кеше түгел.

Диванханә Кузычак угълан хөҗрәсеннән якын гына – кысан аралыктан бераз барасы да сулга борыласы, артык зур түгел, гадилеге күзгә бәрелеп торган, хәер, түшәме төрле гөлчәчәкләр, оҗмах кошлары белән бизәлгән бүлмә иде ул. Тәбәнәк сәкеләргә ефәк белән тышланган сырмалар җәелгән, таянырга мендәрләр куелган. Диванда, гадәттә, хан катнашмый, янәшәдә өстә аның өчен бүлмә бар, теләгәндә, ул анда кереп диванны тыңлый ала – шул максатта түшәмнән астарак челтәрләнгән уем бар. Диван бу мөмкинлекне һәрвакыт исендә тота. Ә болай биредә сөйләнгән сүзләрне ханга диван бәге җиткерә. Баш карачы монда кабул ителгән карарны аңа кереп дәлилли.

Ханыбыз Үтәмеш Гәрәйгә әле дүрт кенә яшь, ул үз хәленең дә, ил язмышының да нинди аяныч икәнен башына да китерә алмый – бәхетсез сабый! Безнең бу газаплы сөйләшүләрдә дә аның эше юк, анасы Сөембикә, бәлки, күрше бүлмәгә кайчакта тыңларга керәдер, тик ул бервакытта да күзгә кереп хөкүмәт эшләренә

катнашмый, үзенең өстенлеген сиздерми, бар гамәлен Кузычак угълан кулы белән эшли, Кузычак аңа ире Сафа ханнан калган таяныч иде. Билгеле, таянычсыз калса, аның да көннәре санаулы булачак. Мәскәүләр Сөембикәне күралмый, Казанның Сафадан соң да бәйсез булырга тырышуында төп сәбәпче ул, дип уйлыйлар, җае чыккан саен аны каралтырга тырышалар, төрле гайбәтләр тараталар иде.

Диван бик тавышлы булды. Хәер, минем хәтеремдә, биредә беркайчан да бер фикергә килү булмады. Һәркем үзен җирнең кендеге саный, бу җәһәттән Казан татары һич тә ләх панынннан калышмый. Кешенең мөкатдәс үздәрлеге өчен фикер төрлелеге яхшы булса да, дәүләтнең көчле бер йодрыкка әверелүенә мондый хәл хилафлык итә иде, билгеле. Мәскәү кенәзлегенең көчәеп китүендә тәхетнең биектә урнашуы иң мөһим сәбәп булгандыр да. Анда олуг кенәзнең генә сүзе сүз. Иң затлы нәсел кешеләре дә олуг кенәзнең колы санала. Нинди үз теләгеңчә йөрү ди ул?! Ни уйлаганыңны кычкырып әйтсәң дә, башта телеңне йолкып алалар, аннары... билгеле инде. Синең яшәвең дәүләт файдасына, ягъни олуг кенәз файдасына гына була ала. Мөгаен, безнең заманда дәүләт шундый хәлдә генә иҗтиһад итә ала. Тик шуны аңлатып кара син башбаштак татар морзасына. Ул тәкәбберлеген байрак итеп күтәргән. Бу татарның элекке күчмәнлегеннән киләдер, үз биләмәсенә анда һәр би үзе хуҗа, ул үзе бер аерым дәүләт, тәхет илендә утырган ханга тыштан буйсынса да, үз биләмәсендә ул мөстәкыйльлеген күз карасыдай саклый. Иреге кысыла башласа, башка үзе ишеләр белән ханны тәхетеннән бәреп төшерергә дә мөмкин. Алтын Урдалы олуг Олыс шул күчмәннәр аркасында җимерелде дә инде. Аның чарпа-чарпа кыйсемнәрен дә, болай барса, шул ук язмыш көтә. Әмма ничек аңлатасың? Үзен иң акыллы санаган кеше бүтәннәрнең фикерен тыңлыймыни?

Мәскәүләрнең шулай күтәрелүенә борынгы ханнарыбыз да сәбәпче булды. Үзбәк хан заманнарыннан ук аларга үзгә урыс кенәзлекләреннән аерым ярлыклар тапшырылды. Мәскәү кенәзенә олуглык хокукы бирелеп, ул тирә-як тарафтан Сарай әл-Мәхрусә өчен салым җыйды. Акча кем кулына тисә дә, күпмедер өлеше ябышып калучан. Бөек ханнар чиркәү карагруһларыннан ясак алмаска боерды, алар тарханлык ярлыгына ия булды. Оныттылар: ит яхшылык, көт явызлык! Чиркәү әһелләре шыпырт кына халыкны гел мөселманнарга каршы котыртып ятты.

Хәзер боларны искә төшерүдән ни файда? Терсәк якын да, тешләп булмый.

Дәүләтьяр кысык күзле, сары йөзле, юантык кына бер кеше, тыңкыш тавыш белән зарланды: Мәскәүдән бик кимсенеп кайткан икән. Шундый затсыз кешене җибәреп, Кузычакның Иванны кимсетәсе килгәндер дә, киресенчә килеп чыккан.

– Архангилга җиткәнче үк аттан төшерделәр, – дип янә зарланды ул.

Соңгы вакытта татар, нугай илчеләрен, түбәнсетеп, шул чиркәү каршында җәяүләтәләр иде. Фәрәнкеләр исә, насарилар буларак, Яхшы хәбәр чиркәвенә кадәр атланып бара. Нишлисең, тагын уфтанырга кала, кенәзнең кырым-ил ишегалдында үз бүрегенә солы тутырып татар баскагының атын ашату йоласы мәңгегә үткәндә калды. Халыкларның тарих сәхнәсендә казгануы шатранҗа уены сыман, уен башында бер ялгыш йөреш ясадыңмы, соңрак шул тулаем җиңелүгә китерә.

– Кичекмәстән урыс җиренә яу чабарга кирәк! – диде Турчы бәк. Яңагындагы яра эзе кара-кучкыл янып чыкты. Ул барышлыкның нечкәлекләрен белми, аңа кылыч болгарга булсын. Аңы да сөңге озынлыгы гына, башкача ни көтәсең тагын? Шуңа да аның сүзенә елмаешып кына куйдылар. Уңае туры килсә, яу чабарга кем каршы? Егет яуда сынала.

– Яуны яу белән генә басып була! – дип янә йөрәксенеп кычкырды Турчы

бәк. Нинди генә тупас яугир булса да, үзенә тәкәллефле мөнәсәбәтне сизде, күрәсең. Ә сүзе дөрес бит!

– Ике-өч татар күренүгә, урыс гаскәре хәзер башын югалтып качмый, – диде Ишми морза. – Яу чапсак, ачык кырда без кырылып бетәчәкбез. Әнә күптән түгел Арслан морза нугайлары чабып караган бит. Тар-мар иткән үзләрен кяфер. Без яуда кырылсак, Казанны кем саклар?

– Сездән башка биредә сарык көтүе мәллә? – дип ярсып урыныннан калыкты Җанбарыс морза. – Барыгыз, яу чабыгыз, без сездән башка да Казанны саклый белербез!

Кол Мөхәммәд сәйед аны бүлдерде:

– Сез дә без юк монда. Булырга тиеш түгел. Барыбызның да йорт өчен җаны фида.

– Мәскәүгә илчеләр җибәрүдән бер файда да юк, кирмәнне ныгытырга кирәк, урларны тирәнәйтергә, бистә диварларын сүтәргә, без анда дошманны барыбер тоткарлый алмабыз, – диде Карамыш угълан.

– Әйе, алар анда тупларын куеп, кирмәнне утка тотачак, – дип өстәде Барбулсын аталык.

– Илчегә үлем юк, без сугышка әзерләнсәк тә, илчене Мәскәүгә юллыйк! – Кадыш баһадир сирәк сакалын сыйпаштырып Нургали бәккә карады.

– Җәмәгать ничек хәл итә, мин шуңа риза. – Нургали бәк тыйнак кына тамагын кырып, кара куе сакалын араларга кереште. – Әлбәттә, куркыныч бар. Мәскәү ул без түгел, илчене дә кайчак зинданга яба... Башсыз да калуың бар. Тик гыйзззәтле олуглар кушса, мин юлга чыгарга әзер. Тәвә кошы кебек башны комга яшерер вакыт түгел.

Кузычак өмет белән сәйедләр сәйеде мөхтәрәм Кол Мөхәммәд агама борылды:

– Динебезнең алтын баганасы, Казан данын үз иңендә тотып торган сәйед хәзрәтләре ни әйтер?

Агам минем иңемә кагылып алды.

– Без менә Кол Шәриф мулла белән киңәштек, – диде ул. – Мәгънәсез эш белән йөрү килешмәс. Иванның һич кабул итмәслек шартлар куячагы билгеле. Шаһгалине тагын тәхеткә уздырсак, безне ни көтәсе дә ачык.

– Сезне! – дип кычкырды Кадыш баһадир.

– Безне! – дип сүзе белән басты нәкыйбер әшрәф. – Яхшыга һич өметләнмә, Кадыш баһадир!

Тәкъдирне укый алгандыр ул агам. Алар икесе дә бер көнне, бер үк сәгатьтә дөньядан кичтеләр. Аркасына хәнҗәр кадалганда, сәйеднең кисәтүен искә алдымы икән Кадыш баһадир?

– Кузычак белән килешмәгән бәкләр качып бетте, – дип сүзгә кушылырга булды Ходайкол угълан да. – Тик кара халык кая качсын? Алар монда болгана. Илдә фетнә купса, эшләр харап...

– Халык – кара сарык, Мәскәүгә баш исәк, бу бәла-казадан котылыр идек, диләр.

– Кяфер кул астында яшәп караганнары юк...

– Халыкны котырталар!

Шау-шуны бүлеп, Кузычак угъланның тавышы яңгырады:

– Мондагы сөйләшүне мин хан хәзрәтләренә җиткерермен. Йорт кайгысын кайгы иткәнегез өчен Аллаһның шөкере булсын. – Ул урыныннан торып, ишеккә атлады. Барыбызга да ачык иде: Мәскәүгә бернинди илчелек тә бармаячак.



*Гөлсинә Ханәфи (Гөлсинә Канәфи кызы Хәйретдинова) 1960 елда Ульяновск өлкәсе Яңа Малыклы районы Зирекле Куак авылында туа. Туган авылында урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1978-96 елларда Куйбышев (Самара) шәһәрендә яши. 1993 елда Куйбышев полиграфия техникумының икътисад факультетын тәмамлап, техник-икътисадчы белгечлеге ала. 1996 елда гаиләсе белән Димитровград шәһәренә күченеп кайта.*

*1992-96 елларда Россия Армиясе сафларында хәрби хезмәттә була.*

*Димитровград шәһәрендәге 22 нче татар мәктәбендә китапханәче булып эшли. «Ак калфак» хатын-кызлар оешмасының да актив әгъзасы, оештыручысы.*

*«Көмеш йөзек» исемле китап авторы.*

Гөлсинә
Ханәфи

# ЯШИ БЕЛЕП ЯШӘҮ – АКЫЛ КҮРКЕ...

## Татарым

Дәүләтеңне тар-мар итеп таратканнар,
Башкалаңны ут яудырып тапаганнар...
Күн итекле гаскәрләрең була торып,
Чабаталы затлар сине таптаганнар?!.

Юкка чыккан ныгытмалы шәһәрләрең,
Дәһшәт уты телгән татар-мишәрләрең.
Сатлык җаннар тамыр җәйгән арасына,
Дошман ничек калкан булсын бу халкыңа?

Калдырганнар Ак пулатны кара көлгә,
Таптаганнар дәрәҗәңне салып җиргә;
Тураганнар тарихыңны кисәкләргә,
Эш табылган ул чорларда күсәкләргә.

Баш имәдең, татар булып кала белдең,
Атамаңны кабул иттең, шуңа күндең...
Саклап калдың изге динең, татар телең!
Бүген сиңа баш иярлек, халкым минем!

Батыршалар, Кубрат ханнар – синең каның,
Кол Галиләр, Мәрҗаниләр – белем таңың.
Бүгенге көн кояшыдыр Тукайларың,
Нәселеңә иркен-азат тугайларың.

Чыктың уттан. Сиңа тугры калды рухың.
Ватаның бар, Казаның бар, кызың-улың.
Хак юлларын кәгъбә итеп тарихыңның –
Яшә, халкым, горур булып кечең-олың!

## Бирелмәгән гомер ике тапкыр

Бирелмәгән гомер ике тапкыр,
Кабатланыр кебек яши кеше –
Дөнья тәртибенә бәйләнмәгән –
Җирне әйләндерә галәм көче.

Дөнья малын җыя берәү – нәфес
Гүя җиде башлы елан ише.
Асты өскә әйләнсенгә дөнья –
Капма-каршы аңа икенчесе.

Шул бер дөнья, бер җир барыбыз өчен.
Яшен тизлегедәй үтә гомер...
Ялгыш яшәү белән риза түгел?!.
Җаннар төрле...
Шуңа әрни күңел...

Заманага сыешмаган кемнәр,
Язмыш иләгендә иләнгән кем?
Кемгә бу җир бары төкерер өчен,
Бары күмелер өчен, җиткәч бер көн?..

Яши белеп яшәү – акыл күрке.
Җирне әйләндерә галәм көче.
Бирелмәгән гомер ике тапкыр!
Кабатланыр кебек яши кеше...

## Тирбәлә бишек

Тирбәлә бишек үзеннән-үзе...
Бишектә энем, йомылган күзе.

Агач бишекнең киндер төпләре,
Тирбәлә бишек –  йомшак сиртмәле.

Үз-үзен көйли шул нәни бала,
Бишек тирбәлә, бишек чайкала.

Урамда кояш көләч елмая;
Бала караучы – үзем дә бала.

Әни юк өйдә, киткәнме эшкә,
Йә суга киткән ерак инешкә?

Иртәнге таңнан эти дә юлда,
Без йоклаганда, ул инде рульдә.

Күрми калабыз кояш батканын,
Сагынып көтәбез эштән кайтканын...

...Бишектә энем туйганмы йоклап,
Елап маташа, мәмиен сорап!

Әти дә эштә, әни дә – озак...
Бишек тирбәлә...
Ишектә – йозак...

## Үткәннәр

Маңгайга язылган язмышның
Мизгелләр агышын кичерәм.
Шатлыклы, сагышлы юлларны
Берәмләп дәфтәргә күчерәм.

Минеке, синеке – кушылган,
Бер язмыш ничәгә әйләнгән.
Ә тормыш сәхнәсе – әйләнмә:
Курчаклар җепләргә бәйләнгән...

Үткәннәр – дәвамлы бер китап,
Өч нокта ахыргы юлларда...
Кызык та, аяныч кайвакыт,
Чумганда кичереш-уйларга.

Тик кабат һәм кабат кайтыла,
Сөекле сөяге бар сыман...
Үткәннәр... Хәзер һәм киләчәк
Буынга дөньялар тар сыман...

## Уйларым

Өстәлдә ак кәгазь, күк каләм,
Уйларым чуала иртәдән...
Уйларым чәчелә – тоталмам:
Бүген дә язмыйча түзалмам.

Уйларым – аклы-күк болытлар,
Югала агылып офыктан.
Ә сүзләр шигъри ямь алыплар,
Мәҗбүри хисләргә юлыккан.

Сихри көч аларны яудыра,
Чигешле юлларга салдыра.
Һушымнан яздырып, яздыра...
Уятып... хәйраннар калдыра!..



*Айсинә Сәлахова 1999 елның 19 декабрендә Актаныш районы Чуракай авылында туа. 6 сыйныфка кадәр Чуракай төп гомуми белем бирү мәктәбендә, аннары Актаныштагы «Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат»ында белем ала.*

*Бүгенге көндә Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Милли мәдәният һәм мәгариф Югары мәктәбендә 2 нче курста укый.*

*Чәчмә һәм шигъри әсәрләре белән «Илһам» бәйгесендә катнашып, беренче, өченче урыннарга лаек була. Казан федераль университетында уздырылган «Шигъри-Сабантуй» бәйгесендә «Трибун шагыйрь» номинациясендә беренче урынны яулый.*

Айсинә
Сәлахова

# КУЛДАШЫМ

хикәя

## Сөн кызы

Заманча җиһазланган иркен бүлмәдә ике өстәл, шкаф, компьютер һәм китап киштәләреннән тыш, тагын бер әйбер үзенә игътибарны җәлеп итеп тора иде. Ишектән керешкә үк үзенчәлекле исе борынга бәрелә дә бөтен фикереңне чуалта да куя. Әлеге «мәкерле нәрсә»не Асия бирегә туган ягыннан алып килде. Һәркөн иртә белән аның янына барып, яфракларын сыйпый, төбе корыса, аз гына суын да сала... Бераз сокланып карап торгач, чәчәкләрен учына алып бер исни дә өстәл артына барып утырып, эшкә керешә. Күпме кешене җәлеп итә алырлык көчкә ия әлеге табигать могҗизасы – яран гөл.

Бүген дә документлар арасында хәлдән таеп утырганнан соң, гадәттәгечә, Асия бераз ял итеп алыр өчен, үзенең яраткан чәчәкләре янына килде. Алар тынычландырып кына калмыйлар, ә вафат булган әбисен дә искә төшереп торалар иде. Тормышның нинди генә ачы җиле оныгына кагылса да, әбисе аны чәчләреннән сыйпап тынычландыра, бөтен борчуларын оныттыра иде. Зур юлга чыкканда да, әбисенең истәлеге итеп, әлеге гөлне алды ул.

Өстәлдә күпме генә эше өелеп ятса да, вакыты никадәр генә тыгыз булса да, Асия аларны онытмый иде. Алдагы семинарга әзерләнеп яткан арада да, «дусларының» хәлен белеп киткәләде. Үзе яфракларын куллары белән әкрен генә сыйпый, үзе авыз эченнән җыр көйли:

...Әнкәй безне Сөннән алып кайткан...

Янәшә өстәлдә генә утырган Сяо Мин бик озак карап торганнан соң, түзмичә сүз башлады:

– Борчыганым өчен гафу итегез, баядан бирле нәрсә турында шулай моңланасыз?

Әлеге сорауны ишеткәч, Асиянең йөзендә елмаю чаткылары күренде. Ниндидер сер яшергәндәй, ул күзләрен ялтыратып, күршесендәге Сяо Минга карады да берни булмагандай янә кызыл чәчәкләргә бакты. Шулай җавапсыз гына елмаеп куюына бераз ачуы килгән Сяо Мин үпкәләгән кыяфәттә телефонында чокчынырга тотынды. Шулчак Асия тәрәзә төбенә терәлеп басты да сүз катты:

– Сяо Мин, сезнең дөньядагы иң матур җирне күргәнегез бармы?

– Матур җирләр күп инде ул, мисал өчен, мин теге елның бишенче аенда[1] Испаниядә булдым, бу елны Америкада... Сез күрсәгез...

– Тсс, туктагыз, тукта...

Сяо Мин үзенең хыялларыннан айнып, тынып калды һәм дәвам итегез, дигәндәй Асиягә якынрак килде.

– Юк шул, юк... Күргәнегез юк сезнең иң матур җирләрне. Күз алдына гына китерегез: ярларына тулып Сөн елгасы ага... Офыкта алтын төсендә ялтырап, кояш күренә... Аның нурлары әкрен генә аккан елга буйлап сузылалар да алмаздай ялт-йолт киләләр.Тегермән, Алкәби таулары...

Агач башларында сандугачлар сайрый. Алар үзләренең җырлары белән бөтен урманны, болын-кырларны йокыдан уята. Иртән төшкән чык тамчыларына ялантәпи басасың да чеби үләннәре буйлап, эчеңнән әкрен генә көйли-көйли, Түбән очка таба төшәсең.

Ә анда синең газиз йортың... Ак яулыклы әбиең, син бозауларны болынга бәйләп кайткан арада табада коймак кыздырып куйган. Аңлыйсыңмы син?! Әбиеңнең шул коймаклары белән кайнар чәй эчәсең. Ул коймактан соң әле куллар ялтырап, майланып кала... Тәмләп тамак ялгаганнан соң, күрше малае Әмиргә кул гына болгыйсың да сәпиткә атланып, чиләгеңне эләктереп, җир җиләгенә китәсең. Әле ул шайтан малай үзе белән кармагын да ала. Башта кып-кызыл җиләкләр белән чиләкләрне тутырасың, аннан Сөн елгасында балык чирттерергә утырасың. Ярты көнеңне шулай табигать кочагында үткәреп, көтү каршыларга кайтасың. Ә кичләрен... Кичләрен өебез каршында яшәүче йөзьяшәр Сәлим бабай гармунын алып, капка төбенә чыгып утыра да бөтен авылга ишетелерлек итеп, «Галиябану», «Оныта алмыйм» көйләрен суза. Күктәге йолдызларны санарга дип, син дә аның янына чыгасың.

– Кайлардан килгән, дисәм, Сунь кызы икән бит бу, – дип Сяо Мин көлә генә башлаган иде, Асия кулы белән туктарга ишарә ясап:

– Сөн! Сөн кызы... – дип төзәтеп куйды.

Сяо Мин берничә кат кабатлады, яңгырашны төзәтергә тырышты:

– Сөн. Дөресме?

Шундый җанлы әңгәмәне ишек тавышы бүлдерде. Күп тә үтмәде, директорның уң кулы Вэн Мин күренде. Ул Асиягә карады да:

– Асия, сезне Шэн Ли үз янына чакыра. Кул куйдырасы документларыгызны да үзегез белән алыгыз, – диде.

– Ярар, рәхмәт.

## Шэн Ли

Асия килеп кергәндә, директор Шэн Ли кем беләндер телефоннан сөйләшә иде. Шунлыктан кыз бүлдерергә теләмичә, ишек төбендә генә басып торуын дәвам итте. Телефонын куйгач, Шэн Ли аңа бер көлеп карады да:

– Ничекләр өйрәтеп бетерергә сине?! Чит кеше кебек ишек янында гына басып торма инде, түргәрәк уз, балакаем, – дип, өстәле янындагы урындыкка төртеп күрсәтте.

Директор Шэн Ли – урта буйлы, кысык күзле бер кеше. Яше кырыкка җитеп килгәнгәме, әллә инде эшенең авырлыгыннанмы, чәче бераз агара төшкән, маңгаенда җыерчыклар күренә башлаган иде. Ләкин үзе яшь егетләрдәй кап-кара костюм киеп, хушбуй бөркеп йөри. Йөзеннән елмаю китмәгәнгәме, аның янында йөрәкне ниндидер курку биләп алмый. Эшчеләр тыныч күңел белән кереп, әйтәсе сүзләрен, теләкләрен әйтеп бетереп чыга. Йөзеннән елмаю китми, дигәч тә, аны эшенә җавапсыз караучы шәхес, дип күз алдына китерергә кирәкми. Киресенчә, ул үзе эш урынында сирәк кенә күренеп, нефть эшкәртү буенча төрле конференция, очрашуларда йөрсә дә, аларның башкарган эшләре турында хәбәрдар булып тора.

Әйе, беренче күрешүдә үк Асия директорның күңеленә хуш килде. Шундый тыныч холыклы, сабыр татар кызын ошатмый мөмкинме соң? Җитмәсә, әле яңа гына укуын тәмамлауга карамастан, эшен чын осталарча башкара бит...

– Сезне борчырга теләмәдем, – дип сүзен башларга теләгән иде, авыз ачарга да ирек бирмичә, Шэн Ли фикерен дәвам итте:

---

[1] Кытайда ай исемнәрен санлап кына сөйләшәләр.

– Нинди борчу? Нинди борчу? Әйтергә дә онытып торам, Ай Ли апаң кич чәй эчәргә чакырды. Әллә нәрсәләр әзерләп тормыйм, диде. Син кил, яме? Алайса, әйтмәгәнсең, дип, мине ачулана.

– Рәхмәтләр яусын инде, – диде Асия.

Кытайда 3 еллык укуын тәмамлагач, Асияне килешү буенча Шэн Ли житәкчелегендәге оешмага эшкә җибәрделәр. Җор телле, шаян Шэн Ли әфәнде аны үз кызыдай кабул итте. Һәрвакыт төпле киңәшләрен биреп, кара алтын өлкәсендәге белемен ныгытып торды. Хатыны Ай Ли төрле тәм-томнар белән сыйлап, Асияне аш-суга өйрәтте, Кытай тарихы, йолалары белән таныштырды. Күңелле яшәделәр...

Килергә сүз биреп, Асия эшкә күчте:

– Берничә җиргә кул куйдырасым бар иде... Ә семинарга килгәндә, бөтен әйбер дә әзер, дисәк тә була, әмма Сяо Лун... Кыскасы, бүген иртәнге тикшерү барышында, Сяо Лунның нормадан арттырып эшләргә теләве нәтиҗәсендә, җиһазның механизмына зыян килүе ачыкланды. Шуңа күрә семинарда әлеге юнәлешне йә төшереп калдырасы, йә нәрсә беләндер алыштырасы була. Чөнки җиһаз тиз арада төзәтелмәскә мөмкин. Шулай ук Сяо Лун үз хатасын танырга теләми.

Әлеге яңалык Шэн Лине чыгырыннан чыгарды. Әлбәттә, мондый хәл белән аның беренче тапкыр гына очрашуы түгел, ләкин тәҗрибәсе үсә барган саен, Шэн Ли әфәнде аның төзәтеп булмаслык хаталарга китерергә мөмкин икәнлеген аңлый иде. Җитмәсә, үз хатасын танырга теләми, ди...

– Кем кушкан, диген?

Бу сорауга Асия җавап бирмәде. Директор:

– Әйдә, киттек, – дип костюмын элде дә, эре адымнар белән бүлмәдән чыкты.

Тәмам югалып калган Асия аңа иярде...

## Сяо Лун

– Сяо Лун, синең урында булсам, минем йөрәк җитмәс иде, – дип, Хәлил дустының җилкәсенә кулын куйды.

Эшчеләр төшке ашка ялга туктаган иде. Һәрвакыттагыча Сяо Лун, Вэн Хуа, Хәлил ашханә каршында ялгызы гына үскән агач төбенә барып утырдылар. Сяо Лун белән Вэн Хуа – күптәнге дуслар. Ә Хәлил әле аларга ике ел элек кенә килеп кушылды. Ул уйгыр булуына карамастан, бала чактан ук Кытайда үскәнгә күрә, ике кулдашы белән тиз арада уртак тел тапты. Бүген дә алар өчәүләп, Сяо Лунның эшләгән хатасы турында гәп корды.

Дустының әйткән сүзенә көлеп кенә куйса да, Сяо Лун тиздән нәрсәдер үзгәрәчәген чамалый иде. Әмма иптәшләренә бу турыда сиздермәскә тырышып:

– Нишлисең инде, – диде.

Әлеге сүзләрдә күпме мәгънә ята лабаса! Вэн Хуа моны тиз аңлап алды, елмаеп:

– Кыз каратуның юлын белмисең син. Бездән сорарга ояласың икән, китап укып булса да өйрән, – дип шаярды.

– Болай итеп йөреп, Сяо Лун, бер килеп кабасың инде син.

– Ярар инде, нәрсә, йоннарыгызны кабарттыгыз. Башка көннәрдә бөтенләй борылып та карамый... Менә хәзер якынча бер атна артымнан саклап йөриячәк әле ул минем. Әйткән иде, диярсез, – дип татлы хыялларга бирелеп утырган Сяо Лунны бүлдереп, Хәлил:

– Татар барда хәтәр бар, дип әйтә минем әни. Шулай булгач, кара аны, – дип куйды.

Ләкин егетне берниндн сүзләр дә куркыта алмый иде кебек. Үзе дә көтмәгәндә гашыйк булды да куйды шул татар кызына! Җиһаз ватып, кыз карату мөмкин түгеллеген аңлый, әмма анысы да чарасызлыктан гына бит. Эштә бүтәнчә күрешеп тә булмый, эштән соң үч иткәндәй, директор Шэн Линың машинасына утырып, кунакка китә. Кайчан күрсен дә, кайчан сөйләшсен?

Иртәнге тикшерү вакытында хәтта Асиянең кырыс карашын күргәч тә, аздан гына эреп китмәде бит. Ә кыз әллә чынлап аңламый, әллә юри йөрәккә тоз салып йөри. Ләкин ни генә дисәң дә, Сяо Лун үзенең эшеннән бик канәгать иде. Асиянең кабаттан киләсен көтеп, минут саен сәгатенә күзен төшереп алгалавын дәвам итте.

Кыз да озак көттермәде, ләкин... Ләкин аның бирегә атлап килүе ниндидер аяныч хәл буласына кисәтү ясаган кебек иде. Артыннан берничә җитәкче һәм директор Шэн Ли күренде.

Хәлил үзләренә генә ишетелерлек итеп: «Татары болай да бар иде инде, менә хәтәре дә килә бугай», – дип куйды. Озак та үтмәде, өч егет тә инде аягүрә басып торалар иде. Сяо Лунны директор үзләре янына чакыртты.

– Хәерле көн! – диде ул, башын аска иеп кенә.

– Бу гамәлеңне аңлата аласыңмы? – дип, директор сүз башлады. Ләкин тынлык озак хөкем сөрмәде. Асия:

– Бу хакта иртән сөйләшү булган иде инде. Әмма ул үз хатасын танырга да теләми, – дип куйды. Шулчак кызның усал карашы Сяо Лунныкы белән кисеште.

Егет юри ачуын китерергә теләп, Асиягә елмаеп, күз кысты да:

– Монда минем хатам юк, чөнки җиһазлар кулланышка яраклы түгел. Аларның ватылуында мине гаепли алмыйсыз, нигә җаваплы кеше кирәкле чаралар күрмәгән? – дип, директорга бик җитди рәвештә үз фикерен әйтте.

– Сяо Лунны бүгеннән гади эшче хезмәтенә төшерегез, – диде дә директор кызу адымнар белән китеп тә барды.

## Яңа көч-куәт

Директор киткәч, Асия ачулы караш белән Сяо Лунга күз ташлады да түзеп тора алмыйча:

– Син үзеңнең нинди мәгънәсез сүз сөйләгәнеңне аңлыйсыңмы? Җиһазда нинди хата булсын? Алар өр-яңа, һәркөн иртән сез эшкә керешер алдыннан аның өчен җаваплы кешеләр тикшереп, майлап чыгалар. Ышандырырлык берәр сәбәп уйлап тапсаң, аңлар идем инде. Директор янына мин хәзер ничек керим?! – дип, күңелендә җыелып килгән бөтен ачуын түкте.

– Әгәр чын дөресен әйтсәм, сезгә тагын да кыенрак булыр иде. Бу ялганым өчен рәхмәт әйтергә тиешсез әле, – дип Сяо Лун көлеп куйды.

Сяо Лун Асияне тәмам чыгырыннан чыгарды. Ул әйткәләшеп торуның бер файдасы да юклыгын аңлап, борылды да туп-туры директор кабинетына юнәлде.

*«Борын төбендә генә семинар булырга тора... Ә монда эшчеләр нәрсә майтарып ята. Әле җитмәсә, «Рәхмәт әйтергә тиешсез», дигән була.*

*Тормыш тәгәрмәчләре тигез юл буйлап кына тәгәрәп барса иде ул... Кайчак каяндыр юлга аркылы ташлар да төшә шул. Шуннан уйла инде ничек урап узасын?*

*Бу хакта еш уйланырга туры килде... Бигрәк тә чит илгә чыккач, фикерләрем чуалып бетте. Әллә инде күңелем йомшардымы шунда: нинди генә каршылык күрсәм дә, бөтенесен ташлап, туган ягыма кайтып китәсем килә башлый.*

*Ләкин кызу баштан әлеге уйларга җиңәргә юл куярга ярамый! Аягыңда нык басып торып: «Менә мин сайлаган мәсләк, менә мин сайлаган юл!» – дип әйтә белергә кирәк.*

Уйлана-уйлана, Асия үзенең директор кабинетына ничек барып җиткәнен сизми дә калды. Ишекне шакып, түргә узды.

– Бүгенге хәл өчен үзем гафу үтенәм. Мин моңа юл куярга тиеш түгел идем. Семинарга килгәндә, әле вакыт бар, эшчеләр төзәтеп бетерер, дип уйлыйм, – дип сүз башлады. Ләкин озак кына уйланып торгач, директор Асиягә борылып карады да:

– Монда синең хатаң юк инде, – диде. Директор Шэн Ли карашын каядыр еракка төбәп утыра иде. Асия чыгарга рөхсәт сорарга, дип авызын гына ачкан иде, директор аны бүлдереп:

– Әгәр төзәтеп бетермәсәләр, яңа станок кайтартырга туры килер, – дип әйтеп куйды. Бу сүзләр Асияне җанландырып җибәрде булса кирәк, ул үзендә ниндидер көч сизеп:

– Кирәк булмас. Җитешербез, – дип елмайды.

Әлеге сүзләрдән Асия чынлап та рухланды. Аның тизрәк эшкә керешәсе, бөтен эшләнгән хаталарны төзәтеп, семинарны уңышлы гына үткәреп җибәрәсе килә иде. Татлы хыялларга бирелеп торганда, директор үзе дә Асиягә бер көлеп карады да:

– Сяо Лунга дамы? – дип сорап куйды. Бу сорау Асияне җавапсыз калдырды. Ләкин тынлык озакка бармады. Кыз өстәл артында утырган Шэн Лига елмайды да мәчедән качкан тычкан шикелле ишеккә таба атлады. Чыгып киткәндә, директорга кутәрелеп:

– Сяо Лун башка очрак, – дип шаярды да күз алдыннан юк булды.

## Аерылган юллар

Директор Шэн Ли оптимист рухтагы кешеләрне ярата иде. Чөнки алар яшәүнең тәмен, ямен беләләр. Асия дә шундыйлардан. Нинди генә каршылык белән күзгә-күз очрашса да, баштарак каушап калган сыман тоела да, соңыннан үзенчә шаяруга бора. Аның әлеге сыйфаты эшчеләрне генә түгел, директорның хатыны Ай Ли ханымны да тиз арада үзенә җәлеп итте.

Менә бүген дә Асия – аларның чакырулы кунагы. Кунак, дип әйтү ялгыш булыр... Алар инде аны күптән үз кызларыдай кабул иткән иде...

– Асия, әйдә, утыр. Хәзер тәмләп чәй эчәрбез. Бүген өчпочмаклар пешереп караган идем әле менә... Тик синеке кебек тәмле чыкмады инде, – дип, Ай Ли ханым өстәлгә кайнар өчпочмаклар куйды.

– Каягыз, чын экспертка бирик әле, – дип, директор Шэн Ли тәлинкәне Асиягә сузды. – Ашап кара да әйтеп бир: 10 баллдан кимме?

– Нинди ун балл инде?! Йөз, йөзне бирәм, – дип шаярды Асия.

Шулай көлешеп, шаярышып утырып, вакытның ничек тиз үткәне сизелми дә кала. Асия еш кына биредә куна калгаласа да, бу юлы баш тартты. Өенә кайтып, семинарга чыгыш әзерлисе барлыгы хакында әйткәч кенә, Ай Ли ханым кайтырга ризалыгын бирде:

– Бүгенгә җибәрүен җибәрәм инде, балакаем... Ләкин киткәнче, бер җырласаң, мин бик сөенер идем, күптәннән моңлы тавышыңны ишеткәнем юк, – дип ялварулы караш ташлады.

– Сезгә бөтен белгән җырларымны җырлап бетердем бит инде, – дип, оялып кына әйтеп куйды Асия. Әмма Ай Ли ханым кыстады да кыстады.

– Ярый, ярый. Төннәрен шигырьләр язарга яратам. Менә берсен көйгә салып караган идем. Тыңлап карагыз әле, – диде дә моңлы тавышы белән сузып җибәрде:

Офыкларда кояш күренгәндә,
Шаян җилкәй сине иркәли.
Таң нурының шулай назлавыннан,
Чык тамчысы бераз төшкәли...

– Балакаем, туган ягыңны сагынуың күзләреңдә, җырларыңда чагыла... Чын дөресен әйт әле: ни өчен син монда килдең? Нинди җилләр ташлады сине чит илләргә?

Әлеге сорауга җавапны Асия бик ачык белә иде. Чөнки туган туфрагын сагынганда, ул үз алдына гел шушы сорауларны куя... Уйларга бирелеп, аларга җавап кына табып калмый, ә үз адымының дөрес булуына кат-кат инана иде.

Бераз тынып торганнан соң, Асия сүз башлады:

– Мин ярлы гына гаиләдән... Ярлы, дип әйтү бик дөрес тә түгел инде, чөнки ашарга, киенергә акча җитә... Ләкин череп баеганнардан түгелбез. Авылда бөтен кешедә шул бер чама инде. Берсендә күрше егете Әмирнең әтисе бик авырый башлады. Без әле ул вакытта бик кечкенә идек, шуңа ничек чирләвен, ни булганын бик аңлап та бетермәдек... Аны зур операция ясап кына коткарып калып була, диделәр, әмма акча җитәрлек түгел иде. Шуннан соң авыл халкы ярдәм итәргә теләп, үзенең барлы-юклы акчасын җыйды. Җитәрлек булмады... Күп тә үтмәде, әтисе җир куенына китте.

Әмир белән әлеге кайгыны бергә кичердек. Бөтен авыл бергә җыелып та бер кешене коткарып кала алмаулары безнең яшь күңелебезне әрнетте. Шуннан соң үзебезгә максат куйдык: үскәч, авылыбызны үстерергә, ничек тә булса, матди яктан тәэмин итәргә.

Мин аннан бер яшькә зуррак идем. Укуым тәмамлангач, калага киттем. Башта бер ел анда укыдым, соңыннан алдымда яңа юллар ачылды, һәм миңа Кытай университеты белән килешү төзү мөмкинлеге туды. Моны мин, әлбәттә, кулдан ычкындыра алмадым. Әмир калага укырга килгән елны чит илгә китеп бардым. Монда килүем юкка түгел: зур тәҗрибә туплап, туган ягыма кайту. Туган ягым минем өчен бик кадерле. Мин аның шушы түгәрәк шарда билгесез бер нокта гына булып торуын теләмим... Без татарларны бөтен дөнья белсен иде. Илебезнең үсүен, үзгәрүен телим... Моның өчен, иң беренче чиратта, халыкның яшәешен яхшыртырга кирәк. Ә безнең илдә кара алтын белән эшләү өчен мөмкинлекләр зурдан. Бары тик тырышасы гына...

Шулай хисләнеп сөйләгәндә, Ай Ли ханым Асияне туктатып:

– Ә Әмир дигәнең кайда? Ул синең китүеңә ничек карады? – дип сорап куйды.

– Без максатларыбызга бергә ирешербез, дип уйлаган идек... Ләкин шулай килеп чыкты инде. Ул миңа ачулыдыр, бәлки... Киткәндә, без саубуллаша алмадык. Бүгенге көндә ул үзебездә кара алтын эшкәртү белән шөгыльләнәдер, ә мин монда, – дип елмайды. Ләкин ничек кенә елмаерга теләсә дә, тамакка төер утырды...

## Яңарыш

Асия семинарның уңышлы үтәчәгенә ышана иде. Директор Шэн Линың да үсендереп торуы көч биргән булса кирәк, ул үзен хәзер тәҗрибәсез дип хис итми, үз-үзенә ышаныч барлыкка килде.

Күңелдә булган сәер дулкынлану аңа йокларга ирек бирмәде. Әле бер, әле икенче якка боргаланды, әмма файдасы гына булмады. Шулай ята торгач, җиргә яңа көн туганын сизми дә калды...

Өстенә җиңелчә генә халат бөркәнеп, тәрәзә төбенә килде. Агач яфраклары арасыннан кояш нурлары күренде.

*Әй, син дөнья... Синдәге серлелекне бернинди алтын ачкычлар, кеше күзе күрмәгән сихри таяклар белән дә ачып бетереп булмый. Ләкин... Ләкин шушы җиһанда яшәүче халкың өчен син бер! Кайда гына булма: Америка, Италия, Испания... яисә минем Сөн буендагы авылымда... Аларны берләштереп торучы ике әйбер бар: берсе – җир, икенчесе – күк. Ул уртак, ул бүленми. Төннәрен яшь парларны озатып килүче Ай да, иртәләрен назлап уятучы шаян Кояш та – уртак күгебезнең зур могҗизалары. Сезгә карап кына мин үземне Туган ягымда кебек хис итә алам... Сезгә карап кына сагынуымны беразга гына булса да баса алам...*

Ниһаять, көтеп алган көн килеп тә җитте. Киенеп, тиз генә капкалап алды да эшкә ашыкты. Аны бүген зур сынау көтә иде...

– Казакъстандагы Шымкент нефть эшкәртү заводы белән килешү төзеп, үзебезнең оешманы да «Бер караш һәм бер мәсләк» проекты кысаларында карау безгә зур мөмкинлекләр бирә. Корылмалар экологиянең дә яхшы саклануына сәбәпче булды. Шулай ук нефть эшкәртү зур тизлек белән артты, ә бу исә икътисади яктан үсешкә китерде. Моннан тыш, без фонтан юл белән кара алтын табу буенча да тәҗрибәләр ясадык. Бүгенге көндә безнең карамакта Гудун, Цзинцю, Чэндун, Ихэчжуан нефть басулары. Әгәр дә планга кертсәк, эшебезне җәелдерә дә алабыз. Мисал өчен, Янсаньму, Шэнто кебек берничә җирлекне дә үз карамагыбызга алсак, табыш 33 миллионнан артып китәчәк.

– Гафу итегез, сезне бүлдерергә мөмкинме? – дип, уртадарак торган бер оешма җитәкчесе мәкерле елмаю аша эндәште. Аның әлеге елмаюында «әкият бу» дигән мәгънә ята иде кебек.

– Әйе, тыңлыйм, – дип, Асия аңа таба борылды.

– Тыңлап-тыңлап торам да, кызык булып китә. Бу Шэнто кебек җирлекләрне ничек үз карамагыгызга алырга телисез соң сез? Мондый бәхет күктән төшәр, дип уйлыйсызмы? Сүздәгечә генә җиңел булса, аны үзенеке итәр өчен инде әллә кайчан меңләгән оешма көрәшкән булыр иде, – дип ярып салды. Әлбәттә, Асия мондый карашлар да булачагын белгән иде, дөресрәге, көткән иде. Ул бер дә югалып калмыйча:

– Әйе, бу чыннан да сүздәгечә генә җиңел түгел. Ләкин бүгенге көндә эш алып барыла бит. Табышның артуы ике як өчен дә файдалы булган очракта, тиз арада хәл дә ителәчәк. Бездә үз эшенең осталары, югары тәҗрибәле эшчеләр эшли. Әгәр дә әлеге җирлекләр белән килешү төзи алсак, ул алар файдасына да булачак. Без аларга «6 айлык яңарыш» проектын тәкъдим итәбез.

Әле яңарак кына масаерга, үз-үзен күрсәтергә тырышкан җитәкче, җиңеләчәген аңлап, бераз арткарак барып басты. Ә Асия сүзен дәвам итте:

– Әлеге проект кысаларына ниләр кирәген экраннардан күреп белә аласыз. Кыскача гына итеп әйткәндә, без алты айлык килешү төзибез. Шушы вакыт эчендә безнең эшчеләр әлеге җирлектә кара алтын табу белән шөгыльләнәчәкләр. Әгәр дә, чыннан да, бу арада үзгәрешләр булып, табыш артса, килешү озайтылыр. Аңлавыгызча, бу очракта без үзебезне корбан итәбез. Ләкин һичшиксез ышанасы килә: безнең ниятләр чынга ашар. Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

Асиянең чыгышы директор Шэн Лины гына түгел, ә башка бик күп эшмәкәрләрне җәлеп итте. Очрашу тәмамланганнан соң да Асиягә күп мактаулар, хезмәттәшлек идеяләре яуды. Семинар уңышлы узды!

## Татар кызы

Ниндидер таныш тавыш Асияне сискәндереп җибәрде. Аның кайтыр юлына Сяо Лун каршы төшкән иде.

– Асия туташ, сезнең вакытыгыз бармы?

– Мондый кызыксыну нигә? – дип кырыс кына җавап кайтарырга теләсә дә, бүген ул бик җылы килеп чыкты... Чөнки ул бүген чиксез бәхетле иде... Күпме әзерләнгән семинарның шулай уңышлы узуы тәмам канатландырды.

– Китергән уңайсызлыкларым өчен гафу үтенергә телим. Берәр кафеда тамак ялгап алмыйбызмы?

– Үз хаталарын танып, гафу үтенгән кешеләр ошый миңа. Ярый соң, тик озакка түгел, – дип якында гына урнашкан «Мандарин» кафесына юл тоттылар.

Күз ачып йомганчы, алар алдында дөгедән ясалган тәмле-тәмле ризыклар, авызны яндырырлык ачы, кыздырылган ит тезелеп тора иде. Кулларына таякчыкларын алып, ашарга керештеләр.

– Бөтен кеше дә шулай гафу үтенсә иде ул, – дип көлеп куйды Асия.

– Сезнең алда гафу үтенерлек кешеләр аздыр, дип уйлый идем.

– Аз инде, аз. Шаярып кына әйтүем.

Сяо Лун үзен бик бәхетле хис итә иде. Янында йөрәкләргә үтеп кергән кара күзләр, барча галәмне әсир итәрлек назлы елмаюлы йөз... Менә сиңа татар кызы! Сяо Лун вакытның ничек булса да әкренрәк үтүен, өстәлдәге ризыкның кимемәвен тели иде. Аның күптән җыелып килгән сүзләрне әйтәсе, күңелен бушатып, бер рәхәтлек аласы килә иде...

Ул Асиягә янә бер күтәрелеп карады да сорап куйды:

– Ни өчен сез кара алтын эшкәртүне сайладыгыз? Хатын-кыз өчен бу юнәлеш бик авыр түгелме соң?

– Нигә авыр булсын? Әле кайчан уфтанып утырганымны күргәнең бар?

– Юк шул, шуңа сорыйм да бит инде, – дип җөпләп куйды Сяо Лун.

– Исеңдә калдыр, Сяо Лун, дөньядагы һәммә эш авыр. Аларның без күрмәгән меңләгән кыенлыклары бар. Аны бары тик шул һөнәр ияләре генә аңлый. Мисал өчен, укытучыны гына алыйк. Бер караганда, нәрсәсе авыр булсын инде: мәктәбенә бара, китап ярдәмендә укыта, өенә кайта. Безнең кебек киеме дә пычранмый, авыр әйбер дә күтәрми. Ләкин уйлап кара: алар бер балага гына белем бирсә, аңларга булыр иде, әмма бит анда төрлесе төрле холыклы йөзләгән бала. Ә укытучы аларның бөтенесен бергә җыеп, берсен дә кимсетмичә, киләчәк тормышка әзерләргә тиеш. Таксистны алып карыйк. Машинасына утыра да көне буе рәхәтләнеп, музыка тыңлый-тыңлый, шәһәрнең бер башыннан икенче башына йөри. Шул эсседә машинасында утыра. Әле куркыныч та бит. Авария булды исә, беттең! Тагын санап китимме?

– Юк, кирәкмәс, анысын мин үзем дә беләм.

– Соң, белгәч, ник сорап торасың? Һәрбер авырлыкның уңай ягын таба белергә кирәк. Төнлә арып кайтып, йокыга талгач, иртән торасы килми, дөресме? Ә син «тагын эшкә барасы» дип торма, «ниһаять, таң атты... бүген мине нинди могҗизалар көтә икән?..» дип уян. Тормыш ямьләнәме? Менә мин дә һәр көнемә сөенеп яшим: яраткан эшем, торыр җирем бар...

Асиянең шулай кулларын селки-селки сөйләве, күзләренең алмаз ташыдай ялтыравы – Сяо Лунны тагын да әсирләндерде. Бу минутта ул инде түзеп тора алмый иде. Бөтен көчен җыйды да:

– Асия, сез миңа ошыйсыз, – дип әйтеп салды. Баштарак аңламый калган Асия бер мәлгә катып калды. Соңыннан елмайды да:

– Куегыз инде шул шаяртуыгызны, – дип куйды.

– Ник шаяртыйм инде? Дөресен әйтәм.

– Ничек була инде ул...

– Менә шулай. Мөмкинлек бирегезче, – дип әйтә генә башлаган иде, Асия аны бүлдереп:

– Сяо Лун, юк, юк, әйдә бу темага сөйләшмик әле. Менә ничек җанлы итеп сөйләшеп утыра идек, әллә кая кердең дә киттең, – дип аңа каршы төште. Уңайсызлыкта калган кешедәй нишләргә белми утырганнан соң, кулындагы сәгатенә карап:

– Ай, әнекәем-канатым, ничә сәгать утырганбыз икән... Кайтырга кирәк, – дип кузгала башлады.

## Мин кайтырга тиеш...

Кабинетка килеп керешкә үк Асиянең каршына Сяо Мин йөгереп килде:

– Сине директор Шэн Ли үз бүлмәсенә чакырган иде. Килгәч үк керсен, диде.

Асия кергәндә, директор Шэн Ли уйга батып, өстәл артында утыра иде. Аны мондый халәттә бик сирәк очракларда гына күрергә мөмкин. Әлеге күренеш Асияне бераз куркуга салды булса кирәк, ул беренче башлап сүз әйтергә кыймады. Урыныннан торып, балтасы суга төшкәндәй, бераз таптанып торганнан соң, директор сүз башлады:

– Читләтеп тормыйм, турысын әйтәм.

– Алай ук куркытмагыз инде, директор Шэн Ли, – дип куйды Асия.

– Туган ягыңа кайтасың киләме?

– Әллә эштән куарга уйлыйсызмы?

– Кумыйбыз, чакырталар.

– Кем чакырта?

– Асия кызым, әле күптән түгел генә узган семинарда син күпләрне үзеңә җәлеп иттең. Бик күпләр синең тәҗрибәле эшче булып җитлеккәнеңне күрде. Россиядән килгән Иван Петрович исә үзегезгә кайтарырга тели...

Бүлмәдә авыр тынлык хасил булды. Асиянең бу сүзләргә бөтенләй ышанасы килмәде... Әле кайчан гына гөрләтеп семинар үткәргәннәр иде, әле кайчан гына Сяо Лунны җавапсызлыгы аркасында ачуланганнар иде...

– Асия, минем сине җибәрәсем килми. Җитәкче буларак, мин сине биш куллап алып калырга әзер, әмма кеше буларак, мин сиңа кайтырга тәкъдим итәм. Синең бит үз алдыңа куйган максатың бар. Туган ягыңа кайтып, шуны тормышка ашырырга кирәктер. Әйбәтләп уйла...

Моңа каршы бер сүз дә әйтә алмыйча, Асия ризалык белдереп баш селкеде дә кабинеттан чыгып китте.

## Кайтыр өчен үтми гомерләр...

– Асия, шулай итеп ташлап китәсезме инде?

Сяо Лунның карашы бүген гадәттәгедән аерылып тора: моңлы, сагышлы.

Асиянең: «Шулай итәргә туры килә инде... Үзебездә кунакка көтеп калам», – дип елмаюына каршы Сяо Лун:

– Менә никләргә минем йөрәгемне кабул итмәдегез инде? Әгәр ризалык биргән булсагыз, гомерлеккә шушында калган булыр идегез, – дип җавап кайтарды.

– Юк шул, юк. Минем әле туган ягыма кайтып эшлисе эшләрем, чынга ашырасы максатларым бар.

Аларның сөйләшүләрен директор Шэн Ли бүлде:

– Шулкадәр нәрсә турында серләшәсез?

Сяо Лун:

– Менә үземә хатын итеп алып калмакчы идем, кайтып китәм, дип әйтә әле, – дип шаярып куйды.

– Мондый татар кызын алып калсаң да була! Ләкин башта әле сиңа үз урыныңны кайтарырга кирәк. Юньсезлегең аркасында эшеңнән коры калдың да, хәзер кызлар карап йөрисеңмени инде? – диде директор.

Саубуллашу шулай күңелле барса да, Асиянең йөрәгендә ниндидер дулкынлану, борчу уятты. Кем белә, бәлкем ул бирегә бүтән килә дә алмас, әлеге шаян, тормыш ямен аңлаучы эшчеләрен дә күрә алмас...

Менә ул туган ягына кайтыр, дуслары, танышлары белән күрешер... Аңа яңа эш

тәкъдим итәрләр. Көне-төне башын да күтәрми эшләр... Ләкин аны мондагыча якын итәрләрме? Ул эшенә мондагыча шат күңел белән барып, яраткан кулдашларын күреп сөенә алырмы?

## «Артист»лар

Әмир, моңлана-моңлана, насосларның башларын тикшереп йөри. Аның шулай үз дөньясында очып йөрүенә бергә эшләүче кулдашлары әллә кайчан күнекте инде. Кайчакта эшләреннән туктап, үзләре үк янына җыелалар. Моңлы җырлый бит! Авыр эштән шулай ял итеп, сихәт алырга буладыр?! Юк, аннан гына да түгел, җырлап эшләсәң, эш үзенә бер күңелле. Әле араларында «артист»лары да булса, кыланып, «биюче»ләре табылса, биеп тә алалар. Бүген дә кәефләре шәптән күренә, иртәннән үк бик дәртле эшлиләр. Әмирнең эчтән генә көйләп йөргәнен ишетеп алгач, Сабир да күп көттереп тормады, зур скважинаның сул ягына барып басты да:

– Ә хәзер сәхнәгә кайнар алкышлар белән Әмир Рөстәмовичны чакырабыз! – дип, үзен зур сәхнәдәгечә тоеп, горур басып торуын дәвам итте. Аның әлеге уенын гына көтеп торгандай, янына Шәкүр дә килеп җитте. Бөтенесенең күзе аларда: ике тел бистәсе бүген нинди шоу ясарлар икән?!

– Кадерле җәмәгать, Әмир Рөстәмовичның бераз эшләре килеп чыкты, шуңа күрә бүген сезнең алдыгызда мин, ягъни барчагызның яратып өлгергән җырчысы, талантлы, булдыклы, матур, чибәр, акыллы, бердәнбер Шәкүр Идрисович. Җылы алкышларны ишетмим.... Катырак!

Эшчеләр бу сүзләрне дә отып алалар. Кул чабулар башлана. Насослар янында йөргән Әмир боларга карап бер көлә дә, эшен дәвам итә. Әйе, күңелле яшиләр...

Әмир насосларны карап чыкканнан соң, кызу адымнар белән Илгизәр Рәсимович кабинетына юнәлде. Аның шундый җитди адымнарын мондагылар инде күптән аңлый: йә берәр хәл булган, йә Әмир нинди дә булса эш башкармакчы.

Бу юлы да ул кабинетны шакып, эчкә үтте дә, сүзне уратып-нитеп тормыйча, турысын әйтте:

– Илгизәр Рәсимович, насосларны алыштырырга кирәк, дип июнь башында ук хәбәр иткән идем инде. Хәзер бер ай үтеп китте...

– Алыштыруын алыштырырбыз да, әмма болары да ярыйсы гына эшли бит. Юкка «расход» чыгармаска кирәк. Икенче елга бездә зур семинар көтелә, барыбер шул вакытка бөтен әйберне яңартып, төзәтеп бетерергә кирәк булачак. Аз гына булса да көтик инде. Майга планлаштырып торыйк.

– Майга кадәр күп бит әле. Әгәр дә насосларны яңарта алмыйбыз икән, рөхсәт итегез: мин кара алтынны фонтан юлы белән алып карарга телим. Бу үзенә күрә бер тәҗрибә дә булыр иде.

– Менә монысын уйлап карарга була... – диде директор уйга калып. – Бер-ике атнадан Кытайдан белгеч кайта. Ул безнең белән берлектә эшләячәк. Биредә фонтан ысулы белән нефть табу зыянлы булмасмы, безнең өчен ул кулаймы – башта әлеге сорауга аннан да җавап алырга кирәк булыр.

– Соң ул безнең җирләрне каян белсен инде? Әнә Кытайныкын сорасагыз, рәхәтләнеп күзен дә йоммый әйтеп бирәчәк... Ә безнекен... Безнекен без үзебез тоярга тиешбез, ник Кытай белгечен көтеп торырга, ди?!

– Бу җирләрне аның синнән күбрәк тә белүе ихтимал әле. Ул бит безнең кеше. Безнең горурлык! Без үстердек бит аны, – дип әйтеп куйды директор. Әлеге вакытта аның күзендә чыннан да горурлык хисләре балкый иде.

Илгизәр Рәсимовичның әйткән сүзләре Әмирнең бераз кәефен төшерде. Ул бит инде җиң сызганып эшкә керешергә әзер иде... Шушы мизгелдә Әмир бөтен нефтьчеләргә, директорга, бар дөньясына ачулы иде...

## Кыска бәхет

– Их, Әмир, күрсәң иде син аның зифа буйларын... Җилдән дулкынланып киткән калын чәчләрен...

– Нәрсә, гомергә кыз күрмәгән кешеләр кебек исереп утырасыз, – дип коры гына

әйтеп куйды Әмир. Шундый салкын җавап булачагын күптән белгән кулдашларыннан берсе түзеп тора алмыйча:

– Ничек шулай таш күңелле була аласыңдыр! Бөтенләй аңламыйм, – дип куйды.

Әмир Асия киткәннән соң, үзенә урын таба алмады. Бер кыз белән дә танышмады, сөйләшмәде. Гомумән, аның уенда гашыйк булу яки өйләнү дигән уй бөтенләй юк иде. Тормышка башкача карый башлавы, кайчакларда кисәк кенә кызып китүе ялгызы гына калган әнисен куркуга салды. Ә бу исә улын ничек тә булса өйләндерергә кирәклеге турында уйланырга этәрде.

«Картлык көнемдә оныклар сөясем килә», «Өйләнергә уйламыйсың мәллә» кебек сүзләрне еш ишетүдән тәмам туйган Әмир көннәрнең берендә әнисе тарафыннан сайланган Югары очта яшәүче Әхмәт кызы Санияне хатынлыкка алды да кайтты.

Тату яшәделәр: Әмир беркайчан да эчеп кайтмады, хатынына кул күтәрмәде. Сания дә ирен тәмле-тәмле ризыкларын пешереп, киемнәрен юып көтеп тора иде. Алар бер-берсенә «яратам» дип түгел, ә «рәхмәт» әйтешеп яшәделәр... Озак та үтми дөньяга нәни кызчыклары туды. Бу тормышларын тагын да ямьләндереп җибәрде...

Ләкин әлеге түгәрәк бәхет озакка сузылмады: берсендә әниләре янына авылга кайтканда, ике машина бәрелешеп, Сания якты дөнья белән хушлашты. Бу вакытта кызына 3 кенә яшь иде әле. Әмирнең күңелендә тагын бушлык урын алды... Әмма ул үзен нык тотты. Кызы-сандугачы өчен ул көне-төне эшләде... Аны бәхетле итәр өчен кулыннан килгәнчә тырышты.

Ир кешегә ялгызы гына яшәү авыр шул... Әнисе тагын: «Өйләнеп карамыйсыңмы соң, улым?» – дип карады, әмма моңа Әмир: «Юк инде, әни, рәхмәт! Бер тапкыр өйләндердең, җитәр. Минем өчен хәзер дөньяда бер генә куаныч бар. Ул – кызым! Ул миңа яшәргә дәрт бирә», – дип кенә җавап кайтарды.

## Кайда соң син, яшьлек дустым...

– Асия Касыймовна, фонтан юлы белән кара алтын табуга ничек карыйсыз? Директорга кергән саен, ул гел сезнең белән киңәшләшүне мәслихәт итә.

– Миннән генә тора, димәк?

– Әйе. Шуңа кистереп әйе йә юк, дип әйтегез дә, эшкә тотыныйк.

– Ә син әйбәтләп әзерләндеңме соң?

– Инде күптән. Җирне кат-кат тикшереп чыктым, бар да әзер.

– Эшчеләрең? Үзең генә эшләргә җыенмыйсыңдыр бит?

– Алар белән бу хакта бер сөйләшкән идек инде. Алар хәбәрдар. Әмма бу гамәлдә беренче тапкыр булганга күрә, хата җибәрүебез бар.

– Әйе, монысы дөрес.

– Сезнең әлеге процесста шәхсән катнашканыгыз булдымы?

– Әйе, булды. Бу бик катлаулы.

*Йа Хода! Менә бит ул минем балачак, яшьлек дустым Әмир... Бераз йончыган... Чәчләре агара төшсә дә, ул барыбер буй-сынын саклый алган... Элеккечә киң җилкәле, озын буйлы. Ә кара күзләрендә ниндидер моңсулык яшерелгән.*

*Нигә ул элеккечә: «Әйдә балыкка»,– дип дәшми икән?! Нигә үзенең усал теле белән шаяртмый?! Вакытлар үтте шул... Ул да үсте... Мин дә...*

*Асия Касыймовна дип эндәшмичә, исемемне генә әйтсә дә... күңелемә май булып ятар иде, әмма юк... Миңа ачу саклый булса кирәк. Шулай саубуллашмый китеп баруымны, киңәшләшмәвемне аңламый торгандыр...*

– Асия Касыймовна, ә безнең эшләп чыга алуыбызда ышаныч бармы? – дип сорады Әмир. Асия уйларыннан арынып, Әмирнең күзләренә күтәрелеп карады да:

– Әмир, – диде. Әлеге тынычлыкны мөмкин кадәр озаграк саклыйсы килсә дә, алай ярамаганлыгын аңлап, Асия сүзен дәвам итте:

– Сине күрүемә шатмын.

Әмир эндәшмәде...

– Аңлыйм, син мине ачуланасыңдыр... Үпкә саклыйсыңдыр...

– Юк, үпкәләп ятарга бала-чагамыни инде без? Үткәннәрне кире кайтарып булмаган кебек, ясаган хаталарда таптанып торырга да кирәкми, – диде дә Әмир сүзне кирегә борды:

– Нишлибез булды соң инде? Тагын директор белән кереп киңәшләшеп чыгыйммы?

Асиянең әйтәсе сүзләре, сорыйсы сораулары бетмәгән иде әле. Әмирнең шулай салкын һәм теманы тиз боруы аның ачуын чыгарды. Ул:

– Кирәкмәс. Иртәгәдән эшне башлыйбыз, – диде дә, борылып, кабинетына таба китте.

## Көчсезләр генә елый

Ул көнне Асия директордан сорап, эштән иртәрәк китте. Авылына кайтып, бераз йорт-җирне караштыргалап киләсе иде. Кытайдан кайткач та, төрле документ эшләре артыннан йөреп, туган авылын урый алмый калган иде. Иртәгә иртән эшкә булса да, күңел тартуы аны туктатып тора алмады. Кайтып, газиз мендәрләремә ятып кына булса да йоклыйм, дип, ашыга-ашыга юлга кузгалды.

Асия әбисе тәрбиясендә үсте. Әти-әнисе бик иртә дөньядан китте. Шунлыктан аны бүген өендә тәмле чәйләрен әзерләп, колач җәеп торучы бер кешесе дә юк иде.

Капка төпләренә машина белән килеп туктады. Танымады: коймалар үзгәргән, өй яңартылып, ике катлы итеп салынган... Монда нәрсә булган? Асиянең балачагын хәтерләтеп торучы зәңгәр коймалар, төтен чыгарып торучы мич инде юк...

Ул кыяр-кыймас кына ишекне какты. Аннан бер ханым чыгып, Асиягә бу йортны инде бер ел элек сатып алулары турындагы хәбәрне җиткергәч, кыз нишләргә белми басып калды. Җавап итеп ни әйтергә белми торганнан соң, күтәрелеп карады да: «Гафу итегез», – дип чыгып китте һәм Әмирләр өенә таба атлады.

Ишектән Асиянең каршысына чыгып килгән Әсма карчык:

– Әлекәем, төшемме, өнемме? Асиякәем, синме соң бу? – дип күрешергә кулын сузды.

– Әсма апа, – дип әйтте дә Асия аның кочагына ташланды. Күңеленә җыелып килгән әрнү шулчак күз яшьләре булып ташый башлады. Кыз ирексездән үксеп елап җибәрде:

– Әсма апа... Бер таныш җан булса да калган икән әле... Өебезне дә сатканнар. Әсма апа, ничекләр түзим? Анда иде бит минем бөтен хатирәләрем... Әти-әнием, әбием исе... Аларның моңы, аларның теле, аларның җаны... Барысын да сатканнар.

– Балакаем, балакаем, тынычлан. Тукта, зинһар.

Әсма карчык үз кызыдай яратып, Асиянең чәчләреннән сыйпап, аркасыннан сөеп торганда, ишектән:

– Әбием, – дип, Әмирнең нәни кызчыгы очып чыкты.

Асия елавыннан туктап, айнып киткәндәй булды. Бер кызга, бер Әсмага карап куйды. Әсма карчык елмаеп:

– Бу минем оныгым була инде, Асия. Кызым, апа белән исәнләш әле, – дип куйды. Кыз әбисе белән Асия басып торган җиргә килде дә:

– Исәнмесез, – диде. Бераз карап торганнан соң янә сүз башлап:

– Апа, сез ник елыйсыз? Әбием бары тик көчсезләр генә елый, ди. Ә көчсезләрне берәү дә яратмый, ди. – Ул Асиянең күзеннән яшьләрен сөртеп алды.

Моңа нәрсә дип җавап бирергә белмәгән Асия:

– Еламыйм, бүтән еламыйм, – дип берничә тапкыр кабатлады да үзен кулга алды.

Бераз тынычланганнан соң, Әсма карчык Асияне үзләренә чәй эчәргә керергә, куна калырга күпме генә кыстап караса да, Асия ризалашмады. Иртәгә иртән эшкә, дигән сәбәп белән китәр юлга кузгалды.

Бер төн эчендә үзгәрде Асия. Ничектер кырысланды, картайды... Әйтерсең, йөрәге ташка әйләнеп, тирә-ягындагыларны күрми, ишетми башлаган иде.

Эшкә килгәч тә, аның элеккечә елмаясы да, кулдашлары белән әңгәмә корасы да килмәде. Шуңа ниндидер салкынлык белән генә әмер бирде:

– Торбага утырачак тозларны юар өчен кирәкле әйберләрне алып килдегезме?

– Әйе.

– Яхшы. Әмир, син бит инде барысыннан да хәбәрдар. Хата ясамассың, дип уйлыйм.

– Ясамам.

– Айваз, син температураны караштыргалап тор, яме?!

Беренче көн уңышлы гына үтеп китте. Һәммәсе үз эшеннән канәгать булса да, әлеге ирешелгән кечкенә уңышлар Асияне сөендермәде... Ул аларга игътибар да итмәде.

Җаны тыныч түгел иде Асиянең. Аңа нидер җитми... Үземне начар хис итәм, дигән сәбәп белән ике көнгә ял алды да өенә кайтып китте.

Икенче көнне аны телефон тавышы йокысыннан уятты. Баштарак алмаска уйласа да, соңыннан җавап бирде:

– Тыңлыйм...

Озак та үтмәде, Асия инде аягүрә баскан иде. Колагында бары тик ике сүз яңгырый: «Әмир», «авария»...

Йа Раббым! Кара алтын чыгарган вакытта басым кирәгеннән артык күтәрелеп, авария булган, диме? Әмир, диме? Юктыр, бу төшемдер... Менә хәзер уянам да, эшкә китәм...

Асия үзенең хисләрендә генә түгел, тормышында да буталып бетте. Ул кая барырга, нәрсә кылырга белми һавада бөтерелгән кошлар кебек үзенең уйларында, хыялларында очты. Әмма бернинди төгәл, җитди фикергә килә алмады.

Әмирнең хастаханәдә ятуында үзен гаепләде... Менә инде өченче көн ул яткан бүлмәгә килә, әмма ишектән үтми генә тышкы якта басып торуын дәвам итә. Эчтә аның кызчыгы, әнисе – барлык якыннары. Ә Асия кем? Яшьлек дусты?.. Ташлап китсен дә нинди дус булсын инде?..

Кинәт ишек ачылып китеп, Әмирнең кызы йөгереп чыкты. Ишек янында басып торган Асияне күреп:

– Әбием, анда теге көнне килгән апа басып тора, – дип кычкырып җибәрде. Асия караклыкта тотылган песи шикелле әле бер, әле икенче якка карап, ни әйтергә белми торуын дәвам итте. Әсма карчык урыныннан кузгалып:

– Балакаем, ник анда чит кеше кебек басып торасың? Әйдә, кер, – дип, Асияне түргәрәк чакырды.

Асия:

– Мин үтеп барышлый гына кермәкче идем... Әмир, хәлләрең ничек соң? – диде.

Әмир инде төзәлеп, ныгып килә. Асия кергәндә, ул мендәренә терәлеп утырып тора иде.

– Әйбәт кенә, бер-ике атнадан чыгаралар инде, – дип җавап кайтарды Әмир. Бераздан тынлыкны бүлеп, Әсма карчык:

– Асия-балакаем, апаңа урындык китереп бир әле, – дип, оныгына эндәште. Асия әле кемгә эндәшкәннәрен аңлый алмый басып торган арада, Әмирнең кызы урындык сузды.

– Минем оныгым – синең адашың бит, – дип сүзне җөпләп куйды Әсма карчык.

Моны ишетеп, Асия югалып калды... Ул әле яңа гына Әмирнең аңа карата булган хисләрен аңлады... Менә кая яшергән ул аларны?!.

***

*Асиянең күңел көндәлегенең соңгы битләре:*

*«Менә Әмир тиздән эштән кайтыр... Ә без Асия белән аңа тәмле ризыклар әзерләп куйдык...*

*Дөнья бигрәк сәер һәм серле нәрсә икән... Шушы ике ел эчендәниләр генә күрмәдем бит, ә? Кытайдан кайттым, Әмир һәм аның кызчыгы белән бер гаилә корып яши башладык, мондагы яңа эшем... Аллаһ бирсә, бирә. Сабыр гына көтә белергә кирәк икән.*

*Тиздән Асиягә энекәш тә алып кайтып бирербез әле. Аллаһ кына ярдәменнән ташламасын.*

*Мин бик бәхетле! Ләкин шушы сәгадәтле минутларны тартып алырлар да барча әйбер юкка чыгар төсле. Кайвакыт төшме бу, өнме, дип утырам да, берәрсе чеметә генә күрмәсен... төшем озаккарак сузылсын, дип куям.*

*Тормышымның яңа баскычына аяк бастым... Шуннан ары тагын ни кирәк?!»*

# АЙСИНӘ СӘЛАХОВА. «КУЛДАШЫМ»

Укып чыгуга, беренче тәэсир – афәрин, Айсинә! Башлап каләм сынаучы өчен текст, чыннан да, кызыксынып укыла, авторының күңел байлыгы, канатлы фантазиясе турында сөйли. Һәм иң беренче күзгә ташланган сыйфаты – укучының караш офыкларын киңәйтә, аны үзгә дөньяларга, чит илләргә алып китеп тә, үз туган җире, халкы, шул халыкның гүзәл көнкүреш гадәтләренә игътибар иттерә.

Сүзне жанрдан башлыйк. «Кулдашым» күләме ягыннан хикәя белән повесть арасында. Бу – татар әдәбиятына хас (аңа гына хас һәм үзенчәлеген билгели торган) күренеш: фольклордан килә торган «озын көй», «озын җыр» әдәбиятыбызга күчеп, XX йөз башы шигъриятендә «озын шигырь» дигән жанр формасын хасил итә. XX гасырның уртасында исә «озын хикәя» пәйда була: аның иң гүзәл үрнәге – Әмирхан ага Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәре дияргә (дөрес, язучыбыз әле жанр формасын беренче тапкыр «Тауларга карап» (1948) әсәрендә сыный, «Җиз кыңгырау»да һ.б. дәвам итә...) җөрьәт итәм! Мондый жанр формасы – татар әдәбиятының зур казанышы, аның ерактан килгән традицияләрне үстереп алып китү сәләте турында сөйли. Әдәбият белемендә аны жанр формасы гына түгел, бәлки, мөстәкыйль жанр дип исбат итү омтылышы да булды (В.Р. Әминева). Әгәр әдәбият үзе хуп күрсә, бу форманы үстерсә, ул фәндә шулай ныгып калырга да мөмкин.

Чит әдәбиятларда мондый күренешләр бармы, дигән сорау туар. Европа әдәбиятларында хикәянең новелла тибындагы һәм драма төре сыйфатларын үзенә туплаган, ягъни көчле конфликтка корылган жанр формалары турында күзәтүләр мәгълүм. Әмма бу мәсьәләдә төгәл генә теория булдырылмаган.

Шунысы гаҗәп: милли әдәбиятыбыз бу жанр формасына үзгәрешләр чорына килеп кергән вакытларда мөрәҗәгать итә. Әйтик, XX йөз башында да, 1920-1930 елларда активлашкан вакытында да «озын шигырь» модернистик алымнарның чит тоелмыйча урнашуына хезмәт итә (бу хакта Д.Ф.Заһидуллина хезмәтләре бар). XX гасыр уртасындагы «озын хикәя» исә татар әдәбиятына социалистик реализм кысаларыннан арынып, романтик, психологик проза традицияләрен кайтарыр өчен кирәк була.

Фәндә повестьның хикәядән аермалы сыйфаты итеп, үзгенә герой сынау, сайлау алдына куела торган йомык сюжет схемасы булу күрсәтелә. Шушы сыйфатның «озын хикәя»дә табылуы аның мөстәкыйльлеген һәм оригинальлеген тәэмин итә. Ә.Еникинең озын хикәяләрен тикшерү исә татар әдәбиятында мондый әсәрләрдә лирик башлангычның көчле булуы турындагы нәтиҗәгә этәрә.

Айсинә Сәлахованың озын хикәясендә дә повестька хас шушы сыйфатлар калкуландырылган. Автор героинясын ике тапкыр сайлау алдына куя. Текстның аерым исемләнгән өлешләргә бүленүе, психологизмны көчәйтүче детальләр андагы лиризмны тәэмин итә. Шушыннан этелеп китеп, әсәр турында аның көчле һәм йомшак якларына кагылып сөйләшеп алыйк.

Беренче уңай сыйфат әсәрнең башламында ук күзгә ташлана: «Сөн кызы» дип аталган беренче бүлекчәдә гади генә деталь – яран гөл образы аша Айсинә героинясының холык-фигылен, эчке дөньясының матурлыгын ача, шуның белән аңа карата кызыксыну уята, укучы текст башланганчы ук аның «ягына» чыга, героиняның «кулдашына» әйләнә! Гөл кызның туган җирен, гаиләсен сагынып яшәвен аңлатырга да мөмкинлек бирә.

Асылда, «Шэн Ли» дип аталган икенче бүлекчә дә кыз образын идеаллаштыруга хезмәт итә. Тыныч холыклы, сабыр, эшкә чын күңелдән бирелгән, итагатьле кебек сыйфатлар шушы өлештә ачыла. «Аерылган юллар» бүлекчәсендә тагын берничә сыйфат – оптимистик рух, нечкә, хәтта шигъри күңеллелеге күренә. Төп героиняның гел уңай амплуада гына бирелүе, бер яктан, әсәрнең романтик-идеалистик пафосына тәңгәл килә. Әмма... ышандырмый: төп герой характер (каршылыклы, катлаулы) буларак ачылырга тиеш, ди әдәбият фәне.

Тәрбияви әһәмиятле фикерләр ачык, әмма арттырмыйча героиня уйларында җиткереп барыла. Туган җирнең һәркем өчен кадерле урын булуы, кешедән үз максатына ирешү өчен ныклык таләп ителү *(«Аягыңда нык басып торып: «Менә мин сайлаган мәсләк, менә мин сайлаган юл!» дип әйтә белергә кирәк»)*; яки халыклар, кешеләрнең охшашлыгы *(«Әй, син дөнья... Синдәге серлелекне бернинди алтын ачкычлар, кеше күзе күрмәгән сихри таяклар белән дә ачып бетереп булмый. Ләкин... Ләкин шушы җиһанда яшәүче халкың өчен син бер!»)*, бер һөнәрнең дә җиңел булмавы *(«Исеңдә калдыр, Сяо Лун: дөньядагы һәммә эш авыр. Аларның без күрмәгән меңләгән кыенлыклары бар. Аны бары тик шул һөнәр ияләре генә аңлый»)* һ.б.

Текст буенча матур детальләр табылган, алар укылышны тәэмин итә.

Әмма... кимчелекләр дә юк түгел. Иң беренчесе – текстның идея ягыннан таркаулыгы! Хикәя яки повестьта да әсәр бер үзәк фикер тирәсенә җыелып бетү шарт. Хәтта берничә фикер калкуландырылганда да, аларның берсе структураны хасил итүче була. Әсәр Асия исемле героиняның, сынаулар үтеп, максатына ирешүе турында. Ул Әмирнең этисен коткарып кала алмау белән бәйле күренешне искә төшереп нығытыла. Болайрак конкретлаша: *«Монда килүем юкка түгел: зур тәҗрибә туплап, туган ягыма кайту. Туган ягым минем өчен бик кадерле. Мин аның шушы түгәрәк шарда билгесез бер нокта гына булып торуын теләмим...»*

Сяо Лунның мәхәббәте һәм илгә кайту белән бәйле сайлау алдында калгач та, кыз шуны төп аргумент итеп куя: *«Минем әле туган ягыма кайтып, эшлисе эшләрем, чынга ашырасы максатларым бар»!*

Әмма әсәр ахырында Асия үзе максатка ирешүен болай аңлата: *«Кытайдан кайттым, Әмир һәм аның кызчыгы белән бер гаилә корып яши башладык, мондагы яңа эшем... Аллаһ бирсә, бирә икән. Сабыр гына көтә белергә кирәк икән. Тиздән Асиягә энекәш тә алып кайтып бирербез әле. Аллаһ кына ярдәменнән ташламасын»*. Шул рәвешле, хезмәт, халыкның тормышын яхшырту теләге – шәхси бәхеткә ирешү биргән канәгатьлек белән чикләнә. Соңгы фикерне әйткән Асия әсәр башында без очрашкан ут күбәләге белән тәңгәллеген югалта. Әгәр уйланма шулай икән (әйтик, тормышның кешеләрне үзгәртүе үзәккә куелса), бу махсус шәрехләүне сорый. «Көчле позиция» буларак, укучы фикерен юнәлтергә, җыярга тиешле әсәр исемендә дә мондый мәгънә юк (гәрчә матур сүз-төшенчәне активлаштыру булса да!)

«Ышанмыйм» дип әйтергә мәҗбүр иткән тагын бер момент шулай ук әдәбият кануннары сакланмау белән бәйле. Язучы үзенең сурәтләү объектын яхшы белергә тиеш! Шуңа да зур язучыларның производствога китеп эшләп, яшәп алуы билгеле. Әсәрдә шушы мәгълүматның җитеп бетмәвенә бәйле ике мөһим күренеш бар. Беренчесе – семинар әзерләү: җиһазның ватылуы семинар уздыруны куркыныч алдына куя. Әмма аны тасвирлау, җиһазга кагылмый гына, Асиянең «6 айлык яңарыш» проектын тәкъдим итүенә (маркетолог эшенә) кайтып кала!

Икенчесе Әмирләр бригадасының кара алтынны фонтан юлы белән чыгарып каравына бәйле. Фонтан ысулы – гомумән, нефть чыгаруның иң беренче ысулы, шуңа күрә аны сынап карау турында сөйләү ышандырмый, Әмирнең авария ясап сырхауханәгә эләгүе, аннан соңгы вакыйгалар сериалларны хәтерләтә башлый.

Сяо Лунның мәхәббәте хакына җиһаз ватуы, аннары гына моның нәтиҗәсенә төшенүе логик аңлатылса да, егетнең бу эштә Асияне гаепләве *(«Монда минем хатам юк, чөнки җиһазлар кулланышка яраклы түгел. Аларның ватылуында мине гаепли алмыйсыз, нигә җаваплы кеше кирәкле чаралар күрмәгән? – дип директорга бик җитди рәвештә үз фикерен әйтте»)* әсәрдәге мотивлаштыру кысаларыннан чыгып китә.

Яшьтән бергә үскән Әмир белән Асиянең XXI гасырда хәбәрләшми яшәүләре, Асиянең, хәтта, өйләре сатылуыннан да бихәбәр булуы кебек детальләр сораулар уята. Әмма болары – осталык, тәҗрибә белән килер. Иң мөһиме, Айсинәдә язу сәләте, тормышны сурәтли алу куәсе, зәвык бар! Шушы сәләтне үстереп, олы әдәбият мәйданына чыгар, дип ышанам.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*

Айшә
Маски

## БҮРЕНЕҢ «ТУГАНЛЫГЫ»

ШИГЪРИ ӘКИЯТ

Бик якын бер заманда, моннан ерак урманда;
Сөйләем мин бер хәлне, булган, ди ул чыннан да.

Урман өсте Аллаһның рәхмәтеннән күгәргән,
Матур кошлар сайрашып, күңелләрне күтәргән.

Пешеп җиләк-җимеше, печәннәре өлгергән,
Шат-шадыман сикереп, киекләре йөгергән.

Төзеп урман канунын тәртип белән эшләгән,
Тынычлыкта һәрбер җан һичбер эштән бизмәгән.

Олы-кече хайваннар төркем булып яшәгән.
Куян да бер куркусыз йөргән, берни дәшмәгән.

Бер читендә урманның чал бүре дә яшәгән.
Ырылдашкан, сугышкан, иреннәрен тешләгән.

Юлсызлык, тәртипсезлек көннән-көнгә үрчегән,
Дуслыгы да бозылган, тирә-ягы – күршедән.

Көчлеләре көчсезләрен буып-талап ашаган,
Пычранган ди җир-сулар: гел чүплеккә охшаган.

Кемнән тартып алсам дип, кемгә көчем җитәр дип, –
Эзләп чыккан чал бүре, җим табарга кирәк бит!

Йөри торгач бер көнне килеп җиткән бер җиргә –
Үрчеп гөрләп яшәгән куяннарның иленә.

Матур гына, тын гына җайлашкан тау битенә,
Исе китеп караган: ышанмаслык ич менә!

Тонык сулы чишмәсе, бозылмаган һавасы,
Туып үскән җирендә уйный куян баласы.

Читтән карап чал бүре, аккан селәгәйләре,
Куяннар бит каршында, зуры-бәләкәйләре.

Куян нәселе үрчегәч, бетмәс ризык гомергә,
Бик рәхәт булыр иде, хуҗа булсаң бу җиргә.

Кем дә каршы килмәс, дип уйлаган да ялманып,
Таптым, диеп, чарасын, елмайган ул шатланып.

Уйлап кына куймаган, капкан куян баласын,
Эчкән тонык суларын, сулап чиста һавасын.

Куркып мескен куяннар, качып кергән өненә,
Нишләрбез, дип, тетрәнеп, ябышкан бер-беренә.

Тәмен тапкан бүре дә болай гына калмаган,
Бер көне дә булмаган куян тотып алмаган.

Каршылык итә алмыйча гаҗиз калган куяннар,
Гариза язганнар, ди, кулларын да куйганнар.

Куяннарның вәкиле әйткән урман ханына:
«Зәмин[1] булды бүре, дип, күп куянның җанына!»

Килеп урман сакчысы кыргыйлыкны туктаткан,
Куяннарның җиреннән ул бүрене чыгарткан.

Чыкса да явыз бүре, китмәгән үз иленә,
Хуҗа булырга теләп, куяннарның җиренә.

Хәйлә эзләп эшенә, барган төлке каршына,
Төлке дә бик шатланган, план төзеп башында.

«Кушылып бу бүрегә, керсәм куян җиренә,
Аш-тамактан кайгы юк, рәхәт булыр гомергә!»

Киңәштән соң бергәләп, барган урман ханына,
Урман ханы баш чайкап, кушылмаган планга:

«Буйсынырга төзедек урман канунын бергә.
Тимә куян иленә, яшәсен үз җирендә!

Бозып урман канунын, карамасаң сүземә,
Хайваннарның барысы дошман булыр үзеңә».

Ишетсә дә хан сүзен, кайтмый бүре юлыннан,
Төшендә дә шул куян, көндез китми уеннан.

Уйлап таба соңында фетнә ясау чарасын,
Хәбәр сала урманга бозарга ил арасын:

«Белмисез бит, җәмәгать, куяннар бик хәтәр, ди,
Ясый алар яшерен бер дару – бик зәһәр, ди.

[1] Зәмин – төп хуҗа

Сезнең эчкән суларга шул зәһәрне салмакчы,
Үзегезне үтереп, җирегезне алмакчы.
Барыгызны кол итеп, урманга хан булмакчы,

Туктатырга тиеш без менә хәзер боларны,
Кушылыгыз миңа сез, бастыраек аларны».

Ишетеп бу хәбәрне шаккаткан, ди хайваннар
Ничек эшли белсен дип, явызлыкны куяннар.

Бик күбесе ышанмый каршы фикер әйткәннәр,
Калганнарын һич кенә икеләнмәс иткәннәр.

Ялган түһмәт[2] яудырган бүре-явыз тынмыйча,
Төлке дә шул ялганны илгә җәйгән армыйча.

Вәсвәсә салып урманга, хайваннарны куркыткан,
Башкаларны тыңламый куяннарга «ук аткан».

Басып, яньчеп, үтереп кереп киткән эчкәре,
Каршы чапкан куянны кискән үткен тешләре.

Бу рәхимсез һөҗүмнән коты чыккан куяннар,
Уңга-сулга йөгергән, урын тапмый җан куяр!

Бүре, төлке берләшеп, башларыннан капканнар,
Тыныч куян җирләре кан эченә батканнар.

Бала куян зар җылый кочып, үлгән анасын,
Эзли үлек арасыннан ана куян – баласын.

Шунда бүре уйнатып вәхши канлы күзләрен,
Үзен хаклы күрсәтеп, сөйли ялган сүзләрен:

«Мескен бала куяннар, миннән куркып качмагыз,
Менә без сезнең яклы, сезнең хакны сорарбыз.

Ата-ана золымыннан котылдырып без сезне,
Иркенлеккә чыгарып, ачырбыз күзегезне!

Сезне куркак иткән шул явыз әби-бабайлар...
Сезнең явыз дошман бит монда үлгән куяннар!
Инде бергә яшәрбез булып якын туганнар!..»

Инде нишләр куяннар?..

*Австралия,*
*Аделаида шәһәре.*

[2] Түһмәт – яла ягу.



Нодар
Думбадзе

# КАН АВАЗЫ

хикәя

Тал чыбыгындагы җепкә ташбашлар тезгән малай, чәче кырылган башын аска иеп, юкә ышыгында басып тора. Ләмгә баткан ялангач аякларына текәлеп, тирән уйга чумган: «Бу карт минем әтиемә шулхәтле охшаган! Көмешләнгән чәч... Кара кашлар... Зур борын... Якты ачык күзләр... Тавышы калын, ягымлы... Күзләремне йомсам, аны әтием, дип уйларга мөмкин...»

Һәм малай күзләрен йомды.

– Менә шуның өчен мин сезне, хөрмәтлем Кишварди, үз яныма чакырдым да инде. Түзәр әмәлем калмады. Кулдан тәмам ычкынды, юньсез!.. Бөтен балалар берүк төсле, ә ул нәрсә... Көне-төне ташбашлар белән мәш килә!.. Беркөн нишләде дип уйлыйсыз? Гоподзе белән уртак коебызга алагаем зур карбыз атты. Карбыз урталай ярылды да, менә инде ике гаилә атна буе су урынына компот эчә!..

– Гаҗәп, валлаһи! Мин ишеткәннәр дөресме, малай? Борчылмагыз, хөрмәтлем Юлия! Мин аны Гуриягә алып китеп, аякларыннан чинар агачына асып куям! Кая керер тишек тапмаячак ул!

– Кай җиреннән асып куйсагыз да, миңа барыбер, әмма шуны искәртәм: әнисе бәхетле, бу җан кисәге белән чиләнергә туры килмәде аңа. Атасы да бәхетле...

– Сүзегезгә караганда, хөрмәтлем Юлия, тынгылык булмаячак алайса...

– Белмим, бернәрсә дә белмим... Уйлап кына карагыз: күптән түгел генә мин аны тегермәнгә җибәрдем... Бер пот менә дигән кукуруз алып киткән иде шайтан баласы, капчык төбенә салып биш фунт он алып кайтты. Калганын Валико Кукалашвилиның юлдан язган балаларына биргән икән. Ишләре күп, ачлы-туклы яшиләр, ди... Күр әле син аны, ә?!

– Аллам орсын, валлаһи! Ишеткәннәрем дөресме, малай?

– Монысы ярар да иде әле... Кичә ул һәм аның яланаяклы дусты Кукури Угулава, үзләрен географиядән укыта торган Датико Цверава бакчасына кереп, кесәләренә шәфталу тутырганнар да шуны тәмәкегә алмаштырганнар. Баш җитмәслек нәрсә, ә?!

– Аллам орсын, валлаһи! Бу дөресме, малай?

– Сез нәрсә, очкылык тоткан шикелле һаман бер үк сүзне кабатлыйсыз? «Дөресме дә дөресме?», имеш. Сез мине алдакчы, дип уйлыйсыз мәллә?

– Нәрсә сез, нәрсә сез, хөрмәтлем Юлия! Шуңа аптырыйм, хөрмәтлем Юлия, малайны коткару әмәле юкмыни соң, ә?.. Ул тәмам юлдан язганмыни?

– Юк, юк, алай ук түгел, аны коткарырга мөмкин, әлбәттә. Ләкин минем моңа көчем җитми... Монда ир-атның каты кулы кирәк. Минем арык җилкәмдә

Нодар ДУМБАДЗЕ (1928 – 1984) *– грузин язучысы, сценарист; «Мин, әби, Илико һәм Илларио...», «Мин кояшны күрәм», «Мәңгелек кануны» һ.б. күпсанлы китаплар авторы. Әдәбият өлкәсендә Ленин премиясе лауреаты.*

Колямның икәве дә утыра бит әле: Зураб белән Вахтанг. Алар бу малайдан чистарак. Озакламый көтүлектән кайтырлар – күрерсез!

– Мда-а-а...Ни генә диим соң, хөрмәтлем Юлия?.. Үзләре исән чагында әти-әнисе аның янына якын да җибәрмәде. Хәзер миңа нишләргә инде? Кешечә яшәргә ничек өйрәтергә аны?.. Йөрәген ничегрәк җылытырга?.. Мин аңа чит-ят кеше! Чит-ят... Аңлыйсыңмы шуны?

– Алай димәгез, хөрмәтлем Кишварди! Ул да ир-егет бит, шулай булгач, ир-ат белән уртак телне тиз табар... Шуның өстенә ул сезнең нәсел дәвамчысы да бит әле!..

– Анысы шулай шулаен... Укуы ничегрәк, хөрмәтлем Юлия?

– Һм...Укытучысының шәфталуларын урлаган һәм бозыклык белән тулы «Декамерон» китабын кулына төшерү өчен әбисенең көмеш бал кашыкларын саткан малайдан ни көтәсең инде? Уку турында уйлыймыни ул, үзегез нәтиҗә ясагыз, хөрмәтлем Кишварди!

– Бу дөресме, малай? Хәл иттем! Мин аны Гуриягә алып китәм дә аякларыннан чинар агачына асып куям!

– Менә үзегез күрегез инде, сокланыгыз аңа карап, без монда нишләргә белми бәргәләнәбез, ә ул төкереп тә бирми, керфеген дә селкетми, ичмасам!

Ә юкәгә сөялгән малай уй диңгезендә йөзә иде: «Әбием Юлия минем белән тәмам чыгырдан чыкты... Элек аның сөйләме ничек ягымлы иде, ә хәзер әнә ничек усал яңгырый... Бәлки, миңа гына шулай тоеладыр? Бабай тыныч кына әңгәмә кора... Их, җибәрмәсен иде әби мине шушы бабай белән, шулай итсә, әбиемне беркайчан да рәнҗетмәс идем... Беркайчан да... Бабайга биреп кенә җибәрмәсен иде... Җибәрмәсен иде...»

– Ятим бит ул, хөрмәтлем Юлия... Чыбыктан тыш аңа наз да кирәк.

– Иркәләүнең ни икәнен беләмени ул... Наз, имеш...

– Бу дөресме, малай? Менә мин аны Гуриягә алып китеп, аягыннан агачка асып куям... Кайчан алып китим, хөрмәтлем Юлия?

– Хет хәзер үк... Аны юлга әзерләү озак түгел.

– Ничек инде алай?.. Үзе дә ике күзе генәмени?

– Узган ел Авчалдан мин аны шул хәлендә алып кайттым, хөрмәтлем Кишварди. Юк әйберләрен укалы тасма белән урарргадыр, бәлки?

– Мескен балакаем минем...

– Юлга чыгар алдыннан ашап алыгыз, хөрмәтлем Кишварди...

– Борчылмагыз, хөрмәтлем Юлия... Самтредиада капкаларбыз, аннан минем өйгә кул сузымы гына...

– Кыстамыйм... Хәерле юл сезгә... Изге Георгий сакласын үзегезне!

– Алла бәхетле итсен сезне, хөрмәтлем Юлия!

– Менә үзегез белән алыгыз, хөрмәтлем Кишварди!

– Нәрсә бу?

– Малайның документлары... Сентябрьдә аны мәктәпкә озатканда, кирәге чыгар. Дүртенче сыйныфка күчте ул... Дөрес, справкасында бер хата бар. Ломджария Нодари дип язасы урынга Ломджария Надири* дип язганнар. Минемчә, хата түгел бу, ул чынлап та шундый.

– Бу дөресме, малай? Ярар, алып китәм мин аны Гуриягә. Һәм асып куям аягыннан.

– Кай җиреннән ассагыз да асыгыз, күзләрем генә бүтән күрмәсен аны...

– Аягыннан асам, аягыннан...

– Алла ярдәм бирсен!

– Алла ярдәм итмәсә, мин аны боргычлап эшкә җигәчәкмен, хәтта кызганудан ташлар да елаячак.

---

*Сүз уйнату: Нодари – ирләр исеме, надири – җәнлек.

– Сау бул, хөрмәтлем Кишварди!

– Имин көннәр телим сезгә, хөрмәтлем Юлия!

1938 елның август аенда Хонида Нодари Ломджария әнисенең әнисе Юлия Микеладзе һәм әтисенең әтисе Ломджария Кишварди арасында менә шундый алыш-биреш булып узды.

Ә бер сәгатьтән 1928 елның 14 июлендә Тбилисида хезмәткәр гаиләсендә туган малай, дөресрәге, Нодари Ломджария, баугa бәйләнгән бозауны хәтерләтеп, башын салындырып, тузанга баткан юлдан атлый иде инде.

Хонидан Кулашига хәтле бабай белән онык җиңел тарантаста кайттылар, аннары Кулашидан Самтредиадага чаклы линейкага утырып килделәр. Чәйләп алгач, Чохатурига баручы чәй фабрикасы машинасы кузовына үрмәләделәр. Соңыннан Интабуети авылына җәяүләп кенә теркелдәделәр.

Бабай алдан атлады, онык аңа иярде. Карт берөзлексез ютәлләде һәм ыңгырашты. Каршына килүче юлчыны күргәч, аның белән ягымлы гына исәнләште, беркадәр вакыт хәл алып торгач, ютәлләргә һәм сукранырга тотынды. Ара-тирә дәшми-нитми генә малайга борылып карады – картайган арык ат колынына шулай борылгалап күз төшерә, соңгы нәсел дәвамчысын югалтудан курка.

Арттан килүче малай болайрак фикер йөртә иде: «Менә алдан ябык, авыру, бертуктаусыз ыңгырашучы, башына төсе кояшта уңган эшләпә кигән карт атлый... Ул мине аягымнан агачка асып куярга вәгъдә итә... Бу карт – минем бабам! Минем әтиемнең әтисе... Бабай!.. Аның артыннан атларга мине ни мәҗбүр итә соң? Ни өчен мин бер хокуксыз кол шикелле тузан ерам? Ике адым читкә атла да, теләсә кайсы якка оч!.. Юк, булдыра алмыйм! Ниндидер көч мине картның аркасына таба этә, картка ияреп атла, ди. Нинди көч соң ул? Нигә соң мин, хәлдән тайган, ач, эсседә сусап тәмам талчыккан малай юлдан читкә чыга алмыйм? Нигә? Ни дип атала ул тарту көче?»

– Нинди уйга баттың, онык?

– Берни турында да уйламыйм, – дип җавапларга ашыкты малай. Ул мондый сорауны көтмәгән иде, юкса сөйләшер нәрсәләр күп бит.

Карт юл читенә чыгып, үләнгә утырды. Бераз хәл алгач, йөткеренде дә малайга текәлде, бармакларын бөгә-бөгә санарга кереште: 28, 29, 30, 31, 32, 33, 34, 35, 36, 37, 38.

– Син, балам, егерме сигезендә тудың. Бүген менә утыз сигезе. Димәк, сиңа унберенче яшь китте. Син зур инде... Шулай булгач, ничек бернәрсә турында да уйламыйсың? Әллә нәрсәне дә булса, бабаңнан яшерәсеңме?

– Әйе, бабай, мин бернәрсә турында да уйламадым, – дип алдашты онык.

– Уйларга өйрәнергә вакыт, онык, вакыт!

Карт йөткерә-йөткерә ах-ух килеп аягына калыкты һәм юлын дәвам итте. Малай да баугa бәйләнгән бозау сыман карышмый-нитми аңа иярде.

***

Кояшта кызарган, маңгае тирләп чыккан малай, тимер көрәгенә таянып, пычранып беткән ялангач аякларына текәлеп, тирән уйга чумган: «Бер елда ничек картайган ул, тәмам бөкрәйгән. Бите тулы җыерчык... Тавышы да гыжылдавык. Ә шулай да ул минем әниемә охшаган! Яшь, чибәр, ягымлы, кара күзле, назлы әниемә охшаган! Чәче дә, йөрүләре дә охшаш... Күзләремне йомсам, аны әнием дип уйларга мөмкин...»

Әмма малай күзләрен йоммады. Малай курка иде.

– Тынычлыгым тәмам югалды, хөрмәтлем Кишварди. Аның бәхетсез анасының шәүләсе өнемдә дә, төшемдә дә мине эзәрлекли... Сез малайны алып киткәннән соң бөтенләй бушанып калдым, әйтерсең лә, йөрәгемне күкрәгемнән суырып алдылар... Кире кайтарыгыз оныгымны, хөрмәтле Кишварди!

– Мин алып киткәндә, ул бала гына иде әле, хәзер ир-егет әнә. Һәр нәрсәгә үзе җаваплы. Сезнең белән китәргә тели икән, китсен, мин каршы түгел.

– Үпкәле ул миңа... Бары тик сез генә, хөрмәтлем Кишварди, безне татулаштыра аласыз. Сез бит акыл иясе...

– Сезнең тагын икәү бар бит әле. Монысын миңа калдырыгыз! Миңа берсен генә булса да калдырыгыз инде, хөрмәтлем Юлия!

– Сандамыни хикмәт? Ике, ун, йөз – бөтенесе дә бер! Онык әбигә барыбер онык инде, хөрмәтлем Кишварди!

– Шулаен шулай да... Тик миңа нишләргә соң? Мин күзләремне мәңгелеккә йомгач, Ломджария нәселе аннан башланырга тиеш!

– Мин аның фамилиясен үзгәртмәячәкмен! Теге икесе дә Ломджария булсыннар, ләкин монысын миңа кайтарыгыз!

– Димәк, малайны алып китәргә килдегез, хөрмәтлем Юлия?

– Мине теге дөньяга гөнаһлы көе озатмагыз инде, зинһар, анда әнисенең күзенә ничек карармын?

– Эх хөрмәтлем Юлия, анда кемнең алданрак китәсе билгесез әле. Алданрак китсәм, аның әтисе белән әнисе миңа ничегрәк карарлар?

– Алла сезгә үлемне ашыктырып китермәсен әле, хөрмәтлем Кишварди!

– Малай минем басуым да, йөзем бакчам да, тегермәнем, каберем һәм ташым да... Юк, үтерсәгез дә бирмим мин аны.

– Алайса мин үз-үземне үтерәм, сезнең алда үтерәм!

– Аллам сакласын, хөрмәтлем Юлия, сез нәрсә сөйлисез?.. Әбиең белән китәсеңме, онык?

– Ничек әйтсен инде, ояла бит ул.

– Бу дөресме, малай?

– Ана назы кирәк аңа, хөрмәтлем Кишварди! Киемнәрен юарга, үтүкләргә, юындырырга, аркасын ышкырга, чәчен тарарга... Сез аның әнисен алыштыра алмыйсыз...

– Ничек әйтәсең бит? Моңа кадәр сер бирмәдем, Аллага шөкер. Сезне ярдәмгә чакырмадык анысы.

– Бәхәсләшмим, бәхәсләшмим, хөрмәтле Кишварди! Әмма барыбер... Йокы алдыннан малайның аякларын юарга, аның артыннан мәктәпкә чабарга кирәк. Ир-ат эше түгел бу!

– Безнең мәктәпкә үпкәсе юк, сезнекендә генә аны җәнлек дип атаганнар. Ә сез моның белән килешкәнсез... Ул бит җәнлек түгел...

– Ул вакытны телем ничек корышмады икән?

– Миндә фәрештәгә әверелде, шәфталулар да урламыйдыр, дип уйламагыз тагын.

– Урласын, урласын соң...

– Онны да теләсә кемгә өләшми, дип уйлыйсыздыр?

– И Аллам, он нәрсә ул? Бөтенесе дә аныкы, теләсә өеп яндырсын шунда, мин каршы түгел!

– Тәмәке дә тарта, шайтан кисәве!

– Бу дөресме, малай?

– Миннән сорагыз монысын. Кесәләрем дә, тәмәке янчыгым да буп-буш.

– Тартсын, рәхәтләнеп тартсын, сәламәт булсын! Үзегез аны ир-ат дип атадыгыз лабаса!

– Бер ай гына түзегез инде. Ефәк кузысы өчен премия алуга шәпләп киендерим башта. Ертык киемнәр белән сезгә биреп җибәрә алмыйм бит.

– Сез аны җибәрегез генә. Оныкны киендерү күңелле мәшәкать ул, хөрмәтлем Кишварди! Үземнекен салып бирәчәкмен мин аңа.

– Һм... Сезнең киемнәр ятышып кына торыр, әйе!

– Шаяртырга оста сез, ә минем йөрәгемә кан сава.

– Әйттем бит, хөрмәтлем Юлия! Ул буй җиткергән егет. Үзе хәл итсен!

– Сез аның өчен диндарларның иконасы кебек. Һәр сүзегез Алла вәгазенә тиң!

– Алладан куркыгыз, хөрмәтлем Юлия! Нәрсә, мин үземнең кандашыма йортымнан кит, дииммени инде? Бәлки, бер ел гына гомерем калгандыр.

– Үтенәм сездән, зинһар, мине вакытсыз гүргә кертмәгез! Бүләк итегез мин карчыкка бу малайны!

– Хөрмәтлем Юлия!

– Мин сезнең алда тезләнәм!

– Сез нәрсә... Аягыгызга басыгыз! Ярар, сезнеңчә булсын!

– И бөек Аллам, син аңа бәхет һәм шатлык бүләк ит! Мин бүтән бәхет күрәлмәячәкмен инде...

– Рәхмәт, Аллам!

– Әбиең белән кит, онык!

***

Алда сөйләнгән вакыйгалардан соң, нәкъ бер ел үткәч, малайның бабасы һәм әбисе арасында шундыйрак сөйләшү булып узган иде, монысы инде алыш-биреш түгел. Бу ике гәүдәдә тамырларындагы канның шаулап агуы, дулкынланган ике йөрәкнең өзгәләнүе иде. Аларның тигез ярату хисе малайның йөрәк тибешен тизләтте, тамагына тозлы төер утырды, маңгаена салкын тир бәреп чыкты, тәне калтыранды, күкрәген нидер авырттырып кысты. Күзгә күренмәс ниндидер көч аны әле әбисенә тартып китерде, әле бабасы кочагына илтеп атты. Малай берничә тапкыр тәнендә коточкыч авырту сизде, әйтерсең лә күкрәген утта кыздырылган ук тишеп узды. Карт белән карчык арасында бу ачы, аңлашылмас сөйләшү барган мәлләрдә малайны курку хисе, хәвеф, нидер көтү тойгысы җәфалады.

Әби аягына калыкты, малай янына килде, аны кысып кочаклады.

– Куанычым минем, күзләремнең нуры, әйдә, киттек минем белән, син миңа тагын ике генә көн булса да гомер өстә!

Карчык елый иде, кайнар яшьләре малайның чәчен юешләде. Елап туйгач, малайны сак кына үзенә сыендырмакчы булды, әмма малай каккан казык күк бер урында басып торуын дәвам итте. Әйтерсең лә, ул тамырлары белән җиргә береккән агач иде.

– Бар, кит, бала, ияреп кит карт әбиеңә... Ул сине яратып туйгач, миңа кире әйләнеп кайтырсың... Ул вакытка инде мин дә сине сагынып өлгерермен... Шулай! Кемнәрнеңдер оныгы булу җиңел нәрсә түгел ул... Аеруча картаеп бетәшкән ике кешенең оныгы булу – яман хәл. Кит, онык! Ә синең балтаң, тимер көрәгең, китмән, кәрзин, сыер, бозау, кәҗә һәм дуңгызың беркая да китмәс, кайтуыңны көтеп торырлар.

Бабасы сөйли, ә малай гаҗәпләнә: балта, китмән, тимер көрәк, кәрзин ишегалдының төрле җирендә аунап ята, сыер, бозау, кәҗә, дуңгыз да теләсә кайда басып торалар иде, ә бабасы һәр нәрсәнең кай төштә икәнен ничек шулай төгәл әйтеп бирә ала икән, ә? Бармагы белән ничек нәкъ шул якка төртеп күрсәтә, һич аңламассың...

Бабасы дәвам итте:

– Менә синең букчаң, грузин телендәге дәреслекләрең, тарих китабың. Бүтән уртак нәрсәбез юк бугай. Чалбарың, күлмәк, чүәкләрең өстеңдә. Самтредиадага хәтле яланаяк бар, юкса кайтып җиткәнче чүәкләрең тетелеп бетәчәк. Менә бетте дә...

Кишварди Ломджария шуны ачык аңлады: сөекле оныгы тимер казыкка, тамырларын җиргә тирән җибәргән агачка әверелгән, ялангач вәгъдәләр белән генә аны урыныннан кубару мөмкин түгел иде. Башкача якын килү кирәк иде. Әмма ничек?

Кишварди Ломджариягә шунысы да мәгълүм: оныгы тылсымлы әйләнә

уртасында басып тора, һәм ике канның тарту көче аны төрле якка өстери. Кайсы көч өстен чыгар? Кайсы кан җиңәр? Көрәш азагын көтү ярамый... Кемдер тамырларда шаулаган кан каналын беренче булып ябарга тиеш... Һәм Кишварди Ломджария әбидән өлгеррәк булып чыкты:

– Нәрсә көтәсең инде син? Синең белән такылдап туйдым...

Малай куркынып бабасына карады.

– Кит! Артыңа әйләнеп карамый кит!

Малай бабасына бик нык рәнҗүен дә, әбисен жәлләвен дә бер үк мизгелдә тойды. Кинәт бәреп чыккан яшьләре күзләрен томалады, ирексездән башы күкрәгенә салынып төште һәм ул, бер сүз дә дәшмичә, бауга бәйләнгән бозау күк, тәмам бетәшкән, бөкрәйгән, кап-карадан киенгән әбисенә ияреп тузанлы юлдан атлап китте...

Кишварди Ломджария камин каршына утырып, бакыр казанда су кайнап чыгуын көтеп калды.

Кишварди Ломджария утка төбәлгән хәлдә тирән уйга батты. Шул ук вакытта күңелсез уйларыннан каядыр читкә качарга, яшеренергә теләде. Ләкин адәм баласы уйларыннан кая качсын соң инде? Кеше бит, Алла түгел... «Малайны җибәрмәскә кирәк иде. Карчыкның кайгысы җебетте мине. Менә хәзер үзем аның хәлендә инде. Алдагы атнада янына барып чыгачакмын һәм малайны кире бирүен сораячакмын. Бирмәсә, көч белән тартып алачакмын... Минем баламны, минем җанымны тартып алырга хокукың юк синең. «Син Алла түгел!» диячәкмен. Әмма... Ул да миңа нәкъ шул рәвешле җавап кайтара ала бит. Мин дә Алла түгел, үлемгә хөкем ителгән гап-гади бер бәндә... Малай миңа газиз булган кебек, аңа да үз... Әгәр дә мин Алла булсам! Ох, Алла булуга караганда, кеше булу мең мәртәбә кыенрак... Аллага шөкер, бу хакыйкатьне коткаручыбыз Иисус Христос үзе дә бик әйбәт төшенде ләбаса... Алдагы атнада барачакмын мин аңа, аяклары астына егылачакмын. Юк, атна буе түзеп торалмам... Берсекөнгә үк китәм... Юк, иртәгә! Иртәгә кояш чыгу белән кузгалам... Таң тизрәк атса икән!»

Бакыр казанда су кайнавын көтеп утыручы Кишвардиның миеннән шундый уйлар йөгерешкән мәлдә ишек ачылып китте һәм бусагада чүәкләрен җилкәсенә аскан малай пәйда булды. Башы аска иелгән иде.

– Аллага шөкер! – дип кычкырып җибәрде карт.

– Мин кайттым, – дип пышылдады онык,

– Кайтасыңны белгән идем! – диде карт.

Аннары Кишварди Ломджария бакыр казаннан тазга кайнар су агызды да озаклап, оныгының юл йөреп талчыккан аякларын юды. Ятакка урын җәйде дә үзенең караңгы почмагына кереп китте. Ул шунда йоклый иде.

Төн уртасында картны малай тавышы уятты:

– Бабай, синең яныңа ятыйм әле!

– Кил, балам! – дип, карт стенага елышты.

«Нинди салкын минем бабай» дип уйлады онык.

«Тәне шундый җылы» дип уйлады карт.

Бераздан карт малайга дәште:

– Минем янга ни кайтарганын беләсеңме?

– Юк!

– Исеңдә тот, бала! Кан чакырып кайтарды сине миңа. Кан авазы бөек көчкә ия ул!

Шуннан соң алар авызларына су капты. Берни турында уйламадылар. Карт һәм онык бик бәхетле йокы кочагында изрәделәр.

Алар өчен кан нидер уйлый һәм сөйли иде. Әмма канның ни уйлавы һәм ни сөйләве бер Аллаһы Тәгаләгә генә билгеле иде.

**Рәшит БӘШӘР** *тәрҗемәсе.*

*«Шифалы куллар» әдәби конкурсы*



Зинаида
Захарова

# ЕЛАМА, ӘНИ!

ХИКӘЯ

– Елама, әни, терелермен, мине врачлар терелтәчәк, – диде бала арбадан башын күтәрә төшеп. – Син елама гына. Бер җирем дә авыртмый, ишетәсеңме, әни, елама гына, яме?!

«Менә баламны чир нишләтте: алты яшьлек сабый олы кешеләрдәй фикер йөртә», – дип уйлап, күз яшьләрен тыярга тырышты ана.

Арба артыннан барган кызы да сүзгә кушылды:

– Савыга Наил. Барыбыздан уздырып аттай чабып йөрер әле, менә күрерсең, әни! – диде, аны юатырга теләп.

– Бирсен Ходай, сүзләрең фәрештәләрнең амин дигән сәгатенә генә туры килсен иде, балам.

Улы терелер, врачлар кулына эләккәч, терелер. Ләкин бүгенгесе бик авыр шул. Улының хәле алга китешле түгел. Аның сызланып ятуларын, җәфаларын күрү бик авыр шул анага.

Малай, аягы авыртуын әйтмәскә, әнисен борчымаска теләсә дә, булдыра алмады.

– Әни, бераз гына туктап торыйк. Аркама әйләнеп кенә ятыйм, булмаса.

– Түз инде, Наил, юл ерак бит, әле чиреген дә үтмәдек. Болай еш тукталсак, кичкә хәтле дә барып җитә алмыйбыз. Ярый син бүлнистә калырсың. Безнең бит әле апаң белән унбиш чакрымны терек-терек, уфалла арбасы тартып, кире кайтасы да бар. Син шуны да исәплә, улым.

Улы әнисе сүзләрен ишетми диярлек. Чөнки үз хәле хәл аның. Нишләп бу кадәр авырта икән аягы? Нигә авыртуны баса торган дару юк икән? Малай китү түгел, идәндә дә басып тора алмый башлады бит инде. Сызлавы да көннән-көн көчәя шикелле. Авырту, ток тоткандай, бөтен гәүдәсенә тарала.

– Кызым, син арбага тагылма, этеп бар, миңа ярдәмең тисен, – дип шелтәләп алды әнисе, кызына таба борылып.

Әнисенең сүзләре кызны айнытып җибәрде.

– Эчәсем килә, су бир әле, әни, – ди Наилә.

– Су бик аз, энеңә генә. Суга зур савыт таба алмадым шул.

– Мин эчмим, бер генә йотам, – ди бала киреләнеп.

Май урталары гына булуга карамастан, көн бик кызу. Кояш нурлары иркәләми, көйдереп ала, миләрне корыткандай итә. Эссегә түзәрләр, өстән

явып, чылатмасын гына. Тоз түгел, эремәсләр анысы, ләкин шәбәрсә, балалар туңып, чирләргә дә күп сорамаслар. Ана кызының яланбаш икәнен шунда гына шәйләп алды.

– Кояш сугар бит, яулык ал, дияргә дә онытылган. Менә, үземнекен бирәм, мә, башыңа яп!

– Кояш сукмый мине, борчылма, – диде Наилә башы авыртуын да, сул як чигәсенең сулкылдавын да яшереп. – Туктап, су йотсам, җиңеләеп китәр идем. Юк, иренемне генә тидереп аласым килә.

– Туктарбыз, әнә теге үрне генә үтик, кызым. Юлы юл булса иде. Бу чокырларны махсус казыганнар, диярсең. Атлар ничек йөри икән бу юлларда?

Ат сорап, авыл советына барырга кыймады шул Тәскирә. Оялды. Бирмәячәкләрен, ни әйтәселәрен белгәнгә, сорап маташмады. Ирең колхозда эшләми, диярләр. Күршесе Талипны да шулай дип борып чыгарганнар. Аерым хуҗалыкка түгел, кохозчыга да бирер хәлдә түгел. Атларыбызның егәре юк, ашатыр әйбер бетте, дип бирми җибәргәннәр. Аның хатынының башында зур шеше бар иде. Кергән саен яулыгын чишеп, Тәскирәгә күрсәтә иде мәрхүмә. Күрше авылның белемле саналган сихерчесенә дә күп йөрде ул, үләннәр белән дә дәваланды, тик терелә алмады. Әҗәле якынлашканда, урын өстендә булган. Зиһене киткән, хәтерсез калган. Шеше тишелеп аккач, бер-ике көн хәле җиңеләеп торган. Болай булса, терeләм дигән... Өметсез – шайтан гына шул. Өченче көнгә якты дөнья белән хушлашкан. Тәскирәнең ире Кыямның да сугышып, илгә җиңү китерүдә өлеше зур икәнен күптән онытты шул сәвитләр. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен алган медальләре сандык төбендә генә юкса. Яраланып кайтып, түшәктә ятуларын, яралары ачылып,тәне бозылуын, коры сөяккә калып кибүләрен күрмәде шул алар. «Ир кадерен ил белә, ил яхшылыкны онытмас», диләр юкса. Ходайга шөкер, ире аякка басты, терелде. Тәскирәсе бик карады шул. Аны аякка бастыру өчен эшләмәгәне калмады. Яраларын көнгә икешәр тапкыр сүтеп дарулый иде Тәскирә. Үзе рәтле ризык күрмәсә дә, бар булганы белән ирен тәрбияләде. Алла рәхмәтле булды аларга, бүгенге көндә Кыям сау-сәламәт. Сугыштан соң өч балалары дөньяга килде, дүртенчесе карынында. Сигез бала алар өчен сигез шатлык булыр, язган булса. Кыямы үлеп ярата аларны.

Ире сугышка киткәндә, дүрт бала белән калган иде Тәскирә. Балалары да кул арасына керердәй түгел, кечкенә иде. Сугыш вакытында күргән авырлыкларны язып та, сөйләп тә бетерерлек түгел. Сугыш беткәнгә дә унбер ел вакыт үткән. Гомерләр судай ага шул. Наил генә терелә күрсен, берүк, исән генә булсын. Ходай бала кайгылары бирмәсен икән. Бирсә дә, узып китә торган булсын. Иң авыр кайгы бала кайгысы икән шул.Үз башыңа төшми белмисең генә.

Улының больницада каласын уйлап, киңәшләрен бирәсе итте Тәскирә:

– Улым, аларның палаталары зур, кешесе булыр инде. Син үскән егет, үзеңне ничек тотарга кирәклеген беләсең, – дип, борылып Наилгә күз салды ул.

– Ничек? – дип сорап куйды бала, башын күтәреп.

– Таякларың белән шакылдама, әкрен йөре. Тихый часларында йокла. Дорфа сөйләшмә, яратмаслар. Иртән кеше белән бергә уянырга өйрән. Анда сине уятырга авыл әтәчләре дә, мин дә булмам. Иртән юынырга онытма – яратмаганыңны белгәнгә әйтүем, улым. Шапшак икән бу малай, димәсеннәр! Иртән уянгач, күршеләреңне: «Хәерле иртә!» – дип сәламлә. Урманга кергәч ничек кычкырасың – урман шулай җавап кайтара, хәтерлисеңме, улым?

– Әйе, хәтерлим, әни, урманда кычкырып йөргән идек. Шунда әйткән идең бу сүзләрне.

– Әйттем шул, ә син онытма. Яхшыны ишетәсең килсә, яман сөйләмә, диләр. Кешегә яхшы булсаң, алар сиңа начар булмаслар. Врачларга ягымлы бул. Сорауларына туры җавап бир. Кирәген генә сөйлә, улым, күп сүз – чүп сүз ул.

– Татарча сөйләшәләрме соң алар? – дип сорап куйды улы. – Мин бит аларныкын аңламыйм.

– Белүчеләр бар анда, борчылма. Булмаса, урысча өйрәнеп кайтырсың. Өйрәнергә тырыш.

– Шулай озак ятаммы анда? – дип сорап куйды бала, тел турында сүз чыккач, әнисен аптырашта калдырып.

– Күпме кушсалар, шулкадәр ятарсың, Наил. Терелгәнче , – диде ана кырыс булырга тырышып.

– Анда нәрсә ашаталар икән? – дип кызыксынды бала.

– Бик тәмле ашаталар, ди, ризыкларыннан баш тартма. Мин яныңа бик барып йөри дә алмам, үзең беләсең, эшнең күп чагы. Сиңа терелергә кирәк, шуңа да ашарга тырыш. Өйне сагынып ятма. Сагынсаң, аягың төзәлмәс, – дип бетерде ул сүзен.

– Кызык син, әни, минем сагынганны аягым белә, димени?

– Ничек кенә белә, әйткәнне тыңла! – дип, үз сүзендә булды ана.

Тәскирә башын да күтәрми алга баруын белә. Наилә күзләре белән тирә-якны айкый күрәмсең. Юкса, юлдан читтә арткы тәпиләрендә баганадай утырган йомранны күрер идеме?

– Карагыз, нинди матур итеп утыра! – дип кычкырып җибәрде кыз.

Туктап, җир өстенә җылынырга чыккан йомранны күзәтте алар.

– Сызгырды, ишеттегезме? – дип сорады Наилә. – Безне шулай сәламли булса кирәк?!

– Юк, кызым, безне күреп, балаларына куркыныч бар, дип хәбәр бирә, – диде Тәскирә.

– Нәрсә ашыйлар икән алар? – дип кызыксынды улы.

– Бөртекләр, үсемлекләр. Салкыннар башлануга, өннәрендә кышкы йокыга талалар, – дип белгәннәрен балаларына сөйләп алды ул.

Юл кырыйларын тоташ келәмдәй сары чәчәк каплап алган. «Сары кояшлар» – тузганаклар.

– Нинди матур! – ди Наилә, чәчкәләргә исе китеп.

– Әйе, матурлар, – дип килешә Тәскирә, соклануын яшерә алмый. – Озакламаслар, ак тузганакка әйләнеп очып китәрләр. Чүп үләне бакчабызда үскәнен яратмыйбыз, ә басуда исә шул чүпкә сокланып барабыз.

Сары төсне сагыш, диләр. Менә бит язлар да сагышлы була икән. Язның сагышыдыр бу тузганаклар. Сагыш кына түгел, хәсрәтле яз килде Тәскирәгә. Киләсе язлары шатлык кына алып килсен иде. Җитәрлек татыды ич ул ачы хәсрәтне, җитәрлек!

Көтмәгәндә, көнбатыштан көчле җил исә башлады. Көчәйгәннән-көчәя бара. Менә сиңа кирәк булса, хәерчегә җил каршы, дигәннәре шушы буладыр инде.

– Кирәкми идең син, каян гына килеп чыктың безнең каршыга, – дип җилне ачулана Тәскирә. Аяк атлаулары авырлашты. Наилә дә арба артыннан көч-хәл белән сөйрәлә.

– Җил мине екмакчы була. Бирешмим, мин аның белән көрәшәм, – ди ул, батыраеп.

Әйе шул, арбаны да этәргә, җил белән дә көрәшергә кирәк хәзер.

– Әни, каян чыга әле җил? – дип кызыксына Наил, ишеткән әкиятен исенә төшерергә теләп.

– И балам, сөйләгәнем бар бит инде. Бик еракта, Каф таулары артында җил иясе – бик карт, сукыр әби яши. Аның зур мичкәсе бар. Җилләрне шунда саклый ул әбекәй. Җил истерәсе килсә, мичкәнең бөкесен борып ача. Аннан яңадан яба. Күзе күрмәгәч, кайчак, мичкәне тиз генә томалап өлгерә алмый. Андый чакта җил озакка китә.

– Тиз генә томаласын иде әби мичкәсен, – дип куйды Наилә. – Чак егылмыйм, әни.

– Күрәм, кызым.

– Миңа җиңел, җил булса ни дә, булмаса ни, – дип елмаерга тырыша Наил.

Кара син аны, апасын үртәп бара, җан кергән үзенә! Араларында иң тәмле теллесе, чаясы да шушысы. Чытлыклыгы да баштан ашкан шул.Чирне дә үзе эзләп тапты. Былтыр көз, уйнап йөргән җиреннән, аяксызланып кайтып егылды. Түбән очка төшкәне дә юк иде югыйсә. Күрәчәк йөртә, язмышлар йөртә шул кеше баласын. Бер оятсызы матай белән бәреп киткән. Авыр хәлдәге баланы алдап: «Мин хәзер киләм, шушында гына утырып тор», – дип, сабыйны җиргә салган да үзе качкан. Кем икәнен күрүче дә булмаган, имеш. Кеше бит андыйны күрмәмешкә салыша. Матай белән авыл уртасында бәреп китсеннәр дә, берәү дә күрмәсен, имеш. Дөньясы бетмәсә, оятсыз адәмнәр бетмәс инде ул, анысы хак. Ничек итеп, ниләр уйлап, тынычлап яши икән ул адәм актыгы – белгән юк. Бәла аяк астында түгел диген инде, менә терәк. Көздән бирле авырый бит Наил, җиде ай була түгелме? Улының сызлануларын, интегүләрен күреп, Тәскирә үзе дә чиргә сабыша бугай инде. Карынындагы баласы гына сәламәт туа күрсен.

– Әни, үрне күптән мендек, нигә һаман ялга туктамыйбыз? – ди кызы, еларга җитеп.

– Сиңа ял итәргә генә булсын инде, кызым. Беркөн сеңлең белән барып кайту күпкә җиңелрәк булган иде. Кечкенә булса да, түземле икән безнең Нәсимә, – дип алдашты Тәскирә, Нәсимәсе белән интеккәннәрен исенә төшереп.

Ул көнне тәмуг утында янгандай булган иде ана. Наиләсенең унҗидесе тула, ә бит Нәсимәсенең уналтысы тулмаган, икесе дә сугыш алды балалары. Арбаны этеп бару түгел, Наил янына ятып барырлык булган иде кызы.

– Нигә мин чирләмим икән, әни, арбада мин булыр идем, – дигән иде мескен бала.

Шул сүзләрне ишеткәч, Тәскирә:

– Арбага тотынып бар, кызым, шулай җиңелрәк булыр үзеңә, – дигән иде Нәсимәсен кызганып.

Кая инде шелтәләү. Ярдәме тимәсә дә, юлда иптәш булды бит аңа кызы. Ул көн уңышсыз булып чыкты шул. Наилне алмадылар, хастаханәдә урыннар булмады. Яшь врач Тәскирәне тыңларга да теләмәде. Авызын ачып сүз дә әйтә алмады ана. Юкса нинди кыенлыклар белән килгән авыл хатынын кызганыр, урынын да табар кебек иде.

– Палаталар, коридорлар авырулар белән тулган, апа. Гафу итегез, бүген алып кала алмыйбыз.

Аңлап та булмый шул ул врачларны:

– Улыгызның авыруы көчле, нигә җиде ай буе врачка күрсәтмәдегез? – дип, Тәскирәне шелтәләп тә алдылар юкса.

– Малаеңның аягы зәгыйфьләнгән, үсүеннән туктаган. Авыру аягы күпкә кыскарак, – диде доктор. Гомер буе аксап йөрергә калган бит. – Нидән шулай булды? – диләр.

– Кемдер авыл уртасында матай белән бәрдереп киткән, кем икәнен белә алмадык, – дип җавап бирде Тәскирә.

– Улыгызны гомергә гарип калдырган кешенең исемен дә белмисез. Җир астыннан булса да табарга кирәк аны. Авылыгызда матайлы кеше күп тә түгелдер югыйсә.

Больницага аласы көннәрен билгеләп, чакырып калдылар. Бик озак итеп дәфтәр тутырып нидер язып та алган булдылар. Тәскирәнең кулына уч төбе хәтле дә язу бирмәделәр үзләре. Шулай тиештер дип уйлады, юллама сорарга кыймады Тәскирә.

Баласының авыруы яман икәнен белә шул ул. Шуңа да юл буе елап кайтты. Яше чыкмаса да, җаны елады. Баласы авырганнан бирле, шулай күңеле мөлдерәмә булып түгелеп, күзләреннән тамчы да төшмәде аның. Каян килде аларга бу бәхетсезлек? Баласын нинди гөнаһлары өчен сыный икән соң Ходай?

Тыела алмый, тыныч кына яшен түкте, юл буе тешен кысып елады. Күз яшьләре дә сытылып кына чыкты югыйсә. Ә балалары әниләренең елаганын сизделәр.

– Елама, әни, ник елыйсың? – диде Нәсимәсе.

– Юк, балам, еламыйм, тирем тама. Эссе ич, – дигән булды ана. Бар, ышандырып кара син аларны...

– Елама, әни. Мин үлсәм дә, елама, – диде шунда Наиле, үзәкләрне өзеп.

– Ничек инде син, егет кеше, үлем турында сөйлисең, улым?

– Әби үлгәч, шулай елаган идең. Мин бит онытмадым.

– Юк, юк бетте, башка күз яшемне чыгармыйм.

Бүген тагын елады шул. Балаларына биргән антын онытып, рәхәтләнеп елады. Балалары: «Елама, әни», – дисәләр дә, туктый алмады. Бүгенге хәсрәтенә, сугыш вакытында күргән кыенлыклар да килеп кушылып, тагын яшен түкте.

Үзен кулга алырга тырышты ана. «Үзеңне кызганма, Тәскирә, кызганма!» – дип, ачуланып, үз-үзенә боерык бирде. Аллага шөкер, бүген улын врачлар кулына тапшырыр. Аягы кыска калса да, аксак булса да, сызламасын, авыртмасын гына. Калган бөтен саны тигез булсын. Бәхете генә булсын инде баласының. Юлга чыгар алдыннан җәймә астына, балаларыннан яшереп, күмәч кисәге салган иде. Ашыйсылары килгәндер. Ялга туктарга вакыттыр. Ял итеп, капкалап алсыннар. Күңелләре күтәрелер сабыйларның, шатлык өчен күп кирәкми аларга. Тәскирә арбасын юлдан читкәрәк алып, туктап калгач, сөенечләре ташып чыкты оланнарның. Наил борылып йөзтүбән ятты. Наилә юл кырындагы зур ташка барып чүмәлде. Әнкәләре кулында күмәч күргәч, шатлыклары икеләтә артты. Тәскирә үзе бөртеген дә капмады. Ул да арба кырына чүкте.

– Әни, бер генә булса да кабып кара, – диде кызы.

Наил дә үз кисәгеннән әнисенә өлеш чыгарырга әзер.

– Юк, юк, ашыйсым да, эчәсем дә килми, балалар, – диде ул елмаерга тырышып.

Әниләре йөзендә елмаю күргән балалар бик тә бәхетле иде, шул минутларда. Бу елмаюның ясалма икәнен аңламый иде әле аның бәгырь кисәкләре. Алар күмәчне бик кечкенә итеп тешләп кабалар. Бу бәхетле мизгелләрне озаккарак

сузып, сеңдереп кенә ашыйлар. Су да йотып куйгач, Наилгә хәл керде. Юк-бар сөйләп, көлешеп тә алдылар.

– Дәресләреңне калдырганга, укытучы апаң ачуланыр инде, кызым.

– Син нәрсә, әнкәй, мәктәптә мине ачуланганнары юк. Билгеләрем әйбәт бит. Гомумән, синнән башка мине берәү дә ачуланмый.

– Үпкәләмә, кызым, әнкәйләр шулай инде ул: ачуланырга да, иркәләргә дә тиеш! – кызын аркасыннан сөеп алды Тәскирә. – Үзең әни булгач, аңларсың әле. Мин дә ачуланмасам, сезне кем ачуланыр, кем тәрбияләр?

Кыз әнисе сөйләгәндә, аның белән ризалашып, башын селкеп утырды. Ачулансын, еламасын гына әниләре...

– Әни, акчам булса, беләсеңме нәрсә алыр идем? – дип кинәт кенә сорап куя Наил.

– Нәрсә икән ул, улым?

– Чын мылтык – ата торганы!

– Нигә кирәк ул сиңа?!

– Теге мине бәрдергән абыйны атам.

– Син нәрсә сөйлисең, җүләр! Ул турыда уйларга да ярамый, улым, гөнаһ була! – Ана тагын ни әйтергә дә белми.

– Үзең бит аны начар кеше, дисең.

– Дөньяда төрле кеше була: начары да яхшысы да! – Тәскирә торып, юлны дәвам итәргә кирәк икәнен аңлады.

– Аягым авыртуга ул гаепле, шуңа гына инде. – Малай үпкәләгәндәй итте.

– Ялгышлык белән булгандыр. Бәлки, сине ташлап китүенә үкенәдер инде ул хәзер. Ә безгә – шулай язгандыр, улым.

– Үкенмидер, Наилне алдап, качып киткән! – дип сүзгә кушыла Наилә.

– Җәзасын алыр әле ул. Ходай аңа авырлыкны бише белән бирер, – ди ана.

– Аның да аягы авыртачакмы? – ди малай.

– Аяк кына димәгән, улым. Ходай җәзасыз калдырмас. Шуңа да кешегә игелек кенә эшләргә тырышырга кирәк, – ди ул.

– Аягы авыртсын! – ди Наил.

– Әйткәнне тыңлагыз, кешегә начарлык теләмәгез! – дип ачуланса да, үрелеп-үрелеп, арбада утырган авыру улын кочып ала. Наил дә әнисенә елыша.

– Улым, Аллаһ күрә ул, хәтта уйларыбызны да белеп тора. Тормышта ак белән кара, төн белән көн булган кебек, изгелек белән янәшә яманлык та бар. Сез шуларның барысына да әзер булырга тиеш.Үзегез кешеләргә игелек кенә кылыгыз!

Бар да тынып кала. Тәскирә, арбаны тартып, юлын дәвам итә. Юлның яртысыннан күбрәк өлеше үтелгән инде. Бирешмәскә, тырышырга, барып җитеп, улын табиблар кулына тапшырып китәргә кирәк. Ананың өметле уйларыннан кәефе күтәрелеп китте. Җил дә бераз басылгандай булды.

Юлда машиналар да очрамый, ичмасам. Ике-өч атлы гына читләтебрәк узып китте. Шәһәргә кергәч, урамнан барулар авыррак булыр, билгеле. Анда җәяүлеләр генә түгел, сирәк булса да, машиналар да, атлылар да йөреп тора. Ничек кенә авыр булса да, түзәргә, әйтелгән сәгатькә барып җитәргә.

Иң мөһиме: соң түгел әле, балаңны дәвалыйбыз, диделәр. Чатан калуына түзәргә инде, нихәл итәсең. Дөньясына чыксаң, шаклар катасың. Берәүнең дә гамь сарае буш түгел, хәсрәтсез кеше юктыр, шәт. Әллә нинди гарипләр бар дөнья йөзендә. Гарип тә кеше, аның да күңеле бар. Һәркем яшәргә талпына, берәүнең дә үләсе килми. Ерак барасы юк. Туганнан туган тиешле сеңлесенең,

егылып, кызы имгәнгән. Чирне берәү дә сорап алмый. Наиле балалары арасында иң үткене, тапкыры, иң булганы иде. Иде дип әйтү ярамас та, бәлки, араларында иң бәхетлесе дә шул бала булыр әле. Ходайның язганын белеп булмый. Борчулы уйларыннан ерак китә алмый шул Тәскирә. Борчулары да якасына нык ябышкан – котылу юк алардан.

– Әнкәй, әллә мин үләмме? – дип сораган иде улы, хастаханәгә алмый, кире борып кайтаргач.

– Нинди яман уй керде, малай актыгы, синең башыңа?

– Әнә бит, Каюмны бүлнискә алмый борып кайтарганнар иде, озакламый үлде дә.

– Аның чире савыгырлык булмаган.

– Минекен кем белә? Аягымның ничек авыртканын миннән башка берәү дә белми бит. Үләсем килми, әни, ишетәсеңме? Мин бик куркам.

– Аягы авыртып, берәүнең дә үлгәне юк әле, шуны аңла, юләр баш!

– Терелтәләрме мине, чынлапмы?

– Бөтенләй өр-яңа аяк ясый алмаслар, аксаклабрак йөрерсең, – диде дә ни әйтер дип сынап, улына карады.

– Аксак күп йөрер, дип көләсез бит Камал бабайдан. Чынлап та күп йөри ич ул! Аксак булса да, ел әйләнәсендә урманнан кайтып кергәне юк. Киекләр, куяннар, төлкеләр атып кайта. Аксак булсам да ярый, авыртмасын гына, үләсе килми!

Улы бик игътибарлы икән бит.

Юл газабы – гүр газабы, дисәләр дә, андый гына газапларга каршы торырлык әле Тәскирә. Ниһаять, төш авышуга, алар хастаханәгә килеп җиттеләр. Хастаханә бакчасына кергәндә, күңелләре күтәренке, өметләре зур иде. Бакчаларына игътибар җитми, ташландык хәлдә икән. Корыган, яфрак ярмаган агачлар да күп күренә. Май урталары гына булуга карамастан, чүп үләне баскан, былтыргысы да җыелмаган, чаж-чож килеп, аякка, арба тәгәрмәченә уралалар. Җыеп куйган чүп өемнәрен дә җил таратып ташлаган. Бөтен тирә-якта тәртипсезлек.

Шөкер, врачка чират юк, күренергә теләүчеләр күренми. Тәскирә балаларны калдырды да хастаханәгә үтте. Хастаханә дигәннәре иске агач барак. Ак халат кигән хатын-кызлар тыз-быз килеп йөреп кенә торалар. Авырулар күренми, ял сәгатедер, аларга коридорга чыгып йөрергә ярамыйдыр, шәт. Хастаханәнең эче чиста, пөхтә күренә. Идәнне юып кына чыкканнар, кибәргә дә өлгермәгән. Борынга хлор, дару исләре килеп бәрелде. Якындагы бүлмәдән ак халатлы ханым күренүгә:

– Миңа врач кирәк иде, – диде Тәскирә, каушабрак.

– Бездә врач берәү генә түгел. Кем кирәк сезгә? – дип кызыксынды урта яшьләрдәге шәфкать туташы.

Беренче килгәндә, Наилен кабул иткән врачның исемен белми иде ана.

– Яшь кенә, чибәр генә иде ул. Бүгенгә чакырулы идек без.

– Кулыгызда документларыгыз бардыр бит?

– Юк шул, бүген килергә кушып җибәрделәр, – диде Тәскирә, кыюлана төшеп.

– Көтегез, – диде дә коридорның тәрәзәле ягына китеп, юкка да чыкты ак халатлы ханым.

Коридор бик озын икән, дип уйларга да өлгерми калды, икенче, тәрәзәсез яктан яшь кыз күренде.

– Врач кирәк иде миңа, – диде Тәскирә күп сөйләми генә.

Урыс кызы икән:

– Где ваше направление? – дип кызыксынды ул.

– Нету, – диде Тәскирә. – Нету шул.

– У нас обед, идите на улицу, ждите там, – диде яшь кыз. Хатынның чыгарга исәбендә юк икәнен шәйләп, Тәскирәне төрткәли үк башлады ак халатлы чибәр.

– Нет, – дип карышты Тәскирә.

– Дайте духтыр, – диде ул тавышын күтәреп.

– Какая вы наглая, апа, – диде кыз.

Марҗа күпме генә куып чыгарырга тырышса да, булдыра алмады – чыкмады Тәскирә.

Аларга әбәт кирәк, ашау тансык. Авылдан унбиш чакрым җәяү килеп, ярма бөртеге дә капмады әле ул, шулай да түзә. Түзми кая барсын? Баласын коткарырга кирәк аңа. Хәлен дә, каян килүен дә сорамадылар хет. Күңел өчен бер җылы сүз дә әйтмәделәр. Яхшы сүзнең изге гамәлгә тиң икәнен дә белми, күрәмсең, Гиппократ анты эчкән затлар. Талчыккан, тиргә батып, кызарып пешкән югыйсә Тәскирә. Күрергә теләмиләр дә, сукыр булып кыланалар. Дөньяда рәхимсезлек – кабер ташыннан да авыр, димәсләр иде.

Бик озак көткән кебек тоелды анага. Әллә бөтенләй туктап калдымы соң вакыт дигәннәре? Бу тәмуг кайчан гына бетәр икән?!

Менә, ниһаять, аңа баласы белән врач кабинетына үтәргә куштылар. Ана урамга атылып чыкты да улын җилтерәтеп арбадан күтәреп алды.

– Әйдә! Тиз! Йоклап ятма, чакыралар! – диде ул йокымсырап яткан улына.

Анның авырлыгын да сизми, очып дигәндәй, хастаханәгә керде. Улын идәнгә дә бастырмый, күтәргән уңайга врач кабинетына үтте.

– Где его карточка? – дип, карточка эзләде врач.

Беренче килгәндә, кабул итеп, чакырып калган врач юк иде шул.

– Ни тый духтыр, – диде белдекле кыланып ана.

– Я – врач! – диде яшь, мөлаем ир, елмаеп.

– Где татар духтыр, харошый?

– Я вам не нравлюсь что-ли, женщина? – дип көлде врач.

Малайны бастырып та, яткырып та карагандай итте ул. Анның кайчан, ничек чирләвен, җентекләп сорады. Ярый шәфкать туташы үзебезнең кеше булып чыкты. Врачның соруларын, Тәскирәнең җавапларын тәрҗемә итеп, аңлатып торды. Бүген алып кала алмыйбыз, урыннар юк, диделәр. Дәфтәр тутырып «история болезни» яздылар.

– Апа, правда, мест нет, мы бы рады вам помочь! – диде врач, кызганган кыяфәт чыгарып.

Кулыңнан килмәгәнне, телең белән сүз бирмә, диләр. Үзләре чакырды, алабыз, дип сүз биргән булдылар. Талымсыз колакка ни әйтсәң дә бара, дигәннәрдер.

– Нигә врачларга күрсәтми озак тоттыгыз, – дип ачуландыгыз бит үзегез, – дип тәкрарлады ана, елап. – Бу ни хәл бу, тагын кире борасыз!

Әмма куян елаганга карап, аучының күңеле йомшармас, дигәннәр. Ярдәм итәргә уенда юк, ахры, табибның. Врачларга үпкәсе зур иде Тәскирәнең – алдадылар. Үпкәләүне ачу белән, утны керосин белән басып булмас, шәфкатьсез елаганны да аямый.

– Үләргә генә калды, үләргә! – дип, улын күтәреп алды да елый-елый ишектән чыгып китте ана.

Алар бик арыган, йончыган иделәр. Шешәләрендә су да юк, ичмасам. Шешәне тоттырып, Тәскирә кызын хастаханәгә кертеп җибәрде.

– Пить хочу диген, кызым, шешәңне күрсәт!

Бераздан кызы тулы шешә күтәреп чыгып та җитте. Бөтенләй өметсез түгелләр икән әле, рәхмәт, су бирделәр, дип уйлап куйды Тәскирә.

Ана улын янә авылга алып кайтып китәргә теләмәде. Нәрсә булса да, алып кайту юк! Белеме булмаса да, баланы кичекмәстән дәваларга кирәген аңлый иде авыл хатыны. Төн чыгу да газапка әйләнде бит аларга. Температурасы да кайчак кырыкка җитә. Бүген дә алмасалар, баласының савыгуын көтәсе дә юк! Улын үлемгә дучар итү була! Шулай уйлады да җәймәсен ишек төбенә салып, улын шунда утыртып куйды ул.

– Ишектән кеше күренүгә кычкырып ела, улым. Ела, улым, ела, яме! Алар ишетерлек итеп: «Мама нет», – дип кычкырып ела. Курыкма, без сине ташлап китәргә җыенмыйбыз. Тик безнең монда икәнне сиздерә күрмә, – диде дә тиз-тиз генә Наиләсе белән арба тартып, бакчаның куе куаклары артына кереп яшеренде. Ишегалды уч төбендәгедәй аермачык булып күренеп тора. Берәрсе чыгар, чыкмый калмас, дип фикер йөртте ана. Баланы кызганырлар, төнгелеккә ишек төбендә калдырмаслар. Врачларның йөрәге таш түгелдер. Бераздан ишектә ак халатлы бер ханым күренде. Малай белән сөйләшеп алдылар. Сүзләре ишетелмәсә дә, улының елаганын шәйләде ана.

– Маладис, улым, – дип шатланып куйды ул.

Наилә генә:

– Кайчан кайтып китәбез инде, – дип тинтерәтә, йөдәтә башлады.

– Аз гына сабыр ит, кызым. Планнарыбыз барып чыкса, шәп була, – дип Наиләне юатты ул.

Ак халат, ай күрде, кояш алды дигәндәй, югалды. Ул да булмады, ишек төбенә өч-дүрт хатын-кыз чыгып басты. Болар да ак халаттан. Малай янында озак юанмадылар. Наил әнисе өйрәткәнне онытмый, кычкырып елый иде.


Улының: «Мама нет», – дигән сүзләрен аермачык ишеткәндәй булды Тәскирә. Булдыра улым, дип уйлады ул. Менә ишектә Наилне кабул иткән врач белән шәфкать туташы күренде. Врач малай белән сөйләшергә теләде, ахры. Кая ул сүз тыңлау, Наил кычкырып елый иде. «Мама нет» сүзләре дә Тәскирә колагына аермачык килеп ирешә. Озак көтәргә туры килмәде, санитарлар чыгып, малайны күтәреп алып кереп киттеләр. Ана белән кыз тиз генә куаклар артыннан чыгып, кача-поса, буш арбаны тартып кайтыр юлга чыкты. Тәскирә тыела алмый елый иде.

– Нигә елыйсың, елама, әни! Сөенергә кирәк, – диде кызы.

– «Мама нет», ди бит ул, балам. Тыйма мине... – диде Тәскирә.



*Татар әдәбияты классигы Шәриф Камал эш кабинетында укучы балаларны кабул итә. Быел, 80 еллап вакыт үткәч, әдип яшәгән йорт Татар китабы йорты дип игълан ителде. 1939 елны төшерелгән фото.*



*Язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Әнәс Хәсәнов.*




*Чуваш язучысы Евгений Турхан.*




*«Ялкын» журналы редакциясе Мамадыш районы Кече Сон мәктәбендә. Сулдан уңга: язучы Рашат Низами, мәктәпнең директор урынбасары Габделхак Мортазин, ВЛКСМның Мамадыш райкомы беренче секретаре Рәшит Вәлиев, журналның баш мөхәррире Роза Хафизова, шагыйрь Рафаэль Газизов, язучы, галим Җәвад Тәрҗеманов, язучы Хәйдәр Гайнетдинов. 1983 ел.*

## *Мөхәррир, әдәби тәрҗемәче, язучы-прозаик Кыям Миңлебаевның тууына 90 ел*



*Каләмдәшләр Кыям Миңлебаев (сулдан уңга), Вил Ганиев, Зиннур Мансуров «Мәдәни җомга» газетасы редакциясендә. 2003 ел.*



*Кыям Миңлебаев сынлы сәнгать әсәрләрен дә ярата иде.*



*Кыям Миңлебаев – микрофон алдында.*




*Теләче районы, Олы Мәтәскә авылындагы Фатих Хөсни музее. Язучылар Кыям Миңлебаев (сулда китапка култамга сала), Мөсәгыйт Хәбибуллин һәм музей директоры Гөлнур Вәлиева. 2000 ел.*

*Сәхифәне* **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** *әзерләде.*

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

# ТУГАН ҖИРНЕҢ БӘРӘКӘТЕ – КҮКРӘП ҮСКӘН ИГЕН КЫРЫНДА

ОЧЕРК

Казанда таң атып килә. Кояш нурлары машина тәрәзәсе аркылы үтеп йөземне җылыта. Рәхәт. Язгы кояшның яктысы да йомшаграк шул. Без бүген Мордовиягә, андагы милләттәшләребез янына кунакка юлга чыктык. Шәхсән үземнең бу якларга беренче баруым. Максатыбыз – Ләмбрә районының Аксёново авылы тормышы белән танышу. Ни хәлләрдә яшәп яталар икән, нинди гамьнәр аларда? Юлыбыз Сембер аша үтә. Республикабыздан читтә дә татар авылларының күплегенә таң калдым. Алар матурлыгы, төзеклеге белән сокландыра...

Көн төшкә авышканда, Мордовиягә килеп җитеп, Ләмбрә җирләренә аяк бастык. Аксёново авылы безне биек манаралы матур таш мәчете белән каршы алды. Әйтерсең биредә динле, иманлы халык яшәгәнлеген авыл башыннан ук искәртеп тора бу иман йорты. Авыл урамнарында татар рухы сизелә, ә җирле халык үзара «кардәш» дип сәламләшә. Татарстаннан йөзләрчә чакрым ераклыкта туган телне ишетүнең күңелдә нинди хисләр уятканын читкә чыгып карагач кына аңлыйсың икән. Аксёново авылын русчалатып, исемен үзгәртеп йөртсәләр дә, чынлыкта бу авылга Әхсән бабай нигез салган. Тирәнрәк тарихи чыганаклардан күренгәнчә, бу авылны Сөнбай исемле кеше нигезләгән дигән мәгълүмат та бар.

Тарих турында гәпләшкән арада Аксёново авылының күренекле эшмәкәре Рәфикъ Аяз улы Фәтхуллов безнең каршыга үзе килеп чыкты. Күрештек, хәл-әхвәл сораштык. Кайнар чәй белән пәрәмәчтән авыз иткәч, танышу киеренкелеге кимеде. Шуннан соң, Аксёново авыл җирлеге башлыгы Гайсә Җафар улы Йосыпов, безне Мәдәният йорты белән таныштырды. Аның диварларында татар халкының күренекле язучылары һәм галимнәренең портретлары урын алган. Бу күренеш тә күңел түренә матур гына кереп урнашты. Журналыбызның баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин һәм проза бүлеге мөхәррире Камил Кәримов авылның урта мәктәбенә очрашуга юл алдылар. Ә мин Рәфикъ Аяз улы белән авыл тормышы, Мордовиядәге татарларның яшәеше, киләчәккә нинди планнар корып яшәүләре турында сөйләшеп калдым.

Зур гына эш бүлмәсе тәрәзәсеннән авылның иген кырлары күренеп тора. Әлегә анда нindидер зур вакыйга алдыннан гына була торган тынлык. Өстеннән пар күтәрелгән кара туфракка тиздән бәрәкәтле орлык төшәр, һәм ул башак булып күккә омтылыр. Татар яшәеше турындагы сүзебез үзеннән-үзе иген, икмәк, зур уңыш серләре турында сөйләшүдән ялганып китте. Туган авылының җирләре, үзе җитәкләгән «Юлдаш» фермерлык хуҗалыгы турында сөйләгәндә, ни өчендер, Рәфикъ Аяз улының күзләре уйчанланып калды. Туган җире өчен шулкадәр борчылып, аның һәр аршыны хакына янып-көеп яши торган кеше икәнлеге күренеп тора. 2001 елда ул «Юлдаш» хуҗалыгын оештырып, анда атлар үрчетергә ниятли һәм Саранскига барып биш ат алып кайта. Бүгенге көндә биредә 500 баш ат бар. Ат җене кагылган дип, шундый кешеләр хакында әйтәләрдер инде ул.

Яңа гасыр башында илдә-көндә үзгәрешләр башлана. Бу үзгәрешләр авыл тормышына аеруча нык тәэсир ясый. Халыкка күпләп пай җирләре өләшәләр һәм озак та үтми аларны сатып ала башлыйлар. Шул чакта авыл халкы, туган туфрагын читләргә бирергә теләмичә, Рәфикъ Аяз улына тапшыра да инде. Атлар үрчетү белән беррәттән,



*Иген тавышын тыңлап... Сулдан икенче Рәфикъ Аяз улы Фәтхуллов.*

хуҗасыз җирләр булырга тиеш түгел дип, җиң сызганып кырларны да эшкәртү эшенә керешә Рәфикъ әфәнде. Туган җирен яратырга, кадерләргә ничек өйрәнде икән ул? Җирләрне карау, иген үстерү эше никадәр генә авыр булса да, ул бу эштән баш тартмый. Туган җир һәм туып-үскән нигез кебек төшенчәләр арткы планда калып, үзләренең кадерен җуйган чорда яшибез бит. Нилектән шундый хәлгә калып бара соң дөнья? Беребезне дә, әти-әнисе, туган туфрагыңны яратма, бу җирләрне кадерләмә, дип өйрәтми. Димәк, кешеләр, төрле авыр шартларга куелып, үз эшләренең кирәксезгә әйләнүе аркасында гына туган җирләрен калдырырга мәҗбүр була. Рәфикъ әфәндегә бу хактагы сорауларым белән мөрәҗәгать иткәч, ул һич икеләнүсез:

– Туган җиремне калдырып китү турында уйлап та караганым булмады. Ул хакта сүз кушып, әти-әни белән сөйләшкәнебезне дә хәтерләмим. Язылмаган канун буларак кабул ителгәндер инде ул. Әтием Аяз Хәсән улы Саранскига йөреп 50 ел буе приборлар ясау заводында хезмәт куйды. Әнием Зәйтүнә Зәкәрия кызы шулай ук Саранскида эшләде. Мәгәр алар авылны ташлап китү турында һичбер сүз кузгатмады. Безнең авыл Саранскидан егерме чакрым гына ераклыкта бит, шәһәрдә эшләп, авылда яшәү мөмкинлеге бар. Бәлки, авылыбыз сакланып калуның бер сәбәбе шулдыр.

Гаиләдә биш бала үстек – дүрт малай, бер кыз. Кечкенәдән бер-беребез белән дус-тату булдык. Урта мәктәпне тәмамлап, Калининград төбәгендә Кызыл Армия сафларында хезмәт иткәннән соң да, туган җиремә сагынып, ашкынып кайттым. Күрше Белозерье кызы Зәйтүнә белән кавышып, матур гына гаилә кордык. Аллага шөкер, бүген ике улыбыз Раушан һәм Дамир да үсеп буйга җиттеләр.

– Туганнарыгыз белән дуслыкның көчле булуы турында әйттегез. Аңлавымча, сез әле дә бер-берегезгә бик якын һәм бер-берегезгә терәк булып яшисез...

– Безнең дошманлашып йөрергә, сүзгә килергә вакытыбыз юк иде, чөнки иртәдән кичкә кадәр эштә булдык. Эштәге кешенең кирәкмәгән нәрсәләргә вакыты калмый. Үзем өчен дә балаларны кечкенәдән эш белән үстерүне төп максат итеп куйдым. Хәзер барыбыз да биш вакыт намазда, әлхәмдүлилләһ. Әнием ягыннан Ибрай бабаем мулла булган, авыл мәдрәсәсендә дини сабаклар укыткан. Димәк, Ислам дине безнең нәсел тамырларында ук бар.

Бу урында, авылга кергәндә, безне каршы алган мәчет күз алдына килә. Аның төзелешенә дә зур өлеш керткән Рәфикъ Аяз улы. Авылларында өч мәчет бар һәм аларның ишекләре һәрчак ачык. Мөнбәрләреннән намазга чакырып, көненә биш

тапкыр моңлы азан яңгырый. Мәчетләргә халык күп йөри. Бик матур итеп, тәравих намазлары, ифтар ашлары, Мәүлид бәйрәмнәре уздыралар икән.

Авылларындагы мәдәният йортында да тормыш кайный. Бүгенге көндә Саранскида төбәк дәрәҗәсендә уздырылучы «Авылым тавышлары» дигән җыр бәйгесе дә Рәфикъ әфәнденең башлангычы белән оештырылган. Узганында барлыгы 250 бала чыгыш ясаган. Сәләтле балаларга ярдәм һәм зур этәргеч булган әлеге чара быел унынчы тапкыр үткәрелә. Татарның рухи байлыгы онытылмасын, авыл моңнары яңа буыннарга да барып ирешсен өчен тырышып йөрүләре юкка түгел. Үз эшләренең нәтиҗәләрен күреп сөенә бүген Әхсән (авылның исемен ни өчендер нәкъ менә шулай – дөресләп язасым килә) авылы халкы. Мәктәпләрендә дә татар мохите яши. Татар теле һәм әдәбияты укытыла. Сабантуйны да уздырмыйча калганнары юк. Быел Әхсән авылына нигез салынуга 350 ел тула икән. Шул уңайдан бик зурлап, Сабантуй бәйрәмен уздырырга әзерләнәләр.

Уңышлар турында сөйләшеп утыру бик күңелле. Барысы да шулай җайлы һәм шома гына алга бара аламы, әллә бер генә каршылык та очрамыймы мондагы татарларга, дигән уй үзеннән-үзе күңелне борчый. Тормыштагы бихисап мисаллар шулай уйларга мәҗбүр итә һәм аерым калыпларга буйсындыра.

– Әлбәттә, проблемалар бар һәм алар күп. Ни өчен дигәндә, авыл хуҗалыгы гомер-гомергә иң күп хезмәт көче таләп ителгән өлкә. Анда эшләү шартлары авыр. Безнең табигать шартлары авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәрен аеруча сыный. Табигать тарафыннан бер сыналсак, уңышны җыйганнан соң икенче сынау башлана. Җыеп алган икмәкне урнаштырырга да кирәк бит. Ә авыл хуҗалыгы товарларына бәяләрне үзегез беләсез. Кыскасы, бу өлкә үзен-үзе берничек тә акламый. Монда күп вакыт табышка эшләмисең, дигән сүз. Шуңа да яшьләр авыл җирендә калырга теләми. Алар шәһәргә китеп, матур киенеп, тыныч кына ял итеп йөрүне өстенрәк күрә. Ә инде түләү дә тиешле дәрәҗәдә булмаса, аларны эшләтү мөмкин түгел. Авыл хуҗалыгы үсештә булсын өчен дәүләт ярдәме бик кирәк. Көнбатыш тәҗрибәләрен күзәтеп барырга тырышам. Анда авыл хуҗалыгы 50% ка дотацияләнә. Бәлки якын киләчәктә безгә дә караш үзгәрер, катлаулы проблемалар белән күзгә-күз калмабыз, дип өметләнеп яшибез.

Бүгенге көндә авыл җирендә хезмәт куйганнарны үзара берләштереп, корпорацияләр төзү хакында да фикерләр ишетелә башлады. Дәүләт башлангычы белән махсус контроль астында узачак ул. Рәфикъ Аяз улының бу җәһәттән үз фикере бар:

– 2017 елның сентябрь аенда «Татар бизнесменнары» исемле клуб оештырдык. Бүгенгә кырык кеше берләштек. Кайсыларыбыз сату-алу, кайсыларыбыз җитештерү белән шөгыльләнә. Һәр атнаның сишәмбесендә әлеге клубны оештыручы 12 эшмәкәр очрашып төрле мәсьәләрне хәл итәбез. Берләшеп, бер-беребезнең ихтыяҗларын исәпкә алып эшлибез. Мәсәлән, кошчылык фабрикасы хуҗасына күпләп сатып алыр өчен бодай кирәк, мин шуңа да алдан сөйләшеп, җирләрнең күп өлешенә әлеге культураны чәчәм. Ул да сыйфатлы ашлык эзләп йөрми, авыл кырында кирәкле бодай үскәнен белеп тора. Мондый берләшүгә мин бер дә каршы түгел, киресенчә, уңай карыйм. Без бу юнәлештә алдан күреп эш башлаганбыз инде, димәк.

– Алга таба нинди ният-максатлар белән яшисез?

– Мин Аллага шөкер, дип яшим. Тормыш алга бара, узган гомер белән бергә тормыш тәҗрибәсе дә килә. Шушы тәҗрибәне яшьләргә биреп калдырасы килә. Улларыбызга да һәрчак бердәм булып яшәргә кирәклекне төшендерәм, үз тәҗрибәмне өйрәтәм. Алар да сынатмаслар, мәгънәле итеп яшәрләр, дип өметләнәм. Алга таба да шулай матур гына яшәргә һәм эшебезне үстерергә язсын.

...Биек манаралы мәчетләре белән әллә кайдан ук балкып торган зур татар авылларын күреп, сокланып кайттык бу сәфәрдән. Кояш та көне буе безгә елмаеп кына торды. Ә Мордовиядә яшәүче милләттәшләребез Казанга һәм халкыбызга күп итеп сәлам әйтеп калдылар.

**Айсылу ИМАМИЕВА**

# ОШБУ ҖИҺАНДА ЯКТЫ ЮЛ...

ОЧЕРК

Күл астында калган тарих телгә килсә, ниләр сөйләр иде икән?.. Татар халкының өлешенә тигән көмеш, шул күлләрне аралап, гөл булып баш калкытыр идеме икән? Таҗларына шәфәкъ алсулыгы, йә булмаса кан кызыллыгы ягылган гөл булып... Дәверләр кичкәндә, калалар, салалар җир йөзеннән юкка чыккан, китаплар яндырылган, бәндәләр мәңгелеккә күчкән; мәчет-мәдрәсәләр юк ителгән, зар тулы ыңгырашу авазын яңгыратып, манаралар гөрселдәп ауган; тулы бер халыкның үткәнен һәм киләчәген, шуның белән бергә иң абруйлы, гыйлемле затларын оныттыру өчен берсеннән-берсе кансыз кануннар эшкә җигелгән. Әмма Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән хәтер дә исән, иман да исән... Татар халкының яшәү рәвеше элек-электән шәригать кануннары буенча тәртипкә салынган. Ислам дине гомер бакый аның рухи терәге, көче, таянычы булган. Шуңа күрә дә халыкны тезләндерү, аннан кол ясау өчен гасырлар дәвамында бәгыреннән нәкъ менә иманны кубарып алырга омтылганнар да инде. Еллар каланчасыннан үткәннәргә күз салсаң, җан калтыранып куя. Һәр гасырның үз елъязмасы... Явыз Иван Казанны басып алганнан соң, утларда дөрләп янган Коръән китаплары. Җимерелгән, ташлары чиркәү-монастырьларга нигез булып яткан мәчетләр. Чукындыру афәтенә эләккән авыллар. Иманын саклау бәрабәренә туган төягеннән чыгып качарга мәҗбүр булган ир-егетләр, хатын-кызлар, балалар... XVIII гасыр исә – татар мәчетләрен указлар яза-яза җимерү чоры. «Мөселман муллаларында гаеп табып, аларны кызганмыйча җәзаларга, мөселман санын киметү нисбәтеннән аларны Уфа һәм Казан өязләреннән сөргенгә сөрергә. Мөселман руханиларын мәчет-мәктәпләрдән алып, гарәп-фарсы телләреннән тылмач итеп, халыктан аерсак, тагын да яхшырак булыр». Бу – XVIII гасырның утызынчы елларында Оренбург комиссиясенең беренче җитәкчесе булган И.К. Кириллов сүзләре... Тарих тәгәрмәче гел бертөсле әйләнә, диярсең... XX гасырның кызыл инкыйлабы дин һәм иман төшенчәсенә тагын да аяусызрак кизәнү белән кизәнә: «Дин – әфьюн. Алла – юк». Атеизм чәчәк аткан бу чорда кешенең баш миенә туктаусыз чүкеп торган әлеге гыйбарәләр кемнәрне генә саташтырмаган да кемнәрне генә адаштырмаган... Авызыңны ачып бисмилла дип тел тибрәтергә дә хакың юк заман... Беренче сыйныф укучысы, дәфтәренә язгыш: «Сара су алла», – дип язгач, укытучының: «Күрсәтермен мин сиңа Алланы!» – дип баланың бармакларын төйгән еллар... Нәсел-нәсәбе белән Себер далаларына, Урал тау итәкләренә сөрелгән, атылган, асылган иманлы затларның рухы мең иңрәү булып күкләр катына ашканда, җирдә калганнарга ярлыкау сорагандыр... Шулай булмаса, инде тәмам өзелә дигән чылбырларны гына түгел, өметләрне өметкә ялгап, XX йөзнең туксанынчы елларында татар илендә манара булып Иман калкыр идеме?.. Бу сүземә, «Татар күңеленнән иманның югалганы да булмады», – дип каршы төшүчеләр дә табылыр. Өлешчә килешәм. Тәрәзә пәрдәләрен көн күзеннән түгел, адәм күзеннән яшереп, сәхәргә торган, караңгы базларга төшеп булса да, биш вакыт намазын укырга омтылган, нарасый балаларның күңеленә мөнәҗәт-бәетләр, «әлеппитиси»ләр белән булса да, иман орлыгы салырга тырышкан әбекәйләр-бабайлар күңелендә барысына да урын табылгандыр.

***

*«Аллаһы Тәгалә – сабырлык итүчеләр белән»*
«Бәкара», 249 нчы аять

Чаллы шәһәренең имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфулла турында язарга, дип кулыма каләм алдым да уйларым, миңа буйсынмыйча, әллә кая китте дә барды... Аның вәгазьләрен генә түгел, гади генә әңгәмәсен тыңлап утыру да үзе бер җан

рәхәте: күңел сафланып кала, үтелгән юлыңа борылып карыйсың. Ул юлларда тормышыңны гына түгел, әллә нинди ерак тарихны да күреп алырга өлгерәсең: халык, милләт язмышын... Егерме ел дәвамында әлеге гаять җаваплы, алай гына да түгел, четерекле, катлаулы вазифаны башкарганда, Аллаһы Тәгалә аңа сабырлыкны өеп бирмәсә, бүген килеп эшләнгән эшләр, якты ниятләр турында сөйләшер идек микән? Сүз уңаеннан шунысын да әйтеп куйыйм әле: бу язмада «сабырлык» сүзе еш кабатланыр. Әлфәс хәзрәтне якыннан белгәннәр барысы беравыздан иң элек аның нәкъ менә шушы сыйфатын ассызыклый. «Сабыр ул!» Башкаларны сабырлыкка чакырыр, гомумән, аларга киңәш бирер, яхшы гамәлләргә, асыл сыйфатларга өндәр өчен ул гамәлләрне иң беренче чиратта үзең башкару һәм аларны үзеңдә булдыру мөһим. Бер риваять кайберәүләргә яхшы таныштыр. Җомга вәгазеннән соң Әбү Хәнифә янына бер кол килә дә үзенең үтенечен җиткерә: «Әй имам, вәгазьләреңнең берсендә колны азат итүнең фазыйләтләре турында сөйләсәң иде. Шуны тыңлап, хуҗам мине азат итмәсме?» Шул вәгазьне ишетергә теләп, кол икенче атнада да килә, өченче, дүртенче атнада да... Бишенче килүендә генә үзе теләгән вәгазьне ишеткәч, аптырап, Әбү Хәнифәдән сорый: «Әй имам, мин синнән әллә кайчан үтенгән идем бит. Ни сәбәпле шулай көттерергә булдың?» «Син сораганда, минем үземнең колым юк иде. Базардан кол сатып алдым, аны азат иттем – менә шуннан соң гына әлеге вәгазьне сөйләргә булдым. Үзем кылмаган гамәл хакында сөйли алмый идем бит инде мин», – дип җаваплый Әбү Хәнифә.

Әлфәс хәзрәтнең дә вәгазьләрендә үзенең тормыш кыйбласы, тәҗрибәсе, холык-фигыле, балачактан күңелгә сеңеп калган сабаклары.

...Әрәмәлек кул сузымында гына, туп-турыга теркелдисең дә Зәй елгасының сай җиреннән теге якка чыгасың. Шомырт җыясыңмы, бөрлегәнме – анысы синең эш. Тик бүген аяклар сөйрәлебрәк бара әле, ник дисәң, җәй эссесе дип тормыйча, салкын тигән. Апасы маңгайга кул тидереп караса, шундук өйгә кире борып җибәрергә дә күп сорамас анысы. Юк инде, авырыйм дип, җыйнаулашып барган шундый рәхәт сәяхәттән мәхрүм каласы юк Әлфәснең... Алты-җиде яшьтә генә булса да, егет-малайларның сер бирмәскә тиешлеген белмиме әллә?.. Әрәмәдә көннең кызулыгына изрәп йөри торгач, дусты Рафаэль белән ялт кына су коенып килергә булды алар.

– Карагыз аны, елганың кай җиреннән чыктык – шунда гына коеныгыз. Анда сай, – диде апасы, малайларны кат-кат кисәтеп.

Һай, елга да тормыш дәрьясыннан һич ким түгел шул: аның да сине бишектәгедәй генә тибрәткән салмак дулкыннары, күзгә күренгән-күренмәгән ярлары, упкын-чоңгыллары бар. Агымга каршы йөзәсеңме син, агым уңаенамы – кай мәлдә ни рәвешле бөтереп аласын башыңа да китермисең... Йөзә торгач, шактый тирән җиргә тап булганын сизми дә калды малай. Басып карыйм, дисә, бөтен гәүдәне кумәрлек. Агым һаман-һаман эчкә сөйри, үзенә тарта. Болай да иртәдән бирле хәлсезлектән тинтерәгән тән бөтенләй көчсезләнгән шикелле. Йөзә белү онытылды, курку хисеннән гайре берни калмаган, диярсең. Кычкырган шәйгә үзенә таба йөзә башлаган Рафаэльне күргәч, баш миенә аек акыл йөгерде: «Килмә!» – диде ул иптәшенә, икәү бергә харап буласыларын мизгел эчендә күзаллап. Ул мизгел... Әле сабый гына булган малайның уч төбенә сыеп бетәрдәй гомер юлын тулаем күз алдыннан үткәрергә мөмкинлек биргән мизгел... Инде «беттем» дигәндә, кире якка сөйрәгән агымны җиңеп, ниндидер могҗизалы көчнең кодрәтенә буйсынып, ярга аяк баскан мәл... Ул чагында сабый акылы белән әлеге вакыйгадан артык зур мәгънә эзләп маташмагандыр. Ә менә бүген, еллар аша шул көнгә күз салганда, Әлфәс хәзрәт күңел дәфтәренә гомерлеккә язып куйган сабакны кат-кат искә төшерә: *кая кергәнеңне чамала! Йөзә беләм, дип масайма! Акыл белән үлчәп кара! Сабыр бул!*

...«Сабыр бул!» Монысы – Гөлҗамал әбисенең сабагы. Алты бала үскән йортта аның «дәресләре» ни өчен нәкъ менә Әлфәскә эләккәндер... Күңелендә – иман нурын, телендә – «Аллаһ» сүзен кырык кат йозак астында тотарга мәҗбүр әбекәйләр барыбер, ни рәвешле генә булса да, шул хәзинәне оныклар белән бүлешергә җай тапканнар бит! Рамазан айларында сәхәргә уятып, тәмле кәнфитләр, җимешләр белән кызыктырып булса да... Пәйгамбәрләр тарихын мавыгулы бер әкият итеп сөйләргә тырышып

та... Коръән аятьләрен ятлатып, кунакка кергән әбекәйләр алдында сөйләтеп, «менә булдырасың, улым», дип күчтәнәчләр белән юмалап булса да... Гөлҗамал әбине ул чор әбекәйләренең җыелма бер образы итеп күзаллыйм: чәчләрен ияк астыннан бәйләнгән ак яулыгы астына яшереп куяр, сөйләшкәндә, шул яулыгының очы белән авызын каплый төшәр; «бүтән кешегә сөйләмә, үземә генә укып күрсәт», – дип, «раббанә-әәәтинә...» догаларын ятлатыр; «әлеппитиси» сыйфатында булса да, гарәп алфавитын өйрәтеп калдырырга тырышыр. Чормада саклаган китаплары турында: «Алып төшә күрмәгез! Ул китапларга тия күрмәгез!» – дип ут йотар. Йотмас иде дә, андый китапларны учак-учак итеп өеп яндырган еллар кул сузымында гына шул, кайтавазы онытылмаган... Аллаһының кодрәте киң: менә шушы оныклар күңеленә тамчы-тамчы сеңдергәннәр берзаман шытым бирер, гөлбакча булып чәчәк атар. Әлегә сабыр итәргә генә кала.

Иреннәрен селкетер-селкетмәс кенә мөнәҗәт әйткән әбекәйләр дә барысы бер сүз сөйли төсле. Хикмәт белән, матур әдәп-әхлак кагыйдәләре аша алар иңдергән сабаклар – киләчәкнең нигез ташлары булган да инде. *Гадел бул! Кешелекле бул! Ярдәмчел бул! Изге гамәлле бул!*

***

«Кешелекле ул». Әлфәс хәзрәтне гап-гади кеше буларак бәяләүчеләр авызыннан икенче булып әнә шундый билгеләмә яңгырый. Бу сыйфатның да төбе-тамыры Каф тавы артында түгел... дидем дә, үзем үк елмаеп куйдым. Сүз дә юк, чишмә башы – һаман да шул ак күңелле әбекәйләрдә, туган туфракта, туган нигездә. Зәй районының Аксар авылына юлым төшкәне булмаса да, аның һәр урамына, һәр йортына шул аклыкның нуры ягылып калгандыр кебек тоела миңа. Нәбиулла агай белән Кәшфия апаның алты балалы гаиләсендә исеменә үк матурлык сыенган акъәби яшәсен дә, аның кул астында тәрбияләнгән балалар кешелекле булмасын, имеш...

Каф тавы артына килгәндә исә... Армия хезмәтенә алынган Әлфәснең Кавказга барып эләгүе – балачакта әллә уйнап, әллә уйлап теләгән теләкләрнең кабул булуымы? Фәрештәләрнең «амин» дигән сәгатенә туры килүеме?.. Мәктәптә укыганда, укытучы инша язарга кушкач, хыял болытында йөзепме, күңел таләбе буенчамы, «танкист булам» дип язган иде. Дөрес, «ул бит профессия түгел», – дип, бик тиз җиргә тартып төшерделәр төшерүен. Ә менә армиягә алынгач, Грузиядә ярты ел танкистлар мәктәбендә укып, чыннан да тимер атны иярләргә туры килә бит үзенә. Өйрәнүләрдән соң Әрмәнстанның Ленинакан шәһәрендә хезмәтне дәвам итү – гамәлләр белән сыналу чоры. Чыдамлыкка. Дуслыкка. Тугрылыкка. Кешелекле булуга.... Төркия чигендә булгангамы, таләпләр аеруча кырыс. Тауларда кар өстендә палатка белән кунулар, танклар батып калса, җәяү атлаулар – болар барысы да баштан уза. Беркөнне алда көткән авырлыкларны үлчәп бетермичә, «сәфәргә» кузгалулары аздан гына аянычлы хәл белән тәгәлләнми кала. «Таулардан да гүзәл таулар гына була ала», – дисәләр дә, бу минутларда шагыйранә матурлыкка иләсләнеп торырдай түгел: инде икенче төнгә кереп барулары – солдатларның ялга туктаганнары, җылы ризык ашаганнары юк. Тәмам хәлдән таеп, арып-талып, туңып беткәннәр, өстәге киемнәр бозланып каткан, аяк атлар хәлләре калмаган. Ниһаять, ялга туктау бәхете тигәч, барлап карасалар – өч солдат юк. Берәүнең дә селкенәсе килми, шулай да, эзли торгач, ике солдатны, артта калып, ял итеп утырган җирләреннән табып алалар. Өченчесе, су төбенә төшеп югалган балта, диярсең. Бу ЧП турында белеп алсалармы... Командирның: «Эзләргә кемнәр бара?» – дигән соравына тып итеп сикереп чыгучы гына күренми. Нәкъ башкалар кебек үк арыган, нәкъ башкалар кебек үк туңган Әлфәс Гайфуллинның: «Мин!» – дип алга атлавы ул чагында үзе өчен һич кенә дә батырлык булып тоелмагандыр. Югалган солдатны – азәрбайҗан егетен ярыйсы гына яхшы белә, дусларча аралашалар. Бу минутта вакытны сузу аның гомере бәрабәренә булырга мөмкин – карлы таулар гүзәл генә түгел, кирәгеннән артык кырыс та була бит... Шуны аңлау көч биргәнме? Эчке бер сиземләүгә буйсынганмы?.. Каралып күренгән һәр ташны капшап барлый торгач, кар өстендә йоклап яткан солдатка юлыгуы үзе бер могҗизага тиң. Тәнен тәмам суык алган егетнең селкенер чамасы да калмаган – сөйрәп диярлек алып кайтырга туры

килә үзен. Әгәр минутлар, сәгатьләр югалган булса, алар белән бергә кеше гомере дә югалыр иде...

Бу вакыйга командирның рәхмәт сүзе белән генә түгел, үз сабагы белән күңел түрендә: *авырлыкның күзенә туры карап атла! Кулыңнан килгәнчә ярдәм ит! Кешелекле бул!*

***

Теләкләрне ишетүче, кабул кылучы, кыл өстендә калган гомерләрне дә үз могҗизасы белән коткаручы барлыгына тормыш үзе ышандырып тора. Күр инде: һаман да шул балачакка гына борылып карасаң да... «Төзүче булачакмын, йортлар төзергә яратам», – дигән уй-хыялларның бик тиздән чынга ашуын ничек аңлатырсың?! Мәктәпне тәмамлап, Түбән Камага электрослесарьлыкка укырга кергәч тә, армиядән кайтып, Зәйнең «Гидромонтаж» оешмасына эшкә урнашкач та, егет кешегә җитмеш төрле һөнәр аз, дигәнне раслагандай, һөнәр өстенә һөнәр өстәлә тора. Норильскида металлургия заводы төзелешенә китәргә җай чыккач, монтажник булып эшләгәндә, анысы да шактый саллы тормыш тәҗрибәсен баета. Чебен-черки явы түгел, Себернең яшьләр күңеленә бер дә хуш килмәгән – спортзалы да булмаган Кайеркан посёлогы романтик ашкынуларга бик тиз чик куйса да, анда эшләү дәвере – рухны тагын да чыныктырган бер баскыч.

Чаллының яшьләр шәһәре, гигант төзелеш ватаны булып халык теленә кергән чагы. Шуңа күрә сукмакларның бирегә алып килүенә гаҗәпләнергә кирәкми. КамАЗда эшләгән елларның, авырлыгы белән бергә, сагынып сөйләрлек үз матурлыгы, үз табышлары бар. Шушы кала Әлфәскә үзенең пар канатын – күрше авыл кызы Рәфисәне очратырга, алай гына да түгел, чәчләрен чәчкә бәйләргә мөмкинлек бирә. Шушы калада, бер-бер артлы ике кызлары туа. Завод системасында эшләгән җиреннән ир-егетнең янгын сүндерү частена китеп баруына иптәшләренең күбесе аптырый: ни өчен, нигә, ни калган... Ә бит һәр адым – Аллаһка якынаю юлы булган... ЗЯБ бистәсендә биш катлы йортның подвалында янгын дигән хәбәрне алып, анда барып җиткәндә, инде башка частьлар килгән, ут белән көрәшәләр. Подвалда газ баллоннары бар, кичекмәстән шуларны эзләп табарга, утны сүндерергә кирәк, дигән боерык бирелгән. Баллонның берсен табып чыгаргач, янә кара төтен эченә кереп китәләр. Беркадәр вакыт узганнан соң, Әлфәс акваланагында кислород бетә башлаганын сизеп, янындагыларга ишарә белән шул хакта хәбәр итмәкче була. Тик анда, үч иткәндәй, һәр ымнан аңлашырга күнеккән үзенекеләр түгел, башка частьтагылар. Күңелгә шом йөгерә. Нәкъ сабый чакта елга чоңгылына эләккән мәлдәге кебек... Ярый әле кулдагы шланга буйлап хәрәкәт итә торгач, кечкенә генә тәрәзә янына килеп җитәргә җай табыла...

Соңыннан, кул яссуыннан аз гына олырак шушы тәрәзә янына килеп, күпме генә уйланмасын – калын кием белән ничек сыйганына, ничек шуышып чыкканына һич кенә дә төшенә алмый ул. Нинди көч, нинди могҗиза аның гомерен саклап калган? Сорауларга җавап табар юлны Аллаһ үзе күрсәтә... Тормышның һәр борылышы – бары тик Аллаһы Тәгаләнең теләге, кодрәте белән генә! Ул белүче, ул ишетүче, ул күрүче, ул хикмәт иясе!.. *Шуны аңлый бел, адәм баласы! Гыйлемгә омтыл!*

***

*«Дөреслектә, мин сине (Ибраһимны) адәмнәргә имам итеп кылмакчымын»*

«Бәкара», 124 нче аять

Туксанынчы еллар – милли күтәрелеш чоры, яңа мөмкинлекләр, сүз ирекe, сәүдә ирекe туган еллар. Бизнес өлкәсенә кереп киткән ир-егетнең сукмагында Хәлвәтдин хәзрәтнең очравы да очраклы гына түгел. Эшмәкәр егетләрдән мәчет төзелешенә ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән мәлдә, кем кемнең ярдәменә ныграк мохтаҗ икәнен белүче дә бер Аллаһ кына... Төзелеш материаллары, кирәк-яраклар белән булышкалап йөргән чагында намаз дигән могҗиза, аннан якшәмбе мәктәпләре белән танышу күңелдәге уйны көннәрдән бер көнне какшамаслык итеп ныгытып куя да инде: «Минем урыным

монда. Мин укырга тиеш!» Инде ир уртасы булып килгәндә, мәдрәсәдә торып уку, элек әбекәйләрнең тез өстенә куйган китапларыннан чуар бер бизәк булып кына күренгән хәрефләрдән сүзләр, җөмләләр оештырырга өйрәнү, дин гыйлеме алу – энә белән кое казудан да кыенрак буласын чамалый анысы. Тик максат куелган, үҗәтлек бар, дөньяның агын-карасын аеру бар, ахирәтне уйлап, бизмәнгә салып карау бар... Моңа тиклем юлдаш булып килгән дөньяви белем дә, һөнәрләр дә, холыкны формалаштырган сабырлык, кешелеклелек кебек сыйфатлар да менә кайчан ныклап таяну ноктасына әйләнә! 1993 елда Чаллының 48 нче бистәсендә өр-яңа мәчетнең тәүге субайларын кагып, төзелеш башлап җибәргәндә, боларның барысының да ничек кенә кирәге чыга әле! Авыр еллар, буталчык еллар. Җитмәсә, заводта булган зур янгын – шәһәр халкын, оешмаларны, эшмәкәрләрне ярык тагарак янында утыртып калдырган еллар. «Булышырбыз, төзелештә ярдәмнән калдырмабыз», дигәннәрне дә вәгъдәләрен онытырга мәҗбүр иткән еллар...

Күренекле шагыйребез Равил Фәйзуллинның: «Җаныңныңваклыгын сылтама заманга...» дигән шигъри юлларын беренче тапкыр гына мисал итеп китерүем түгел. Алга якты һәм игелекле максатлар куелганда, чорның нинди булуына карамастан, Аллаһы Тәгалә ярдәменнән беркайчан да ташламый... Үтсен, биек манарасын калкытып, «Нур-Ихлас» мәчете сафка басканчы унбер ел үтсен; халык гает намазын булачак мәчетнең ишегалдында ап-ак карга тезләнеп укысын – күңелдә иман һәм ышаныч булганда, мондый гына авырлыклардан артка чигенмисең инде. Ул авырлыкларны җиңү юлында күпме сабырлык, күпме эзләнү таләп ителгәнен эш башында торганнар үзләре генә белә.

Шәһәрнең бишенче мәхәлләсе оешкач, шунда имам-хатыйб итеп билгеләнгән Әлфәс хәзрәткә 1999 елда, «вакытлыча, бер елга имам-мөхтәсиб булып тор», – дип, тагын да җаваплы вазифа тапшыралар. Ул «бер ел» инде менә егерме елга сузылган. Үз-үзенә дә, башкаларга да таләпчәнлек, шул ук вакытта һичкемгә беркайчан күтәрелеп бәрелмәү, сабырлык, кешелеклелек, зирәк белем – Әлфәс хәзрәтнең үз абруен гына түгел, Чаллы мөхтәсибәтенең, мөхтәсибәт карамагындагы 14 мәхәлләнең, шәһәр мөселманнарының да дәрәҗәсен күтәрүче төп сыйфатлар.

ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Чаллы мөхтәсибәте үзенең эш тәҗрибәсе белән бик күпләргә үрнәк булып тора. Мөхтәсибәт тарафыннан башкарылган эшләрне күз уңыннан уздырган мәлдә, бер уй сызылып үтте: халыкның рухын, милли үзаңын уяту өчен, сәяси мөнбәрләрдән сөйләнгән сүзләргә караганда, менә шундый чын үрнәкләр күпкә отышлырак лабаса... «Ак мәчет» мәдрәсәсендә ел саен никадәр кешегә асыл белем бирелә! Мөхтәсибәт каршында эшләп килүче «Хәзинә» мөселман балалар клубында никадәр сабый күңеле иман нуры белән өртелә! Яшьләр бүлегендәге мөселман егетләренең төрле спорт чараларын гөрләтеп уздырулары күз алдында. «Ихсан» хәйрия фондының эшчәнлеге нәтиҗәсендә никадәр кешегә – ятимнәргә, мохтаҗ гаиләләргә, картларга, балалар йортларына ярдәм күрсәтелә! «Хәят» мөслимәләр оешмасына, «Мәрхәмәтле ярдәм» гаилә кору үзәгенә кемнәр генә мөрәҗәгать итми... Мөселманнар өчен уздырылган татарча көрәш һәм кул көрәше турнирлары егетләргә олуг хаҗга юллама белән бүләкләнү мөмкинлеге бирә. Балалар өчен ел саен уздырылган рәсәйкүләм Коръән уку бәйгесе турында аерым язма әзерләргә мөмкин: 3 яшьтән 15 яшькәчә малайлар һәм кызлар арасында коръәнхафизлар да күреп, күзләрдән яшь килер дәрәҗәдә ихласлык һәм тәкъвалык бәйгесе икәненә инанасың... Дини йолаларны үтәргә булышу, милли гореф-гадәтләребезне саклап калу өчен башкарылган эшләрне дә берәм-берәм саный башласак... кул бармаклары гына җитмәс. Иң мөһимнәренең берсе – мөхтәсибәт тырышлыгы нәтиҗәсендә шәһәр халкы хәләл ризыкның ни-нәрсә икәненә аек күз белән карый башлады, хәләл ризык җитештерүче оешмалар барлыкка килде. Бу юнәлешләрнең бер урында таптанмавына, алга китешенә, эшләп торуына ирешер өчен имам-мөхтәсибтән җитәкче генә түгел, оста психолог булу да таләп ителәдер, мөгаен...

*– Имамнар психолог булырга тиеш тә. Аның өчен махсус укымасаң да, тәҗрибә белән килә ул. Халык белән сөйләшергә өйрәнү, хикмәт белән чакыру кирәк. Имам – алда торучы, ияртүче бит ул. Мәсәлән, берәр мәҗлескә чакырдылар ди. Кайчагында*

*шулай да була: хәзрәт килә, аның тиз генә укып бетерүен көтеп утыралар, тиз генә дога кылсын да шуның белән шул... Мондый очракларда да ачкыч табыла: «Мин бит сезгә ирештермәсәм, Аллаһы Тәгалә каршында җавап бирәчәкмен. Менә шунда бардың – нишләп аңлатмадың, диячәк бит Аллаһы Тәгалә», – дип, барыбер сөйлисең вәгазеңне. Аннан үзләре үк кызыксынып сорау бирә башлыйлар... Аллаһының тәкъдиреннән узып булмаганны аңлау кирәк, безнең үзебездән генә тормаганны аңлау кирәк. Аллаһтан килдек – Аллаһка кайтачакбыз. Аллаһ безгә хәерлесен тели. Менә шуны аңлау гамәлләребезне дөрес итеп алып барырга, дөрес бәя бирергә ярдәм итә. Мине нәрсә сөендерә, дисезме? – Үтелгән юлларга борылып карагач, нинди зур проблемаларны чишкәнне, нинди авырлыкларны җиңгәнне күрү сөендерә. Бүген дә җиңел түгел, әмма эшләгән эшнең нәтиҗәсен күреп сөенәбез. Күңел төшкән, бик авыр мәлләр дә булган бит – сынмаганбыз, һаман алга барганбыз. Иманлы кешеләр артканны күреп тә, балаларда үз өлешебезне күреп тә сөенәм. Нәрсә көендерә, дигәндә – бик күпләрнең әле намазда булмавын, үзләрен мәңгелек җәннәттән мәхрүм итүләрен белү көендерә. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйткән бит: «Үзеңә теләгәнне башкаларга да теләмичә, хакыйкый мөселман булмассың», – дигән. Сөйләп, аңлатып карыйбыз, «ярар, ярар» диюдән узмаучылар бар...*

***

*«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар»*
Коръәни-Кәрим, «Бәкара», 256 нчы аять

Аллаһы Тәгалә җир йөзендә халыкларны кавем-кавем итеп яралткан. Аларның ак тәнлеләре бар, кара, сары тәнлеләре... Һәрберсенең үз теле, милләте бар... Ул милләтләрнең бүгенгәчә яшәп килгәне, бөтенләй юкка чыкканы бар... Гаяз Исхакыйның: «Әүвәл әхлак бозыла, икенче – дин бетә, өченчедән, ул халык үзе бетә», – дигән мәгълүм гыйбарәсе күпләргә таныш. Бай тарихлы халкыбызга мондый инкыйраз янамый, дип кистереп әйтә алабызмы? Гасырлар кичеп, утта-суда сыналып, чыныгып исән калган милләтнең ни өчен бүген килеп туган теле, киләчәге – шул киләчәк дигән сүзгә нисбәттән, үткәне, бүгенгесе, әдәбияты, мәдәнияте кыл өстендә? Бу сорауга гадидән дә гади генә итеп җавап табып булыр иде микән?..

– Балаларыбызны Ислам диненә, әдәп-әхлакка өйрәтергә кирәк – һәр ата-ананың бурычы бу. «Теге ярамый, бу ярамый» дигән тыюлар белән түгел, күркәм гамәлләр белән, яхшы сүз белән өйрәтергә кирәк. Шул рәвешле, путаны көннән-көн ныграк кысыбрак бәйләп куясың инде. Кинәт кенә кыссаң, тының бетәргә мөмкин бит – барысын да җай белән, хикмәт белән эшләү сорала. Туксанынчы еллар башына кадәр яшәп килгән әхлак чыгып бетте шул хәзер. Ярый ла безнең буынга ул кагыйдәләрне биреп калдырырлык әби-бабайлар эләкте. Ә менә без үзебез тиешенчә бирә алдыкмы соң? Хәзер бит яңа буын әби-бабайлар заманы. Гореф-гадәтләр дә, дин белән сугарылган әдәп тә югала бара. Битарафлык аркасында яшьләргә үз вакытында биреп өлгермәгән тәрбиянең җимешләрен күрәбез инде бүген. «Бала чакта алынган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы үзгәртә алмас», – дигән бит Ризаэддин Фәхреддин. Шуңа күрә балаларыбызга иманлы тәрбия бирергә омтылсак иде.

Әлфәс хәзрәтнең бу сүзләрендә – гади, шул ук вакытта гали бер хакыйкать. Без кемнәр, каян килгәнбез, кая китәчәкбез? Җир йөзендә яшәгән гомеребездә үз бурычларыбызны тиешенчә үтәргә өлгерәбезме? Адәм баласына акыл ни өчен бирелгән? Аллаһы Тәгалә бу дөнья тормышын безгә нинди максат белән бирде? «Иманлы тәрбия» дигән гыйбарәнең асылында менә шул сорауларга җавап ярылып ята. Ул җавапны тану өчен күңелдә иман нуры, сабырлык, кешелеклек, гыйлем булу кирәк тә инде...

**Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА**

*Кайтаваз*

## ВАТАН ДИГӘН ТАТЛЫ СҮЗ

Муса Җәлил һәм аның үзедәй батыр рухлы, ватанпәрвәр көрәштәшләре турында әдәбият һәм сәнгать әсәрләре аз түгел. Ш.Маннурның «Муса», Г.Әпсәләмовның «Агыла болыт» романнары, Н.Исәнбәтнең «Муса Җәлил», Р.Ишморатның «Үлмәс җыр», Т.Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» драмалары, Р.Харисның «Җәлилчеләр» дигән шигъри циклы һәм башкалар. Дөресендә, бездә бу каһарманнарыбызга багышлап, нинди дә булса әсәр тудырмаган каләм әһеле сирәктер. Шулар өстенә Г.Кашшаф, Р.Мостафин, И.Зәбиров, Ш.Хамматов, И.Гыйләҗевләрнең хезмәтләре, тоткынлыктан исән кайту бәхетенә ирешкәннәрнең истәлекләре һәм башка чыганаклар бу хактагы күзаллауларыбызны киңәйтә тордылар. Хәтта ул чорда дошман ягында торып көн күргән кайберәүләрнең искә төшерүләреннән дә хәбәрдар була бардык. Шөкер, нәрсәнең нәрсә икәнлеген көне-сәгате белән әйтә ала торган сәламәт акыллы каләмдәшләребез булган кебек, кибәкне алтын бөртекләреннән аера белүче халкыбыз бар.

Әлеге каһарманнарыбыз хакында мәгълүмат күп еллар буена бөртекләп җыелды. Әле илленче елларда, шушы хәлләрдән соңгы унъеллыкларда язылган әсәрләрдә белеп бетерелмәгән хәлләрнең еш кына фараз итү нәтиҗәсендә генә бәян ителүе сизелеп тора. Әйтик, 1959-1964 елларда Ш.Маннур «Муса» романын иҗат итте. Моның өчен ул шагыйрь дустының туган якларыннан алып соңгы сулышын алган Алмания җирләренә кадәр барып җитә, бик күп кешеләр белән очраша, шактый мәгълүмат туплый. Әмма шулай да бүгенге еллар кешеләре белгән күп кенә фактлар аңа билгеле түгел. Шулар арасында каһарманнарыбызның гильотинада җәзаланулары хакында ул әле кайдан белсен? Шушы фаҗиганең ни рәвешле булганлыгын раслаучы төгәл документ шактый еллар үткәч кенә табылды. Бу хәлләргә шаһит булган чит ил кешеләренең кайберләре татарлар үлем алдыннан нindидер җыр җырладылар дип тә әйткәннәр. Әмма ул нинди җыр? Ш.Маннур аны халкыбызның Г.Тукай сүзләренә башкарыла торган «Тәфтиләү» җыры дип уйласа, Т.Миңнуллин исә җырларыбызның башкасын күрсәтә. Без аның тәгаен генә нинди җыр булганлыгын әле бүген дә кистереп әйтә алмыйбыз. Ихтимал, ул изге Коръәнебезнең аятьләре булгандыр, дип уйлау мөмкинлегебез дә бар. Алманлы, бельгияле, итальян кешеләр, безнекеләрнең дога укулары җыр булып тоелгандыр.

Алар хакында ак таплар әле дә шактый. Шулар турында уйлап, фаразлап йөрү бер нәрсә, ә инде аларны ачуның гамәленә керешү – бөтенләй икенче эш. Каләмдәшебез Рафис Корбан әнә шундыйлардан булып чыкты. Ул эзләнүләрнең нәтиҗәләрен быел, «Ватан» исемле романында туплап, сурәтләп бирде.

Беренче карашка романның исеме үтә рәсми, аңа әдәби әсәргә хас булырга тиешле образлылык җитенкерәми дә кебек. Әмма әсәрнең эченә үтеп керә барган саен, биредә гәүдәләндерелгән кешеләр өчен «Ватан» төшенчәсенең никадәр әһәмиятле, хис-кичерешләр белән бәйле икәнлегенә төшенә барасың. Тора-бара ул М. Җәлилнең «Җырларым» шигырендәге Ватан образы белән тәңгәлләшә башлый. Аның җырлары, ягъни шигырьләре – илгә хәбәр җиткерү, намуслы исемен халыкка кайтару чарасы. Р.Корбан М.Җәлилнең Ватан турындагы уйлануларын туган тел белән янәшә куеп алып бара. Каһарман шагыйрьнең бу хактагы фикерләвенең бүгенге вазгыятькә бәйләнешле агышы романның заманча яңгырашын тәэмин итә. «Ватан һәм туган тел, – ди ул, – иң изге төшенчәләр. Ватан һәм туган тел бер-берсеннән аерым була алмый. Алар гел бергә – Ватаның юк икән, туган телең дә юк. Туган телең бетә икән, Ватаның да калмый».

Бу урында сорау туарга мөмкин: Муса Җәлил, чыннан да, үзе тарыган шартларда шундый юнәлештә уйланганмы? Тарихи шәхесләр теленә без бүгенгедән торып, үзебез нинди дә булса фикер сала алабызмы? Язучының андый мөмкинлеге бар, тик бер шарт белән – теге яки бу тарихи образның сүз сөреше вакыйгалар чолганышы белән акланган, үз шәхесенең үзенчәлекләре белән бәйле булырга тиеш. Күренекле рус язучысы А.Толстой бер хатында болай дип яза: «Сез тарихи шәхеснең биографиясенә «үзеңнән өстәргә мөмкинме?» дип сорыйсыз. Мөмкин. Ләкин моны шундый итеп

эшләргә кирәк, бу уйлап чыгарылган, чынбарлыкта булмаса да, булырга тиешле итеп бирелсен». Образларның нәкъ менә шул таләпләрне исәпкә алып фикерләүләренә ирешү – авторның үзе яза торган тормыш чынбарлыгын тирәннән белүен таләп итә.

Шуны искә алырга кирәк, Р.Корбан документаль роман язмаган. Аның каләме, тормышның үзендә булган хәл-әхвәлләргә таянып, әдәби, ягъни сәнгатьчә тукыма тудыра. Шуңа күрә образлар, вакыйгалар турында белгәннәрен күзаллавы белән тулыландырып, укучыга тәэсир итәрлек чаралар тапкан, шуның белән каһарманнарыбызны яңа яклары белән ачуга ирешкән. Үз алдына куелган төп бурычны – чынбарлыктагы затларны холык-фигыль бөтенлегенә, кешелек сыйфатларына бәрабәр гәүдәләндерүне уңышлы хәл иткән.

Романда Муса образы үзәкне тәшкил итә. Хакыйкатькә тугры калып, Гайнан Кормашның көрәшне башлап җибәрүдәге урынын да дөрес билгеләп, автор Мусаны алгы планга чыгара. Бу табигый хәл ителә. Ни өчен дигәндә, Мусаның, әсирлеккә дучар булганнарга сугышка кадәр үк билгеле булуы, шул ук вакытта биредә дә үз-үзен тотышы белән әхлакый таянычка әверелүе аңа әйдаман вазифасын йөкли. Ул – күпләр өчен, шул исәптән үзеннән шактый яшь Г.Кормашка да, бу шартларда кирәкле һәм тиешле юнәлешне бирүче. Дөресен әйткәндә, аларның гамәлләрен үлчәүгә салганда, һәммәсенең дә батырлыгы тигез тарта. Шул ук әсирлек, шул ук яшерен көрәш, дошман киемен өсләренә кигәндәге шул ук җирәнү хисләре барысына да уртак. Иң хәтәре – Ватанда аларны ничек бәяләрләр икән, дигән утлы сорауның һәрдаим баш өстендә торуы. Иң өстенлекле яклары – иман ныклыгы һәм Ватанга тугрылыкның аларны гильотина астына китереп салуы шартларында берсенең дә гомер сорап, җәлладларга гозерләнмәве. Менә ул сугыш чоры ватандашларыбызның «берәү – бөтенесе өчен, бөтенесе – берәү өчен» дигән бөек шигаренең көче! Һәркем үзенең мәнфәгатен генә өстен күргән башка җәмгыятьләрдә мондый күмәк батырлыкның булуы мөмкин түгел. Безнең тулаем җиңүебезнең нигезендә дә шушы бөек фәлсәфә ята да инде.

Шул ук вакытта Р.Корбан каһарманнарыбызны аерым-аерым тасвирлауны да игътибар үзәгендә тота. Иң кирәклесе – аларның үзләренә хас үткән юлын, холык-фигыльләрен, эчке дөньяларын тасвирлап, күңелләрендәге кадерле хатирәләрен яңартып, бүгенге хәлләренә китереп бәйли, нәкъ менә шушы шартларда ул сыйфатларның үзләрен ни рәвешле белдерәчәкләрен фаразлый, шуларның барышын әкренләп күрсәтүгә ирешә. Бу да сурәтләү осталыгының әһәмиятле ягы буларак бәяләнә ала.

Бу урында тагын бер нәрсәгә ачыклык кертеп куясы килә, романны укыгач, кемдер уйлар: дошманнар илендә, аларның хәрби формаларыннан яки гражданлык киемнәреннән иркенләп йөрү, кемнәргәдер аш мәҗлесләренә бару рөхсәт ителгән кешеләрне ничек бәяләргә? Чыннан да җитди сорау. Әмма без спектакльләрдә яки фильмнарда тәкъдим ителгән шартларда тиешле костюм киеп уйнаган артистларга алар башкарган рольләргә карап мөнәсәбәт күрсәтмибез бит. Әлмәндәр ролен уйнавы белән мәңгелеккә истә калган Шәүкәт Биктимеров шул ук театр сәхнәсендә палач ролен дә башкарды. Аңа карап, безнең бу талантлы шәхесебезгә булган карашыбыз үзгәрдеме? Һич юк. Бары тик аның сәләте алдында башыбызны идек, шушы хөрмәтебез бүген дә күңелләребездә яши. Аерма шунда: җәлилчеләр сәхнәдәге артистлар түгел, алар тормышның үзендәге рольне башкарырга тиеш булды. Бу «уен» өчен алар алкыш түгел, башлары кыелып төшү ихтималын ачык аңлый. Шуңа карамастан, бу көрәштә җанны кызганмаска дигән антларын үз каннары белән беркетәләр. Әлеге символик гамәл егетләребезнең хәлиткеч мизгелләрдә үзәкләре нык калуына китерә.

Рафис каләмдәшебез әсәренең тагын бер яңалыгы шуннан гыйбарәт: ул безгә исемнәре моңа кадәр дә билгеле булган татар мөһаҗирләренең кылган гамәлләрен дә шактый иркенләп ача. Шәфи Алмас, Әхмәт Тимер, Галимҗан Идриси кебек мәгълүм кешеләрнең шул мохиттәге үз-үзләрен тотышлары, аларны аңларга тырышып сурәтләнгән. Бу тирәлектәге тагын байтак кешеләр әсәрдәге вакыйгалар чолганышына кертелгән, алар хакында киң даирәләргә билгеле булмаган бик күп мәгълүматлар тупланган. Әлеге кешеләр дә образ дәрәҗәсенә җиткерелеп сурәтләнгән. Бу җәһәттән дә Р.Корбановның әдәби осталыгын тагын бер тапкыр билгеләргә туры килә. Моңа кадәр аларны бер буяу – кара төс белән генә сурәтләп килделәр. Роман авторы исә аларның да, бертөрле генә булмауларын истән чыгармый. Инкыйлабка кадәр сату-алу

яки башка шөгыльләр белән мәшгуль кешеләрнең байтагы, илне асты-өскә китергән үзгәрешләр вакытында чит мәмләкәтләрдә калырга мәҗбүр булды. Ватаннары аларны чит итте. Алар шулай да өметләрен җуймады. Мал-мөлкәтле, эш рәтен белүчеләрне чит иткән җәмгыять үзе дә озак тереклек итә алмас дип көттеләр. Теләгәннәре тормышка ашмагач, бу көнне якынайтуда Алманиядә, Италиядә, Япониядә барлыкка килгән кешелексез көчләргә өмет белән карый башладылар. Имеш, Уралга кадәрге җирләрне басып алгач, Гитлер аларга милли дәүләтчелек булдырырга да ярдәм итәр. Аларның инануынча, мондый ил төзеләчәк инде, аның булачак түрәләре кәнәфиләре өчен үзара көрәш башларга да була. Ш.Алмас дигәне, мәсәлән, бу алышта өстенлек ала, һәм ул бөтен тырышлыгын, мал-мөлкәтен шушы хыялын тормышка ашыруга куя. Үз даирәләрендә бер-берләренә нәзакәтле мөнәсәбәт күрсәтсәләр дә, һәркайсының үз исәбе, үз кыйбласы. Шәфи Алмасның мәсләктәше Әхмәт Тимерне Алманиядән үк китеп барырга мәҗбүр итүе шуның бер генә мисалы. Әмма Ә.Тимер өчен моның ахыр чиктә уңай ягы да була. Ни өчен дигәндә, ул фашизмның үз өнендә тар-мар ителүе, шул хәлләрдә Ш.Алмас кебекләрнең дә ярык тагарак алдында калуы вазгыятеннән читтә кала. Бу хакта Р.Абзалова-Сәлмәнова төзегән «Ахмет Тимер: Возвращение» дигән китапта да (1912) искә алынган. Анда Ә.Тимернең 1943 елда Берлинда М.Җәлил белән очрашуы турында да мәгълүмат бар. Ш.Алмаска килгәндә, аның дошман башкаласы үзәгендәге алты катлы «керем» йортын совет самолётыннан ташланган бомба чәлпәрәмә китерә. Шуның белән дәүләтчелекне хилафлы юл ярдәмендә кайтаруга булган омтылышы да җимерелә. Дәүләтчелекне кайтару кебек изге эш мондый алымнар белән тормышка ашырылырга тиеш түгел. Аның нигезе саф, игелекле, иманлы булырга тиеш!

«Ватан» романының фикер азыгы булырлык сәхифәләре болар белән генә чикләнми, алар байтак. Шулай да Р.Корбанның Гаяз Исхакыйны төрле имеш-мимешләрдән аралавына аерым тукталасы килә. Автор М.Җәлилнең шушы хәлләрдә Г.Исхакыйны еш кына искә төшерүе, аның татар бәхете өчен җитди сәяси-оештыру эшчәнлеге алып баруы белән Ш.Алмаслар хәрәкәт иткән юнәлеш арасындагы аерманы тиз чамалавы, «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәре авторына өстенлек бирүе ассызыкланып килә. «Бик дөрес уйлаган бит Гаяз Исхакый «Идел-Урал» дигән дәүләт төзү турында. Бары тик шул дәүләт кенә безнең Ватан була алыр иде. Ә бит гений булган Гаяз Исхакый! Их, күрәсе иде шул кешене! Төркиядә яшәп ята, диләр үзен. Ни өчен «Идел-Урал» редакциясенә килеп күренмәде икән соң ул? «Идел-Урал» дәүләтен Гитлер кулы белән торгызырга теләмәгән шул ул». Бу инде «Гаяз Исхаки, он же Шольс» дип аталган язма белән матбугатта чыгучы безнең көннәр уйдырмачыларына («Советская Татария», 1989, 19 февраль) ачык бер җавап булып та кабул ителә.

Җыеп әйткәндә, моңа кадәр талантлы балалар шагыйре буларак кабул ителгән Рафис Корбан үзенең прозада да мөмкинлекләре зур икәнлеген раслады. Иҗатындагы уңышы өчен сөенеп, аны әйбәт романы белән ихлас котлауларга кушылам.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН**

## НӘФРӘТ УЯТМАДЫ, ЛӘКИН КҮҢЕЛНЕ КАЙТАРДЫ

Быел журналның январь, февраль, март саннарында Рафис Корбанның «Ватан» исемле романы басылып чыкты. Шундый роман көтелә, дип, гыйнвар башында миңа Абдулла Алиш туганы Азат абый Сөнкишев хәбәр иткән иде.

Азат абый сүзләренә караганда, Р.Корбан «җәлилчеләр»не матур сурәтләп, алар турында объектив язарга тырышам, дип, аңа үзе сөйләгән; бу объективлык, имеш, Шәйхи Маннурда да, Габдрахман Әпсәләмовта да юк. Романны укып чыккач, чынбарлыкта ул бер Җәлил турында гына дигән нәтиҗәгә килдем. «Ватан»ның да төп максаты – Җәлилне элек дөнья күргән бөтен әсәрләрдәге кебек үк, әсирлектә фашистларга каршы яшерен көрәшнең төп фигурасы итеп күрсәтү. Шуңа күрә роман бары тик Җәлилне чиктән тыш мактаган чираттагы бер панегирик булып чыккан, минемчә.

Романда әсирлектә яшерен көрәшнең куркыныч якларын, конспирация кагыйдәләрен Җәлил генә иң яхшы аңлап, кулга алынганчы һәр очраганга сак булырга, немецларга

каршы көрәшергә кирәк, дип, армый-талмый акыл өйрәтә. Шуңа иң көлке мисал – аның легионга керергә тәкъдим итүенә Кормашның реакциясе: «Муса абыйсының сөйләгәнен тын да алмыйча дикъкать белән тыңлап торган Гайнанның маңгаена тир бөртекләре бәреп чыкты…». Җәлилнең үзен, алдан оештырган яшерен төркемгә тарткан, аннан башка бүтән иптәшләре белән бергә өч батальонны Кызыл Армия ягына күчәргә инандырган, Фин сугышында катнашып өлгергән Кормашка ике айлык политрук курсларында гына укыган, фронт газетасы корреспонденты нишләргә дип акыл сата, ә профессиональ разведчик Кормашның шундый ап-ачык хакыйкатькә үз башы җитми, имеш...

«Гаилә һәм мәктәп» журналының 2019 елгы 3 нче санында Р.Корбанның романы турында интервью басылган. Аның кереш сүзендә «җәлилчеләр» турында элек язган авторлар арасында Мәскәү профессоры, тарихчы Абдулхан Әхтәмҗан да телгә алына; шул профессор китабын Рафис Харисович укыганмы икән? «Муса Джалиль и его соратники в Сопротивлении фашизму» исемле китабында А.Әхтәмҗан яза: «Главным зачинщиком» татарского сопротивления нацистам имперский суд признал Гайнана Курмашева…» (Рафаэль Мостафин бу хакта 2002 елда ук әйткән иде); «…эту группу советских военнопленных татарского происхождения правильнее и точнее было бы называть «Группой Курмашева». Именно под этим девизом можно продолжать поиск в германских архивах». Әйе, романның беренче бүлегендә Р.Корбан яшерен төркемне Кормаш оештырганын таный тануын, ләкин оешма җитәкчесе булып, барыбер никтер Җәлил кала («…бөтен оештыру эшләре Демблиннан, Гайнан Кормашев аркылы алып барылды. Һәм Җәлил белән килешенеп башкарылды»; «Җәлил җитәкчелек иткән яшерен оешма…» һ.б.), ә интервьюда барыбер: «Мусаның каһарманлыгы яшерен оешма төзүдә генә түгел…», ди автор.

«…Баш күтәрүгә чакырып язылган листовка төргәкләренең иң күбесе Гайнан ятагыннан табылгач, оешманың башлыгы да ул, дип уйладылар», дигәнне уку да көлке; мин бу сүзләрне тупас хата, Кормаш ролен киметеп күрсәтү, дип бәялим. Кормашны оешма башлыгы дип, «ятагында табылган» листовка саныннан чыгып түгел, Империя Суды подпольщиклардан сорау алу нәтиҗәсендә таныйлар.

Автор Җәлил белән бергә җәзалап үтерелгән иптәшләренең биографияләреннән элек әсәрләрдә очрамаган вак-төякләрен китерә; аларны «матур сурәтләү» шуннан гыйбарәт, дип аңларга кирәкме? Фашистлар белән хезмәттәшлек иткән Гариф Солтан, Әхмәт Тимер, Шәфи Алмас һ.б., хәтта оккупацияләнгән («көнчыгыш») территорияләр буенча Германия рейхсминистры Альфред Розенберг биографияләре дә бәйнә-бәйнә яктыртылган; димәк, автор аларны да әсирләр белән бертигез матур сурәтләгән килеп чыга.

Җәлил тирәсендәге әсирләрнең уйлау сәләтләре да әллә ни югары булмаган кебек тәэсир кала. Алишны үзе белән бер баракта тотылучы Газыйм исемле егет күреп, аңа: «Сезне таныйрлык та түгел, йөзегезне сакал-мыек баскан. Күптән кырынганыгыз да юк, ахры», – дип гаҗәпләнә. Кеше йөзен сакал-мыек баскач, ул күптән кырынмаган, дигән нәтиҗәгә ничектер килә алган бу Газыймны автор кызганамы, әллә шулай «матур» итеп сурәтлиме? Рәхим Саттарның әсирлектән качарга, дигән нияте турында ишеткәч, Җәлил аны да: «Качарга һәрвакыт җай чыгарга мөмкин. Ләкин көрәшергә кирәк, Рәхим дускай», – дип акылга утырта. Фин сугышында катнашкан, командованиенең махсус биремнәрен үтәгән десантчыны, яшерен оешманың актив әгъзасын... Ә яшерен оешмасын «ачкан» Абдулла Баттал турында юк-бар риваять ике бит диярлек кенә: «Баттал Мәхмүткә ачыла башлый: беркатлылыгы, кешеләргә ышанучанлыгы белән аннан шикләнми дә...» һ.б.

Яшерен оешмасын ачуда Батталның гаебе расланмаган, бу турыда миңа хәтта Германия тарихчылары әйтте; шуның белән язучы Туфан Миңнуллин да ризалашып, «Моңлы бер җыр» исемле пьесасыннан Батталның «артык ышанучанлыгы»на үкенгән урынын алып ташлаган. Шуннан соң романда нинди объективлык турында сүз бару мөмкин?

Романда бүтән чыганакларга туры килмәгән фикерләр моның белән генә чикләнми. Әйтик, немец офицеры Клаус Шенк граф фон Штауффенберг турында «20 июльдәге заговорны менә шушы полковник оештыра да инде», диелгән. Ә «Известия» газетасының 2009 елның 29 гыйнвар (№14) санында немец тарихчысы, профессор, Берлиндагы нацизмга Каршылык мемориаль үзәге (Герман Каршылык музее)

җитәкчесе Йоханнес Тухель бер интервьюсында Штауффенбергны Гитлерга каршы заговорның төп фигуралардан берсе булса да, шул заговорны ул гына оештырган, дию дөрес түгел, дигән. «Операция Валькирия» фильмына бәя биреп, ул Штауффенберг турында «…Он показан этаким лидером, зажигающим сердца окружающих его людей,.. ведущим на борьбу с режимом фюрера. В реальности это было не так», дигән. («Фильм «Операция Валькирия» – некорректный и неправдивый» исемле мәкаләдә). Романда подпольщик Михаил Иконниковның дусты Русанов тоткынлыктан азат ителгән, ә А. Әхтәмҗан китабы буенча, НКВД капитаны Александр Дмитриевич Русанов тоткынлыкта газапларга чыдый алмыйча, кан тамырларын үзе кисеп һәлак булган. Романда Рәхим Саттарны партизаннар немец дип белеп, ялгыш атып үтерәләр, ә язучы-эзтабар Шаһинур Мостафин фронтовик-язучы Шәйхи Маннурның шундый сүзләрен китерә: «Саттаров һәм аның белән Едлинодан качып киткән кешеләр» «...фронт сызыгын үтәргә өлгерә алмыйча, немецларның засадасына юлыга. Печән кибәненә яшеренгән легионерларны, огнемёттан атып, яндырып үтерәләр фашистлар». («Алар – Җәлил-Кормаш йолдызлыгыннан!..», 26 бит). Сүз уңаеннан шундый сорау да туа: ант биргәндә, подпольщиклар учларын кан чыгарлык итеп кискәннәрен автор кайдан алган?

Ачыктан-ачык әйткәндә, «җәлилчеләр» турындагы китапларда хаталар еш очрый.

Интервьюда Р.Корбан «...Әсирләрне ач үлемнән коткарып калу өчен легион оештыру ул вакытта бердәнбер дөрес юл булган, дип уйлыйм», ди. Легионны немец командованиесе оештырган; өстәвенә урыс булмаган әсирләрне үлемнән коткару өчен түгел, Советлар Союзына каршы сугышка җибәрер өчен; шул турыда әсәрендә автор үзе дә сөйли бит, ә подпольщиклар аларны ватаннарына каршы сугышмаска өндәп агитация эшен алып барганнар.

«Мусаның гаилә хәле турында минем тәфсилләп сөйләп торасым килми. Романны укыган кешеләр үзләре күреп аңлар», ди автор. «Җәлил нәселенең кайбер вәкилләре белән элемтәдә торам, кайберләренең безнең илдән күченеп китүеннән дә хәбәрдармын». Гафу, мин барыбер шуны аңлап бетермәдем: Җәлилнең улы Альберт 1999 елда вафат, аның оныклары Казанда яши, дип ишеттем; кызы Люция үз кызы Лилиана, оныгы Баграт белән Петербургта яши, кызы Чулпан үз кызы, оныклары белән – Мәскәүдә, дип белә идем. Шулай булгач, Җәлил токымнарыннан безнең илдән кем китә алган икән?

Быел мартта мин Казанның 31нче мәктәбеннән «делегация»гә кушылып, Минзәләгә Муса Җәлил музеена барып кайттым. Анда, педагогия колледжы бинасында урнашкан музейда безгә Чулпанның оныгы Миша Митрофанов музыкага өйрәнергә Израильгә киткән, дип әйттеләр. (Бөтенләйгәме – билгесез). Р. Корбан шул очракны күздә тоткан булса, ник ачыктан-ачык әйтмәгән? Җәлил нәселеннән теләсә кемнең туган иленнән китү турында анык әйтүнең «патриот-шагыйрь»нең шәхси тормышына нинди катнашы бар һәм бу аның намусына ничек кагыла алсын? «Бөек шәхеснең шәхси тормышында тирәнрәк казынуны үземә бурыч итеп санамадым», – ди Р.Корбан. Димәк, Җәлил нәселе кешеләре белән үзең элемтәдә, тормыш яңалыкларыннан хәбәрдар булып тору «бөек шәхеснең» шәхси тормышында казыну булып саналмый, ә әсәрләр-интервьюларыңда икеле-микеле тәгъбирләр аркасында укучыларда үзең уяткан табигый сораулар казыну булып чыгамы?

Интервьюда Р.Корбан сүзләре: Җәлил һәм аның көрәштәшләрен «...каралтып күрсәткән әдәби әсәрләр, матбугат язмалары дөньяга чыкты. Үзләрен милләтче дип санап йөргән ул авторларга карата күңелдә нәфрәт уянып, быелтыр мин, ниһаять, шушы романны язарга җөрьәт иттем»; «Муса Җәлилне әүлия итеп күрсәтергә тырышу – ул совет җәмгыятенең коммунистларны идеаллаштырып күрсәтү сәясәте җимеше». Р.Корбан романы, әлбәттә, миндә үзенә нәфрәт уятмады, ләкин күңелне кайтарды: буыннан-буынга макталган шагыйрь бу төссез әсәрдә дә чираттагы мәртәбә шул ук әүлия итеп күрсәтелә. «Рафис «Җәлилчеләр» турында язган бу соңгы роман булачактыр, чөнки әлеге тема сүнә бара дигән», – диде Азат абый Сөнкишев. Вакытлар узу белән әллә нинди вакыйгалар турында хәтер сүнә, әмма мин Кормаш төркеме турында шундый әсәрнең соңгысы булуына өметләнәм.

**Фәрит БАТТАЛОВ**

# ТУКАЙ: ПУШКИННАН «ИГЪТИБАС ИТКӘН БУ БАШ»

Кайсы гына милли әдәбиятның үзган юллары шәрехләргә алынмасын, тикшеренүчеләргә һәрчак та диярлек аның башка әдәбиятлар белән теге яки бу дәрәҗәдә багланышта яшәгәнлегенә игътибар итәргә туры килә. Моның белән без татар әдәбияты тарихына мөрәҗәгать иткәндә очрашабыз. Чал тарихтан аның шәркый (гарәп, фарсы, башка төрки) әдәбиятлар белән тыгыз мөнәсәбәттә булганлыгы мәгълүм. XIX йөздә исә милли әдәбиятыбызга рус һәм аның аша көнбатыш әдәбиятлары йогынты ясый башлый. XX йөз башында бу нәрсә үзен аеруча сиздерә. Мондый тәэсир татар әдипләренең дөньяны сәнгати күзаллауларында, фикерләү алымнарында чагылыш таба. Бу, аерым алганда, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Дәрдемәнд, С.Рәмиев, Н.Думави, С.Сүнчәләй, Г.Камал, Г.Ибраһимов, Ш.Камал һ.б. иҗатында күзәтелә. Татар язучылары А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, Н.В.Гоголь, Л.Н.Толстой, И.С.Тургенев, А.Н.Островский, А.П.Чехов, М.Горький иҗатларына аеруча зур игътибар бирәләр.

А.С.Пушкинга (1799–1836) килгәндә, «аның сәнгати-эстетик ачышларының, җәмгыяви-әхлакый идеалларының татар әдәбиятына йогынтысы гаять дәрәҗәдә тирән, төрле яклы һәм югары иҗади потенциалга ия була» *(Татар энциклопедиясе. Казан, 2008, т.1, 271 б.)*.

Татар халкының милли горурлыгы, бөек шагыйрь Габдулла Тукай аеруча да Пушкин иҗатын якын күргән. Бөек рус шагыйре яңа рус әдәбиятына һәм әдәби теленә нигез салучысы булса, татар әдәбияты һәм әдәби теле өчен Тукай да – нәкъ шундый шәхес. Алар икесе дә язма телгә үзгәрешләр кертүне төп милли бурыч булуын аңлыйлар, яңа телнең нигезе итеп гади халык телен саныйлар. Әмма сөйләм-көнкүреш теле дәрәҗәсенә төшмичә, гасырлар буе тупланып килгән тел байлыгының барлык катламнарыннан да файдаланалар. Бер шигырендә Тукай Пушкинны якты кояшка тиңли, үзен исә шул яктылыкны чагылдыручы ай дип атый. Татар әдибе Пушкинга «Пушкинә» (1906), «Бер татар шагыйренең сүзләре» (1907), «Җавап» (1908), «Мәхәббәт» (1908), «Пушкин вә мин» (1912) шигырьләрен багышлый, аның «Пока супруг тебя, красавицу младую...» («Пушкиннән» дип исемли; 1906), «Любопытный» («Ике иптәш арасында»; 1910), «Узник» («Мәхбүс»; 1907) шигырьләренең, «Сказка о золотом петушке» («Алтын этәч»; 1908) поэмасының иркен тәрҗемәләрен тудыра. Пушкин әсәрләреннән («Евгений Онегин». «Про себя», «Весёлый пир», «Когда твои младые лета...», «Я пережил свои желанья», «Сказки о мёртвой царевне...», «Десятая заповедь») файдаланып, «Кемне сөяргә кирәк», «Үз-үземә», «Мәҗлес», «...га (Шома тормыш...)», «Теләү бетте», «Җил», «Тәүбә вә истигъфар» шигырьләрен иҗат итә.

Бөек рус шагыйре иҗатына ихтирамлы мөнәсәбәте Тукайның мәкаләләрендә дә чагылыш таба. «Безнең милләт тә, башка милләтләрдәге кеби, хамисез, мәлҗәэсез, фәкыйрь вә эшче халыкның файдаларына тырышучы, биш фәкыйрьне бер бай этенә алмаштырыр вакытлар үткәнлеген аңлаучы вә аңлатучы егетләргә мохтаҗ. Безнең милләт тә Пушкиннәргә, граф Лев Толстойларга, Лермонтовларга мохтаҗ. Кыскасы гына, безнең милләт тә башка милләтләрнең тәрәккыйләренә сәбәп булган чын мөхәррирләргә, рәссамнәргә, ... яңа-яңа милли шигырьләргә, музыкаларга вә гайреләргә, вә гайреләргә мохтаҗ», – дип саный шагыйрь. *(Габдулла Тукай. Әсәрләр. Казан, 2015. т.3, 195 б.)*

«Шигырьләребез» мәкаләсендә (1907) Пушкин әсәрендәге «Еду, еду в чистом поле, Колокольчик динь-динь-динь...» дигән юлларны мисалга китереп, татар шигыре ритмикасында русныкына охшашлыкны әйтә. «Халык әдәбияты» исемле рисаләсендә (лекциясендә) Пушкинның «Алтын балык» һәм «Алтын этәч» әкиятләрен, «Кызлар җыруы»н («Пока супруг тебя, красавицу младую...») мисалга алып, аларның халык авыз иҗатына, халык җырларына таянып иҗат ителүенә басым ясый. «Мөкаддимә» мәкаләсендә исә Пушкинның ярты гомере «Байрон җәнабләренә тәкълид вә аның

рухыннан илһам эстәү белән үтмеш»ен искәртә, С.Сүнчәләйгә хатында аның С.Рәмиев тарафыннан тәрҗемә ителгән «Пәйгамбәр» шигыре турында сүз алып бара, 1911 елгы 22 гыйнварда җибәрелгән хатында да аның исеме яңгырый. 1911 елның 4 мартында С.Сүнчәләйгә ул болай яза: «Бер поэма хакында башымда әнвагъ төрле хыяллар йөри. Фәкать зиһен варить итеп чыгарганы юк әле. Гаяи хыялым – татарча, татар рухында, татар геройлары белән дөньяга бер «Евгений Онегин» чыгарудыр. Алла ни бирер» *(Габдулла Тукай. Әсәрләр. Казан, 2016, т.5, 219 б.)*. «Мәкаләи махсуса» (1912) мәкаләсендә Онегин һәм Татьяна арияләрен грампластинкадан тыңлавын әйтә. И.Пехтелев «Тукай һәм рус әдәбияты» (1946) китабында Тукай-Пушкин бәйләнешларына зур урын бирә.

Тукай рус шагыйре иҗаты белән 1895 елда Уральскига килгәч, Әхмәтша остаздан белем алганда таныша һәм мәдрәсәдә чакта да рус әдәбиятын укып бара. Пушкин иҗатына карата кызыксынуы беркайчан кимеми, киресенчә, еллар үткән саен арта, киңәя генә бара. Пушкин иҗатын нигезле белүе турында Тукайның әсәрләре сөйли. «Шүрәле» поэмасына Тукай түбәндәге искәрмәне ясый: «Әлеге әкиятне мин авылларда сөйләнелә торган әкиятләрнең сюжетын эшкәртүче шагыйрьләр – А.Пушкин һәм М.Лермонтовтан үрнәк алып яздым». Тукай рус шагыйрьләре куллана торган чыганаклар белән кызыксынган һәм аларны үзе дә яхшы белгән. Ике шагыйрьнең якынлыгы – бу күчерү яки охшарга тырышу гына түгел, ул – ике бөек шагыйрьнең рухи якынлыгы. Пушкиннан ирекле тәрҗемәләренең кайберләре оригиналга якын тора, кайсылары күпмедер аерыла. Әйтик, «Мәхбүс» – оригиналга иң якын булган тәрҗемәләренең берсе. Күп очракта Тукай аның иҗатына мөрәҗәгать итә дә, чыганакның төзелешен һәм образларын үзгәртеп, әсәргә милли колорит өсти торган яңа детальләр белән баета, татар укучысының игътибарын җәлеп итәрдәй урыннарны көчәйтә һәм, шулай итеп яңа шигырь тудыра. Бу бигрәк тә «Алтын әтәч» мисалында ачык күренә. Берникадәр төшереп калдырулар һәм өстәмәләрне исәпкә алмаганда, ул Пушкин әсәренең тулы тәрҗемәсе булып тора. Тукай әкиятнең сатирик үткенлеген саклый алган.

«Пушкин вә мин» шигырендә (1912) иҗатының башлангыч чорында Тукай Пушкин белән Лермонтовны остазлары дип саный. Алар мирасыннан өлге алуын, әдәби осталыкка өйрәнүен яшерми. *«Шунда да күрмим үземне һич тә Пушкиннән түбән; / Тугъры күз салсаң эшенә – ул үзе миннән түбән»*, – дип яза Тукай. Үзен Пушкин белән янәшә, хәтта халыкчанлык нисбәтеннән аңардан өстенрәк тә куеп, ул һич кенә дә остазының рухын рәнҗетми, аңа «Хәзрәти Пушкин» дип олылап эндәшә. «Пушкин әсәренә хас югары өслүбне Тукай тормыш-көнитеш дәрәҗәсенә төшерә. «Пушкин вә мин» – Тукайның әдәбият тарихында үз урынын билгеләгән, элгәрләре белән иҗат юнәлешен бәхәстә раслаган әсәрләренең берсе», – дип яза Т.Галиуллин *(Габдулла Тукай. Энциклопедия. Казан, 2016. 530 б.)*.

Р.Ганиева язуынча: «Иҗатының башлангыч чорында касыйдә (ода) рәвешендә язылган «Пушкинә» (1906) әсәрендә яшь татар шагыйре Пушкин иҗатына үзенең олы мәхәббәтен белдерә, аны «нәзыйрсыз» (тиңдәшсез) шагыйрь итеп саный, аның якты кояшка тиң («мисале шәмсе рәхшандыр») шигыре көенә агачның, ташның биюен әйтеп, үзенең Пушкин гөлбакчасына кереп, җимешләреннән авыз итүенә шатлана, гүя очып йөри» *(Габдулла Тукай. Энциклопедия. К., 2016. 530-531 б.)*.

«Пушкиннән» (1906) шигыре – иҗади тәрҗемәнең ачык үрнәге. «Татар һәм, гомумән, Көнчыгыш хатын-кызлары тормышы, язмышы белән китаплар яисә икенчел чыганаклар аша гына таныш Пушкин фаҗигане тетрәндергеч яссылыкка күтәрә алмый. Тукай шигыренең мөстәкыйльлеге күләм үзгәрешендә дә күренә. Пушкинга фикерен әйтү өчен 9 юл җитсә, Тукайга кичерешне ачып, җәеп салуга 20 юл кирәк була», – дип искәртә Т.Галиуллин *(Габдулла Тукай. Энциклопедия. К., 2016. 531-532 б.)*.

Әледән-әле Пушкин белән дә «сөйләшеп» иҗат итү Тукай иҗатының хисси, сәнгати яңгырашын көчәйтүгә, фикри эчтәлеген сизелерлек тирәнәйтүгә, халкыбызның күңел дөньясына хас, милли хосусиятләрне шигырь телендә чагылдыруга хезмәт итте.

**Рәйсә МУСАБӘКОВА,**
*филология фәннәре кандидаты*

# «ИМАН ҺӘМ ГАИЛӘ – ТОРМЫШ НИГЕЗЕ»

*Исмәгыйль Шәңгәрәев татар дөньясында, беренче чиратта, Гарәп Әмирлекләрендә яшәүче милләт җанлы татар эшмәкәре буларак билгеле. Укучыларыбызга аның белән әңгәмә тәкъдим итәбез.*



*Исмәгыйль Шәңгәрәев очрашуда.*

**– Исмәгыйль Каләметдинович, ни өчен нәкъ менә Гарәп Әмирлекләрен сайладыгыз? Чит җирләрдә миллилекне саклап яшәү ни дәрәҗәдә мөмкин?**

– Беренче итеп шуны әйтергә кирәк, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре – әлеге дәүләткә нигез салган Шәех Зайд ибн Солтан Әл Нахайянның уникаль проекты, ул үзендә мөселман Көнчыгышының мәдәни үзенчәлеген һәм дәүләт һәм җәмгыятьнең англосаксларча корылышын берләштерә. Мондый синтезның нәтиҗәсе чын мәгънәсендә таң калдырды, мин аны гомумкешелек кыйммәтләре миллилек белән гармониядә яши торган киләчәк дәүләтенең үрнәге итеп күрдем.

«Кешеләр төрле телдә сөйләшергә мөмкин, йөрәкләр бердәй типсен», диләр бит. Минем өчен, мөселман кешесе буларак, Гарәп Әмирлекләренең рухи мәдәнияте үтә дә аңлаешлы. Бүген үзеңне иркен хис итә, традицион киемнән йөри, кайсы милләттән булуыңны, милли ашларыңны ирекле рәвештә күрсәтә торган башка ил җир йөзендә юктыр. Чит кавем кешесе буларак, анда нәрсә генә эшләсәң дә, сиңа берәү дә «безнең гореф-гадәтләргә ярашлы итеп эшләгез», димәячәк. Киресенчә, һәрьяклап ярдәм күрсәтәчәкләр, синең традицияләреңне, мәдәниятеңне аңларга һәм кабул итәргә тырышачаклар.

Бу – толерант Ислам, мәгърифәтле Ислам дөньясы, дияр идем. Анда һәркем үзенең нинди милләттән, нинди диннән булуына карамастан, дәүләт һәм җәмгыять тарафыннан аңлау һәм яклау таба. Шул ук вакытта әлеге гаҗәеп илне хыялымда йөрткән ил итеп кабул итсәм дә, мин барыбер дә бөтен йөрәгем һәм күңелем белән русияле булып калам.

**– Сез Оренбург өлкәсенең Әсәкәй районында туып үскәнсез, Мәскәүдә яшәгәнсез. Сезнең Гарәп Әмирлекләрендәге рестораннар челтәре дә «Казан» дип атала. Казан Сезнең өчен хыялдагы шәһәрме, әллә рестораныгызны болай атауның башка сәбәпләре бар идеме (мәсәлән, Әмирлекләрдәге татар диаспорасының очрашу урыны...)?**

– «Барлык юллар да Казанга илтә», – дип язган идем мин үземнең «Ислам һәм дөнья: Көнчыгыш классиклар күзлегеннән» китабында. Мәсәлән, Лев Толстойның Казанда иң яраткан ял итү урыны Черек күл булган, анда кышларын бушлай шугалак катырганнар, җанлы музыка яңгыраган. Минем өчен исә Казан – еракта калган 80 нче елларда ук әле бизнеста үз-үземне эзләү чоры, яшьлегем, өметләрем шәһәре ул. Хәер, хәзер дә Россиянең Гарәп Әмирлекләрендәге күпмилләтле диаспорасы, элекке СССР

илләреннән килгән мөһаҗирләр Фарсы култыгы ярларында бөтен юлларның да «Казан» ресторанына илтүен белә. Менә дистә елга якын инде ул билгеле сәясәтчеләр, мәдәният һәм спорт вәкилләренең очрашу урыны булып тора. Әлеге бизнес-проектым хаклы рәвештә социаль-мәдәни учак дип санала ала, чөнки ул затлы иҗади берләшмәләрнең иң яхшы традицияләренә җавап бирә.

**– Сүз уңаеннан, ортодоксаль мөселман илендә татар кухнясын ничек кабул итәләр?**

– Әйе, мөселман мәдәниятле ил булса да, биредә ортодоксальлек юк һәм булмады да. Алай гына да түгел, биредә ортодоксальлекнең күләгәсе генә булса да, бу ил цивилизациянең XXI гасырдагы техноген характердагы югарылыкларына ирешә алмас иде. «Казан» ресторанына еш кына Гарәп ярымутравы илләреннән гарәпләр дә керә, һәм моңа кадәр әле татар яки рус кухнясы ошамады, дигәннәре булмады.

Биредә Аллаһ каршында барысы да тигез һәм барысы да Шәех Зайд тарафыннан расланганча, түземлек һәм үзара ихтирам принципларына таянып яшәргә омтыла.

**– Ресторан бизнесыннан тыш, Сез күчемсез милек һәм туризм белән дә шөгыльләнәсез. Гарәп илләрендә бизнес алып баруның үзенчәлекләре нидә?**

– Дубай күчемсез милек агентлыгы (ДАН) – Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә минем иң беренче һәм иң уңышлы тәҗрибәм. 2006 елда Гарәп Әмирлекләрендә чит ил кешеләренә күчемсез милеккә инвестицияләр кертергә рөхсәт биргән канун чыкты, һәм мин эшкә алындым. Минем генә түгел, ә командамның да тырышлыгы нәтиҗәсендә Real Estate барлыкка килде. Һәм, мөгаен, Дубайдагы иң яхшы агентлыкларның «Топ-5» рейтингын төзегәндә, Independent Expert Group (UAE) бәйсез экспертлар төркеме ышанычлылык дәрәҗәсен дә кертеп, ун критерий буенча бәяләгәндә, ДАНның җиңүче булуы закончалыклы иде.

**– Сезне бизнес-команда туплаганда, Татарстаннан килгән егетләргә һәм кызларга өстенлек бирә, диләр. Бу үзенә күрә аларга ярдәм итүме?**

– Юк, мин аны ярдәм, димәс идем. Яшьләргә өстенлек бирүгә килгәндә, мәдәният тарихындагы иң күренекле энциклопедист-галим Әбүгалисина фикере белән килешәм. Ул теләсә кайсы эштә үз вакытыңны белеп, урыныңны яшьрәкләргә калдыру кирәклеген әйтә.

Шулай ук мин командамны гендер принцибы нигезендә дә бүлеп карамыйм, минем өчен кешенең эшне башкарып чыга алуы мөһим.

Урыныңны яшьрәкләргә калдыру дигәннән, бу турыда әйтүе генә җиңел, әмма үз кулларың белән төзегән корабның капитан штурвалын икенче бер кешегә калдырып китү авыр. Ләкин мин яшьләргә ышанам. Бер генә мисал китерәм. Ун елдан артык Гарәп Әмирлекләрендә Татар-башкорт диаспорасы ассоциациясен төзедем (уртак чаралар өчен шактый зур чыгымнар тотарга туры килде), һәм аны халыкара дәрәҗәдә презентацияләр вакыт җиткәч, Ассоциация рәисе итеп өлкән улымны – Ислам Шәңгәрәевне тәкъдим иттем.

**– Татар мәдәниятен үстерү өчен хәйриячеләр, меценатлар таләп ителә, дигән сүзләр дә еш ишетелә. Ничек уйлыйсыз, хәзерге заман шартларында меценатлыкның эчтәлеге нидән гыйбарәт була ала?**

– Мин проектларны һәм программаларны инвестицияләү яклы. Бүген без кулдашларым белән мәдәниятара һәм конфессияара диалоглар үсеше, аз санлы милләтләрнең хокукларын яклау, милли традицияләрне, гореф-гадәтләрне, телне саклау максатында проектлар булдырып, аларны финанслауны системага салу буенча эшлибез. Без киләчәкне гомумкешелек кыйммәтләре аз санлы милләтләрнең мәнфәгатьләре белән аваздаш булган проектларга нигезләнеп төзибез.

Мәсәлән, Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендәге Татар-башкорт диаспоралары ассоциациясе – беренче чиратта, Татарстан белән Башкортстаннан килеп, Абу-Даби, Аджман, Дубай, Рас әл-Хайма, Умм-әл-Кувейн, Фуджейра, Шарджа әмирлекләрендә яшәп ятучы ватандашларыбызның социаль-мәдәни берләшүенең ачык системасы ул.



*«Иман һәм гаилә – тормыш нигезе» – Шәңгәрәевләр нәселенең төп шигаре.*

Ассоциация традицион мәдәният нигезләрен үзләштерү, халыкның гореф-гадәтләренә кушылу, милли һәм рухи-дини бәйрәмнәрдә катнашуны максат итеп куя. Мин моңа акчалар тотам. Аны меценатлык дип атарга да була. Үзем исә моны халкым алдындагы бурычым дип саныйм.

**– Сезнең шәхескә игътибарны җәлеп итә торган тагын бер үзенчәлек – сез хатыныгыз Мәрьям белән 11 баланың әти-әнисе. Бүгенге көндә сезнекедәй ишле гаиләләр сирәк очрый. Балалар тәрбиясендә сез нинди принципларга таянасыз?**

– Әйе, 11 балабыз, 10 оныгыбыз бар. Мин гаиләдә балалар тәрбиясен оештыруның үземә ярашлы моделен озак эзләдем, чөнки Аллаһның рәсүле (с.г.с.) болай дигән: «Бер генә ата да үзенең баласына яхшы тәрбиядән дә кыйммәтлерәк нәрсә бүләк итә алмый».

Балаларым да, оныкларым да дүрт телдә – татар, рус, гарәп һәм инглиз телләрендә иркен сөйләшә. Туган телләре – татар телен өйрәнү өчен Татарстаннан укытучы чакырттым.

Тәрбия формаларыннан мин фермерлык тибындагы уртак хезмәт төрен сайладым. Әйтергә кирәк, гаилә бизнесы – Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә иң киң таралган эшчәнлек өлкәсе, чөнки ул гарәп дөньясының мәдәни традицияләренә җавап бирә, Шәригать нормаларына нигезләнгән үзара мөнәсәбәтләргә корылган.

Тәҗрибә күрсәткәнчә, гаилә әгъзаларыннан торган компанияләр базардагы үзгәрешләргә сизгер, карарлар кабул иткәндә, сыгылмалылык күрсәтә, кадрлар сәясәтенә дә җитди карый.

Константин Довлатов үзенең «Бизнес. Уңыш биеклегеннән генә күренә торган кануннар» китабында болай дип язган: «Кем ул яхшы ата? Ул йә ике буын варислары туздырып бетерә алмаслык байлык калдыра, йә гаилә бизнесы калдыра». Мин икенче юлны сайладым һәм үкенмим, гәрчә, турысын әйтәм, балаларың белән эшләү җиңел түгел.

Мин шушы гаилә бизнесы, әхлак мәктәбе булдыру юлыннан озак еллар барам инде, улларым акча эшләргә генә өйрәнеп калмыйча, этиләренең шәхси үрнәгендә зыялы, киң күңелле, юмарт һәм мәрхәмәтле булырга өйрәнә, рухи үсеш юлына баса.

Балаларга яхшы тәрбия бирү – көн саен кирәкле сүзләр табып, үрнәк булырдай гамәлләр кылып хәл ителә. Балаларым һәм оныкларым, үз чиратында, минем өчен гаилә кыйммәтләре булып тора, мин алар хакына эш кешесе генә түгел, ә рух кешесе булырга да омтылам.

Гаилә тормышының уңышы – иман һәм мәхәббәткә нигезләнгән ныклы әхлак.

*Әңгәмәдәш* – **Ландыш ӘБҮДӘРОВА**

# КУБРАТ ХАН ТОКЫМНАРЫ ЯЗМЫШЫН АЧЫКЛАУ

VII гасырның 30 нчы елларында Дуло төрки ыруыннан чыккан Кубрат хан (605 елда туган, Константинопольдә Ираклий сараенда тәрбияләнгән) җитәкчелегендә болгар кабиләләре берләшә. Азак (Азов) һәм Кара диңгез арасында тарихка «Бөек Болгар» исеме белән кереп калган көчле дәүләт төзелә (635 ел). Әмма Кубрат хан вафатыннан соң (665 еллар), әлеге дәүләт таркала.

Тарих дәреслекләре Кубрат ханның биш улы, үз илләре-кабиләләре белән төрле якларга таралуын хәбәр итә. Кара диңгез буе далаларында калган икесе – Баян (Батбаян) һәм Котраг (византия һәм рус чыганакларында – «Кара болгарлар») җитәкләгән кабиләләрнең Хәзәр каһанлыгы кул астына керүе мәгълүм. Соңрак Котраг хәзерге Украина җирләреннән безнең төбәккә килә, Идел буе Болгарын нигезли. Аспарух хан үзенең болгарлары белән 679 ел тирәсендә Дунайга китә һәм бирердә Беренче Болгар патшалыгын төзи. Кубратның тагын ике улы Үзәк һәм Әлчекнең Ауропага юл алуы тарихи чыганакларда теркәлгән. Аның берсе – Әлчек – Ауропада маҗарлар дәүләтен (бүгенге Венгрия – Һунгария нигезен) кора.

Тарихта Кубрат хан улларының уңайлы урыннарны ни өчен ташлап китүе, бу хәлнең ничек баруы турында төрле фаразлар яши. Татарстан археологларының маҗар (венгр) археологлары белән республикабыз җирләрендә алып барган казу эшләре, аның нәтиҗәләрен иң соңгы фән технологияләре ярдәмендә тикшереп карау бу «Бөек күчеш»нең маҗарларга караган тарихына көтелмәгән яңалыклар алып килде.

Әлеге яңалыклар Татарстандагы Алексеевск районы Зур Тигәнәле авылы җирлегендә 1974-1984 елларда табылган, Көнбатыш Европадагы иң олы каберлектәге казу эшләре белән бәйләнгән. Бу казу эшләрен төрле елларда Казан галимнәре А.Х.Халиков, Е.А.Халикова, В.Ф.Генинг, Е.П.Казаков җитәкли. Каберлектә 150 кабер барлыгы ачыклана, аларда сугыш кирәк-яраклары, бизәнү әйберләре, савыт-сабалар, көмеш битлекләр табыла. Эзләнүләр нәтиҗәсендә А.Х.Халиков, Е.А.Халикованың «Кама һәм Урал буйларында борынгы маҗарлар (Зур Тигәнәле каберлеге)» дигән монографиясе языла һәм 1981 елны алман телендә Венгриядә нәшер ителә.

Мондагы археологик табышларны өйрәнеп, Казан археологы Е.П.Казаков (Татарстан Фәннәр академиясенең А.Х.Халиков исемендәге Археология институты) Зур Тигәнәле материалларының Кушнаренко һәм Кара-якуп культуралары белән охшашлыгын дәлилли. Маҗар галимнәреннән, бу мәсьәлә белән фән докторлары Иштван Фодор («Маҗарлар: борынгы тарих һәм Ватанны табу» китабының авторы, Венгрия Милли музее директоры, Татарстан Фәннәр академиясенең чит ил әгъзасы), Аттила Төрк (Петер Пазмань исемендәге Католик университет) һ.б. шөгыльләнә.

Күп кенә фаразлар соңгы елларда ясалган ДНК-экспертизалар, антропологик һәм палеогенетик тикшеренүләр ярдәмендә дәлилләнә. Шуларга таянып, татар һәм маҗар галимнәре зур ачыш ясый: Ауропага киткәнче, маҗар кабиләләре Идел-Урал буйларына килеп урнашкан, монда яшәгән. Тарихи чыганакларда «Magna Hungaria» («Бөек Маҗарстан» яки «Бөек Һунгария») дип аталган, маҗар этносы формалашкан урын Уралдан – Идел-Кама-Агыйдел-Ык буйларына кадәрге зур территорияне биләп торган.

Бу яңалыклар 2018 елның 15-20 октябрендә Казан шәһәрендә уздырылган IV халыкара маҗар симпозиумында яңгыратылды. Венгр галиме Аттила Төрк (Будапешт) – угыр-маҗар темасына кагылышлы археологик һәм фәнни тикшеренүләрнең, татар галиме Айрат Ситдыйков – 2017-2018 елларда Зур Тигәнәле каберлегендәге казу-тикшеренү эшләренең яңа нәтиҗәләре белән таныштырдылар. Материаллар борынгы маҗарларның матди һәм рухи мәдәнияте, көнкүреше, йола-гадәтләре хакында шактый тулы күзаллау булдыра.

**Айрат СИТДЫЙКОВ,**
*тарих фәннәре докторы, профессор,*
**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*

# ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИНЕҢ ТАШКИЧҮДӘГЕ МУЗЕЕ

«Хәтнә җирлеге тарихы борылыш кичерә» дигән фотоальбомда Рөстәм Зәкуанның мондый юлларын укый алабыз: «Һәр төбәкнең һәм анда яшәүче халыкларның үз тарихы бар. Минем уйлавымча, тарихның милләте юк. Тарихка караш та субъектив булырга тиеш түгел. Ләкин, кызганычка каршы, тарихны язучыларның еш кына сәяси һәм милли күзлектән чыгып эш итүе аркасында, чын тарих дөреслеген югалта». Сүз башы итеп, юкка гына Зәкуан фикерләренә мөрәҗәгать итмәдек. Арча районы Ташкичү авылында Шиһаб хәзрәтләренең исемен мәңгеләштерүгә ул фикердәше Лотфулла Шәфигуллин белән бергәләшеп зур өлеш керттеләр. Дөреслек халык телендә йөргән риваятьләрдә, еш кына тарихи шәхесләрнең туып-үскән җирләрендә сакланып кала, дигән фикергә таянып, алар музейның һәр экспозициясен уйлап, тамашачыга белем алырлык, тирән хисләр калдырырлык итеп җиһазларга тырыштылар.

Ташкичү мәктәбенең тормышына зур үзгәрешләр алып керде ул музей. Ш.Мәрҗанинең мирасын барлау, халыкка җиткерү максатында зур эшләр башкарылды, музей бөек галимгә багышланган материаллар белән баетылды.

Музейга килеп керүгә, күз иң элек Ш.Мәрҗани портретына төшә. Гүя бөек фикер иясе безне үзе каршы ала. Кулында борынгы кульязма. Сылу гәүдә, күзләр залга керүчеләргә төбәлгән һәм ул: «Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк», – дип әйтә кебек.

Экспозиция Ш.Мәрҗанинең тормыш юлы белән ачыла. Галимнең бала чагын, нәсел-нәсәбен, Бохарада, Сәмәркандта укыган чорын, Ташкичү авылы тормышын чагылдырган стендлар күп мәгълүмат бирә. Казан чоры һәм галим булып китү турында аерым күргәзмә бар. Шунда ук Ш.Мәрҗанинең укытучылары, фикердәшләре, шәкертләре, аның юлын дәвам итүчеләрнең портретлары, галим турында әйтеп калдырган фикерләре урын ала.

Музейда Ш.Мәрҗанинең шәҗәрәсе, туганнары, балаларына зур урын бирелгән. Шәҗәрәгә карап, бүгенге көндә галим нәселен дәвам итүчеләрнең исемнәрен табарга мөмкин.

Музей түрендә Ш.Мәрҗани утырып эшләгән борынгы өстәл, урындык, шкаф. Стенадагы борынгы сәгать узган вакытны саный кебек. Өстәл өстендә Ш.Мәрҗани кульязмаларының күчермәләре. Галим әле генә чыгып киткән дә, кайтып, янә шушы урындыкка утырып, эшләр кебек тоела.

Ш.Мәрҗани яшәгән чорны тасвирлаучы почмак иске Казан белән бүгенге Казан арасындагы охшашлык һәм аерманы күз алдына китерерлек мөмкинлекләр ача. Кайчандыр Кабан күле буйларында Ш.Мәрҗанинең кызу-кызу атлап барганы шәйләнә кебек.

Музейның соңгы экспозициясендә «Таттелеком» компаниясенең соңгы елларда татар халкы мирасын кайтаруда куйган хезмәтләре чагыла. Ул «Казан арты тарихы – чорлар һәм тарихлар мирасы...» дип атала. Яңа Кырлай авылында Сәгъди абзый утарын яңарту, Хәтнә авылында Перцов чиркәвен, Ш.Мәрҗани нигезен яңадан торгызу, галимнең каберен төзекләндерү һәм башка игелекле эшләр башкарылганына инанасың.

Музей эчендә китаплар, китаплар... Алар арасында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивларында саклanучы Ш.Мәрҗани кульязмаларының күчермәләре, Ш.Мәрҗанинең 200 еллыгына багышлап чыгарылган «Татар Геродоты» дип аталган китап һәм башкалар бар.

**Алсу ӘХМӘДУЛЛИНА**



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**БАТУЛЛА**

## Язучылар

– Язучылар кемнәр алар, сез ниндиләрен хөрмәт итәсез?

– Язучылар төрле була! – дигән Батулла. – Яла язучы. Әләк язучы. Отчёт язучы – алары коммунист язучылар. Бар әдәби әсәр язучы. Бар әдәби әсәр язам, дип уйлап та, әдәби булмаган әсәр язучы. Бар язмый торган язучы. Бар яза торган әдипләр.

– Ничек инде ул язмый торган язучы, язмагач, язучы буламыни инде ул?!

– Була! Язмый торган язучыларның байтагы дәреслекләрдә классиклар дәрәҗәсендә йөртелә.

## Пычак

Мөдәррис Әгъләм Батулла өенә килеп керә. Батулла ялгызы гына аш пешереп маташа икән. Хуҗаның бик җитез суган тураганын карап, Мөдәррис әйтеп куя:

– Карале, Батулла, синең пычагың бик үткер икән, ә каләмең минем пычагым төсле!

– Шуңа күрә дә сине бер генә хатының да өйдә тотмый бит, куып чыгара. Пычак үткенләргә дә ярамаган ир пычагымамыни?! – ди Батулла.

## Бәхетсез кеше

– Ркаил, сине Батулла кыйнаган, диюләре хакмы?

– Хак! Һәм мин моның белән горурланам.

– Нигә?

– Син – бәхетсез кеше.

– Нигә?

– Чөнки сине Батулла беркайчан да кыйнамаячак.

– Нигә?

– Батулла үзе кебек талантлы кешеләрне генә кыйный.

## Озын гомерле әсәр

Батулланың «Сөйгән ярым ятка кала» исемле җырлы-биюле комедиясе Камал театрында куела. Халык бу тамашаны бик алкышлап каршылый. Спектакльне карарга Илһам Шакир да килә. Батулла белән сөйләшкәндә, Илһам әйтә:

– И җанкәм, «Диләфрүз...» кебек озын гомерле булачак бу әсәрең! Безнең халыкка шушындый шырдый-бырдый нәрсә ошый инде ул...

***

– Кайсы режим яхшырак? Тоталитарныймы, әллә авторитарныймы?

– Татаритарный!

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

### БӨЕК ҖИҢҮГӘ – 74 ЕЛ

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов татарстанлыларны Бөек Җиңүнең 74 еллыгы белән котлады. «Сугыш уты көйдергән җиребездә Бөек Җиңү турында хәбәр алынган шатлыклы көннән соң бик күп дистә еллар узды. Әмма фаҗигале һәм героик бу чор вакыйгалары буыннар арасында рухи-патриотик бәйләнеш чылбырының какшамас бер өлеше булып хәтеребездә мәңге сакланыр», диелә әлеге котлауда.

Казанның Меңьеллык мәйданында хәрби парад булды. Мәйданнан 2 меңгә якын кеше, 17 берәмлек хәрби техника узды. Тантанада ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Премьер-министры Алексей Песошин, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Казан мэры Илсур Метшин, министрлыклар, ведомстволар җитәкчеләре һ.б. вазифаи затлар катнашты.

«Үлемсез полк» дип аталган дан һәм хәтер ташкыны республикада – 377 мең, Казанда 165 мең кешене берләштерде. ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов улы Искәндәр белән бергә атлады. Рөстәм Нургали улы – туган абыйсы Галимҗан Миңнеханов, ә Искәндәр әнисе ягыннан бабасы Барый Сафиуллин рәсемен тоткан иде. ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев – әтисе Шәһишәрип Шәймиев, ТР Премьер-министры Алексей Песошин – бабасы Владимир Яковлев, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин әтисе Хәйрулла Мөхәммәтшин, Казан мэры Илсур Метшин бабасы Мөҗәһит Метшин портретларын тотып бардылар.

### ПРАЙМЕРИЗ

8 сентябрьдә узачак ТР Дәүләт Советына сайлауларга кадәр алдан тавыш бирү – праймериз булып узды. Аны «Бердәм Россия» партиясе оештырды. Алдан тавыш бирү җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уятты. Нәтиҗәдә әлеге чара оешкан төстә үтте. Киләчәккә планнар, уй-фикерләр, максатлар дебатларда да ачыктан-ачык күренде. ТР Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин праймериз нәтиҗәләрен РФ Премьер-министры Дмитрий Медведевка ирештерде.

### 19 МАЙ – ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАТБУГАТЫ КӨНЕ

Татарстан Республикасы Матбугат көне уңаеннан ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин массакүләм мәгълүмат чаралары җитәкчеләре, журналистлар белән очрашты. Ул соңгы ике дистә елда Татарстан журналистикасының ныклы үсеш юлы узуын, матбугат чараларының эше парламентарийларның күз алдында булуын әйтте. «Хакимият һәм идарә органнары белән конструктив диалогта сез республикадагы, илдәге, дөньядагы катлаулы процессларны дөрес һәм объектив чагылдырасыз. Инандырасыз, күндерәсез, җәмәгатьчелек фикеренә тәэсир итәсез», – диде ул. Фәрит Хәйрулла улы күпләрнең, мәгълүмат өчен җаваплылык тоймасалар да, медиакиңлеккә үтеп керү мөмкинлеге булган чорда журналистиканың яңалыкка монополияне югалта баруын искәртте. Ике телдә эшләүче журналистлар әзерләү кирәклеген әйтте, Татарстанда спорт газетасын булдырырга тәкъдим итте, эчтәлексез язмаларына кызыктыргыч исем кую белән мавыгучыларны тәнкыйтьләде, каләм ияләрен илкүләм проектларны, социаль программаларны гамәлгә ашыру, ТАССРның 100 еллык юбилее, Театр елы һ.б. темаларга активрак язарга өндәде, Татарстан матбугатын үстерүгә зур өлеш керткән массакүләм мәгълүмат чаралары җитәкчеләренә һәм вәкилләренә дәүләт бүләкләре тапшырды.

***

Казанда «Пирамида» мәдәни-күңел ачу комплексында «Бәллүр каләм» XXII бәйгесе (аны «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы һәм Татарстан Журналистлар берлеге оештырды) җиңүчеләрен бүләкләделәр. Бәйге биш номинациядә («Һөнәргә тугрылык өчен», «Елның иң яхшы редакциясе», «Елның иң яхшы журналисты», «Объектив аша караш», «Туган тел») үткәрелде. «FIFA футбол буенча дөнья чемпионаты – 2018», «Россия Федерациясендә волонтёр елы», «Татарстан Республикасында Лев Толстой елы», «Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 200 ел» кебек махсус проектларда җиңеп чыгучылар да бүләкләнде. Быел

бәйгегә 1,5 меңнән артык эш тапшырылган. «Һөнәргә тугрылык» номинациясендә «Казан утлары» журналы редакциясенең проза бүлеге мөхәррире Камил Кәримов җиңүгә иреште. Хезмәттәшебезне котлыйбыз! «Казан утлары» журналының «Елның иң яхшы редакциясе» номинациясендә һәм «Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 200 ел» проектында номинант булуы да безнең өчен куанычлы вакыйга. Җиңүчеләргә «Бәллүр каләм» статуэткалары, дипломнар һәм акчалата премияләр (40 мең сум, «Һөнәргә тугрылык» номинациясендә 80 мең сум, гомуми премия фонды – 360 мең сум) тапшырылды.

Бәйрәмнең иң югары ноктасы Гран-при иясен игълан итү булды. Аны ТР Премьер-министры Алексей Песошин игълан итте һәм ТР Президентының бүләге – «Лада гранта» автомобиле ачкычын «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе милли тапшырулар хезмәте башлыгы Миңназыйм Сәфәровка тапшырды.

Хөкүмәт башлыгы массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен ТР Матбугаты көне белән котлады.

Каләм ияләрен «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айрат Зарипов һәм Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Илшат Әминов та тәбрикләде.

### ТУКАЙ УРАМЫ БӘЙРӘМЕ

Казанда беренче тапкыр Тукай урамы бәйрәме үткәрелде. Әлеге чара кысаларында шигырь бәйрәме, Г.Камал театры артистлары катнашында әдәби спектакль, концерт, ярминкә, викторина, экскурсияләр, мастер-класслар оештырылды. Шигырь бәйрәмендә Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рәмис Аймәт, шагыйрьләр Зиннур Мансуров, Гәрәй Рәхим, Ринат Мәннан, Наилә Ахунова, яшь шагыйрьләр Фәнил Гыйләҗев, Гөлназ Газизова, Лениза Галиева һ.б. чыгыш ясады.

### ТАТАР КИТАБЫ ЙОРТЫ

Казанда Шәриф Камал һәм татар әдәбияты музее бинасын реконструкцияләү тәмамланды. Татар телен саклау һәм үстерү, яшьләрнең игътибарын китапка җәлеп итү максатында монда яңа экспозиция – Татар китабы йорты ачылачак. Аның директоры вазифасына Луиза Шарова (шагыйрә Луиза Янсуар) тәгаенләнде.

### ИСТӘЛЕК ТАКТАСЫ КУЕЛДЫ

Фронтовик-шагыйрь, Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Мөхәммәт Садри истәлегенә мемориаль такта ачылды. Ул Казандагы Себер тракты урамындагы 9/5нче йортка куелган. Монда М.Садри 1954 елдан 1999 елга кадәр яшәгән. Истәлек тактасын ачу тантанасында ТР Мәдәният министрлыгы вәкилләре, язучылар, шагыйрьнең туганнары катнашты. Мөхәммәт Садриның кызы Гөлнур ханым әтисенең истәлеген мәңгеләштерүләре өчен ТР Мәдәният министрлыгына, Татарстан Язучылар берлегенә рәхмәт әйтте.

### ИСКӘ АЛУ КИЧӘСЕ

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында шагыйрә, мөхәррир, тәрҗемәче Бикә Рәхимованың тууына 80 ел тулуга багышланган искә алу кичәсе булып узды. Аны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов ачты. Кичәдә язучының иҗаты турында филология фәннәре докторы Гөлшат Галиуллина сөйләде. Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ, шагыйрә Эльмира Шәрифуллина һ.б. истәлек-хатирәләрен уртаклаштылар, Г.Камал театры артисты Дания Нуруллина шагыйрәнең шигырьләрен укыды. Кичәдә җырчылар Эмиль Җәләлетдинов, Римма Ибраһимова, Мирсәет Сөнгатуллин, Регина Сәйфи һәм бер төркем яшь башкаручылар, нәфис сүз осталары чыгыш ясады. Әлеге чарага Бикә Рәхимованың Мәскәүдә яшәүче улы, РФ Президенты аппаратының җаваплы хезмәткәре Алмаз Фәйзуллин гаиләсе белән кайткан иде. Кичәдә Бикә Рәхимованың оныклары да катнашты. Чулпанның фортепьянода классик композиторларның әсәрләрен башкаруы, Ильяснең баянда татар көйләрен уйнавы, Камилнең дәү әнисенең шигырьләрен туган телебездә укуы ямь өстенә ямь булды. Искә алу кичәсен К.Тинчурин театры артисты Резеда Сәлахова алып барды.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен **«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Ялкын» журналы редакциясе филиалы коллективына** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте белдерелде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә өлеш кертүе өчен «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Казан утлары» журналы редакциясе филиалы мөхәррире **Гатауллина Лилия Илгизәр кызына** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте белдерелде.

***

Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм нәтиҗәле эшчәнлеге өчен шагыйрь, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» (Иҗат берлеге) иҗтимагый оешмасы рәисенең иҗат мәсьәләләре буенча беренче урынбасары **Аймәтов Рәмис Кыям улына** (Рәмис Аймәткә) «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман Р.МУХАМАДИЕВА «Отчего желтеет белый лист…», отрывок из романа Р.ЗАЙДУЛЛЫ «Кул Шариф», повесть М.КАБИРОВА «Молитва»; либретто для маленькой оперы Р.МУХАМЕТШИНА «Мой Такташ»; стихи М.МИРЗЫ, Р.АХУНЗЯНОВОЙ.*
*«Новые имена»: рассказ А.САЛАХОВОЙ «Мой напарник», стихи Г.ХАНАФИ.*
*«Актуальная критика»: рубрику ведёт Д.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*«Детская библиотека»: сказка А.МАСКИ «Родство» волка».*
*«Литература народов мира»: Н.ДУМБАДЗЕ «Кровь» (перевод Р.БАШАРА).*
*Конкурс «Исцеляющие руки»: рассказ З.ЗАХАРОВОЙ «Не плачь, мама!».*
*«Татарстан. История. Личности»: очерки А.ИМАМИЕВОЙ и А.АХМЕТГАЛИЕВОЙ.*
*«Отклик»: статьи Ф.ГАЛИМУЛЛИНА и Ф.БАТТАЛОВА.*
*«Тукай и татарская литература»: статья Р.МУСАБЕКОВОЙ.*
*Интервью Л.АБУДАРОВОЙ с И.ШАНГАРЕЕВЫМ.*
*«Наука»: статья А.СИТДИКОВА и Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ «Судьбы рода Кубрат хана».*
*«Наши музеи»: А.АХМАДУЛЛИНА. «Музей Шигабутдина Марджани в селе Ташкичу Арского района».*
*«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.*
*Из фотоархива журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: дом-музей Шигабутдина Марджани в г.Казани.*
*Фото Л.Губайдуллина.*

# IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by R.MUKHAMADIEV «Why a white sheet turns yellow…» a fragment from the novel by R.ZAIDULLA «Kul Sharif», story by M.KABIROV, «The Prayer»; libretto for a small Opera by R.MUKHAMETSHIN, «My Taktash»; poems by M.MIRZA, R.AKHUNZYANOVA.*
*New names: story by A.SALAKHOVA «My partner», poems by G.HANAFI.*
*«Actual criticism»: section is conducted by D.ZAGIDULLINA.*
*«Children's library»: tale by A.MASKI «Kinship» of the wolf».*
*«Literature of the peoples of the world»: N.DUMBADZE «Blood» (translated from Russian by R.BASHAR).*
*Contest «Healing hands»: story by Z.ZAKHAROVA «Don't cry, mum!»*
*«Tatarstan. History. Personality»: essays by A.IMAMIEVA and A.AKHMETGALIEVA.*
*«Response»: articles by F.GALIMULLIN and F. BATTALOV.*
*«Tukay and Tatar literature»: article by R.MUSABEKOVA.*
*Interview of L.ABUDAROVA with I.SHANGAREEV.*
*«Science»: article by A.SITDIKOVA and D.ZAGIDULLINA «Fate of Khan Kubrat’s bloodline».*
*«Our museums»: A.AKHMADULLINA. «The Museum of Shigabutdin Mardzhani in the village of Tashkichu of Arsk region».*
*«Pages of humor»: section is conducted by M.GALIEV.*
*From the photo archive of the magazine.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: house-museum of Shigabutdin Mardzhani in Kazan. Photo by L.Gubaidullin.*

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Шиһабетдин Мәрҗанинең Казандагы музей-йорты.

*Ленар Гобәйдуллин фотосы.*